ISSN 0206–4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

2.2011





**Нәҗип Җиһанов**
**(1911—1988)**

# Казан утлары
# Qazan utları

2011

**2**
**(1060)**

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:
**«ТАТМЕДИА»**
*ачык акционерлык җәмгыяте*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

*Мөхәррирләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Рөстәм Галиуллин, Марат Закир, Камил Кәримов, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир—562-10-62.
Баш мөхәррир урынбасары—292-93-16.
Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.
Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-39-63.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Гамәли хезмәткәрләр—562-11-28.
Исәп-хисап бүлеге—222-09-80. kazanutlari@yandex.ru
**Факс**—(843) 562-11-28.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Салисә ГӘРӘЕВА. Якты хәтер яшәр... *Шигырьләр.* ... 5
Халисә МӨДӘРРИСОВА. Соңгы сер. *Бәян.* ... 9
Рим ИДИЯТУЛЛИН. Кайту. *Шигырьләр.* ... 35
Әхәт МУШИНСКИЙ. Һаваларда—ак күгәрчен... *Роман.* ... 39
Нәҗибә ӘМИНЕВА. Догам. *Шигырьләр.* ... 91

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Локман ЗАКИР. Сәяси парчалар ... 93
«Шомалыкны, шомаларны сөймим!» *(Рәфикъ Юнысның Адлер Тимергалин белән әңгәмәсе)* ... 149

**ХӘТЕР**

Фәнис ЯРУЛЛИН. Хәтер төпләрендә утлы күмер. *Көндәлекләр* ... 100

**Г. ТУКАЙНЫҢ 125 ЕЛЛЫГЫН КАРШЫЛАП**

Бөеклек баскычлары ... 111

**САТИРИК ӘСӘРЛӘР КОНКУРСЫ**

СӘЙЛӘН. Авыл мәктәбен япкач, мөгаллимнәре ни диләр? ... 117

**ТАРИХ**

Тәлгат НАСЫЙРОВ. Татар матбугатының авыр хәле ... 121
Ф. ФӘТКУЛЛИН. Мохтар Әуэзов һәм Муса Җәлил: әдәби бәйләнешлар тарихы ... 168

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Рамил ХАННАНОВ. Төрек-татар әдәби бәйләнешләре ... 134

**БЕЗНЕҢ МУЗЕЙЛАР**

Рашат НИЗАМИЕВ. Җәлил белән очрашу ... 145

**ФӘН**

Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы ... 161
«Татар энциклопедиясе» битләреннән ... 164

**АК ҖИЛКӘН**

Фәнзаман БАТТАЛ. Бәләкәй Баттал ... 173
Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ. Мин ышанам, халкым, кайтыр язлар... *Шигырьләр* ... 178

**ТАТАР ГАЛӘМЕ**

Хәсән ТИМЕРБУЛАТОВ. Ул Ялтада, ләкин ял итми ... 183

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ... 188

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман А. МУШИНСКОГО «Шейх и звездочет» (прод.); повесть Х. МУДАРРИСОВОЙ «Последняя тайна»; стихи С. ГАРАЕВОЙ, Р. ИДИЯТУЛЛИНА, Н. АМИНОВОЙ, САЙЛАН.
«Публицистика»: Л. ЗАКИР. Политические этюды; «Гладкая жизнь—не по нутру!»—интервью Р. ЮНУСА с А. ТИМЕРГАЛИНЫМ.
«Память»: дневниковые записи Ф. ЯРУЛЛИНА.
«К 125-летию Г. Тукая»: хронология жизни поэта.
«История»: Т. НАСЫРОВ. «Татарская пресса в тридцатые годы»;
Ф. ФАТКУЛЛИН. «Мухтар Ауэзов и Муса Джалиль: к истории литературных связей».
«Литературная критика»: Р. ХАННАНОВ. «Турецко-татарские литературные взаимосвязи».
«Наши музеи»: Р. НИЗАМИ. «Встреча с Джалилем».
«Наука»: Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень» (прод.).
Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Белый парус»: Ф. БАТТАЛ. «Маленький Баттал»; стихи Ф. ГИЛЯЗОВА.
«Татарский мир»: Х. ТИМЕРБУЛАТОВ. «Ему в Ялте не до отдыха».
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Зимний пейзаж»;
поэт Ленар Шаех.

## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: novel by A. MUSHINSKY «Sheikh and astrologer» (continuation); story by H. MUDARRISOVA «Final mystery»; verses by S. GARAEVA, R. IDIYATULLIN, N. AMINOVA, SAYLAN.
«Journalism»: L. ZAKIR. Political etudes, «Smooth life is against inside!» Interview of R. YUNUS with A. TIMERGALIN.
«Memory»: diaries by F. YARULLIN.
«To 125th anniversary of G. Tukay: chronology of poet's life».
«History»: T. NASYROV. «Tatar press in thirties»;
F. FATKULLIN. «Mukhtar Auezov and Musa Jalil: history of literary relations».
«Literary criticism»: R. KHANNANOV. «Turkish-Tatar literary relationships».
«Our museums»: R. NIZAMI. «Meeting with Jalil».
«Science»: F. GARIPOVA. «History of our villages» (continuation).
Pages from Tatar Encyclopaedia.
«White Sail»: F. BATTAL «Little Battal»; poetry by F. GILYAZOV.
«Tatar World»: H. TIMERBULATOV. «He wasn't in Yalta to have a rest».
Diary of a social-cultural life.
On our covers: «Winter Landscape»;
poet Lenar Shaeh.

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 01.02.2011, график буенча 01.02.2011.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Р–72. Тираж 4160.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтнең Татарстан буенча идарәсендә, 2010 елның 1 апрелендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ №ТУ 16-00337
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААҖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2010 ел.



Салисә
Гәрәева

# ЯКТЫ ХӘТЕР ЯШӘР...

## Шагыйрь халык

**Шагыйрь булган бабаларым, чәчән булган.**
**Шагыйрь җаны аларда хөр, исән булган!—**
**Курай сызып, гөслә, дутар чыңгылдатып,**
**Алар Җирне чиктән—чиккә гизәр булган.**

**Төнге күктә күргән алар йолдызларны:**
**Күмәкләрне, якты, эре, ялгызларны;**
**Җидегән йолдыз, Казык йолдыз, Чулпан йолдыз**
**Сокландырган сере белән ир, кызларны...**

**Галәмнәргә илткән—кемнең рухы олы,—**
**Якты эзле, серле Киек Казлар юлы.**
**Яланнарга, күл, тау, инеш, елгаларга**
**Сихри, гүзәл исем кушкан татар улы!..**

**Юлларга чык—гиз тауларны, далаларны,**
**Үзәннәрне, таштан салган калаларны;**
**Күңелгә уй, хәтергә сал, ятла. Җырла**
**Матур, моңлы бер җыр итеп син аларны!..**

**...Яңрасын җыр, сызсын курай! Тальяннарның**
**Моңлы көе илләр аша ишетелсен!**
**Безнең әле исән, тере һәм ялкынлы**
**Шагыйрь халык икәнлекне дөнья белсен!..**

---

Салисә ГӘРӘЕВА—*шагыйрә, «Уралым», «Тау сукмагы», «Йолдыз яңгырлары» һ. б. китаплар авторы. Татарстан мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Һ. Такташ исемендәге премиясе лауреаты. Казанда яши.*

***

Кайнап, янып, шашып гомер иткәч,
Бәйгеләрдә чапкан ат кебек,—
Картлык дигән яланлыкка җиткәч,
Бер карауга дөнья ят кебек...

Күнегелгән тизлек алга дәшә,
Дәртләр бар да...дәрман чамалы
Күңел тыя—синең чорың үтте,
Шашма берүк, бел, ди чаманы...

Мәңге зәңгәр, мәңге сүнмәс Күктән
Җанга иңә якты калгыну:
Сыенасы килә Бер Ходайга—
Тирбәлдерә уйның талгыны...

Бездән үтте!
Изге якты Дөнья—
Башкаларга бәйге урыны.
Күзгә якты, моңлы уйлар ява,
Гарешләргә җаның орынып...

Өстебездән Вакыт җиле оча,—
Һәм хәкимдер шуны аңлаган!
Бөек бу Җир, Җиһан, Яшәү, Сөю...
Тик янында бер дус калмаган,
Шушы Хакыйкатьне аңлаган!..

## Коры килгән җәй

Эссе җәйнең
Кипкән коры җирдә
Алҗып-янып җиткән бодае
Амбарларга керде.
(Татар йортын
Икмәкле ит берүк, Ходаем!)

Май башыннан бирле яңгыр күрми
Кипте үлән, җирләр ярылды:
Ашыгып сары кунган башакларга
Ярып бирер идем җанымны!..

Инде җиргә җылы яңгыр ява.
Яшь курпылар җирдән дым тарта:
Бәлки, килер елда ашлык уңар,
Дип күңелдә өмет яңарта.

## Йөрәгемдә скрипка елый

Йөрәгемдә скрипка елый,
Галәмнәрдән көчләр иңә дә:
Үз җаныммы, минем җанымнанмы—
Кемдер әллә ниләр инәлә!..

Йөрәгемдә чишмә тамагында
Сулкылдаган судай өннәр бар.

Айдан—сагыш, йолдызлардан—тылсым
Чыңлап-сызлап иңгән төннәр бар...

Кайчагында гобой инәлүе
Дәшә кебек офык артына.
Борынгыдан килгән чакырулар
Дулкынына җаным тартыла...

Кыйтгаларны кичеп, яңа чикләр
Аръягына килә чыгасым.
Әллә нинди серле шомы белән
Сискәндерә мине бу гасыр.

Йолдызлы моң эчеп, давылларда
Сөңге аткан яшен эзеннән,
Әй, очасым килә Галәмнәргә, —
Алга ыргып үзем-үземнән.

Сөңге аткан Яшен эзеннән!..

## Үткәннәр кирәк

Эзләнә барлык халыклар
Нигезләрен, төпләрен,—
Ерак тарих чоңгылында
Бабалары үткәнен!..
Кемгә—җиңү, кемгә—үлем,
Кемнең күге ишелә;
Киләчәккә үтәр өчен
Үткән кирәк кешегә!..
Үткән кирәк: кем булган ул,
Җир өстендә ни кылган?
Рун язулар, чөй язулар
Кызыксынып укылган.
Кемнәр хуҗа архивларга—
Шулар сүзе җөпләнә:
Хакыйкатьләр гарипләнә,
Елъязмалар бикләнә!..
Җир астына төшә заман:
Үткәнен эзли һаман:
Сарай, кирмән, ук-садагы
Җиргә күмелеп калган.
Алтын саркофаг эчендә
Сары сөяк өеме:
Дәүләт башы булганлыгын
Сөйләп тора...киеме.
Шәһәр һәм сарай нигезе,
Су агызган торбалар,
Каберлекләр,табылдыклар
Тарих сөйләп торалар...
Эзләнә җир халыклары—
Тарихын эзли, атын.
Үткәннәр кирәк кешегә,
Җаяр өчен канатын...
Үткәннәр кирәк! Киләчәк
Тамырлары—үткәндә!
Эзләнә Кеше, атом-төш
Җирне дер селкеткәндә...

## Кошлар озатканда

Көмеш сулар өстен моңсулатып,
Күтәрелде кошлар канатка:
Бер Ходайның көче аларны да
Сәйяр җаннар итеп яраткан!..

Туган илдән бердәм күтәрелеп,
Зар-интизар булып китәләр.
Сагышлатып илдә калганнарны,
Карашларны моңсу итәләр...

Без дә шулай туган-үскән җирдән
Зар-интизар юлга чыгабыз.
Кошлар—өмет! Алар әйтә кебек:
Без чыдыйбыз, сез дә чыдагыз!..

Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз илгә,—
Ташламасын безне ак өмет.
...Кошлар китә.Канат асларына
Сагышыбыз китә, эленеп...

Әй, илемнең кучмә канатлары,
Исән кышлап, исән кайтыгыз!
Ядкарь булып бары Хәтер яшәр,
Якты хәтер—сәлам хатыгыз!..

## Кызыл яфрак

Җил чыкты да,
Өзеп алып китте
Каен яфрагының сарысын.
Шул хәбәрдән
Курку биләп алды
Яшел каеннарның барысын.

Кызыл төлке кебек,
Шыпырт кына,
Сиздермичә аяк эзләрен,
Картлык моңсулыгы
Талгын гына
Өстебезгә иңә көзләрен...

Сары яфрак итеп,
Сайлап-сайлап
Ул очырта якты көннәрне.
Сары көзләр
Салкын бакый йортка
Алып китте әллә кемнәрне...

...Мин үзем дә
Көзге өрәнгедән
Өзелгән бер кызыл яфракмын:
Мин ашлармын
Алтын бөртек үскән
Бер кантарын
Туган туфракның!..

## Вөҗдан

Үзәк өзеп, җанны сызландырып,
Искәрмәстән сине өтә ул;
Җимерелгән тарих, куылган ил
Өсләреннән очып үтә ул!..

Рәнҗетелгән ана, үксез бала
Күз яшьләрен даим эчә ул;
Бер хаксызга читкә этәрелгән
Дус артыннан диңгез кичә ул...

Очып барган чакта тотылмаган,
Кулга эләкмәгән Җиңү ул.
Якты талант килеш, Язмыш кушып
Яңгыр булып Җиргә сеңү ул...

Икмәк төсе күрми, хәсрәт чигеп
Дуңгәләктәй гомер итү ул;
Нахак гаеп белән тоткынлыкта
Гаделлек һәм Ирек көтү ул...

Ул гел минем күкрәгемдә яши—
Рәхмәт инде!—сулый, тере ул.
Һәр адымда юлга нурын сибеп,
Үзем белән бергә йөри ул,—
Иман исеменнән сөйли ул!..



Халисә Мөдәррисова

# СОҢГЫ СЕР

БӘЯН

*Әсәр булган вакыйгаларга нигезләнә.*

—Миш-ша, Миш-ша, nein[1], Миш-ша-а-а-а!

—Кая йөгерә егыла-егыла, вәт, дивана хатын, баласын харап итә бит.

—Поездны куып житеп буламыни, дура!

—Verlass mich nicht[2], Миш-ша-а!

—Немка бит, үҗәт.

—Кайсыгызның күчтәнәче?

—Ха-ха-ха.

—Молчать!

Теплушкадагы солдатлар состав артыннан баласын күкрәгенә кысып йөгергән, чәчләре җилгә тузгыган, аның саен ерагая барган яшь кенә немец хатынына көлеп тә, кызганып та карап калдылар.

Кече лейтенантның тамак төбеннән гөрелдәп чыккан ачулы командасына һәм солдатларның туган илгә кайту шатлыгыннан ургылган дәртле тавышларына, иләсләнеп кычкыруларына, көлүләренә, сызгыруларына перрон буйлап паровоз артыннан йөгергән Динаның ялварып, илереп елаган тавышы ургылып аккан көзге болганчык суда тамып эрегән, юкка чыккан көмеш тамчылар шикелле генә чынлап кушылды да, елан шикелле боргаланып-боргаланып борылмага кереп барган паровозның үзәк өзгеч соңгы хушлашу тавышына сеңеп юкка чыкты.

—Вот и все,—диде кемдер.

—Герман җирендә берәүнең орлыгы кала.

—Кем булып үсәр ул, кеше булыпмы, фашист булыпмы?

—Барысы да бертөрле аларның, дөмектереп бетерергә кирәк иде үзләрен,

---

[1] Кирәкми

[2] Ташлама мине

---

Халисә МӨДӘРРИСОВА—*шагыйрә, прозаик; татар, башкорт телләрендәге «Көмеш дага», «Шәмахә төн», «Балан» һ. б. китаплар авторы. Башкортстанда яши.*

ирләрен дә, хатыннарын да.

—Айгырын әйтер идем инде, әйтерсең туган җирдә хатыннар беткән, дошман тегерменәнә «су» салмаса.

—Трибуналдан да курыкмаган, молодец!

—Андый эштә трибуналны кем уйлап тора инде...

—Ха-ха-ха!

—Молчать,—диде тагын кече лейтенант.

Көпчәкләр көенә тик Мәрдәннең генә йөрәге сулкылдады. «Калдылар...», «калдылар...», «калдылар»...

Сугыш гарасаты куркытып, болан баласы кебек һәр тавыштан өркеп торган тал чыбыгы кебек ябь-яшь хатын нинди фашист булсын ди инде, дип уйлады ул җаны әрнеп.

«Калдылар, «калдылар», «калдылар».

Дина белән бергә аның улы да мәңгелеккә герман җирендә калды. Сугыш афәте дөньяны икегә бүлгән, кешеләр арасында аңлатып бетерәлмәслек дошманлык, кан үче, атлап та, йөзеп тә, очып та чыга алмаслык упкын барлыкка китергән дәрьяның икенче ярында аның якын кешеләре—улы һәм сөйгәне калды.

Мәрдәннең йөрәгендә утлы давыл кубарыла, аяусыз ялкын күңелен ялмый, зиһенен әйтерсең кызган тимер өтә, һәрбер күзәнәге аңлатып бирәлмәслек авырту кичерә. Үзенең көчсезлегеннән, хәл-вакыйгаларның аннан өстен, җинеп була алырлык булмавыннан, үзенең бу дөньяда бөҗәктән дә бәләкәйрәк, әһәмиятсезрәк булуыннан ул күңел газаплары кичерә иде.

Нинди фашист булсын инде алар—гөнаһсыз ябь-яшь ана һәм тугыз гына айлык сабый—улы Александр, аның йөрәк парәсе, аның каны. Их, алып кына китәргә иде дә бит үзе белән аларны! Сикереп кенә төшәргә дә, баласын күкрәгенә кысып, Динаны кулыннан алып поездга тартып алып утыртырга да, үзенең кадерле иленә, туган җирләренә, җылы, якты өйкәенә алып кайтырга иде. Юк шул, булмый, булырлык түгел. Сугыш вакытының үзенең аяусыз законнары, үз кануннары, үз трибуналы, үз хөкеме. Перронда егылып калган Дина һәм улының аяк асларында Мәрдәннең йөрәге дә мәңгегә яраланып, канга батып тәгәрәп калган шикелле булды.

***

...—Житәр инде, картатай, кычкыртма әле шул радионы, йокыны ачасың.

—Булды, йокы чүлмәкләре, торыгыз, шул гомер кеше йоклыймыни, кояш төшкелеккә житте, бәрәңге кәтмәннәргә чыгыгыз, шәһәр ялкаулары,—дия-дия, Мәрдән карт аның саен радионы ныграк ачып, чүәкләре белән ныграк кытырдап, үзенең ятагына—җылы кухня ягына үтеп китә.

Тормый хәл юк. Бу тавышка инде йоклап булмаячак. Үсмер оныклары—Диана һәм Айнур бераз чырык-чырык килешеп, тарткалашып, шаярышып алдылар да, юынырга дип ихатага йөгереп чыгып киттеләр.

Төн буе дискотека дип урамда ыргу-сикерү дисеңме, таңга чаклы матайда чабулау дисеңме? Ә кигән киемнәре? Адәм ыстырамы—тишек, ерткаланып беткән зәңгәр киндер чалбарны модалы джинси диләр. Кызларының күлмәк итәкләре кендекләренә кидергән алкаларын да капламый, бот төбеннән ыштан үзләрендә. Бетте оят, бетте тәүфыйкъ. Ә төшкә кадәр йокы симертәләр. Менә шулай бетә, югала икән матурлыклар. Кайда икән нечкә билне кысып торган алъяпкычлар, ак челтәрдән каймаланган якалы аллы-гөлле килешле күлмәк кигән озын толымлы кызлар?! Хәер, һәр заманның үз матурлыгы буладыр шул.

Оныгы Диана да искиткеч матур. Сылу кыз булып үсеп килә, нәнәсенә тартым. Дулкынлы озын кара чәчләр, куе кара керфекле сөрмәле зур күзләр. Оныгы Айнур Мәрдәннәр ягына тарткан. Зәңгәр күзле, салам түбәле, дәү гәүдәле егет булырга охшап тора. Бәхетләре генә булсын!

Ата-аналары иркәләп үстерәләр дисәң дә, әлләни ялкау дип тә булмый үзләрен, менә дигән итеп өй эчләрен, ихатаны да җыештырып куялар. Кушсаң, бакчада да булышалар, чүп утау, су сибү дә алар өстендә. Бигрәк тә соңгы бер айда Мәрдәннең үзенең хәле йомшарып киткәч. Моңарчы дөньяга «мах» бирми иде бирүен. Кыбырдап йөреп тора иде ихатада. Әз-мәз эш карау белән көнен үткәрә иде. Абзардагы ялгыз бозауга да печәнен салып, суын эчереп керсәң, вакыт та тизрәк үтә, кәеф тә күтәрелә, тамакка да ачыгып, теләп ашый иде. Менә бер айлап инде аш бик чамалы гына бара башлады. Сөт-катык үтә үтүен, тик бер-ике тапкыр ихатага чыгып, абзарга күз салып, урам эскәмиясендә бераз утырып тора да кереп яту ягын карый. Ярый әле оныкларының каникул вакыты. Хәзер күңел күтәренкерәк. Тиздән улы белән килене дә ялга кайтып төшәргә тиешләр. Алар кайткач, бәлки хәле дә шәбәебрәк китәр.

Ниһаять, оныгы Диана өйгә кереп чәй куйды, газ плитәсе өстенә кичәге шулпаны җылытырга утыртты. Үзәкләрне өзеп, ачыктырып, башларны әйләндереп, өйгә тәмле аш исе таралды. Яшь булса да, аш-суны әйбәт әзерли оныгы, әнисе яхшы өйрәткән, дип канәгать уйлады Мәрдән. Аш-суга оста хатын ирен гомерлеккә үзенә бәйләп куя ул. Юккамыни урыслар: «Ир-ат йөрәгенә юл—ашказаны аша»,—дип әйткән.

Мәрдәннең хатыны Мәдинә дә шәп пешерә иде. Бигрәк тә иртә таңнан мич кызуында алсуланып пешкән, майлары тамып торган тәбикмәкләре уңа иде аның. Ә тары ярмасы «тәкәләре» сон? Менә ичмаса аш! Күп төрле ризыклар тәмләргә туры килде аңа. Ләкин мондый да тансыкны кандырырлык тәмле ризык ашаганы булмады Мәрдәннең үз гомерендә.

Иртәнге мич кызуга табаларга «эре» генә, «тәкәббер» генә «тәкәләр» тезелешеп тула да мич куенына кереп кунаклый. Мич авызыннан чыккан җылы өйнең каршы як стенасында талгынланырга, ул гынамы, гыйнвар суыгы төрле сурәтләр төшергән тәрәзәдә таңның таүге нурлары уйнарга да өлгерми, «тәкәләр» табагач һәм табаларның күңелле чыжылдаган матур җырлары астында табын уртасына килеп тә кунаклыйлар. Башта әле алар берничә генә минутка икегә бөкләнгән ак шадра сөлге белән ябылып куелалар—болары «тәкәләрнең» әзрәк усаллыгы сүрелсен, «мөгезләре» йомшарсын, эчендәге ярма катыш алтын кебек күзнең явын алырлык кабак шакмаклары мәмрәсен өчен эшләнә. Ә ул арада карчыгы Мәдинә мич алдына кисәү агачы белән казан астыннан куз тартып, өстенә ваклап туралган суган белән яшь сарыкның эч маен таба белән эретергә куя. Өй эчендә кызган суган исе белән тәмле сызык, кыр төтене—куырылган ит исе дә тарала.

Мәрдән пычак белән үзенең учы хәтле зур «тәкә»не каерып ачып җибәрә. Аннан тәмле бу күтәрелә. Өстәлгә куелган кайнар табадан бер кашык суганлы-майлы сызыкны тәкә эченә мул гына итеп аудара да ризыкның тәмлелегеннән ләззәтләнеп, өч чынаяк сөтле чәйне ике-өч тәкә белән бергә «бәреп тә ега». Ә мич артындагы иркен такта сәкедә теге өч сыбызгы борын мыш-мыш килеп йокы симертә. Такта сәке киң, тагы ике малай сыярлык урын да буш булып, һаман кемнәрнедер көтеп торган шикелле ятимсерәп тора...

Әй, гомерләр... Үткән дә киткән... Мәдинәсенең гүр иясе булуына да ел ярым вакыт узды. Бар нәрсәнең кадерен югалткач кына беләсең икән, тересәк якын да бит, тешләп булмый. Кадерен белеп бетермәде Мәрдән

Мәдинәнең. Кызу булды, усал булды, кул күтәреп сукмады-сугуын, ләкин җылы сүз әйтергә дә ашыкмады.

Яшьлегендә өзелеп сөйгән ярларының сүзсез рәшәләреме, алардан соң йөрәктә уелып калган әрнүләрме, ышанычы югалуымы яки киресенчә, артык яратып, югалту авырлыгы яңадан кабатланудан куркумы, әллә инде йөрәгендә булган сөю хисен иң каһәрле—сугыш дип аталган тәмуг утының ялмап йотуымы, әллә башка сәбәпләрме, ул күп вакытта хисләрен тышка чыгарырга, хәтта гомер буе дөнья көткән хатыны белән дә уртаклашырга ашыкмады.

Иренең сүзеннән бер адым да чыкмаган, каршы бер сүз дә базып әйтәлмәгән, ни кушса шуны «баш өсте» дип үтәргә әзер торган Мәдинәнең кем икәнен, күңелендә ниләр ятканын, нинди өермәләр уйнаганын һәм тынганын, нинди гөлләр үскәнен һәм коелганын, нинди хыяллары булганын һәм җимерелгәнен ул белми дә калды шикелле.

Күп вакытта, «ике бозауга кибәк тә аерып бирә белмәгән хатын белән гомерем узды», дип битәрли иде ул аны. Аерып та бирер иде Мәдинә ике бозауга кибәкне, Мәрдәннең кырыс холкы, һәрнәрсәдә бары тик үз фикерен генә алга сөрүе йомшак күңелле, кыюсыз Мәдинәне көчсезләндерә һәм буйсындыра да куя. Шәхес буларак, Мәрдән аннан күпкә өстенрәк иде шул.

Сонлап, инде кырык ике яшькә җитеп кенә өйләнештеләр алар. Сугышта ирен югалткан Мәдинә Мәрдәнгә кызын ияртеп килде. Кызы күп тормады бу гаиләдә, бик яшьли, һөнәрчелек училищесына укырга дип, шәһәргә китте. Шул арада Мәрдәнгә Мәдинә ике кыз, бер малай табып бирергә өлгерде. Мәрдән эчеп кайткан чакларында (гәрчә үзенең хаклы түгеллеген күңел төбеннән аңласа да): «Син—кеше хатыны, кеше калдыгы» дип тә каты-каты кагылгалады. Нихәл итәсең, Мәдинәнең дә яше үтеп, гомере узып бара иде шул. Сугыштан соң дөнья көтүләре җиңел түгел, күрсәтми генә рәнҗеш яшьләрен сөртеп алыр да, тешен кысып, Мәрдәнне көйләр, юатыр, йокларга яткырыр, иренең саташып: «Дина, Дина» дип, нindидер хатынны чакыруына да бик исе китмичә, тагын үзенең бихисап, бетмәс-төкәнмәс өй эшләренә тотыныр, балаларын карар, Мәрдәнгә хезмәт итәр иде. Кадерен белергә тиеш иде дә бит Мәрдән Мәдинәсенең, юк шул инде. Ялгыз кешегә хан сараенда да «салкын өй, салам түшәк».

Ирексездән, яшьлегендә җырлаган җыр күңелгә килә:

> Кара урман эчләрендә
> Сак-Соклар сайрый бугай.
> Сак-Сок хәлләрен сорамыйм,
> Хәзер үзем дә шулай.

Бу бит мәхәббәт җыры түгел, дип уйлап куя Мәрдән, бу бит язмыш җыры: гомер буе бергә яшәп тә, әйтәсе килгән сүзләрне, белдерәсе килгән хисләрне, соралмаган гафуларны, биреп җитәлмәгән күңел җылысын, күзгә-күз карашып, күңел тулылыгыннан еларга тиеш булып та, еларга оялып, бозга әверелгән хисләр, үкенечләр, вак мин-минлекләрнең, очсызлы горурлыкларның кайтавазы булып үзенә әйләнеп кайтуы икән бит бу җыр. Кабер авазының салкын сулышы, инде кайтарып та, чакырып та булмаган үкенү җыры икән бит.

Гомер үткән дә киткән. Менә үзе балалары кулына калып бара. «Анасыз корт бал җыймас, бал җыйса да мул җыймас», диләр. Хатынсыз өйнең яме юк. Ә балалар? Балаларның үз дөньялары, үз мәшәкатьләре.

***

Мәрдән бераз оеп ятканнан соң күзен ачты. Өйгә тәмле аш исе таралган.

—Кызым, мичкә ягып, берәр таба ашы пешереп бирмәссең микән?—диде Мәрдән Дианага.

—Аш әзер бит, картатай, аш ашап карасаң?

—Аш үтми бит, кызым, иртән ашап карадым, бер-ике дә йотып булмады, йоткылыктан җибәрми.—Ул шыр сөяккә әйләнгән нечкә, зәңгәрләнеп беткән кулларын юрган өстенә чыгарып салды. Яңаклары, баш сөякләре беленеп торган маңгае, каш сөякләре, эчкә баткан күзләре өмет белән оныгына төбәлде.—Таба ашы үтәр кебек.

—Ярый, картатай, хәзер газ өстендә генә коймак коеп алам.

Менә бит бала-чага! Һаман үзенчә. Тик ул кызып киткәнен сиздермәскә тырышып:

—Мич тәбикмәге ашыйсым килә, кызым, табада, ут алдында, йөзе килгәнне... Сары май белән майлап... Онытмагансыңдыр бит, нәнәң ничек пешерә иде?

—Хәзер, картатай. Айнур, утын алып кер, мич кызганчы камыр ачып чыга ул.

Дианаһың тәбикмәге пешеп чыкканны түземсезлек белән көтте Мәрдән. Бик күп һәм бик тәмләп ашар кебек тоелды үзенә. Яңа чүпрәдән эшләнгән чемердәп торган йөгерек камырның әчкелтем тәмле исе борын тишекләренә үтеп иркәләде, чаж-ж-ж итеп кызу табага коелуы, ничек итеп пыш-пыш килеп тишекләнеп кыбырдап-кыбырдап алуы, ничек итеп матур, моңлы, нәкъ Мәдинәсе барындагыча, табагачның табаны чынлатып эләктереп алуын, мичтән чыгаруын, оныгының җәһәт кенә, нәнәсеннән өйрәнгәнчә, өстәлгә ак сөлгегә әйләндереп салуын күреп, ишетеп, кинәнеп, хозурланып, түземсезләнеп көтеп ятты карт.

Ниһаять, сары гәрәбә тәбикмәкләр майланып, пар бөркеп, көязләнеп, авыз суларын китереп, карт алдына килеп яттылар. Чынаякка куе сөтле чәй коелды.

Мәрдән калтыранган бармаклары белән бер кисәк тәбикмәкне кабып җибәрде, тик ризык нихәтле генә авызда әвәләнсә дә, чәйнәлсә дә, чәй белән чылатылса да, йотылмады, үнәче йотарга тырышып, бер аска, бер өскә хәрәкәтләнде. Диана, күрмәмешкә салышып, күзләренә тулган яшьне сиздермичә, эш белән булышкан булды. Картатасы капкан ризыгын да йота алмады. Аш үтми иде инде аңа.

—Булмый,—диде карт бераз ятып хәл алганнан соң. Аның йомык күзләре читеннән ике бөртек яшь агып төште.

Шактый озак тын гына ятканнан соң, ул акрын гына күзләрен ачты:

—Кызым, бу дөньядан күчкәнче сиңа сөйләп калдыра торган серем бар. Акыллы баласың, аңларсың, хәзер аңламасаң, үскәчрәк аңына барып житәр. Ничек кенә булса да гүргә алып китәсем килми үзем белән әлеге серне. Дөньялар да үзгәрде, үзем дә картайдым, мондый нәрсәләр өчен хәзер суд та, трибунал да юк бугай, алар белән куркытып та булмыйдыр инде.

Мәрдән карт бераз тын алды да дәвам итте:

—Сезнең Германиядә абыегыз бар, булырга тиеш. Исәндер бәлкем, сугыштан соң туган малай—Александр исемле. Элегрәк сөйләсәң, эзләсәң, сәвит власте аяусыз тегермәнендә тарттырачак иде. Мине генә түгел, әтиләреңне, апаларыңны да. Ә нәнәңә мин ул турыда үзем сөйләмәдем, авыр булыр дидем. Ә хәзер ярый инде. Нәнәң—гүрдә, мин дә тиздән аның янында булырмын. Гафу итәр, бәлкем. Ул минем өчен бик зур һәм бик кадерле сер, балам.

Якынрак кил, балам, тавышым ныклы түгел, кычкырып сөйләп булмас, аңларга тырыш. Бу сер бакыйлыкка күчәргә ирек бирми, җибәрми, чабуымнан тарта. Тизрәк котылырга кирәк миңа аннан.

***

...Каты яраланып, госпитальдән-госпитальгә күчеп, ниһаять үлем тырнагыннан ычкынгач, яраларны ямаштырып, ныгытырга дип, Белоруссия җирләреннән Мәрдәнне туган ягына бер айга, бик сирәк һәм бик бәхетлеләргә генә эләгә торган ялга җибәрделәр.

Тиздән фронт дошман территориясенә күчәчәк иде. Халыкта җиңүгә ышаныч аның саен артты, көннәрдә тиздән булачак җиңү тантанасы бөреләнгән иде инде.

Мәрдән өйдән ярты ел хат алалмады, үзенең дә, госпитальдән госпитальгә күчеп йөргәч, адреслары буталып бетте. Аякка басармын да, аннары язармын дип юатты ул үзен. Сагынды, өзелеп сагынды гаиләсен. Өшеп, туңып, окоп туфрагын кочаклап, юеш җиргә сыенып сеңеп ятканда да, үкереп килгән фашист танклары траншеяларны изгәндә дә, сугыш башында җиде кешегә бер винтовка белән атакага барганда да, «илем» диеп, «Сталин өчен» диеп, туган җирем, әткәм кабере, әнкәм, сөйгән ярым, балам, дип алга ташланды. Алар саклады Мәрдәнне үлем чалгысыннан. Ә сугышта нәрсәгәдер тирән ышаныч булмаса, үлем козгыны сине шул минутында ук үзенең корыч тырнакларына эләктерә.

Тиздән ашкынып көткән минутлар җитәчәк. Мәрдән, ниһаять, кадерле кешеләрен күрәчәк, кочагына алачак, улы үскәндер инде. Хәзер инде танып та булмыйдыр, үзе танымас, киткәндә күкрәк баласы булып кына калган иде бит. Күзләрен зур ачып, «тиз кайт, әткәй», дигән төсле тешсез авызын ачып елмайгандай иткән иде. Ә Илсөяре ничек шатланыр инде, ә әнкәсе. Алар бит аның кайтасын да белмиләр.

Мәрдән эшелон көпчәкләренең бертөрле тукылдауларына колак салып, оеп китте. Төшендә ул Барыен күрде. Яшел яланда Илсөяр белән Мәрдән печән чабалар. Яннарында үлән өстендә Барый шуышып йөреп бөҗәкләр куа, имеш. Үзе көлә, көлүе нәкъ көмеш тәңкә чынлавы инде, челтер-челтер килә дә үләннәр арасында югала бара, ерагая бара. Мәрдән улы артыннан китә, кая соң ул, тавышы ишетелә, үзе күренми, Илсөяр дә кинәт юк булды. Алар яланның икенче ягыннан ябырылып килгән куе томан эченә кереп баралар лабаса. «Баланы кара, баланы, кермә, барма анда», дип кычкыра Мәрдән хатынына, ә ул артына әйләнеп ничектер моңсу итеп елмая да үзе һаман томанга таба ашкына, имеш. Мәрдән әле Илсөяр, әле Барый артыннан ташлана, Барые куе үләннәр арасыннан үрмәләп, һаман текә ярга якынлаша да якынлаша, имеш. Менә ул яр читенә килеп тә житте, «әти», «әти» дип куркып ачыргаланып кычкырды. Кинәт исеп киткән көчле җил Барыйны үләннәр арасыннан тәгәрәтеп ярдан төшереп җибәрде, имеш. Чыр-чу килгән тавышка Мәрдән уянып күзләрен ачты. Аңа каршы урынга өч баласы белән чегән хатыны кереп урнашкан иде.

Бу куркыныч төш Мәрдәннең күңелендә хәвеф уятты, төш тәэсирендә шактый күңелсез утырганнан соң, чегән гаиләсе акрынлап аның игътибарын үзенә җәлеп итте.

Хатынның кара куе бөдрә чәчләре зур чуар яулыгы астыннан чыгып, маңгаен каплаган, иске генә кызыллы-каралы кофтасының бер чабуы белән исә күкрәгендәге песи баласы кадәр генә сабыен япкан. Каракучкыл озын беләкләрендә төрле төсле муенсалардан урап киелгән ике беләзек, шундый ук төстәге озын алкалары иннәренә төшеп тора. Катлы-катлы киң юбкасы өстеннән зур чуклы шәл бәйләгән. Гәүдәсенә карап егермене

дә биреп булмаган бу хатынның күзләренә 40 яшьлек хатын-кыз кайгысы тулган иде.

Мәрдәнне бигрәк тә чегән балаларының үзләреннән дә зуррак кирәк-ярак салган биштәрләрен югалтмаска тырышулары, өсләрендәге зур сәләмә киемнәре, такта шикелле юка гәүдәләре, упкын төсле ач күзләре тетрәндерде. Чегән хатынының күзләре тулы өметсезлек иде. Ачлыктан сүз әйтергә дә хәлләре калмаган ике малае ике беләгенә ябышкан, инде хәер сорашырга да көчләре беткән, соңгы чиккә житкәнлекләре күренеп тора. Куенындагы имчәк баласы, песи баласы шикелле сирәк-мирәк шыңшып, инәсенең сөтсез имчәген суырып ала да, өметен өзеп, әллә йоклап, әллә һушын югалтып, тынып кала.

Сугыш аларны да—һәр вакыйгадан жинел чыга белүче, хәйләкәр һәм тапкыр, бераз алдакчырак һәм карагырак, һәр вакыйгага яраклаша белүче табигать балаларын да тезләндергән, дип уйлап алды Мәрдән.

Аның йөрәге сулкылдап куйды. Кайдан килеп кая китеп бара—ирек яратучы, дөньяга артык дәгъва тотмый, иркен яланда атлар уртлатып, мәңгелек күк астын йорт түбәсе итеп яшәргә өйрәнгән халыкның бу бер кыйпылчыгы! Аларны да сугыш челпәрәмә китергән, кайсы тукталышта, нинди исемсез кабердә ятып калыр бу гаиләнең беренче, икенче, өченче, яки дүртенче вәкиле? Беренче булып беренче кабердә, яки юл читендә күзләре эчкә баткан, ачлыктан шашырга житкән, инде егылам, егылам дип утырган шушы хатынмы? Сугыш, каһәр суккан сугыш! Бу гаилә агачының дәвамы калырмы—мәңгелек йолдызлы күк астындагы учак яктысында, гитара моңы, атлар кешнәвенә кушылып күктән йолдызларны үрелеп алырдай булып дәртләнеп биергә тиешле бу халык?!

Мәрдән солдат капчыгын чишеп бер бөтен икмәк һәм бер кисәк сало чыгарды. Каршыдагылар күзләре белән йотардай булып икмәккә текәлде. Ул солдат пәкесе белән кисеп ярты икмәкне һәм бер кисәк салоны хатынга сузды. Хатын, чын микән бу дигән сыман башта аптырап торды, аннары ябык куллары белән икмәкне борынына китереп, күзләрен йомып, тирән итеп иснәде, икмәк кисәгенең яртысын сакланып кына бүлеп балаларына тоттырды. Киң чегән итәге кесәсеннән ялтырап торган хәнжәр тартып алды һәм салоны шикәр шакмагы шикелле генә кисеп, балаларының учларына салды, калганын кулындагы төенчегенә кадерләп төреп, куенына кыстырды. Алар ашамлыкларын озакка сузарга тырышып бик кадерләп һәм тәмләп, ләкин бик тиз ашап бетерделәр. Ничектер тынычланып калган шикелле дә булдылар. Жылы вагонда йокымсырап киттеләр. Чегән хатыны гына:

—Рәхмәт, солдат! Инде әллә ничә көн ризык капканыбыз юк иде. Булганын юлда урладылар. Бездән, хәтта бездән дә урладылар, дип көлемсерәде ул.—Сербиянкалар без, язмыш бөтен илләр буенча йөртә менә. Белоруссиядә иремнең туганнары булырга тиеш, шунда барырсыз дигән иде Роман. Үз бакчалары, үз өйләре белән торалар. Бәрәңгеләре, чөгендерләре булса да үскәндер әле. Анда инде жирләр азат. Ә ирем...—ул еламаска тырышып, аскы иренен тешләде.—Бер ай элек үлем кәгазе алдым.

Бераз тын гына барганнан соң чегән хатынының үзенә текәлеп карап торганын сизде Мәрдән.

—Солдат, телисеңме, язмышыңны әйтәм. Мин дөресен әйтәм, сиңа да ни күрсәм—шуны әйтермен. Бу безне икмәк биреп ачлыктан коткарган өчен генә түгел, күреп торам, яхшы күңелле кеше син. Тик дөресен әйткәнгә ачуланма. Минем каргамәт—уен түгел, ул миңа әбиләрдән, әниләрдән күчкән. Ни кушсам шуны үтәргә вәгъдә бир, ул синең гомереңне саклап калачак!

Гәрчә андый нәрсәләргә ышанып бетмәсә дә, Мәрдән аңа кулын сузды.

Сербиянка дикъкать белән анын учына карады. Маңгаенда сизелер-сизелмәс кенә сырлар пәйда булды, кашлары җыерылып, бергәрәк кушылдылар.

—Солдат, ай, бәхетлесең, гомерең озын була. Сугыштан исән кайтасың, мул яшәячәксең, йөрәгең җылы, ләкин холкың кискен икән... Ашыкма, эшләр эшеңне уйлап эшлә... Югалтулар аша табышларга килерсең, рәнҗешләреңне эчеңә йом, морадыңа ирешерсең. Биш балаң була, шуларның дүртесе синең гомереңнән озаграк яшәячәк, өеңдә сине әнкәң көтә. Сабыр бул. Бер киңәш сиңа—өеңә револьверыңны алып кайтма, ташлап кит аны, төзәтеп булмаслык хата эшләргә мәҗбүр булма, коралыңны ыргыт, яки бир миңа, үзем ыргытам.

Мәрдән ачлыктан миңгерәүләнгән хатынның бу сүзләрен аптырабрак, ышанмыйчарак тыңлап торды. Кайдан белә ул шинель кесәсендә револьвер ятканын? Тапты ул аны сугыш яланында, табылган коралны ташлыйлармыни? Фашист белән сугышырга кирәк ул. Винтовка гына түгел, револьвер ул, күренми, кеше күзеннән ерактa һәм һәрчак дошманга сиздермичә, елан урынына күренмичә генә һөҗүм ясый, тиз, кисәк һәм төгәл итеп. Сугыш кырыннан табылган бу коралны кирәкле җиргә тапшырырга өлгерәлми калды, юлга чыгарга туры килде.

Ял итәр, яраларын төзәтер дә тагын фронтка китәр. Тыныч туган якта, билгеле инде, револьвер аңа кирәк булмаячак, шуңа күрә ул аны, бил артына, гимнастерка астына ук яшереп куйды. Чегән хатынының ялварулы карашына Мәрдән җавап бирмәде. Иркенрәк урын алып, азык тулы вещмешогын баш астына куеп, револьверының катылыгын гәүдәсе белән тоеп, чалкан ята төшеп, йоклап китте.

Мәрдән күзен ачканда, чегән гаиләсе вагонда юк иде инде. Төш булдымы бу, өн булдымы? Алар урынына инде барлы-юклы йөкләре белән башка кешеләр кереп утырганнар. Ул торып утырды, әйберләрен барлады. Барысы да урынында, тик... тик... билгә беркетелгән, нығытып каешка бәйләнгән револьвер юк иде.

Ахмак, дип уйлады ул үзе турында. Шул чегән хатынына ышаныч бармыни? Бур бит алар, коралны ашамлыкка алыштырыр өчен йоклатып, урлап алган инде, тик ничек шул хәтле сак, шул хәтле нык яшерелгән коралны алырга кирәк? Ашамлыкка алыштырырга дисәң, капчыгы белән ризыгын алып чыгып китү җиңелрәк тә булыр иде. Мәрдән уйга калды.

Озак юллар үтеп, поезддан-поездга күчеп утырып, ниһаять, үзләренең станцияләренә таң атканда килеп төште Мәрдән. Станциядән соң да шактый ерак атлыйсы бар иде аларның авылына кадәр.

Таң беленергә тора, чын көз артыннан гына була торган җылы әбиләр чуагы. Басулар инде буш. Булган игеннәр җыеп алынган. Чәчелми калган җирләрдә чүп үләне орлык очыра. Ат юлына ике яклап үскән тигәнәкнең йодрык хәтле ут кебек кызыл чәчәкләрен әйтерсең инде көя элпәсе каплаган, гөрләп торган басу чәчәкләре: ромашкалар, күкчәчәкләр төссезләнгән, куырылганнар, бары тик аерым-аерым түгәрәк куаклыклар тирәсендәге чабылмый калган үләннәр арасында сукыр кычыткан, сары мәтрүшкә, ачы әрем һәм башка чәчәкләр масайган кебек, кыраудан качканнарына мактанышып утыралар.

Ул акрын гына биек аркадан төшә башлады. Менә аның туган төяге, менә аның тамырлары береккән, кендек каны тамган, балачактагы эзләре тузанда уелып калган, ялгыш пыяла кисәгенә яки кадакка басканда кан тамчылары җиргә сеңгән кадерле авылы. Газиз баласын ефәк чаршау ябып йоклаткан назлы ана кебек, иртәнге томан уйсулыкта утырган авылны каплап алган. Ә уң якта кинәт кенә текә булып авылның горурлыгы, матурлыгы, мактанычы—каен урманы үскән яшелле-кызыллы Мәхәббәт

тавы күтәрелә. Мондый матур, тик каеннар гына үскән биек һәм зур тау бу тирәдә Мәрдәннәр төбәгендә генә. Менә бүген дә ул томан аша яшелле, сарылы шәлен болгап, солдатны каршы алды. Мәрдәнне кинәт әйтеп бетерәлмәслек күңел күтәренкелеге, дәрт, кайту куанычы биләп алды. Ул үзе дә сизмичә кычкырып җырлап җибәрде.

Олы юлның каенына
Ямщик атын бәйләгән.
Исән йөреп сау кайтырга
Ходай насыйп әйләгән.

Әйе, каеннар, аның каеннары. Хәер, бу авыл халкы өчен алар барысы да тик аларныкы гына кебек. Чөнки бу авыл яшьләренең иң беренче мәхәббәт серләрен, тәүге очрашуларын, сүз куешуларын, тәүге үбешүләрен, вәгъдәләрен нәкъ менә шушы Мәхәббәт тавы, мәхәббәт каеннары саклый. Ә ике тау арасыннан— югарыдан, шул мәхәббәт хисләренең бәрәкәте шикелле, Кавышу чишмәсе агып төшә. Исеме җисеменә туры килеп тора. Вәгъдәләр өстә—Каентауда бирелә, ә яшь киленнәргә су юлы шушы чишмәдә күрсәтелә.

Авылның теге башында көтүче чыбыркы шартлатты. Шыгырдап капкалар ачыла башлады. Бидрә-чиләк чылтыравы, хатын-кыз сөйләшүләре ишетелгәләп алды. Авылга җан керә башлады. Тик бу җанлылык барыбер ничектер сәеррәк, чирле кешенең халәтен хәтерләткән кебегрәк, сүлпән җанлылык иде.

Сугышка хәтле көтү куу—ул авылның үз барометры белән бер иде. Хатын-кыз сөйгән хәләле белән ләззәтле төн үткәргәннән соң тавышларында калган наз малкайларга да күчеп авыл өстенә, капкадан-капкага, өйдән—көтүгә ияреп, болын араларына ук барып житә. Бәхетле хатыннарның: «Әйдә, малкаем, атла, матуркаем минем, әй, мөгезлемне, усаллыгыңны да яратам үзеннең, юньле йөре түлке»,— дип үгезләрен куганы, янбашларыннан сөя-сөя сыерларын чыгарулары...

Кайсы гаиләдә бүген ни хәлләр барлыгын көтүчедән дә яхшырак беркем белми.

Гөлфия апа әнә үгезенең арт ягына чыбык белән сыдырып чыгарып җибәрде. Эшләр унмаган, Әнфәс абзый кичә кич исереп кайтып, тракторын чак сүндереп, өенә кереп ауган, димәк. Аның каравы, көн дә талаш та тиргәш ишетелеп торган өеннән Сәкинәттәй бүген кояштай балкып сыер саварга да кершән сөртеп чыккан. Кичә Рәсүл абзый, ниһаять, жимерек мунча мичен янадан сипләп-сылап, ягып та җибәрде. Мунча тәрәзәсендә утлары төн ауганчы булды, әллә онытып калдырганнармы, дисәм, юкәдә икән чикләвек. Димәк, бүген сыер да «үләт» түгел—«карагат», үгез дә «мөртәт» түгел, «канатым» икән. Болар барысы да сугышка кадәр иде. Ә бүгенге көтүгә озату чыннан да авыру өйдәге өмет белән өметсезлекнең көрәшүе кебегрәк хис калдырды Мәрдәндә.

—Йә, малкай, исән йөреп, сау кайт, туйдыручыбыз син безнең. Алдыңа-артыңа карап йөр, тоякларыңны сакла, каударланып эре ташка басма, күп итеп сөт алып кайт, Ходай саклап йөртә күрсен үзеңне,—диебрәк озаталар иде малларны хатыннар.

Мәрдән чишмәгә төште, кушучлап чиста суын эчте, битен, муеннарын чылатты, чишмә аңа: «Исәнме, Мәрдән, кайттыңмы, мин дә исән, Мәрдән, мин дә барыгызны да көтәм, кайтыгыз тизрәк»,—дигән шикелле чылтыр-чылтыр килде дә, юлын инеш итеп кече елгага, кече елгадан олы елгага, аннары аркылы елгага һәм аннан соң инде җиде чакрымда аккан

Сөн суына алып китте.

Күрше авылдан килгән кунак кызы белән Илсөярен дә Мәрдән беренче мәртәбә шушы су юлында күрде. Күрде дә капланды, диләрме әле? Өне дә, төше дә бергә буталды аның. Аһ, бигрәк сылу иде шул ул кызыкай. Килмәгән жире юк. Озын нечкә билле, сызылып торган кашлары, дисеңме, уң каш өстендә тары ярмасы шикелле генә миңе ап-ак йөзенә үзгә бер мөлаемлек, әйтеп бетергесез ягымлылык биреп тора. Ә чәчләре—чәчләре, тирә-як авылда беркемдә дә аныкы кебек озын, аяк йөзләренә чаклы төшеп торган толымнар юк. Ялгыз гына яшәгән, инде туксанын куган, кышын гына бабаен жирләгән, Газраил белән якалашып урын өстендә яткан карт әбиенә ярдәмләшергә дип килгән икән яшь сылу. Яшьрәк чакта бергә уйнап үскәндә Мәрдәнгә ул озын сыйраклы, йоны чыкмаган торна баласын хәтерләтә иде. Кара син аны, берничә елда торнадан аккошка әйләнгән дә куйган бит!

Кызга бер Мәрдән генә гашыйк түгел иде. Озын буйлы, мәһабәт гәүдәле, зур башлы, калын тавышлы, кеше арасында үзен күрсәтә белгән Фәтхи атлы егет тә Илсөяргә «кармак» салды. Тик Илсөяр Мәрдәнне якын күрде.

Әбисе үлеп кырык көн үтүгә, күрше авылга кызның әнисенә яучы жибәреп сораттылар да, туй шикеллерәк бер нәрсә оештырып, Илсөярнең мәрхүм әбисеннән калган бәләкәй генә өенә күченделәр.

Ә май аенда дөньяга аларның мәхәббәт жимеше—уллары Барый сөрән салды.

Ләкин бәхет озакка бармады. Кешелек өстенә дөньядагы иң зур дәһшәт—сугыш килде...

***

Мәрдән кайтып кергәндә әнкәсе иртәнге намазын тәмамлап, дога кылып утыра иде. Өй эче әле караңгырак, салкынча. Ак яулыгы астыннан әнкәсенең аз гына бөдрә чал чәчләре күренеп тора, куллары ябыгып, сөяккә калган, яргаланган. Әнкәсе өйдә кемнендер барлыгын чамалап алып, ни уйларга белми, ишек ягына борылды. «Кем анда? Кем бу? Алтаф, күрше, синме әллә, нәрсә булды, таң тишегеннән йөрисең?»—дип, намазлыктан күтәрелде.

—Бу мин... Әнкәй!

Өйдә тынлык урнашты.

—Кем дисең? Булмас!

—Мин, әнкәй, мин—Мәрдән!

Карчыкның юка гәүдәсе чайкалып китте.

—Улым, бәгырькәем, синме бу, чынмы, Ходай рәхмәте?! Йә Раббым, теләгән теләкләрем тормышка аштымыни, кылган догаларымны Ходаем ишеттемени, иншалла, шушы көннәрне дә күрер көнем житте микәнни?

Ана калтыранган гәүдәсе белән улының киң кочагына сыенды. Исән-имин микән дип башларын, кул-аякларын, битен, күзләрен, колакларын капшап чыкты, шөкер, барысы да үз урынында икән, Алланың рәхмәте.

—Улыкаем, бәгырь кисәгем, чынмы бу! Мең шөкер бер Ходаема, төшемә дә кермәден бит, ничекләр ирештерде Ходай Тәгалә теләкләремне үзеңә,—дип, әле елап, әле пышылдап такмаклады ул. Аннары кинәт хәле бетеп ава башлады.—Без кара кәгазь алган идек, батырларча ... диеп.

—Әнкәй, әнкәй, тынычлан инде, исән бит, мин—бу, кайттым бит инде,—дип Мәрдән аны иңнәреннән күтәреп сәке өстенә утыртты.—Менә, ышанмасаң, тагын тотып кара,—дип шаярткан булды ул.—Сугышта андый кара кәгазьләр ялгышып күпләргә китә. Исәнмен бит менә!

Аннары Фәрхиямал, нәрсә эшләргә дә белмичә, әле ашъяулыгын жәя

башлады, әле самоварына барып тотынды, сандыгын бер ачты, бер япты, аннанниләрдер чыгара башлады.

—Балам, балакаем, мә, аякларыңа җылы оекбаш. Кулларыңны ю, саклап тоткан сабыным да бар, хәзер казан астына ягып, умач уып алам, кәҗә катыгы белән рәхәтләнеп җылы аш ашарсың. Ай, Алла, белмәдем шул, белмәдем, мунчасын да өлгерткән булыр идем,—дип өтәләнде ул.

—Әнкәй, каударланма, ашыкма! Өлгерербез, мин бит тизгә генә кайтмадым, әле вакыт бар.

—Бар, дип ни, юлдан булгач...

—Әнкәй, кая минекеләр? Илсөяр кайда, улым кайда? Йорт бикле, мин мондалар, дип уйлаган идем. Ишекләре, тәрәзәләре кагылган. Кая алар, әбиләргә кунакка киттеләрме әллә?

—Әй, Аллам, балакаем, утыр әле. Хәзер, хәзер, чәем өлгерә, син кайтуга дип әзерләп куйган кишер чәемне кая тыктым сана, чукынгыры...

—Әнкәй, кая Барый, кая Илсөяр?

—Әй, балакаем, юынып ал әле, ашап ал, аш эш калдырмый.

—Әнкәй, утыр әле, нәрсә булды?—Мәрдәннең йөрәге кысылып куйды.

—Улым, ни бит әле, сабыр бул, шулай булып китте бит әле...

—Нәрсә булды, тиз әйт, әнкәй! Кая киттеләр? Менә улыма уенчыклар да алып кайттым...

—Улым... Барый юк инде...

—Нәрсә?

—Улың вафат, ике яше тулганда чирләп вафат булды. Өшкертеп тә, имләп тә карадык, берничә көн эчендә сызды да куйды, шәм кебек эреде. Дифтерит диләрме шунда, күп балалар һәлак булды.

Мәрдән бөгелеп төшеп хәтсез утырды.

—Илсөяр кайда?

—Әнисенә кайтып китте.

—Мин аның янына барам.

—Улым... туктале, сөйләшик әле... Йөрмә син Илсөяр янына.

—?

—Тиң түгел ул сиңа. Сөйләгәч, сөйлим инде, башкалардан ишеткәнче, миннән ишет: яхшыдан яман туган нәстәкәй булып чыкты ул килен дигәнебез.

—Бу ни дигән сүзең, әнкәй?

—Синнән кара кәгазь килгәч озак та тормады, сугыштан яраксыз булып кайткан офицер кисәге Үрге оч Фәтхи белән бутала башлады. Хәер, Фәтхи бер аның белән генә буталмый инде ул, кулында влач, сельсоветта учетчикмы шунда, малы бар. Икмәге, тозы дигәндәй, шуларга алдана ач солдаткалар. Белмәдем шул, белмәдем баштарак. Хәбәре дә бит аның иң соңыннан каза күргәнгә килеп җитә, шул мөртәт белән бәйләнгәнен сизсәм, Барыемны үземә генә алган булыр идем.

Мәрдәнне әйтерсең зур тау чаклы дулкын күмеп китте. Фәтхи, Ата Фәтхи дип йөртәләр иде аны. Яшьли үк хатын-кыз белән шаярырга яратты ул.

—Атам,—дип уйлады ул,—икесен дә атып үтерәм. Иң беренче булып Фәтхине. Сугыш утында янган солдат ярларын бер кадак онга кочкан бур песине, хәлсезләнгән корбаннарны бугазлаган шакалны, азгын кәҗә тәкәсен үтерәм,— дип сикереп торды ул.

Аның йөзе танымаслык булып үзгәргән, күзләрен кан баскан, борын яфраклары ап-ак булган, муенындагы һәр тамыры беленеп тора, йодрыклары чуен гер кебек йомарланган иде. Ул арада капка тавышы һәм кемнәрнеңдер сөйләшә-сөйләшә өйгә кереп килгәне ишетелде. Кырый күрше Алтаф карт

белән каршы күрше—чатан Мәгънәви икән.

Алтаф та, чатан Мәгънәви дә гөр килеп, геройны каршы алган кебек, «ах» та «ух» килделәр:

—Менә, «теге дөньяга сыя торган кеше түгел ул, үләргә никак не может»,—дип әйттем бит мин сиңа, Фәрхиямал җиңгәчәй, сүзем рас булдымы?— дип гөрелдәде Алтаф карт.

—Телеңә бал да май, Алтаф кайнеш,—дигән булып, Фәрхиямал тиз генә табын кора башлады.

—Фәрхиямал килен, безне гафу итә күр инде, алты яшьлек сәфәрдән кайтса, алтмыш яшьлек хәл белергә кирә, ди. Түзеп торып булмады, кердек инде, гаепләмә, үзең дә малаеңны күреп туя алмагансыңдыр әле. Ни бит, беләсе килә, фронтта ни хәлләр икәнен, ишетәсе килә, ни бит әле, менә шулай,—дип, гаепле кеше кебегрәк имән утыргычка утырды.

Гражданнар сугышында бер аягын югалтып кайткан Мәгънәви карт стена буендагы сандыкка кунакларга уйласа да, бөгелми торган тәпәч аяк бер якка да сыймады. Каршы утырса, идән аша мичкә терәлеп сыймый калды, өстәл астына тыкса, бүкән тез өстәлне күтәрә. Ниһаять, ул җаен тапты: өстәлгә аркасын куеп, аягын ишеккә чаклы сузгач кына уңайланды.

—Алдан килгән урын өчен, соңлап килгән тамак өчен,—дигән булды Алтаф карт.

—Әйдәгез, бары белән,—диде Фәрхиямал кунакларга.—Ерак кардәштән тату күрше яхшы.

—Әйе, әйе, дөрес әйтәсең, Фәрхиямал җиңги. Урын сайлама, күрше сайла,—дип тәртеребрәк җибәрде Мәгънәви. Шуннан соң гына барысы да дәррәү килеп өстәлне Мәгънәви ягына уртага күчереп куйдылар.

Алтаф белән Мәгънәви карт Мәрдәннең гаилә хәлләренә тоз салып тормадылар. Солдатларча турыдан-туры фронт хәлләренә күчтеләр. Өстәлгә Фәрхиямал карчыкның булы умачы менеп кунаклады. Солдат капчыгыннан Мәрдәннең армейский фляшкасы горур гына башын күрсәтте. Фәрхиямалның тьфү-тьфү диюенә карамастан, чыра телә торган пычак белән «каты борын» мае киселеп, өч ирнең алдына куелды, чиста пычак белән тәмле икмәк киселде. Һәм берәр кырлыны төшереп алганнан соң, фронт хәлләренә күчеп, тиздән дошманны үз өендә дөмектерү турында ныклы, ышанычлы авыл, алай гына да түгел, тиздән бөтен Җир шарын фашист мәлгуньнәрдән тазартырлык стратегик планнары корыла башлады.

Балаларын, ирләрен, туганнарны сораучылар: «очратмадыңмы?», «күрмәдеңме?», «ишетмәдеңме?», «исәннәрме икән?», «кайчан сугыш тукталыр икән?» дигән сораулар белән килүчеләр көн буена дип әйтерлек өйдән өзелмәде.

Килүче-китүчеләр төн уртасында гына таралышты. Мәрдән тышка чыкты. Шушы көннең тәэсире, тирән дулкынланулар, эчелгән спирт зәһәреннән аның башы әйләнә иде. Ул лапаска керде. Мәрдәннең яраланган, теткәләнгән җаны шикелле тишек-тошык лапас стеналарыннан учма-учма тулы ай нуры эчкә үтеп керә дә, каралып, корт тишеп беткән иске бүрәнәләргә төшеп уйный. Ул йөрәк әрнүенә түзә алмыйча, лапас баганасына маңгаен терәп, яралы ерткыч кебек саңгырау үксү белән елап җибәрде. Яу кырында егылып үлеп кенә калган булсачы! Бу кадәр йөрәк газапларын кичермәгән булыр иде.

Менә кайда ул дошман, менә кайда ул хыянәт, мәкер, аркага пычак кадау. Кем бит әле! Иң яраткан кешең—җаныңны ярып бирергә әзер торган ярың!

Төн уртасында Мәрдән күрше авылга китте.

Илсөярнең авыл читендә бөрешеп кенә утырган өенең тәрәзәсен какты.

—Кем бар анда?—дип пәрдә читен күтәрде «әби» булган кеше.

—Ә, синмени, кияү,— дип куркып кына дәште агарынып калган Хафизә карчык пәрдә артыннан.—Әйдә, үт, өйгә кер, кияү.

—Кергән чаклар булып үтте инде бу өйгә, «әби»,—диде, кинаяләп Мәрдән.—Илсөяр кайда?

—Өйдә, ни, йоклый.

—Чыксын!

—Авырып тора бит әле.

—Ашап бетермәм, үлмәс,—диде Мәрдән.

—Көндез килгәч сөйләшерсез, бәлки,— диде «әби» кеше, кыяр-кыймас кына.

—Өегезне төртеп аударганчы чыксын, дим мин сиңа.—Мәрдәннең түзәр тәкате калмаган иде.

Өй эчендә чыш-пыш, елашу китте.

Ишек ачылды, бусагадан озын ак күлмәктә, аягы йөзенә чаклы кара чәчләре дулкынланып төшкән чандыр гәүдәле, ак йөзле, бик кадерле, бик якын, шул ук вакытта нindiдер бик чит тә, чиркангыч хис тә тудырган Илсөяр чыгып ишек яңагына сөялде.

Аны күрү белән буып ыргытырга әзер булган Мәрдән телсез калды. Элекке Илсөяр белән хәзерге Илсөяр арасында җир белән күк арасы иде. Йөзе ап-ак булып суырылган, бит очлары гадәти булмаганча тимгелле-тимгелле, кызыл күзләре эчкә баткан, иреннәре кара көйгән. Янып-уйнап торган күзләрендә нур әсәре калмаган.

—Гафу итәлсәң ит мине, Мәрдән, итәлмәсәң, үпкәм юк,—диде акрын гына Илсөяр.—Баланың, Барыемның үлемендә минем зәррә дә гаебем юк, дифтериттән вафат булды улым, күз нурым, коткарып кала алмадым. Күп балалар авылда шулай үлде. Былтыргы кыш аяусыз булды, аяктан екты, синнән кара хәбәр дә шул чакта килде. Баланы күмдем, өметемне өздем, ачлыктан шешендек, әнкәйгә кайтып егылдым.

—Ә Фәтхи? Бәлки сине Фәтхи коткарып калганга исәнсеңдер, нигә үзең үлмәдең? Нигә минем улымны саклап калалмадың? Фәтхи кочагы кайнар идеме? Аның майлы иреннәре туендырдымы? Их, Илсөяр!!! Мин иң авыр минутларда да, үлем белән күзгә-күз карашканда да «сез» дип Газраил тырнагыннан котылып, үлемнең үзен бугазладым, сезгә кайтам, сезне кочаклыйм, сезнең белән бергә булам дип, мең җәһәннәмнән котылып калалдым, нәрсә эшләттең син мине, Илсөяр, ни эшләттең, үтердең бит син мине, улыбызны гына түгел, минем җанымны да үтердең син!

—«Кара» кәгазең килгәч, мин сине инде кайтмассың дип уйладым, улымны—Барыемны да югалттым, хәер, хәзер инде мин үземне дә югалттым,—диде Илсөяр ишетелер-ишетелмәс кенә.—Ә Фәтхи, Фәтхи—беркем дә түгел миңа, ул минем өчен юк кеше. Батып баручы кеше саламга ябышкан кебек, бер мизгел генә булды ул. Улыма, Барыйга файда итәлмәсме дип кенә мин аннан ярдәм сорадым, ә ул үзенчә аңлады.

—Аңлады... Нык аңлаттымы? Аңладыңмы соң?—диде Мәрдән ысылдап.

Мәрдән Илсөярнең кап-кара толымын йодрыгына урады. Илсөяр ыңгырашып, артка тайпылды, авызыннан гырылдык аваз ишетелде, ирен читеннән ак яңагына кызыл тасма булып кан саркып төште. Мәрдән куркып китте, үзен кулга алып, Илсөрнең толымын җибәрде, Илсөяр чайкалып, ишек яңагына сөялде, күзләрен йомды:

—Борчылма, син гаепле түгел монда, инде берничә атна йөткергәндә

тамактан кан килә,—диде ул, елмаерга тырышып.—Врачлар үтәр диләр, үтмәс, үзем беләм үтмәсен. Гафу ит мине, Мәрдән, каһәр суксын бу сугышны! Бәхил бул!

Ул арада Илсөярнең әнисе ишекне ачып:

—Нишләвең бу, кул күтәрмә хәл өстендә яткан балама, гафу итәсем юк, гаепле түгел кызым, каһәр суккан сугыш гаепле, тынычлап җан бирергә ирек бир кызыма, мөртәт! Үзең генә ут эчендә йөрисең дип уйлама, монда без дә тәмуг эчендә.—Карчык Мәрдәнне этеп чыгарып, эчтән ишеккә аркылы күгән салды.

Мәрдән Фәтхине атмады. Һичшиксез атар иде, һәм үзен дә трибунал көтәр иде, ләкин поездда очраган чегән хатыны чыннан да барысын да күреп, белеп торган икән. Шуңа да ул яхшылыкка—яхшылык белән коткарган: бер биштәр ризыгын урлап таю урынына ниндидер җаен туры китереп револьверын алып ыргыткан Мәрдәннең. Хәзер генә барысын да аңлады ул.

Атмады, ләкин җаен туры китереп бик каты кыйнады ул Фәтхине. Җан ачуы белән изде аны. Канга батып, мескенгә әйләнгәнче, аяк астында шуышып ялынганчы дөмбәсләде. Бусы сугыш утында йөрүче барлык ирләр исеменнән дә дип, җан җиренә кизәнептерәп типте дә, өстенә төкереп китеп барды.

Отпуск дигәне тиз үтте, ләкин авыр вакыйгалар белән тулы булды. Бер атнадан Илсөяр үлде. Гәүдәсен улы Барые кырына җирләде Мәрдән, алар яныннан чирле әнкәсе үзенә урын калдыруны сорады. «Инде озак тормам бу дөньяда, оныгым янында сине сугыштан көтеп алу җинелрәк булыр»,—диде ул...

***

...Кызым, әзрәк хәл алыйм әле. Яңа чәй җылытчәле, чәй үтсә, хәл кереп китә.

Мәрдән күзләрен йомып тынып ятты.

...Маршал Александр Василевский җитәкчелегендәге 3нче Белоруссия фронты һәм Балтыйк Флотына Көнчыгыш Пруссия операциясе барышында Кенигсберг группировкасын да юк итү, шәһәр белән крепостьне алу заданиесе дә куелган иде.

Фашист ныгытмалары әкияти җанвар оясы, дию өне шикелле җинеп булалмаслык крепостьне хәтерләтә иде.

Бихисап көч, техника сугышчылар белән ныгытылган озайлы оборонага исәпләнгән цитадель Гитлер өчен соңгы ышаныч-өмет булса, совет гаскәрләре өчен бу җиңү Берлинга туры юл булачак.

Шәһәрне алу өчен дүрт көн барган аяусыз артиллерия һәм һава һөҗүмнәре тукталып тормады. Менә шушы бөек кыйралышта бәләкәй генә җанына бар дөньяны, бөтен җиһанны, аның бар ләззәтен, газапларын, кайгы-шатлыкларын, матурлыгын, өмет-ышанычларын сыйдырган Мәрдән атлы солдат та окоп туфрагына сыенып ята иде.

Бу һөҗүмнәр җир белән күкне бергә тоташтырды, әйтерсең Җәбраил фәрештә инеп, сур быргысын өрде һәм җирнең асты өскә килде, күкләр ишелеп төште, кояш югалды, хәтта тын алырга һава үзе дә бетә шикелле.

1945 елның 6 апрелендә төньяктан һәм көньяктан совет гаскәрләре берьюлы һөҗүмгә күчте. Сугыш пехота, танк, орудиеләр ярдәмендә шәһәрнең һәр урамы, тыкрыгы, һәр йорты өчен барды. Фашист солдатлары белән берлектә коралланган җирле халык та аяусыз каршылык күрсәтте.

Ниһаять, 9 апрель көнне Крепость өстенә ак флаг эленде.

Кенигсберг тезләнде, фашизм оясы һәм аның плацдармы, ышанычы

булган Көнчыгыш Пруссия совет сугышчысының аяк астына егылды. Бу инде Берлинга, ниһаять, юл ачык икәнен күрсәтә иде.

***

...Дина, Дина! Яшел хәтфә үлән шикелле яшел күзле, җәйге кылган төсле йомшак сары чәчле, суда чумып уйнап йөргән көмеш балык кебек житез, болан баласы шикелле өркүчән, әйтеп бетергесез якын, җәл һәм кадерле җан иясе.

Нәрсәдән башланды соң әле бер законга сыймый, буйсынмый торган, ләкин үзләре өчен изгеләрдән дә изге бөек мәхәббәтләре?

...Анда-монда сазлыкларда торып калган каршылык күрсәтүче вак немец төркемнәрен исәпкә алмаганда, Кенигсберг тирәсендә һәм Көнчыгыш Пруссиядә тынычлык урнашкан иде. Хәрбиләрне һәм җирле халыкны азык-төлек белән тәэмин итү, ачка үтермәү өчен яз, җәй иң җаваплы вакыт.

Хәрби комендатуралар халыкка кагылышлы бурычларны эшләп халыкны таныштырдылар. Монда азык-төлек программасы да, өйләрен югалткан немец халкын урнаштыру, аларны тәгаенләнгән норма буенча азык-төлек белән тәэмин итү, медицина хезмәте күрсәтү, тәртипләрен контрольдә тоту, шул ук вакытта, совет солдатларының да рухи һәм мораль тәртибенең ныклыгы, җирле халыкка карата совет солдатлары ягыннан тәртип нормасы, халык санын алу, болар һәм башка кагыйдәләр бар иде.

Апрель аеннан җирле халык белән берлектә язгы чәчүгә әзерлек башланды, шул ук вакытта таралып, югалып, тузынып беткән сыер малларын бергә хуторларга җыю, бозауларын коткарып калу хәтсез күтәрелгән, әле бирешмәгән чәчеп үстерелгән үләндә герман җирендә немец сыерларын көтү, аларны вакытында саву, сөт азыкларын әрәм-шәрәм итми, кирәкле җиргә тапшыруны оештыру да совет солдатларына, шул исәптән авыл егете—гомер буе мал асрап яшәгән Мәрдәнгә дә йөкләнде. Биш елга якын винтовка күтәреп сугышып йөргән Мәрдәнгә—Берлинны алу дәрте белән янган сугышчыга бу хәл мәзәгрәк тә булды-булуын. Ләкин приказ—приказ иде.

—Берлинны сезсез дә алырлар,—диде политрук—монда, күптән түгел генә дошман оясы булган территориядә, тыныч тормыш кору, немецларны шуңа өйрәтү, эшләтү җиңел булмас. Курыкмагыз, Берлин өстенә байрак элү белән, сезне дә монда озак тотмаслар, кулларыгыз тыныч хезмәт эшенә өйрәнә торсын.

Кенигсбергның хәрби комендатурасы шәһәрдән жиде чакрымда гына—Нойхаузен дигән бистәдә урнашкан иде.

Мәрдән белән Вася исемле сугышчыга шушы бистәдән ерак түгел, буасы һәм кечкенә тегермәне булган, Иоганн исемле немец картының хуторында эш оештырырга задание бирделәр. Үлән инде аяк астында шактый ныгыган. Анда-монда таралган, адашып, кырда бозаулап ядрә шартлауларыннан куркып, тегеләй-бу битләүдә, агач-куаклар арасында өркеп йөргән малларны җыеп алу җиңел булмады, билгеле. Ләкин Мәрдән, авыл малае, малларның гадәтләрен белгәнгәме, бер атна дигәндә унбишләп сыер малын җыеп, Иоганн картның өеннән ерак түгел, бер ягы бомба төшеп җимерелгән мал сараен, аннан-моннан кадаклап сыер, бозауларны бергә туплый алдылар.

Ләкин бу әле ярты эш кенә иде. Тирә-якта урнашкан хәрбиләргә дә, җирле халыкка да ачка үлмәс өчен ашарга кирәк. Чәчү яңа башлана, солдат паегын барысына да бүлеп житкереп булмый. Җан асрар өчен сөт, эремчек кирәк.

Малкайлар нәселле, сөтле, итле сыерлар. Сугыш гарасаты үтүгә

карамастан, якты яшел көтүлекләр Польша чикләренә чаклы барып тоташа. Якындагы су тегермәне буасында ниндидер хикмәт белән тере калган үрдәкләр, кош-корт йөзә. Тирә-якка карасаң, үзенне нәкъ туган як болыннарындагыча хис итәсең. Туган якта үлән яңа гына яшел хәтфә булып калка булыр, ә монда инде үлән аяк йөзен күмә. Андагы ястык-ястык болытлар да нәкъ үзебездәгечә, тик нидер барыбер ят, чит икәнен сиздерә: жил башкачаракмы, кошлар башкачарак сайрыйлармы, һавасы, борынга дулкын-дулкын килеп бәрелгән хуш исләре икенче төрлерәкме, нәрсәдер барыбер безнеңчә түгел.

Менә тегермән буасы янындагы куакларда ниндидер кош сайрады. Тик ул нигәдер чит телдә, аңлаешсыз телдә сайраган шикелле тоелды. Менә су өстендәге кыр үрдәкләре камышка, ояларына чумды, алар, ни өчендер, бала елаган тавыш чыгарган кебек булды.

Мәрдән ике кулы белән колакларын томалады. Юк, ул гомердә дә бу тавышны оныта алмас инде. Бу онытыла торган тавыш түгел.

***

...Разведка Белоруссиянең бәләкәй генә бер хуторына дистәләгән немец солдатының партизаннарны эзәрлекләп килеп кергәнлеге турында хәбәр житкерде. Мәрдәннәрнең группасына хуторны сизмәстән һәм кинәт азат итү заданиесе йөкләтелде. Бинокль аша көндезге эсседә немец солдатларының өсләрен салып кызынулары, су сибешүләре, өстәл тирәсендә кунак булып утырулары күренде. Ә бер читтә ике солдат күкрәгенә яшь баласын кыскан анадан кызып-кызып допрос ала. Өстәрәк лапас тәрәзәсеннән тугыз-ун яшьләрдәге малайның моны карап торганы күренә. Исерек, жиннәрен сызганган фашист ананың кулыннан сабыен каерып алып читкә, түтәлләр өстенә ыргытты. Бала чырылдап елап жибәрде. Бала елаганын авыр кичерүчән Мәрдәннең баш миенә жәберләнгән барлык балаларның да елау тавышы кереп тулган кебек булды. Ул автоматын кысып командирга карады. «Иртәрәк әле» дигәнне аңлатты командирның күз карашы.

Ана балага ташланды, тик исерек солдат хатынны сугып екты һәм типкәли башлады, аннары баланы ботыннан күтәреп алып, читән аша урамга томырды. Яшь бала лап итеп жиргә барып төште дә тынып калды.

Лапас башындагы малай кинәт сикереп төшеп, дүрт япьле тимер сәнәкне жан ачуы белән фашистның аркасына батырды. Чучка суйгандагы тавышлар чыгарып, немец жиргә гөрселдәде. Моны һич көтмәгән берничә немец малайны типкәләп, лапаска өстерәп алып кереп киттеләр. Ана алар артыннан йөгерде. Һөжүмгә ташланырга команда яңгырады. Йөгереп килеп житкәндә, фашист солдатлары да атыша-атыша чигенәләр иде инде. Мәрдән белән өч сугышчы бәрәңге бакчасы аша ихатага бәреп керделәр. Ихатада жәйге агартылган мич өстендәге чуенда берни дә булмагандай бәрәңге кайный, янында ак самовардан пар бөркелә, өстәл өсте генә немецлардан калган самогон, азык калдыклары белән тулган. Тып-тыныч, әйтерсең берни булмаган. Өй янындагы миләш ботагында немец фотоаппаратының чехолы бауда тирбәлеп тора. Тирә-якта жан әсәре юк. Берничә солдат өйгә бәреп керделәр. Өй буш. Бик сәер тынлык иде бу.

Мәрдән эчке киеренкелек белән монда ниндидер шом тойды. Ул йөгереп барып ярым ачык лапас ишеген ачты. Йә, Алла, лапас ишеге төбендә аркасы шыр канда хатын-кыз гәүдәсе аунап ята. Аның каршысында лапас өрлегендә тугыз яшьләр тирәсендәге малай асып куелган. Зәп-зәңгәр күзләре кабакларыннан чыгардай булып киерелгән, сап-сары чәчләре үтәли жилгә тибрәлә. «Саша, кис бауны»,—дип, кычкырып жибәрде Мәрдән һәм йөгереп

килеп малайның гәүдәсен күтәреп алды. Бауны кисүгә малайның ак муены табигый булмаганча кинәт иелеп иягенә төште. Әле ныгып та житмәгән нечкә генә ак муен ватылган курчак шикелле сынган иде.

Бу вәхшәтнең коточкыч имәнечлеге дә агартылган мич өстендә пешеп утырган бәрәңге исе, кайнап утырган самовар пары, тирә-яктагы күзне камаштырырлык якты яшеллеге, бары тик үз жирен, үз гаиләсен саклап калырга тырышучы бу гөрләп торган язгы табигать кочагында, яшел чирәм өстендә үлем каршылаган гөнаһсыз кешеләрнең жансыз гәүдәләре белән беррәттән иде.

Кинәт Мәрдәннең башы әйләнде, күз алдына улы—Барые килеп басты, солдатны әйтерсең алыштырдылар. Менә хәзер, шушы минутта аның улын—Барыен фашист үтерде, фашист һәлак итте. Аның аңы томаланды. Күзләрен кан басты, зиһене чуалды, бүгенге белән кичәге буталды, үлем белән яшәү урыннарын алыштырды. Ул әйтерсең икенче бер дөньяга күчте. Аның аңында бары тик бер генә максат иде: бу сабыйларның гомерен өзгән фашистны ул дөмектерергә, жир йөзеннән юк итәргә, изәргә, бетерергә тиеш, шуны эшләмәсә, бу дөньяда яши алмаячак.

Бәрәңге бакчасы артындагы сай гына инешне ничек сикереп чыкканын да, күпме ара йөгергәнен, күпме жир үтүен дә сизмәде. Урманга таба йөгерешкән фашистларны гына күрә иде.

Менә алар: солдат күлмәкләрен терсәгенә хәтле күтәреп ураган, каты табанлы озын итекләр белән туган ил туфрагын таптап, дөньяны канга батырып, басып, изеп, пычратып йөрүче хәшәрәтләр. Берәү, икәү, өчәү. Мәрдән пулясыннан алар жиргә каплана бара, тагын, тагын берәү калды. Тик патроннар беткән иде. Фашист та артка борылып, эшнең нидә икәнен тиз абайлады. Пистолетын Мәрдәнгә төбәп ата-ата чигенә. Берәү, икәү, өчәү... Хәзер бетерәм мин бу акылын жуйган урысны, дип уйлады немец. Тик аның да пистолетында патроны бетте. Дошманнар бер-берсенә карап туктап калдылар. Ике көч—ике дөньяга сыя алмаслык нәфрәт дулкыны электр дугасы шикелле алар арасында яшьнәп үтте. Алар бу минутта ике ерткычны хәтерләтәләр иде. Мәрдәнгә аның яшел күзләре, усаллыктан чалшайган авызы, агарган йөзе, һәм ни өчендер уң як каш өстендә борчак зурлыгыдай миңе генә күренде. Әгәр аның пистолетында пуля булса, ул һичшиксез нәкъ шул миңенә генә утыртыр иде.

—Син, хайван, бала жанын алучы Газраил, беттең син,—дип акрын гына пышылдады Мәрдән. Ул юлбарыс сыгылмалыгы белән гитлерчыга якынлаша башлады. Кинәт немецның йөзе үзгәреп китте.

—Юк, мин түгел. Мин асмадым пацанны. Аларны Ганс белән Уберт үтерде. Син аларны аттың инде. Мин балаларга каршы сугышмыйм. Мин репортер, газетага язучы, мин гаепле түгел,— дип, рус телен вата-кыра сөйләнә башлады ул чигенә-чигенә. Ни өчендер бу минутта фашистның бар усаллыгы тыны чыккан шар шикелле, югала бара иде.

—Минем үземнең гаилә бар, мин балаларга каршы сугышмыйм, балаларым өчәү. Мин—репортер.

—Әгәр репортер икәнсең, син нигә безнең балаларны асып, аналарын үтереп, фотога төшереп, газетага бирәсең, фашист. Кабахәт, канэчкеч!

Мәрдән кыргый мәче кебек кинәт дошманына ташланды һәм хәнжәрен бугазына батырды. Немец бер-ике секундка тораташтай басып торды. Аннары чалгы белән чапкан үлән кебек жиргә шуып төште. Нәрсәдер әйтергә теләде, тик тавыш урынына бугазыннан гөлт-гөлт итеп кан ургылды. Ул ямь-яшел күзләрен күккә төбәп, гажәпләнеп калды. Уң як каш өстендәге кара миңе генә ике тапкыр дертләп алды...

***

...Сугыш бетте, сугыш бетте, сугыш бетте! Бөтен дөнья жиңү шатлыгыннан канатланган, хисләр ташкан, башлар әйләнгән, күнелләр иләсләнгән чак. Тирә-яктагы бөтен нәрсә матур, бар кеше якын, кадерле, туган кебек күренә.

Күнелдә әйтерсең карангы, куркыныч тоннельгә кереп бик озак адашып, аяусыз ерткыч белән көрәшеп, аның үңәченнән алып, канлы күзләрен чокып, үлемечле тешләрен җимереп, шул ерткычны җиңеп, үтереп кояш яктысына, һавага, азатлыкка чыккандагы шикелле иләс хисләр иде. Кайтырга вакыт якынлаша кебек. Туган-үскән якларга, үз җиркәемә...

Кемнәрдер ата-ана янына ашкына, кемнәрдер сөйгән ярларга, кемнәрдер—балаларга. Ә Мәрдән кемгә? Кем көтә Мәрдәнне анда?

Сугыш авырлыкларыннан бөрешеп, сукыраеп, кайгы өстенә кайгы кичереп, гүр куенына кереп киткән газиз анасы кабере, шул кабер белән янәшә тагын бер кечкенәсе—газиз улы—Барые кабере, Илсөяр кабере!

Юк, аны илендә көтүче кеше юк. Көтсә, шул кадакланган тәрәзәле, бикле ишекле, иске өе генә инде. Тик барыбер туган як тарта. Туган туфрак әйди.

***

...Немец Иоганн картның гаиләсендә хатыны Клара, тумыштан гарип, колкяскада утыручы 27 яшьлек улы Эрнест, оныклары—яшүсмер игезәкләр Себастьян һәм Карл яши. Алар барысы да эшкә яраклы дип исәпләнәләр.

Аларның җаваплылыгында—мал карау, сыер саву, сарай чистарту, хуҗалыкны тәртиптә тоту. Мәрдән белән Вася сәгать дүрттән аларны эшкә килеп ала, карап эшләтәләр, җитештерелгән продукцияне әрәм-шәрәм итми, казнага тапшыралар. Тәртип монда каты. Ни дисәң дә инде, җиңү килсә дә, тирә-якта һаман-һаман пулемет тавышлары, анда-санда урман арасында шартлау-атыш ишетелгәләп тора. Солдатлар үзләрен җиңүче итеп тойсалар да, элекке дошман җирләрендә икәнлекләрен онытмыйлар. Монда һәр яктан куркыныч яный. Җирле халык арасында төрле кеше барлыгын бер минутка да истән чыгарырга тиеш түгелләр. Комендатурада һәр немец кешесе исәптә. Һәр хуторда, һәр йортта ничә кеше, кем яшәгәне барысына да билгеле.

Немецларның хезмәте авыр булса да, алар үзләренең җиңелүчеләр икәнлеген аңлыйлар, шуңа да баш иеп, бернинди ризасызлык белдермәскә тырышып иртәдән-кичкә чаклы хезмәт итәләр. Бигрәк тә яшь, әле буыннары катып бетмәгән Себастьян белән Карлга авырга туры килә. Электр станциясе еш сафтан чыкканлыктан, күп нәрсә кул көче белән эшләнә. Малайлар сөт савыша, авыр чиләкләрне сөт бакларына ташып торалар, сыерларны бәйлиләр, ычкындыралар, чистарталар, кирәк чакта ашаталар, көтүгә куалар, алып кайталар.

Мәрдәннең карашы малайларның күзләре белән очрашканда ул аларда яшерен ерткыч усаллыгы күреп кала. Бигрәк тә Себастьян усал бүре баласына охшап тора. Ә беркөнне чиләкле сөтне бак янына күтәреп алып килеп куйгач, беркем дә күрми дип уйлап, ул сөт чиләгенә төкерде. Шул минутта Васяның затвор тавышы ишетелде. Ярый әле Мәрдән якын иде, ул яшен тизлегендә сакчының автоматын читкә каерды. Кыска пулемет очереды чиләк белән бакны кыеп алды, җиргә атылып сөт чаптырды.

—Син нәрсә, малай гына бит әле ул, акылы юк.

—Малай түгел, шакал ул, фашист,—дип усаллашып җавап бирде солдат.

—Ашыкма, өлгерерсең, чын фашист әнә урманда ята, патроныңны сакла.

Ул арада фрау Клара атылып килеп Себастьянны кочагына алып, читкә, ышыккарак алып китте. Бу вакыйгадан соң Иоганн да, Клара да Мәрдәнгә үзләренең коткаручыларына караган шикелләрәк рәхмәт белән карый башладылар. Тик Себастьян гына барыбер күңеле төбендәге дошманлыгын яшерә алмады.

Вакытын туры китереп икәүдән-икәү генә калганда, Мәрдән аңа русчалап-немецчалап халык мәкален аңлатырга тырышты: «Коега төкермә—суын үзең эчәрсең». Себастьян аңладымы, юкмы моны, тик бераз гына холкын тыйды кебек.

Кырык бишенче елның яңгырлы июль таңында Мәрдән һәрвакыттагыдан алдарак уянып, иртән эшчеләрен алырга китте. Иоганн карт йорты, сугыш үтүгә карамастан, пөхтә итеп киртәләп алынган, алма бакчасы уртасында. Таштан салынган йорт кызыл черепица белән ябылган, ул әйтерсең кызыл шәлен ябынган яшь хатын сөйгәнен көтеп утырган шикелле, яңгыр астында моңаеп утыра. Снаряд, мина ярчыклары тигән җирләре сизелеп торса да, пөхтә хуҗалар яшәгәне күренеп тора.

Таң беленеп килә, ләкин әле бик иртә, ә бәлки көн болытлыгамы, төн акрын чигенә.

Соңгы вакытта юньләп йоклый алмый иде Мәрдән. Туган якны сагыну хисләре, югалту газаплары әрнетәме аны, күңеле тыныч түгел. Бүген ул иртәләгән иде. Өй түрендә бүлмәдә ут янса да, капка эчтән эленгән, хуҗалар әле келәне ачмаганнар. Мәрдән шакып тормады, тәбәнәк койма аша җәһәт кенә ихатага сикереп төште. Овчарка Генри абалап тимер сеткага ыргылды. Хуҗалар белән беркадәр уртак тел тапса да, менә Генри белән Мәрдән һич кенә дуслаша алмады. «Фашист» дип уйлап куйды Мәрдән эт хакында. Аркада мылтык бар—барын, эт тә җан иясе шул, тик торганнан кан коясы килми. Ул тышкы ишек янына килеп кыңгырауга басарга теләп кулын күтәрүе булды, шул минутта кинәт ишек ачылды. Ишектән чыккан япь-яшь, 16-17 яшьләрдә булыр, ямь-яшел күзле, житен чәчле, зифа буйлы, искиткеч матур кыз Мәрдәннең кочагында калды.

—О-о-о,—дип улап җибәрде ишек катында торган фрау Клара.—Nein, nein, үтенеп сорыйм, зинһар харап итмәгез, дип такмаклап еларга ук керешге.

Ул арада йөзе ап-ак булып агарган Иоганн күренде. Мәрдән беренче тапкыр бу карт немецның күзләрендә чын-чынлап курку күрде.

—Гафу итегез, гер солдат, ул минем оныгым—Дина. Ул ятим. Әти-әниләре сугышта үлде. Ул әле бик яшь, аңа нибары 16 гына. Зинһар, харап итмәгез, комендатурага җиткермәгез, үтенеп сорыйбыз.

Алар икесе дә тезләнеп Мәрдәннең аякларыннан, кулларыннан үбеп ялварып елый башладылар.

Чыннан да комендатурада исәптә булмаган кешене гаиләдә яшереп тоту чын мәгънәсендә зур гаеп иде. Һәм моның өчен тиешле җәза бирелергә мөмкин. Сугышның үз кануннары, үз законнары.

Ә кыз исә болан баласы кебек калтыранып, ишек янагына сыенган, йөзе агарынган, күзләренә курку, хафа, ялвару тулган. Мәрдән бу хәлгә ничек тә үз бәясен бирергә белми, аптырап торды. Иоганн карт тагын бер немецча, бер русча вата-җимерә аңлатырга кереште.

—Яшь әле ул, җәлләдек. Авыр эштән ватылыр, үзен солдатлар рәнжетер, дип курыктык. Тентүләр булганда сарайда, печән астында, бочка эчләрендә, подвалда иске әйберләр астына яшердек, гер солдат, нәрсә телисез шуны алыгыз, тик харап кына итә күрмәгез,—дип ялвардылар алар.

Ул арада урамга Себастьян белән Карл да килеп чыкты, гаиләләренә нинди хәвеф янаганын аңлау, курку аларга да күчте.

—Шнель, тиз-тиз эшкә җыеныгыз! Эшкә!—диде Мәрдән катгый гына.—Шнель, кызыгыз өйгә керсен!

Немецлар дәррәү өйгә кереп, тиз-тиз генә әзерләнеп эшкә киттеләр.

Гаилә көн буе башын иеп сүзсез генә эшләде дә эшләде. Хәтта шул ук Себастьян да бер генә кыек гамәл дә кылмады. Нишләргә, дип көн буе уйланды Мәрдән. Комендатурага әйтсә, боларны, һичшиксез, җәза көтә. Сорау алулар, төпченүләр, төрмә, лагерь...

Ә кыз яшь, шундый матур, немкалар арасында да шундый гүзәл зат булыр икән. Алар, гадәттә, җирән чәчле, сары, төссез күзле, кызыл чырайлы, озын борынлы, такта гәүдәле була. Ә Дина киресенчә, соры ефәк чәчле, зур ямь-яшел күзле, кара кашлы, озын кара сөрмәле керфекле, урта буйлы, йомры гына матур кыз. Тикмәгә яшермәгән Иоганн оныгын, дип уйлады Мәрдән. Күзләре ничектер таныш кебек, кайдадыр күргән кебек ул шундый күзләрне. Хәер, дөньяда охшаш күзләр беткәнмени!

Бу көн дә, икенчесе дә, өченчесе дә үтеп китте. Тик гаиләгә афәт янау һич кенә дә кимемәде.

Карт анасының шәүләсе, бу дөньяга килеп тә яшел үләнне рәхәтләнеп таптап йөри алмаган, гүр куенына кергән улы, лапас өрлегенә асылган белорус малае, урамга тузанга «гөрс» итеп барып төшкән сабый гәүдәсе—барысы да Мәрдәннең күз алдына килде. Каһәр суккан сугыш, дип уйлады ул, хәшәрәт Гитлер, бар дөньяны кайгы, үлемгә күмү генә түгел, үз халкын, үз кешеләрен дә нинди аяныч хәлгә калдырды.

Тентүләр, анда-санда совет солдатларына һаман почмак артыннан, урман арасыннан атулардан соң оештырылган облавалар, еш булып торды. Беркайда да теркәлмәгән, бернинди дә документы булмаган Динаның иртәме-соңмы тотылу ихтималы ачык иде.

Бер караганда: «Нигә җәллим әле мин бу немецларны, барыбер безнең өчен дошман инде алар, сугышны бит үзләре башлады, миллионлаган халыкны җир йөзеннән кырды, күпме кешенең бәхетен җимерде, гомерләрен өзде. Гади кеше булса да, Иоганн, аның гаиләсе, аның кебек үк башка гап-гади немецлар сугышка каршы чыкмадылар. Нигә алар үзләренең хаин Гитлерларын туктата алмадылар? Нигә үз өннәрендә үк бумадылар үзләренең аждаһаларын?»—дип уйлады Мәрдән.

Икенче караганда: «Ни гаебе бар инде бу шәлберәгән немец карты белән немец карчыгының, инвалид уллары һәм яшь кенә оныкларының. Алар да бит сугыштан үзләренең җәзаларын тулысынча алганнар. Иоганн белән Кларанының улы, килене, оныкларының әти-әнисе сугышта һәлак булган»,—дип үз-үзенә каршы төште.

Күп тә үтми бу вакыйга үзеннән-үзе чишелде дә куйды.

Хәрби комендатура заданиесе белән җирле һәм эш урыннарындагы халыкның төгәл санын алып комендатурага тапшырырга кирәк булды. Бу—халыкны азык-төлек белән тәэмин итү өчен дә кирәк иде, сәясәткә кагылышлы башка максатлары да бар. Халык санын алуга немецларны эшләтүче солдатлар да зур ярдәм күрсәттеләр. Шушы исемлеккә Динаның да исемен кертеп җибәрү иң ансат юл иде. Һәм ул җиңел эшләнде, беркем сизмәде дә.

Мәрдән кичен Иоганнарга китте. Шакуга шомланып кына ишек ачылды. Дина ялт итеп шкаф артына посты.

Фрау Клара тиз-тиз йөгерткәләп кофе кебегрәк нәрсә кайнатып алды, Иоганн икенче бүлмәдән графин белән эчемлек чыгарды.

—Солдат әфәнде, рәхим итегез, шнапс,—диде һәм бәләкәй генә рюмкаларга эчемлек койды.

Мәрдән эчеп куйды, артыннан алма капты. Иоганн тагын салды, үзе дә бераз гына йотып куйды.

—Дина яшь, эти-әнисе сугышта үлде, улыбыз нацист түгел иде, ул—журналист иде. Гитлер—капут!—диде Иоганн.

—Яхшы,—диде Мәрдән, немецчаны яхшы гына «сукалый» белә иде инде ул.

—Дина иртәгә фермага эшкә чыксын, башка яшеренеп ятмасын, ул рәсми исемлеккә кертелгән, курыкмасын,—диде дә чыгып китте.

***

Мәрдән белән Дина арасындагы мәхәббәт кара болыт баскан күк йөзендә бер балкып, бер яшеренеп йөзгән ай, танклар таптап үткән, ләкин үлми калган маргариткалар чәчәге өстендәге таңгы чык, яңгырлы иртәдә ялт-йолт килгән аҗаган кебек гаҗәп оялчан да, самими да, бар булмышны бөтереп алырлык көчле дә, бәллүр кебек саф та иде. Мәрдән бинибая ышаныч белән үзенә караган зур яшел күзләр дөньясында калды, әйтерсең лә алар арасында сугыш та, милләт тә, сәясәт тә, дин дә, тел аермасы да—берни дә юк иде.

Зифа буйлы кыр кәҗәсе кебек житез, бар булмышы наз, үзенә тартып торучы көч һәм шул ук вакытта куян баласы шикелле куркак, калтыранып, киеренкелек белән тулы буй-сынлы Дина бар дөньяны, бу шәфкатьсез чынбарлыкны оныттырып, Мәрдәнне үзенә тартты.

Хатын-кызның булмышыннан шактый хәбәрдар булган, хәтта гаилә корып яшәп караган Мәрдән өчен Динага булган тартылу бөтенләй икенче, көтелмәгәнчә, баш әйләндергеч, аңны томаларлык, барлык дөньяны оныттырырлык көч белән тулы иде.

Дина да эш арасында аның ягына күз сала, алар арасында урнашкан бу күзгә күренмичә бер-берсен тартып торган жеп белән бәйле икәннәрен аңлый. Күзләре Мәрдәннеке белән очрашса, каушап кала.

Жәйге көннәрнең иң кызу мәлендә Мәрдән юынып алу теләге белән буага килде, ул чишенеп киемнәрен яр буена куйды, инде суга чумарга дип торганда гына куак артында су дулкынлануын күреп, сагаеп калды. Анда исә Дина кулларын жәеп, чалкан ятып дулкыннар кочагында иркәләнеп, су өстендә тибрәлә иде.

Мәрдәннең башына кайнар дулкын бәрелде, йөрәге күкрәк читлегеннән чыгардай булып кага башлады, ул акрын, сиздермичә генә йөзеп килеп, Динаны кочагына алды. Дина куркып китте, ләкин Мәрдәнне күреп тынычланды һәм күндәм генә аның кочагына сыенды.

***

—Яратам, сезненчә ничек була?—дип сорый Дина.

«Я-ра-там»,—була.

—Матурсың син,—ди Мәрдән Динага.

—Ташлама мине,—ди моңсу гына Дина.

«Я-ра-там»—дип кабатлый тагын ул.

—Мин синсез яши алмыйм,— ди Дина.

—Син яшәргә, яшәргә, һәм бик озак яшәргә тиеш,—дип жавап бирә Мәрдән.

—Син зур кош,—ди Дина Мәрдәнгә.

—Ә син чабак,—ди Мәрдән Динага,—көмеш балык. Зур кош кечкенә көмеш чабакны менә шулай эләктереп ала һәм менә шулай ашап бетерә,—

дип Динага ташлана. Кочагына ала, алар көлә-көлә киемнәре белән суга мәтәләләр.

Җәйләрдән соң дымлы дингез җиле Германия җиренә елак көзләр китерде, тирә-як таушалган, чагу төсләрен югалткан карт хатынга охшап калды.

Казарма тәрәзәсенә бәреп яуган кара янгыр Мәрдәнгә туган якларын, кочагына авылын сыендырып утырган каенлы тауларын, Кибән сыртны, Биек арка урләрен исенә төшерде, күз алдына туган йорты, ап-ак мич буенда тәмле тәбикмәк пешереп торучы әнкәсе килде, колагына тәрәз пыяласына чиртеп чакыручы миләш тәлгәше тавышы ишетелде.

—Сагынасыңмы, брат,— дип дәште аңа напарнигы Вася.—Озакладык бугай шул без чит җирләрдә, мин дә сагынам үземнең туган Борисовомны. Мичтә томится иткән кайнар борщ, ыслы чучка салолары төшләргә кереп йөдәтә. Олеся да көтәдер инде, «сине көтәм, кияүгә чыкмыйм», ди иде, хәзер сугыштан кайткан фраерлар—геройлар күбәядер инде, берәр козгын тибеп алмаса. Бүтән частьлардан кайтып китеп торалар, безне менә ни өчендер онытты лар. Кызлар монда да бар инде ул, тик немкалар бит—дошманнар, хатын-кызны болай да ирнең иң беренче дошманы, диләр, ә болар—икеләтә дошман инде алар. Иоганн картның Динасы чибәр кыз да, куркыта. Якын барсаң, әллә ни булыр. Синең яктан күзен дә алмый. Синең дә аны күрү белән күзләрең май ашаган мәче кебек ялтырап-ялтырап китә. Кара аны, штабистлар сизеп алмасыннар...

...Салкын, юеш яңгырлары, дингез якларыннан үтәдән-үтә искән җилләре белән кыш та үтеп китте.

Апрель аеның таңында Дина малай тапты. Аңа Александр дип исем куштылар. Бу хәл Мәрдәнне әллә нинди аңлатып бетерәлмәс уйларга салды, баш әйләндергеч катлаулы халәтләр эчендә калдырды. Ул—ата, ул—икеләтә ата, беренче улы Барый урынына әле биләүдә иреннәрен кыймылдатып, әнисенең күкрәген эзләп, зәп-зәңгәр күзләрен бер ачып, бер йомып, йодрык хәтле тере җан иясе—аның булмышын, нәселен дәвам итүче баласы ята. Һәм ул «дошман» дип аталган хатында, димәк «дошман» карынында яралган аның орлыгы. Аның бер кисәге.

Әллә нинди каршылыклы уйлар эчендә йөзде ул Дина янына килгәндә. Тик балага бер күз салу белән, иреннәрен әнисенең имчәгенә терәлеп чәпелдәтеп имә башлавын күрүдән, бармаклары белән сабыйның алсу, җылы битенә орынудан бу төерчекнең никадәр якын, никадәр үз икәнен бар җаны-тәне белән тойды.

***

...Көннәр, айлар үтә торды. Мәрдән башкаларга сиздермәскә тырышып Дина белән улына ашарга ташыды, паегын бүлеште, булдыралган саен, мөмкинчелек булган саен ачлы-туклы яшәүче Иоганн гаиләсенә онын-ярмасын, шикәр, тушенкасын юнәштергәләде.

Тик без капчыкта ятмый шул. Мәрдәннең, совет солдатының тәртибе хакында сигнал комендатурага барып ирешкән иде инде. Ыспай киенгән, яхшылап кырынган зәңгәрләнеп торган ач яңагыннан одеколон исләре аңкып торган, кыр сумкасын таккан лейтенант Мәрдәнне эзләп килеп керде.

Күзгә-күз булган бу сөйләшү казарманың Кызыл почмак дип аталган бер бүлмәчегендә үтте.

—Нәрсә, солдат? Ирек туйдырдымы әллә, трибунал кирәкме сиңа? Немкалар кызыксындырамы, әллә киресенчә, немкаларны син кызыксындырасыңмы? Нәрсә обещать итәләр? Бәлки вербовка хакында ук

хыялланалардыр ул фашист токымнары. Ә син шулар кармагына эләгүгә шатсыңмы?—Һәм башкалар, һәм башкалар. Сөйләшү озак һәм күңелсез булды.

Соныннан ялтыр лейтенант: «Хәзергә «бывай», тик очрашу соңгысы түгел»,—дип кузгалды. Бу инде турыдан-туры янау иде. Мәрдәнне авыр уйлар чолгап алды. Сугышны үтеп, күпме югалтулар, авырлыкларны җиңеп, инде кечкенә бәхет күзе ачыла дигәндә башка кусәк белән суккан кебек булды аңа.

Бигрәк тә Дина һәм улы өчен хафаланды ул. Аның үзенә янаган куркыныч ул кадәр түгел. Динаны—дошман агенты, совет солдатларын вербовать итәргә тәгаенләнгән элемент дип гаепләргә һәм улы Александрдан аерып, әллә кайда, лагерьларга җибәрергә, хәтта бу болганчык чорда үлем җәзасына да хөкем итәргә дә мөмкиннәр. Ул төн буе йоклый алмады: нәрсә эшләргә? Ничек бу хәлдән котылырга, кая барырга, кайда яшерергә аларны? Беркайда да, берничек тә котылу, ычкыну юлын күрмәде ул.

Тик Мәрдәннең дә, Дина белән улының да бәхет йолдызлары әле сүнмәгән, ашар ашлары, эчәр сулары бетмәгән икән.

Лейтенант кайтыр юлында, шартламый калган минага эләгеп, машинасы белән күле күккә очкан. Бу хәлдән соң Мәрдәнне беркем дә бимазаламады, әллә аның хәлен бары шушы лейтенант белгән булып, кәгазьләре янгач, эз калмады, әллә башка сәбәпләрдәндер, аңа кагылучы кеше булмады.

Дина белән Мәрдән арасындагы мөнәсәбәт үз җаена төште, яшьлек, мәхәббәт үзенекен итте. Очрашкан минутлар алар өчен тормышларының иң матур мизгелләре иде. Мәрдән күрешкәндә улын сөеп туялмый. Аңа агачтан юнып үзенчә уенчыклар ясап алып килә. Дина көлгән була, ләкин моңсулыгын сиздермәскә тырыша, хушлашканда яшь тулы күзләрен Мәрдәннән яшерә.

***

...—Картатай, нигә син болар хакында элегрәк, нәнәй яшьрәк чакта сөйләмәдең, бәлки анда калган Динаны, Александрны табып булыр иде. Германиягә барыр идегез, эзләп табар идегез, очрашыр идегез,—диде Диана.—Нигә «Эзлим сине», «Көт мине» телевизион тапшыруларына сорау җибәрмәдегез?

—Әй, кызым, ул заманнарда бу хәлләр хакында авызны да ачып булмый иде, дошманлыкта гаепләячәкләр иде. Ябып ук куймасалар да, «сатлыкҗан» дигән кара мөһер шунда ук маңгайга сугылачак иде. Ә сезнең әтиегезнең, апаларыгызның да язмышы ничек булыр иде? Һәр заманның үз авырлыгы бар шул, балам. Язмыш кеше башыннан йөри, дигән әйтем кешелек дөньясы яралган тарихтан ук киләдер ул.

—Картатай, ә бәлки алар сине эзлиләрдер, бәлки ул синең улың, безнең абый Александр инде зур үсеп, яхшы, бөек кеше булгандыр. Ни дисәң дә, Көнчыгыш Пруссия, Кенигсберг туфраклары, без тарих китапларыннан укып белгәнчә, даһилар туа торган яклар. Анда бөек философ Кант, Амадей Гофман кебек бөек кешеләр дөньяга килгән.

—И балам,—диде Мәрдән карт авыр сулап,—сугыш дигән нәрсә күзләрне, аңнарны томалый, кешелек хисләрен ерткыч хисләре белән алыштыра. Сугыш кеше дигән җанварның иң элекке, миллион еллар геннарында черем итеп, йоклап яткан кыргый, ерткыч, вәхшилек хисләрен уятып җибәреп, үзе кебек, үзенә охшаган, үз вәкилләренең берсе булган кешенең дә авырту нервылары, йөрәкләре, язмышлары, кичерешләре, сөю-назлары, гаиләләре, табигать тарафыннан бер генә

тапкыр бирелгән гомерен аямыйча, хәтта, дошманының, ягъни үзе кебек үк кешенең аеруча ләззәт белән гомерен ала. Менә нәрсә ул—сугыш, кызым!

Аннары 1946 елның 2 августында Потсдам конференциясендәге килешү буенча ул чакта инде Калининград дип йөртелгән шәһәр һәм Көнчыгыш Пруссиянең төньяк өлеше РСФСРга кушылганнан соң эшелоннар белән җирле немец халкы совет армиясе яулап алган Германия территориясенә күчерелде. Чөнки 1946 елның августында бу җирләргә СССРның утыз бишләп өлкәсеннән совет кешеләре күчеп утырды. Болар барысы да Динаны, Александрны эзләп табу мөмкинлекләрен бик нык кыенлаштырды. Хәер, алда әйткәнемчә, хат белән дә, сораулар белән дә эзләү ул елларда хәвефсез эш түгел иде.

—Ә хәзер, хәзер, картатай, нигә хәзер «Көт мине»гә язмыйбыз?

—Хәзер вакыт үткән инде, кызым, гомер үткән. Динаның да, Александрның да үз язмышларыдыр. Бәлки, аларның хәзер мине күрәселәре дә килмидер. Александр бәлки мине бөтенләй белмидер, башка бер немецны әти дип йөридер. Бәлки алар хәзер бөтенләй икенче төрлеләрдер. Исән булсалар... Ә бәлки эзлиләрдер...

—Картатай, ә почтальон капка шакып, «Мәрдән бабай, сиңа Германиядән хат бар», дисә, нишләр идең?

Ә теге чегән хатыны: «Дүрт балаң исән булачак, гомерләре синекеннән озын булачак, дип әйткән иде бит!»—дип уйлап алды карт өмет белән. Ул күзләрен йомып бик озак сүзсез ятты. Мич артындагы такта сәке үлчәп эшләнмәсә дә, ни өчендер дүрт бала сыешлы киң итеп килеп чыккан иде бит.

***

...1946 елның җылы җәе житте. Көтүләр көтүлекләрдә. Бакчаларда күкрәп яшелчәләр үсә, тавыклар кыткылдаша, көннәр чалт аяз тора. Сугыш инде бик ерак калган шикелле. Табигать чәчәк ата. Печән житә, дөньяда мәхәббәт патшалык итә.

«Мин матурмы?» дип сорый Дина әллә йөзенче тапкыр инде иркәләнеп Мәрдәннән. Ул сары чәчләрен кояшка сибеп салган, йомры ап-ак тез башлары ялтырап күренеп тора, үзе юып кибәргә элгән сөт чиләкләре шикелле чиста, матур, яңгыравыклы, көмеш тавыш чыгарып көлеп жибәрүе йөрәкләрне жилкендерә.

Муенында нечкә генә көмеш чылбырда үтә күренмәле бал тамчысы кебек гәрәбә медальон яна. Мәрдән аның кояшта каралган матур озын муеныннан, килешле тыгыз күкрәкләреннән күзен алалмый.

—Ошыймы?—дип сорый Дина Мәрдәннән медальон турында.—Кояш ярчыгы ул. Шулай диләр бездә бу таш турында. Ә миңа икенче легендасы күбрәк ошый. Бу минем шикелле синең кайнар кояш нурлары астында катып, асылташка әйләнгән диңгез күбеге. Матур легендамы?—Һәм ул ялт итеп муеныннан медальонын салып Мәрдәннең муенына кидерде.—Сиңа булсын! Ул сугыш һәлакәтеннән, чирләрдән, афәтләрдән, начар күзләрдән саклый. Уныш, көч, акыл бирә һәм иң мөһиме—мәхәббәтне саклый.

Тагын сиздермичә көзләр килде. Кояш көндезләрен җәйге көннәр шикелле мул җылысын бирә. «Матурсың син!»—дип йөзенче тапкыр әйтә Мәрдән Динага. «Ә беләсеңме, минем фотоаппарат бар, көннәр суынганчы, әйдә, фотога төшәбез. Иртәгә Александрны да алып кил»,—ди ул дәртләнеп.

Чыннан да икенче көнне Дина белән Александрны күргәч, Мәрдән

аулак урынга фотоаппарат күтәреп килде. Дина чырык-чырык көлә. Шул ук күлмәген кигән, бу юлы тагын да чибәррәк булып күренде ул Мәрдәнгә. Дина шунда ук Александрны кулына күтәреп күкрәгенә кысты. Мәрдән объективны аларга юнәлтеп, төймәгә басты. Дина кинәт үзгәреп китте. Баланы жиргә бастырды, ялт итеп Мәрдән янына килеп басты, кулыннан фотоаппаратны тартып алды һәм әйләндереп-әйләндереп карап, немец телендә бертуктаусыз кызу-кызу нәрсәдер сөйли, сораша, төпченә башлады. Аның күзләре аптырау, гажәпләнү, өмет һәм берүк вакытта тирән курку белән тулган иде. Мәрдән берни анламый гажәпләнеп, аңа карап торды һәм ниһаять, Дина:

—Кайдан, ничек, кемнеке?—дип анлата алды.

—Сугыштан, фашистныкы. Капут булган фашистныкы,—дип жавап бирергә тырышты ул.

—Капут? Nein. Ул журналист, ул журналист, минем әти,—дип анлата алды ул, ниһаять. Аннары күзләрен зур ачып, курку катыш сорау белән Мәрдәнгә карады. Шул чакта гына бу күзләрнең кайдан шулай үзенә таныш икәнен анлады солдат.

Әтисе, димәк ул Динаның әтисенең бугазына пычак кадаган. Кинәт Мәрдәннен бар булмышын ул минуттагы халәт биләп алды: ничек итеп немецнын аңа йөзе белән борылганы, курку катыш югалып калган тирән карашы, «nicht, nicht фашист» дип тамак төбеннән чыккан тавышы колак төбендә аермачык булып янгырады. Кул мускуллары, бармаклары тагын бер тапкыр кинжалның муен мускулын тишеп үтүе, бугаздан кан ургылуы, немецның бу хәлгә ышанмау катыш газап белән зур булып ачылган яшел күзләренең күккә багып хәрәкәтсез калуы, уң як каш өстендәге миненең ике тапкыр тартышып алуы тагын бер тапкыр күз алдыннан үтте.

Мәрдән тораташ кебек катып калды. Дина кинәт куллары белән йөзен каплап, бөгелеп-бөгелеп елый башлады, чәчләре дулкын булып иннәренә ишелде. Мәрдән чарасыз булып калтыранган бу юка гына гәүдәне кочакларга теләде. Александр үкереп елап жибәрде, Мәрдән улын кочагына алды. Ләкин Дина:

—Nicht, кагылма, тимә балага. Ерткыч, кит, югал, үтерүче, үтерүче,—дип чигенә-чигенә ачыргаланып кычкырып, Александрны күтәреп хутор ягына йөгерде.

Бу хәлдән соң алар арасында салкын таш стена калыккандай булды. Дина башын иеп, Мәрдән ягына әйләнеп тә карамыйча, эшләде дә эшләде.

Иоганн карт белән карчыгы, Дина белән Мәрдән арасында ни булганын сорашып-сорашып та, барыбер белә алмады.

Үзәкләргә үтәрлек төнге гыйнвар жиле казарма тәрәзәсе артында улый, елый, ыңгыраша иде.

Мәрдән шул жилгә колак салып йокылы-уяулы халәттә изрәп ята. Оеп киткәндә төшенә туган авылы, шәм кебек ап-ак каусәле, яшел шәлле каенлы таулары, тау астыннан чылтырап тибеп яткан ширбәтле чишмәләре, шул чишмә суына көянтә-чиләкләре белән суга килгән Дина керә. Тезгеннән тотып, ат эчереп торган үзе дә кебек, ат өстендәге орчык малай—зәңгәр күзле Александр да кебек, бер карасаң Барые да, имеш, аһ, ул да түгел, муены сынып инбашына авып төшкән белорус малае икән ич. Ул куркып уянып китте.

Озак йоклый алмый ятты, тагын оеп китте.

Дина белән Александр тегермән буасында суга бата башладылар, имеш, Мәрдән баланы коткарырга тырыша, йөзә, аларга таба ишә башлады, тик нидер аның үзен су астына тарта, өстери, тыны кысыла.

—Тревога, подъем!—дип кычкырды кера-керешкә часовой.

—Әйберләрне жыярга, 15 минут сезгә, шатланышыгыз, стариклар, туган илгә, Россиягә, эшелон сезне көтә!

Мәрдән бу көннең кайчандыр киләчәген белә иде. Икеле хисләр белән көтә иде ул аны. Ләкин бу тиклем көтмәгәндә һәм бу хәтле тиз арада булыр дип уйламаган иде. Иртәнге дүрт. Казармадан ул иң соңгысы булып чыкты.

—Вася, шушы фотоаппаратны Динага тапшырырсың инде,—диде ул.

—Анлыйм, брат, минем эшелон әле бусы түгел. Хәзер үк илтермен.

—Юк, хәзер түгел. Соңрак илт, эшелон кузгалгач...

...Бар дөнья шавын басып, үзәкләргә үтәрлек әрнү, өметсезлек, фаҗига белән тулган хатын-кыз тавышы бер мизгелгә генә вокзал шавын күмеп китте.

Nicht! Нет! Нет!

Тарихта булып үткән яки булачак бөтен сугышларга каһәр укып, аталыдан атасыз булган баласын күкрәгенә кысып, чәчләрен җилгә чәчеп, эшелон артыннан бер хатын йөгерә.

Милләте кем аның, сәясәткә мөнәсәбәте бармы, нинди телдә сөйләшә ул, дине нинди аның? Кем генә булса да, ул сугышка каршы, ул бары тик имин илдә, тыныч, тулы гаиләдә, ир хатыны булып яшәп, дөнья киләчәген дәвам иттерергә теләүче гади хатын гына. Сугышка ләгънәт укып, перроннан, сугыш эшелоны артыннан мәңгелек хатын йөгерә.

***

Үлем бугазыннан алгач та Мәрдәннең һаман күз алдында балалары басып тора кебек тоелды. Беренчесе, икенчесе, өченчесе, хәтта үзе янына чакырып торучы Барые да. Ә Александр?

—Кызым, кызым, Диана,—карт оныгының кулын кулларына алды, аның учына нечкә генә көмеш чылбырга эленгән кояш ярчыгы тамчысын хәтерләткән гәрәбә ташлы медальон салды һәм саташу катыш пышылдады:—Кызым, тиз бул, капка кагалар. Капкада кеше бар... Ачыгыз капканы, ачыгыз... ач...

*2010 ел.*



## Рим Идиятуллин

# КАЙТУ

***

**...Һәм утырдым тузган нигезгә;
Аңлап булса телен ташларның,
Ефәк кенә җилләр искәндә,
Дастан көйләр иде ул безгә.**

**«Чабаталы морза» бабамдыр,—
Маңгай тирен кагып алгандыр,
Башын чөеп күккә карагач,
Язмышларны юньгә юрагач,—
Ташны ташка тегеп салгандыр.**

**Тукталмаган җирдә сугышлар,
Көйрәп яткан сыйнфый ызгышлар.
Гаҗәп!
Ул чакта да шулай өздереп,
Үләннәрнең башын идереп,
Сайрадымы икән бу кошлар?!**

**Тынмаган ич җирдә сугышлар!—
Онта булган күпме язмышлар;
Мүкләп өлгермичә бурасын,
Яуга чапкан әткәм дә авып,
Ашлап ята Балтик туфрагын.**

**Бездән Кояш кала, Ай кала;
Җилфер гәүдәм җилдә чайкала.
Көн белән төн тора карашып;
Әйтерсең, мин озак адашып
Өен көчкә тапкан бер бала...**

Рим ИДИЯТУЛЛИН (1940)—*Башкортстанда (Уфа) яшәүче татар шагыйре, «Хәерле иртә», «Хәерле көн», «Хәерле кич» һ. б. китаплар авторы. Татарстан мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Һ. Такташ исемендәге премиясе лауреаты.*

**...Утырган да туган нигезгә,**
**Яшен түгә шагыйрь бахыры,**
**Күрми беркем,—**
**Дөнья дөм сукырдыр ахры...**

***

*Авыл—йөрәктәге мәңгелек давыл!*
Фоат Садриев

**Аһ, чәчкәләр үлгән... кипкәннәр;**
**Кайтканнар ич тәки киткәннәр,—**
**Түр зиратка кереп ятканнар;**
**«Нихәл!» диеп күзгә карап тора**
**Гасыр күрешмәгән якташлар.**

**И җиләкләр монда! Чыктай чиста,**
**Саркып торган кандай—кып-кызыл;**
**Җиләкләрне күзләп ятар өчен**
**Кичкәннәрдер, аңлыйм, озын юл.**

**Кайткан алар мәңге туң тарафтан,**
**Сәхрә җирләрдән дә, ни хикмәт?!**
**Төшләренә кереп җирсеткәндер,**
**Күкрәгенә терәп, Әнкәйләре**
**Елмаеплар кискән ак икмәк.**

**Бакчы, Ана кысан гүрендә дә**
**Бер ялгызы түгел асылда:**
**Баш баласы ята баш очында,**
**Ә төпчеге—аяк очында...**

**Шундый ымсындыргыч җиләк. Юк, юк,**
**Балачактан сеңгән: ярамый!**
**Сез бәхетле, бәлки...Кайгы-хәсрәт**
**Әрвахларга инде янамый.**

**Йөрәк кузын атар идем суга!**
**Их,**
**Корып беткән икән агымсу.**
**Кай якларга илтеп ташлар безне**
**Алга карамыйча алгысу...**

**«Аяк аста—оҗмах!» дисәләрме,**
**Кем еракка китәр эзләргә?!**
**Туган туфрак!—түнгән баш очыма**
**Әнкәм салган мамык мендәргә**
**Бигрәкләр дә охшаш.**
**(Соң шул аңларга.)**

***

**...Тетрәтте гел каудыр гомеремне**
**Синдә булган алтын сабырлык;**
**Сакладыммы аны бәлзәм итеп—**
**Типкеннәргә дучар хәсрәтленең**
**Күз очына кырып салырлык?**

**Яктыртты гел гомер сукмагымны**
**Кәүсәр чишмәседәй күңелең;**
**Кичәгемне кичтем, оныкларны**
**Үптем, гөлең исән; тик ниләргә**
**Жанга жылы өрми бүгенем?!**

**... Әнкәм!**
**Чүгәләп мин синең каршыңа,**
**Тигезәм кул кыршыл ташыңа.**

***

**Әйтә Гайса Инжил үбеп:**
**«...Үкчәмә үк минем басып,**
**Гаярь буын килер кебек...»**
**Юк шик!—**
**Бикле булса ишек-тәрәз,**
**Моржа аша керер карак;**
**Үлемтеккә дигән малың**
**Талап алып, кыяр жаның,—**
**Гаярь буын тормас аяп...**

**«...Бөртек орлык жимеш бирер**
**Үзе тәмам череп бетсә...»—**
**Дип кабатлыйм хак Тәүратны;**
**Ай-һай!—**
**Махмыр хаким сөреп илне,**
**Йөз бөртек бай-хәшәрәтне,**
**Борча итеп, чәчте жиргә;**
**Череме дә лә үзләре!—**
**Ил череде, корып лары...**

**Ак хыяллар күп Коръәндә:**
**«...Илегездә шат көнегез—**
**Аегыз күк тиелгесез...»**
**Амин!**
**...Ил капкасын какты берәү,**
**Жаны авыш, кирәк терәү;**
**Түрдән әмер атты түрә:**
**—Әнә арба, анда нужа,—**
**Сукранмыйча гына сөйрә!..**

**...Шөкер кылам: бүгеннәрдә**
**Шагыйрь теле түгел бәйдә,**
**Әйттем исә кайттым мин дә,**
**Бизгайбә!**

***

*Хакыйкать атамнан кадерлерәк.*
(Петр Чаадаевның бер сүзен үзгәртеп)

**...Манара күк очлы таулардан**
**Томан ертып килә Исрафил*:**
**—Әйт, адәмчек! Бу ил—нинди ил?**

**—Ахмаклар иле.**
**Тәннәрендә жан бар әле,—**
**Рухлары үле.**

**—Ни саласың сүзләреңә?**
**Күзләрендә якты күрәм,**
**Балкыш шәйлим йөзләрендә.**

**—Күрәмсеңдер!—Алма пешкән:**
**Төскә матур, черек эчтән;**
**Шашты адәм бозыклыктан,—**
**Кызару юк оят эштән;**
**Курыкмыйлар Күктән... күптән.**
**Ә күргәнең—элеккенең**
**Уңып беткән эзе генә.**

**...Җилләр кисеп килә Исрафил,**
**Каршысында калтыр мосафир;**
**—Әйт, бәндәләр кая йөгерә?**

**—Бу кавем—иртәгесезләр;**
**Табыналар тик бүгенгә,**
**Шәүләләрен тотмак булып,**
**Җиттеләр җиде буынга.**
**Хәер, куып тотарлар да,—**
**Шуа Кояш әнә баюга...**

**...Дулкыннарның сыйпап ялыннан,**
**Үле диңгез кичте Исрафил;**
**Кара өер—Ходай балчыгы,**
**Бөкте билен балчык башлыгы.**
**Күк илчесе атты күз угын:**
**—Ә ник сайрар кошлар оялар**
**Агачларга кунган бу картлар?!**

**—Егәре бар кала тотынып,**
**Арыкларын җиргә коялар,**
**Бай тирәкне* яман селкетеп;**
**Яңарттык без кыргый горефне.[1]—**
**Тиккә яши алар гүр көтеп...**

**... Кара гөлнең басып башына,**
**Уйлар уйлап торды Исрафил;**
**Исле һава эчкәч бер йотым,**
**Салкын тынын сипте иренгә:**
**Ахры, бозлы хәбәр бирергә...**

---

[1] Кыямәт көнен ирештерүче фәрештә; адәми затлар; ата-баба утырткан нәсел агачы; борынгы Африка кабиләсендәге кыргый йола: тотынып тора алганнарын исән калдырганнар.

Әхәт
Мушинский

## ҺАВАЛАРДА—АК КҮГӘРЧЕН...

РОМАН

Вакыт төшкә таба якынлаша. Күк буенча җинел болытлар йөгерешә. Без Немец Швейцариясенең иң мәһабәт тау түбәсенең бер кырыенда утырабыз һәм бертуктаусыз ни турындадыр лыгырдыйбыз. Нәрсә турында? Әй, монысы мөһиммени? Башкасы хәтердә калды һәм күнелдә сакланды: гадәттән тыш биеклек һәм безнең алда җәелгән чиксез кинлекләр, гаҗәеп рухи тынычлык һәм гүзәллек белән гармонияне беркайчан да кабатланмаслык итеп тою хисе. Бу хис гади һәм акыллы, ул кешегә, әгәр, гомумән, бирелсә, бер генә тапкыр бирелә торгандыр, ул аның бөтен тормышының алтын кисеме булып торадыр, мөгаен. Әле алда югары күтәрелүләр дә, башка, аннан да югары күтәрелүләр дә булыр, чөнки гомер озын бит... Тик аның менә мондый чисталыгы гына булмас инде. Шул ук кешеләрне җыйсаң да, шул ук тауга менсәң дә—барыбер булмас! Үзем дә күптәннән андый түгел: килеш-килбәтем белән, бәлки, җитдирәк, намуслырак булып калганмындыр, ә менә, нишләмәк кирәк, гомер юлы буенча атлаганда өскә шактый гына тузан да кунды.

Ләкин барысы да ничек агучан һәм үзгәрүчән! Әле моннан бер минут элек кенә бал эчтем сыман, күңел тулышыннан шатланган-сөенгән идем һәм менә хәзер, кинәт кенә дегет чөмердем шикелле. Мин кисәк кенә бу кызның мине түгел, ә башканы сөюен аңлап алдым. Моны аңлавы авыр түгел иде. Мин нәрсә турында гына сөйләсәм дә, нәрсә генә тәкъдим итсәм дә, нинди генә үткен сүзләр әйтсәм һәм акыл сатсам да—барысы да алар колагын читләтеп үтә торды. Алар миңа күз буяу өчен генә баш каккан булалар, ә чынында бары тик бер-берсен генә ишетәләр һәм күрәләр. Мин моны үземнең акылым белән төшенеп алдым да, мәхәббәт уеннары вакытында ике көпшәдән дә берьюлы атылган суер шикелле тынып калдым.

Алар сизмиләр дә. Алар төрле юк-бар турындагы сүзләрдән челтәр бәйли. Һаман шул Шәех әлегә тикле төзәтмәгән «Альпинист» турында... Ләкин күзләре сон! Күзләре аларны баш-аяклары белән сата.

Миңа торырга да, нининдидер сәбәп белән моннан табанны ялтыратырга кирәк иде дә, ләкин мин китмим. Мин үземне чиксез артык кеше итеп сизәм, алай да авызыма үлән кабып, Бөкре күпердән Ленин күперенә хәтле аккан елганың салмак агымын күзәтеп, кузгалмыйча тик утыра бирәм. Ул теләсә нинди һава торышына, кәефнең ничек булуына карамастан,

*Дәвамы. Башы узган елның 12нче санында*

карашны әсир итә һәм уйларга тарта. Казансу елгасы өстеннән әле Постник Яковлевның үзе тарафыннан күтәрелгән мәһабәт Спасс манарасымы, Благовещенск баһадирымы, кызыл кирпечтән салынган бердәнбер легендар патшабикә сыман нечкә, сылу, үзенең Пизан туганы шикелле бер якка авышкан, марсиан ракетасы сыман күккә ашкан Сөембикә манарасымы,— болар барысы да безнең шәһәрнең вакытка бирешми торган җимерелмәс нығытмалары. Болар барысы да йөз ел элек тә шулай булган, хәзер дә шулай һәм тагын йөз елдан соң да шулай булачак.

Аһ, шул чактагы ялгыз минутларымда мин мәңгелек белән якынаерга, җирдәге минутлык вак-төякләрдән арынырга ничек теләгән идем!

Ләкин арынып булмады.

Әтәчне санамаганда, шулай өчәүләп кире кайтып киттек. Хәер, бәлки, мине дә санамаска кирәк булгандыр. Әнә хәтта әтәч, йоны йолкынасы бу җан да үзенең сары күзләре белән миңа буш урынга караган сыман карап тора.

Мин Шәехтән көнләшмәдем. Аны бүләкләгән Юлия карашыннан, минем уйлавымча, мыскыллы көлү сизелеп тора. Ул аннан көлә иде. Мин моның, күп малайлар шикелле, яшерен явызлыктан түгел, ә кызыксынудан икәнен аңлый идем. Алай да кешеләр гадәтләнгән кабыктан чистартылган бер үк нәрсәгә төрлечә карыйлар бит. Берәүләр рәхәтләнеп аны яңадан кире кабыкка кертергә, кабул ителгән гомуми нәрсәгә төрергә-киендерергә омтыла, икенчеләре икеләнеп-шикләнеп кала: янәсе, бу нинди фрукт һәм аны ни белән ашыйлар? Өченчеләр, азсанлылар, моңа кызыксыну белән карыйлар, үз куллары белән тотып-капшап карарга телиләр.

Менә Юлия дә аны үзенчә җәзалый иде. Миңа шулай тоелды, ул минем дустым белән дә туйдырганнан соң ватык һәм эче актарылган килеш ташларга да мөмкин булган курчак белән уйнаган шикелле уйный иде. Ул, мәсәлән, сөйләшүне ярты сүздә бүлеп: «Менә шушы күпер култыксасы аша үтә аласыңмы?»—дип сорарга да мөмкин... Күпер бик тә тирән чокыр өстеннән салынган, аннан аска таба каравы да куркыныч. Шәех, уйлап та тормыйча: «Бик ансат кына үтә алам, ләкин моны расларга җыенмыйм»,— дип җавап бирде. Көлке. Ир-атлар болай сыналмый. Ләкин инде кыз күренмәс күңел кыллары белән уйный белә, аңа өйрәнгән иде. Ахырда Шәех, тотып торырга дип әтәчне миңа сузып, инде култыксага сикереп менәргә дә җыенган иде, кинәт Юлия: «Шаярттым гына бит мин, синең битеңә акка кара белән язылган акылсызлыгыңда шигем юк»,—дип көлеп җибәрде...

Бу миңа ошамады. Кызның авантюрлыгы да, Шәехнең моны күңеленә якын алуы да. Әйе, мин Юлияне ярата идем. Ләкин миңа Шәех тә бик якын иң. Һәм мин, мөгаен, кызны аңа, аны кызга караганда азрак көнләшмәгәнмендер. Ниндидер юк кына кыз безнең дуслыкка чөй каксынмы, минем дустымны тартып алсынмы?.. Гафу итәсез, була торган эш түгел бу!

Әгәр дә безгә шунда Галя очрамаса, белмим, ул чакта йөргәндә мине бер чиктән икенче чиккә тагын күпме ташлаган булыр иде икән. Кызлар бер-берсен очратуларына бик тә шатландылар, култыклашып алдылар һәм киттеләр... Шәех белән без алар өчен икенче дәрәҗәдәгеләр идек инде.

Нишләмәк кирәк, без бераз арткарак калдык. Менә шунда алар янына Жбан белән Киләле килеп чыкты. Кызлар безне эзләп тирә-юньгә каранды. Шулчак мин дөньясын оныткан Шәехкә төртеп алдым. Миндә ниндидер икегә аерылып калган хисләр барлыкка килде, әйтерсең эчемдә ниндидер бинокль яхшы күрә торган итеп көйләп куелды: безне эзлиләр, димәк, без аларга кирәк.

Аларны куып житкәндә Жбан Юлиянең битеннән кем шундый дәрт белән үбеп алуын ачыклап маташа иде. Безне күреп, ул:

—Менә бит алар, гусарлар!—дип көлеп куйды.

Без жавап кайтармадык, тыныч кына яннарында атлый бирдек.

—Юк, син күрденме, Киләле,—дип дәвам итте Жбан, тегенең кабыргасына төртеп, дустының игътибарын тартып,—Шәех верхолаз икән бит, акроба-а-ат!

—Шулай булмый соң!—дип килеште Киләле, иптәшенең каты итеп төртүеннән читкә тайпылып. Һәм әтәчне чакыра башлады:—Чеп-чеп-чеп!

Аларның кыланмышлары ике төрле уйларга урын калдырмый, барысы да өстә ята иде: Анатолий Жбанов, башка күпләр кебек үк, Юлиягә карата, «ашкынулы дәрт» белән яна иде. Равил Гарипов, ягъни Киләле бик елгыр дипломат булмаган, бер үк вакытта Юлиягә дә «ябышырга» теләгән, бу мәсьәләдә шулай ук аның абыйсы Пичуга белән дә мангайга-мангай килүдән качарга тырышкан дусты Жбанны гел хуплап тора. Жбановның мәхәббәт проблемаларыннан Киләлегә кызык кына. Ул безнең арада бертуктаусыз хехелдәп көлүче берденбер кеше иде. Ул бит бездән дә көлә. Бу минутта Шәех белән без чынлап та гусарга түгел, ә күбрәк кызарган гимназистларга охшый идек. Хәл югары дәрәҗәдә ахмакларча иде: сугышып та булмый, түзеп торуы да авыр.

Хәер, нинди сугыш турында сүз була алсын? Әгәр дөресен генә әйткәндә, шушы көнгә хәтле минем бер сугышуда да катнашканым юк әле. Шәех тә шулай. Ул үзе белән кемнедер каплап калырга, араларга, кем өчендер утка керергә мөмкин, ләкин йодрык белән башка кеше йөзенә сугу дигәндә—юк, ул моны булдыра алмый иде.

Тик бер Юлия генә ваемсыз күренде. Ул Жбан белән Киләленең үткен сүзләрен кире кага тора, үзе көлә. Ә Жбан ничектер болай гына, очраклы гына килеп чыккан сыман, җиңнәрен иңбашына тикле диярлек сызганып куйгач һәм, янәсе, теләмичә генә үзенең шар шикелле мускуллары белән әле генә ничек итеп күрше районнан килгән ике малайны мәктәп ишегалдында кыйнап ташлавы турында мактана башлагач, Юлия, аннан да ваемсызрак итеп, менә әле хәзер генә аның үзен бер кечкенә генә егетнең ничек итеп күтәреп алуы һәм аны аркасына китереп салуын күрүе турында әйтеп куйды.

Жбан кирпеч шикелле кызарып калды. Ә күзләре белән гаҗәпләнгән булды: кайчан, янәсе?

—Әле менә моннан сәгать-сәгать ярым элек кенә,—дип хәтерләтте аңа Юлия.—Без Галя белән күләм янында ук утыра идек. Теге егет кисәген көрәшче дип әйтерлек тә түгел—чикерткә кебек кенә. Ләкин шундый житез ул... Менә, чыннан да, кечкенә дә төш кенә инде!.

—Беләм мин аны, еланны,—диде Жбан хурлыклы рәвештә калтыранган тавыш белән,—беләм, «Динамо»да иректә көрәш белән шөгыльләнә ул. Ә син нигә авызыңны ердың әле, шакшы су чокыры сыман?—Монысы күңеле күтәрелеп киткән Киләлегә әйтелде.

—Син нәрсә, Толян, мин бит бөтенләй башка нәрсә турында.

—Бөгештермә...

—Һичшиксез!—Һәм шунда Киләле заговорчыларча жәйге туңдырма кафесы ягына таба ымлап куйды.—Кара әнә, терәгеч янында...

Верандада терәк багана янындагы өстәл янында Александр Пичугин ут сыман жирән гүзәлкәй белән салкынайтып жибәрә торган эчемлекләр белән ләззәтләнеп утыра иде. Ул, матур хәрәкәтләр ясый-ясый һәм үзенең бодай сыман чәчләрен мангаеннан артка таба ташлый-ташлый, нидер

сөйли. Минем аның менә шундый илһамлы, бәхетле, малайларча ачык итеп елмайган чагын моңарчы беркайчан да күргәнем булмады. Бернинди тәкәбберлек, бернинди меланхолия дә юк иде анарда.

Минем аны элек тә төрле кызлар белән очраткалаганым булды. Ул аларны перчатка шикелле алыштырып тора, ә үзе бер дә алышынмый. Ә монда... Без гаҗәпкә калдык. Минем исемә аның мәктәп ишегалдында футбол уйнаганда уен бозылганнан соң мизгел эчендә боек, чытык йөзенең ничек яктырып, тормыш җанлы булып киткән вакыты исемә төште. Дөресрәге, йөзе бик нык үзгәреп калды ул чакта. Ләкин бу тормыш дигән нәрсә белән бергә шулай бит. Ә тормыш дигәнең якты дөньяга төрлечә тишелеп чыга шул ул...

Мин аның кем алдында шулай акыл сатуын күзләдем дә гаҗәпкә калдым. Кыз аннан шактыйга олырак иде. Кыз да түгел иде ул, ә чибәр, үз бәясен үзе белә торган күркәм ханым. Мин таныдым аны. Ул безнең ишегалдында, фармацевтика училищесы артында яши. Минем аны еш кына шундый ук җирән сигез-тугыз яшьлек укучы кызы белән йә «Бригантина» кибетләрендә, йә базарда күргәнем бар.

—Беләсеңме син аны?—дип пышылдадым мин Шәехкә.

—Беренче мәртәбә күрүем,—диде ул. Шәех күзәтүчәнлеге белән әлләни аерылып тормый иде.

Дама кашыктан тундырма ялый һәм авыр, калтырап-дерелдәп торган керфекләре астындагы ачык карашы белән бертуктаусыз Пичугага карап-карап алгалый. Ә без исә аны күзәтәбез. Жбан белән Киләленең дә бу җирән гүзәлне беренче генә күрүләре иде бугай.

Ә Юлия ничек? Ул кашын да селкетмәде, әйтерсең җирән ерткычның күзләре аның абыйсына карамый.

—Мен-нә Сашок!—дип куйды Жбан, бөтен йөзе белән балкып.—Кәефләнә! Булдыра бит, шайтан! Әйдә барып килик әле,—диде ул Киләлегә кагылып. Һәм дуслар тундырма кафесына таба атлады. Киләле, бераз баргач, борылып карады, янәсе, без дә килмибезме? Юк, без үз юлыбыз белән китеп бардык. Юлия белән Галя шулай ук алдан, Шәех белән без—алар артыннан.

Озак йөрмәдек, аяклар безне үзләре үк парктан Алмалыга алып чыкты. Башта безнең ишегалдына кайттык, астан күгәрченнәр кетәгенә карап тордык. Шәех күрсәтер өчен эскадрильясын куып чыгарырга теләгән иде дә, ләкин шунда Юлия, өйгә кайтырга вакыт, безне озатырга кирәкми, диде һәм барган җиреннән артына борылып:

—Шәех, Ренат, яхшы малайлар сез,—дип кычкырды.

### Кияү

Кызлар белән саубуллашып, без әтәчкә яна яшәү урыны билгеләү өчен китеп бардык.

Төштән соң безнең сарай кабарып торган зур ябалдашлы канәфер агачы һәм ишегалдында ялгызы гына биек булып калкып торган (куаклыклар исәпкә керми) алыптай нык имән күләгәсенә яшеренә. Шуңа күрә, әгәр Шәех резиденциясендә иртәләрен кояшлы һәм җылы булса, төштән соң, кояшның иң кыздырган чагында, монда салкынча. Сарайның безнең өлеше стена аркылы гына (Шәех белән монда да күршеләр идек), ләкин мин үзебезнекендә озак булмыйм, чөнки анда бернинди яхшы нәрсәбез дә юк диярлек. Бары тик утын әрдәнәсе дә төрле иске-москы, хәтта велосипед та көчкә сыйды анда.

Ишектә Рәшидә апа күренгәндә без такта ятакта, аның кушуч киндер

белән ничек туенганын күзләп, әтәчнең киләчәк язмышы турында уйланып утыра идек. Аның шулай көтмәгәндә килеп чыгуында гаҗәпләнерлек берни дә юк иде, чөнки ул һәрвакыт шулай килеп керә. Тик бу юлы аның күзләрендәге күнелле, ниндидер тере ялтырау сәер тоелды. Җитмәсә, элек бер дә булмаганны, иреннәрен дә буяган иде. Ул бөтенләй усал итеп түгел, ә йомшак кына тавыш белән безнең кайда югалып торуыбыз турында сорашты, бушка килгән әтәчкә тыйнак кына сөенеп алды, аның токымлы, итләч икәнен билгеләп үтте һәм Шәехне өйләренә чакырды. Ул, дәшмичә генә буйсынып, сараен бикләде дә без аерылыштык. Мин, карлыган куаклары арасында күренеп-күренеп киткән әнием яулыгын шәйләп, бакчага юнәлдем.

Соныннан беленгәнчә, минем дустымны өендә көткән вакыйга белән чагыштырганда, ул көннең бик ачык, зур вакыйгалары да шул кадәр үк әһәмиятле булмаган икән.

Эш шунда, Рәшидә апаның инде күптәннән кияүгә чыгарга теләге бар иде. Аны яхшы белгән һәркем, шул исәптән минем әти-әни дә, мондый адымның зарурилыгына ышандырырга тырышты. Инде үлгән ирен теге дөньядан кире кайтарып булмый, ә тормыш дәвам итә бит. Малайны да аякка бастырасы бар. Хәтта бу мәсьәләдә минем әнинең төгәл генә уе да бар иде: нигә еракка барып йөрергә, янәсе, менә бит Николай Сергеевич—ишеге кухня аша гына, бик тә җайлы-унайлы кеше, үзе бер мәртәбә дә өйләнмәгән. Алтынчы дистәне ваклый башлаган икән, зарар юк, аның каравы ул фәнни кеше, астроном, хуҗалыкта да юк-барга тыкшынып йөрмәс, димәк, тулы иреклек булыр дигән сүз. Рәшидә апа моның ише сүзләргә колак салгалады, бәйрәм көннәрендә бу ялгыз күршесенә пироглар да кертте, ә тегесе күчтәнәчләрне дулкынлана-дулкынлана кабул итә торды, ләкин читләтеп әйтелгән кинаяләрне дә, турырак әйткәнне дә һич төшенә алмады. Аның мәхәббәт белән дәрте башкарак якка карый иде бугай. Аннары аның белән сөйләшкәндә «перипетия» белән «перепития»не бутаган, Сервантес «Тонкий ход» дигән китабын уныш казану өчен язган дип санаган Рәшидә апага авыр да иде.

Тора-бара ул яртысы үзенеке, яртысы башкалар тарафыннан тагылган бу уеннан кире кайтыр дип тә уйларга мөмкин иде. Ләкин әйтегез, бу дөньяда хатын-кызның җан көчен бөтен тирәнлеге белән кем үлчи алган? Өермә тынган һәм инде су өсте тынып та калган кебек, юк шул, су асты агымнары бар икән бит әле, алар кайный, ташларны кайрый, үткенли...

Диваннары башындагы мендәрне ярым кочаклаган хәлдә анда таныш булмаган ир-ат утыра. Бу Шәехнең булачак үги әтисе икән. Гәрчә әнисенең кияүгә чыгу мөмкинлеге турындагы сүзләр (алар дустымны ярсытып һәм үз-үзенә йомылырга мәҗбүр итеп, арканат кебек кыштырдап, өйдә очып йөрде, йә шаяру-такмазаларда ачыктан-ачык янгырый иде)туктамаса да, Шәех әле ул чакта моны бик төшенеп җитмәгән булган. Үги әтисе белән беренче очрашуы турында Шәех миңа соныннан тулы итеп сөйләп бирде.

—Карыйм мин аңа һәм һич кенә дә аңлый алмыйм,—диде ул,—эчемне ниндидер нәфрәт, куралмау хисе тырный. Карап торырга болай үзе гадәти ир-ат шикелле, гарип тә түгел, матур да түгел. Тик тамырлар челтәреннән бите генә кызылаеп калган. Бер уйласаң, шуннан ни булган инде, йә? Ә менә булдыра гына алмыйм бит... Хет кис, хет ас—ошамый ул миңа!..

—Аңлашыла,—дидем мин, яңа әти алып кайтканга кем шатлансын?

—Ю-ук... Алай түгел. Мин бит әле башта бу турыда берни дә төшенеп җитмәгән идем.

—Алайса нәрсә соң? Утыра бирә кеше, тешләми, синең белән сөйләшә...

—Гел рус телендә сөйләшә. Ә үзе... Ә үзе—Гайнан Фазлыгалләмович.

—Шуннан ни булган, хәзер барысы да русча, беләсең, ничек сибәләр!

—Аның каравы, ишетсәң икән, татарчасы—«миннән киткәнче, хуҗасына җиткәнче», анда да түбәнновгородлылар кебек «о» ны сузып сөйләшә. Аның яшендәгеләр туган телләрендә сүзләрне чиста итеп әйтәләр. Яисә үзләренчә бөтенләй сөйләшмиләр. Ә үзенең исемен болай дип аңлатты: «Гайнан,—ди,—дөрес, чын дигәнне аңлата». Карап торам мин аңа һәм эчемнән, нишләп гел ачуым килеп тора икән соң әле үзенә, дип уйлыйм. Аңа күзләремне акайтып-акайтып карыйм... Менә эш нәрсәдә икән: аның күзләре төрле якка сибелгән...

—Ничек инде ул?!

—Төрле якка карыйлар. Менә кылый күзлеләр бар, ә моның ничектер киресенчә: берсе чәршәмбегә, берсе дүшәмбегә караган. Аларның кайсына карарга да белмисең. Аннары борынының ике күз арасындагы өлешенә карап бактым. Нишлисең, читкә карап утырып булмый бит. Ә ул сибәмсең сибә! Тавышы аның, дөрес... Левитанныкы дип белерсең: а-ля-мафо, мадера-фигус-краба!

—Ә болары нәрсә тагын?!

—Белмим. Ул шулай ди.

—Французчамы икән әллә?

—Белмим, дим бит.

—Әллә сүгенүеме?

—Шайтан белгән аны!

Алар кара-каршы утырганнар һәм Шәех әллә кая китеп юкка чыккан әнисе югында түземлелек белән «фронтын да, тылын да, үлемен дә һәм ачлыгын да күргән» кешенең акыллы уйларын түземлелек белән тыңлап утырган. Кунак үзен бик иркен, үз кеше сыман тоткан. Тиз-тиз генә сораштырган, ярты колагы белән генә тыңлаган, күбрәк үзе сипкән: бу-бу-бу. Шәех әйтмешли, аның тавыш моторчыгы бик түбән ешлыкта эшләгән.

—Сиңа ничә яшь дисең? У-у, ир-ат инде!.. Ә камин сөрәме? Аның каравы нинди матур—а-ля-мафо-мадера-фигус-краба! Ә мин, туган, отставкадагы майор. Хәрби майор. Нәстә авызыңны ерасың? Сугышны үттем, сугышны-ы! Кисәсеңме, хәрби майор тыныч вакыттагысыннан ни белән аерыла? Дөрес уйлыйсың, гәрчә дәшмисең, погондагы минем йолдыз бер тоннага авыррак.—Ул үз сүзләреннән үзе үк көлемсерәп куйган һәм үзе дә сизмәстән уйларга чумган. Аннары уянып киткәндәй булган:—Ә? Нәстә?

Шунда Шәехнең әнисе кайтып кергән. Күзләре җанланган, йөзе кызарган. Шундук: «Редиска, суган үзебезнеке, Алла бирсә, кыяр белән помидорлар быел да унар, чөнки көннәр бик яхшы тора»,—дип сөйләнә-сөйләнә өстәл әзерләргә керешкән. Ул татарча сөйләнә, ә кунак алай да, болай да. Шәех төрле салатлар, бәлеш янында сырлы, зур авызлы стаканнар һәм ярты литрлы шешә пәйда булганын сизми дә кала.

—Гайнан Фазлыгалләмович, үзегез боерыгыз!—ди әнисе, шешәне аңа табарак этәреп.—Әз генә йотып, кабып алыйк, аннары сөйләшербез... Тиздән шулпа да өлгереп җитә. Улым бигрәк тырышкан, шундый кучтәнәч алып кайткан... Кастрюльдә чиста кояш эри сыман...

Шунда Шәех урыныннан күтәрелгән дә:

—Нинди кояш?—дип сораган.

—Рәхмәт инде, улым, рәхмәт!

Шәех тиз генә ишеккә таба юнәлгән.

—Син кая?

—Хәзер...—дигән дустым һәм чыгып киткән. Кухня аша, кастрюльдәге

«янган кояш» белән минем яннан йөгереп үтте ул.

—Әй, псих, кая ычкындың әле?—дип сорадым мин.

Ул җавап бирмәде. Текә баскыч буенча тыпырдап узды да—үзенә, сарайга. Анда, күгәрченнәр кетәгенә менә торган урын астында аны хуҗасыз калган ялгыз бау белән чәчелгән киндер генә көтә иде. Ник бер каурый кисәге булсын!

Шәех түбәгә менгән дә кетәк артындагы куләгәлеккә килеп яткан. Ул әнисенең аны ничек чакырганын, аста, сарайда эзләгәнен ишетеп торды, әлбәттә, аннары Рәшидә апа бакчаларына кереп чыкты, тагын ишегалдына әйләнеп кайтты, урамга күз салды. Юк малае!

Мин Шәехкә:

—Сине әниең эзли,—дип кычкырдым.

—Беләм,—диде ул ваемсыз гына.

Без башка сөйләшмәдек. Мин помидор һәм кыярларга су сиптем. Шәех, бераз ятканнан соң, күгәрченнәрен очыртырга кереште. Таягы белән болганды, аның турманнары ничәшәр тапкыр мәтәлчек атканын санап, күзләрен кыса төште.

Әй, матур да инде бу кошлар! Күгәрченчеләр арасында нигәдер күренми алар хәзер. Аларны әле икенче төрле, катуннар, дип тә йөртәләр. Югарыга менәләр дә шар булып аска тәгәриләр. Тәмам җиргә төшеп җитәрәк кенә исләренә киләләр, аннары өерләрен куып җитәләр дә, тагын мәтәлчек ата башлыйлар. Хәтта кайчак тын кысыла: менә-менә имгәнерләр төсле тоела. Аларның баш аша яисә, дөресрәге, канат аша әйләнә торганнары бигрәк тә кызу, ашкынулы. Ләкин миңа барыннан да күбрәк «арткы сальто» ясый торган турманнар ошый иде. Очалар, очалар, башкалардан берни белән дә аерылмыйлар. Һәм кинәт койрыкларын җилпәзә итеп ясыйлар да, бар көченә очкан килеш туктап калалар, аннары шундук үзләренең җилпәзәләре аша артка таба әйләнергә тотыналар. Искиткеч манзара! Онытылудан бары тик әнинең муен төбенә менеп төшүе генә исемә китерә:

—Шулай авыз ачып карап торырсыңмы, әллә су сибәрсеңме?—ди ул.

Әнисе кунак белән баскыч төбенә чыкканда, Шәех үзенең гадәттәге «чи-чи-чи»ен кабатлый-кабатлый күгәрченнәре өерен кетәкнең алгы өлешенә кертеп ята иде.

—Менә бит ул!—дип кычкырып җибәрде Гайнан абый.—Ә без аны көтәбез, дулкынланабыз, ә ул—а-ля-мафо...—Кунакның болай да сөт шикелле булмаган йөзе хәзер Рәшидә апаның август аендагы түтәлләрендә (аның, авыл хатынының бакчасы һәрвакыт безнекеннән мулрак уңыш бирә) яхшы өлгергән яшелчәләренә охшый иде.—Ярар, сау бул диимме,—дип, үз-үзенә хәерле юл теләгәндәй, кулын югары күтәреп куйды ул һәм акрен генә көйләп җибәрде:—Очыгыз, күгәрченнәр, очыгыз!

Рәшидә апа өчен ул, бәлки, чыннан да күгәрчен булып тоелгандыр. Соңгысы, ахыргысы, шуңа күрә ак канатлы булып күренгәнедер. Кичен, ниһаять, Шәех өйгә кайтып кергәч, ул аны ачуланмады, хәтта әтәч өчен үзен бераз гаепле итеп тә сизде.

—Табыныргамыни инде аңа, бүген-иртәгә барыбер... Аша, улым, ашы бик тәмле.

Шәех йөзен чытып куйды.

Малаеның холкын белгәнгә, ул башка кабатлап тормады, чөнки әле алда аңа иң мөһим хәбәрен җиткерәсе бар иде. Шуңа күрә ул гадәттәге тормыш вак-төягенә кагылышлы сүзләр белән малаеның көйсезләнгән җанына күпер салырга кереште: һава торышы, бакча, үзенең исәпсез-хисапсыз авырулары һәм күптән инде аңа яңа чалбар сатып алырга кирәклеге, хезмәт куеп алган һәр тиеннең аңа зур авырлык белән генә керүе турында сүз башлады. Шулай

акрынлап-акрынлап аның авызында Гайнан исеме барлыкка килде.

Ул бик тырышып һаман бер үк пластинканы әйләндерде. Янәсе, Гайнан абыең урта кул кеше түгел, майор, тормышны ишетеп кенә белми, комнан бау ишә торган ир-ат. Һәм башкалар, һәм башкалар...

—Кем булып эшли дип беләсең? Циркта склад мөдире булып!

Шәех Юлиянең транзисторы белән маташа иде, аны бүлдермәде, иреннәрен бүтән турсайтмады, һәм әнисе, ниһаять, батырчылык итте.

—Улым, ничек тоелды соң ул сиңа?—дип сорады ул, бераз дәшми торганнан соң. Түземсезлек белән сорады:—Ошадымы?

Шәех ваемсыз гына:

—Кыз түгел лә мин: ошады, йә ошамады, дияргә...

—Аңлыйм мин, улым, ләкин алай да?

—Бәйләндең! Турысын гына әйт, ни телисең син, әни?

Әнисе кытыршы куллары белән алъяпкычын сыпырып куйды.

—Без синең белән күпме вакыт әтисез инде! Ә башкалардан ким буласы килми бит...—Ул карашын алъяпкычыннан алды.—Аның безнең белән бергә яшәвен телим...

Шәех әнисенең кайсы тарафка таба тартуын чамалый иде, тик аның соңгы сүзләре аны барыбер яралап алды.

—Ничек итеп?

—Синең яңа әтиең шикелле.

—Улмы?

—Ә нәрсә? Мине хәзер риваятьләрдәге Йосыф кызыксындырмый инде. Ир-ат ич ул... Беләм, тормыш җанлы хуҗа булачак ул.

Шәех күзләре белән әнисенә таба атты: хуҗа? Ләкин дәшмәде. Алай да әнисе аның карашына да ирек бирмәде:

—Фатирда торучы итеп түгел бит инде!

Шәех шөрепборгычын читкә куйды да кулына пинцет алды.

—Нәрсә авызыңа су каптың?—диде әнисе.

—Ә нишләргә тиеш ди мин? Котлыйм!—Ул пинцетын ташлады да бүлмәдән чыгып китте.

—Кая барасың?

—Николай Сергеевичка керәм.

—Анда сине бал белән сыйлыйлармы әллә? Сәгатьләр буе шунда, өйдә утырганың да юк. Шунда кун да, шунда яшә алайса!

—Шулай туры килер, мөгаен, яңа өйләнешүче яшьләргә комачаулап булмас бит инде.

Әнисе әле менә хәзер генә табак-савыт сөрткән чүпрәген эләктереп алды да аның артыннан ыргытты. Ләкин бу ачудан түгел, болай гына, соңгы сүзенең аныкы булып калуын сиздерү өчен генә. Аның һәр гамәл-эшендә яхшылык белән начарлык бер үк төрле чагыла иде.

## ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК

### Сары саквояж

Алтын сыман бөдрә чәчле кечкенә Николай открыткалар белән сары саквояжны Алмалыдагы өенә мең дә тугыз йөз унсигезенче елның август төненнән соң көндезен, баш күтәргән ак чехлар Казанга яшенле яңгыр коеп яуганда килеп кергән чакта алып килде.

Засыпкин урамындагы Забродин йортында күк күкрәү гөрелтесе һәм бертуктаусыз артиллерия атышларыннан кич буе тәрәзәләр зеңгелдәп һәм бүлмәләрдәге люстралар селкенеп торды. Ике туп якында гына, яр буенда шартлады. Икенче якта, күпер артындагы шәһәр тегермәне янында, кара,

дымлы һавага кара төтен көлтәләре ыргыта-ыргыта, амбар яна иде. Николай үзе йокларга тиешле ярым подвалдагы бүлмәсенең түшәмендә кызыл нур шәүләләре уйнавын күзләп ятты. Икенче катның тәрәзәсе яныннан аны куып җибәрделәр, өенә кайтып китәргә дә рөхсәт итмәделәр. Янәшәдә генә йокысыз бабасы мышный иде.

Федор Софронович Николайны—үзенең соңгы оныгын өзелеп ярата торган булган. Үз балаларын тәрбияләргә аның вакыты булмаган, аларны—кызы белән малаен әниләре, Марья Никитична—урыны җәннәттә булсын!—караган, ә монда инде гомере ахырында анда кинәт балаларны чиксез ярату хисе уянган. Федор Софронович оныгын, аның әти-әнисеннән сорап, төрле ял көннәренә, җәйге һәм кышкы каникулларга—Козловкага да, соныннан Засыпкин урамына да алгалаган. Менә шул елда да бөтен җәен, хәер, язын да, кечкенә Николай бабасында, аның Казандагы яңа йортында уздырды, адашып ерактагы Сыер күперенә хәтле житеп, елга яры буенда йөргән. Малайның сабыр-салмак ул йөрешләрендә аның яшенә туры килми торган сәер житдилек күзәтелгән. Ул мондагы бала-чагалар белән «лапта» дигән туп уены уйнамаган, казак-юлбасар булып та чапмаган, һәрвакыт уйчан булып, еш кына, таяк белән комга нәрсәдер сызгалап, үз-үзе белән сөйләшкәләп торган. Бабасы аның уйчанлыгын укырга артык иртә тартылуыннан күргән. Китаплар—бу яхшы, кеше китапсыз һавасыз шикелле, ләкин аңарга шулай бик иртә, дүрт яшьлек сабый чагыннан нигә баш белән үк чумарга ди?! Аннан соң бөтен балалык чоры, уеннар, дуслар урынына—китаплар, китаплар, китаплар гына булырмы?.. «Катырып куйган сын шикелле утырасың син. Әйдә бура уены—городки буенча ярышабыз!» —дип ул еш кына Николайны җанландырып җибәрергә тырышкан. Федор Софронович «катырып куйган» оныгының күңелендә, күп тә түгел, аз да түгел, революция кайнаганын чамалый алган идемени соң! Әйе, әйе, ярсулы кечкенә йөрәктә бик күптәннән үк инде әдәбиятта Герцен, Джованьоли, Войнич, декабристлар һәм народоволецлар турында яктыртылган вакыйгалар һәм Октябрь, кояш давылы сыман, анда исәпсез билгесез хисләр тудыра. Инде мең дә тугыз йөз унҗиденче елның языннан, февраль вакыйгаларыннан соң, кечкенә Николайниндидер татлы сөрем эчендә йөри, яши башлый. Һавада атналар буе чаң тавышлары эленеп тора, бик тиз генә пычрак,көрән кар чикмәннәрен салып ташлаган шәһәр бакчалары бүртеп килгән яңа тормышның авыз камаштырырдай хуш исләре белән борыннарны кытыклый. «Россия азат, Россия патшасыз!» Искиткеч,—дип пышылдый малай эченнән,—очраклы тууымның мине бөек вакыйгалар замандашы итүе искиткеч! Нигә ирек өчен көрәшүчеләр хыялланып башларын салган вакыйгаларны нәкъ менә миңа күрергә туры килде икән?» Ләкин иң мөһиме—унҗиденче елның ул пасха көннәрендә аның кулына Петербург профессоры Ю.Д.Хвольсонның Эйнштейнның революцион теориясен яхшылап аңлаткан «Чагыштырмалылык принцибы» дигән зәңгәр тышлы юка гына брошюрасы килеп керә. Ул исә малайны тәмам тетрәндерә. Кайбер традицион фәнни доктриналарны юкка чыгару, пронстранство-киңлек һәм вакытның чагыштырма булуын раслау, һич тә көтелмәгән яктылык тизлеге максимальлеге аксиомасы—болар барысы да анда берьюлы аптырау да, соклану хисе дә тудыра. Бер елдан соң бу турыда совет бердәм хезмәт мәктәбенең икенче баскыч укучысы Николай Новиковның борынгы грек философиясе һәм психология укытучысы, соныннан оригиналь шахмат темасы буенча күренекле хатын-кыз рәссам булачак, хәзергә Николайның класслашы булган Галина Сотонинаның абыйсы Николай Иванович Сотонин класслар буенча таратачак анкетасында яза. Сүз уңаенда әйтеп китим, бу хатын-кызның язмышы озын һәм,

уйлавымча, бәхетле була. Ә абыйсыныкы... Утызынчы елларда җирле газетада бер-бер артлы аңлашылмый торган «Сотонинчылыкка чик», «Сотонинчылык өчен туклыклы мохит юк» дигән башлар белән һәм тагын шуныңише исемнәр астында үткен, җанга тия торган бүтән, оппортунист, сәяси уйнашчы һәм совет яшьләрен юлдан яздыручы Сотонинны фаш итүче мәкаләләр басыла. «Ул ,—дип языла аларның берсендә,—зарарсыз әдәби-эстетик түгәрәкләр оештырудан башлады, ә язучы-эстетлар иҗатын ударник-эшчеләр әдәбияты, шулай ук борынгы грек философиясен Маркс, Ленин, Сталин тәгълиматы белән чагыштыруга хәтле барып җитте...» Газеталарда, халык алдында шулай кыйналганнан соң, Сотонин кулга алына һәм Себергә озатыла, аннан инде реабилитациядән соң да әйләнеп кайтмый.

Һәр фамилия артында—аерым повестька керергә хаклы язмыш. Николай Сергеевич безгә бу гаҗәеп, башкалар кебек фикер йөртмәгән философ, зур кеше, дөрес, шул ук вакытта зур каршылыклардан да азат булмаган Николай Иванович Сотонин турында күп сөйләде.

Шулай итеп, Сотонин анкетасының: «Сез тормышыгызны нәрсәгә багышларга телисез?» дигән соравына кечкенә Николай бик кыска гына: «Фәнгә», дип җавап бирә. Аның икенче: «Сез үзегезнең киләчәк тормышыгызда барыннан да бигрәк нәрсәдән куркасыз?» дигән соравына биргән җавабы да бөтенләй үк кызыксыз түгел. Укучы анда: «Гаилә тормышыннан һәм картлыктан»,—дип яза. Аның уенча, гаилә тормышы аның интеллектуаль үсешенә һәм фәнни эшенә киртә булып торачак. «Картлык»ка килгәндә исә, монда күз алдында менә нәрсәне истә тотарга кирәк. Калган яшәеше тоташ авырулар белән авыраер һәм шуңа күрә тормыш тулы кыйммәтле, тулы канлы һәм нәтиҗәле булмас дип ышанган Новиков утыз яшькә хәтле генә яшәргә уйлаган. Анда бу җаваплар инде унҗиденче елда ук өлгергән булган, ә унсигезенчедә ул моны язып куя алмаган, чөнки күңел тәрәзәсен беренче мәхәббәт чиерткән һәм шуннан соң беренче шигырьләр шәлкеме барлыкка килгән. Шәлкемме ул, түгелме, ләкин укучы дәфтәре бер тышыннан икенчесенә кадәр тулы була. Тышына: «Яз, революция, мәхәббәт»,—дип исеме дә чыгарыла.

Унсигезенче елның язы белән җәе дә сизелмичә үтеп китә. Августта, бабасында рәхәтләнеп ял иткәннән соң, Николай Алмалыга, өенә кайтырга җыена башлый. Ләкин Казан урамнарында инде сугыш гөрселдәгән була.

—Йокла хәзер үк, йокла!—дип ясалма рәвештә ачуланган була бабасы тынгысыз оныгын.—Анда төн буе дөбердәтер әле, әнә күк ничек күкри!

—Күк күкрәми, ә артиллерия, нәрсә, мин анламыйммы әллә?—ди аңа оныгы.

Николай, туп атулар мылтыкныкы белән алышынып, ә күк күкрәве Идел артына, Югары Осланга таба киткәч кенә, төн урталарында гына тынычланып кала. Федор Софронович төн буе кечкенә генә тәрәзәгә караштырып чыга һәм әледән-әле оныгының юрганын төзәткәләп куя.

—Күкләрдә яшәүче атакаебыз безнең, саклый күр, Аллам, һәм үзеңнең колың Николайны ярлыка,—дип пышылдый ул караңгылыкта.—Әгәр кирәк икән, минем, әдәпле христианин Забродин Федор Софроновичның җанын ал, үзеңнең гадел ачуыңны миңа юнәлт! Бары тик минем Николаемны гына сакла! Минем карап туймаслык Николаемны гына сакла һәм кичерә күр!

Иртән Федор Софронович капкасын ачып урамга карый. Шәһәр үлгән сыман. Ишегалды себерүчеләр дә, гадәттә, бу вакытта Засыпкин урамы астыннан шәһәрнең калку үзәгенә таба ашыгучы фабрика һәм завод эшчеләре дә күренми. Бары тик таш түшәлгән урам башыннан брезент белән ябылган бер арба гына килә. Менә ул өенә кайтып җитә алмаган

эчкечегә охшап юл читендә бөгәрләнеп яткан кеше янында туктады. Ләкин ир-атны аракы екмаган бугай. Ат йөртүче белән арбаның тагын ике кешесе—солдат белән кара кительдәге офицер (каппельчедер, мөгаен) аны күтәреп алдылар. Мескеннең җансыз башы артка салынып төште, кепкасы, җимерелгән, ә бәлки туп кыйпылчыгы яисә пуля белән тишелгән муен чокырын ачык калдырып, җиргә килеп төште. Федор Софронович аннан ерак түгел генә «кечке яшен»гә дучар булган тагын ике кешене күреп алды. Ләкин арбадагылар алар белән кызыксынып тормады, күрәсең, үзләренә кем кирәген яхшы беләләр иде алар.

«Менә бит нинди эшләр майтарыла монда!..»—дип сөйләнә-сөйләнә Федор Софронович урамнан, шәһәрдә тәртип урнашмый торып, оныгын өенә җибәрмәү турында ныклы ният белән әйләнеп керде.

—Уку башланганчы вакыт бар әле,—диде ул, иртәнге ашны ашаганда,—кая ашыгырга? Тагын берәр атна торырсың, ә әти-әниенне мин кисәтеп куярмын, бүген үк барып килермен аларга. Борчылалардыр, шәт, һәм дөрес тә.

Түтәйләре—Федор Софроновичның апалары да бер авыздан:

—Аһ-аһ, урамда нинди куркыныч нәрсәләр генә кыланмыйлар, җибәрә күрмә аны, Федор!—дип ахылдадылар.—Сөйләп тә торасы юк, беркая бер адым да ясамыйсың, Николай!

Ләкин аны бу да куркытмады, эшләре барып чыкмады. Һәрвакыт килешүчән Николай бу юлы кискен протест белдерде:

—Юк, юк, юк! Миңа бүген мәҗбүри рәвештә өйдә булырга кирәк. Әйттем бит, без Таня һәм Семён белән инде әллә кайчан ук бүгенге көнгә сөйләшеп куйган идек... гербарийлар өчен барырга... паркка... Биргән сүземне боза алмыйм ич инде мин!

—Нинди гербарийлар!?—дип тамак кырып куйды Федор Софронович.—Ишегалдында—сугыш!

—Ник дөньяны су басмый шунда! Ирләр сүзе барлык хәлләрдән дә өстен, дип син үзең өйрәттең бит мине, бабай.

—Ләкин бит ниндидер чара булырга тиеш, Николай, аек чара. Ниндидер үлән сабагы өчен утка керергә ярамый бит инде!

—Урамда тынлык ич.

—Тынлы-ы-ык... Тирә-якта үле гәүдәләр аунап ята. Әле генә күрше хатын кергән иде... Ике кешене, дип сөйләде, Поп Тавында бернинди сәбәпсез тыкрыкта үтереп ташлаганнар. Кемдер бармагы белән төртеп күрсәткән. Янәсе, кием алмаштырган комиссарлар—һәм бар суды-ние шунда...—Федор Софронович чукынып куйды да, өстәл яныннан торып, шкафтан сюртугын алды.—Керосинга барып киләм мин.

Николай түтәйләре белән өйдә калды.

Төш җитәрәк Арча кырындагы артиллерия казармалары янында соңгы орудия залплары яңгырады. Әле кайдадыр берән-сәрән мылтык тавышлары чытырдый иде, ләкин инде шәһәр халкы урамнарга сибелде. Купшы киенгән тәкәббер әфәнделәр утырган ике тәгәрмәчле җиңел арба —кабриолетлар, эшләпәле һәм бантиклы кызлар төркемнәре, галстук-күбәләк таккан мыексыз көяз яшьләр, хәбәрләргә караганда, яңа власть лидерлары, Комучның махсус вәкилләре—Фортунов һәм Лебедев чыгыш ясарга тиешле булган Театр мәйданына агылдылар. Шулай ук «халык армиясе» частьларының парады да көтелә иде. Шәһәр буенча тәэсирләнгән кибетчеләр һәм поплар әрле-бирле йөренде, рус, чехословак, серб офицерларының погоннары ялтырады, университетның анатомик театрына һәм зират урнашкан Арча кырына аз санлы туганнары озатуында мәетләр төягән санитар арбалары һәм кызыксынучы ачык авызлар агылды. Төш вакытында шәһәр чаннары күңелле генә чыңлап куйдылар.

Федор Софронович кибеткә, керосинга караганда, разведка ясап, тирәюньгә күз салып кайту өчен барды. Онығы аны өйалдында каршылады һәм һаман үзенекен итте: өйгә дә өйгә!

—Үзеңне генә җибәрмим, алайса,—диде Федор Софронович аннары, түземлеген югалтып.

Николай, бернинди артык сүзсез, җыеныр өчен бүлмәсенә йөгереп кереп китте.

—Ә открыткаларны кая куярга?—дип сорады ул инде ярты ел өенә алып кайта алмаган бабасының бүләге турында. Һаман төрле сәбәпләр чыгып торды. Менә хәзер дә бабасы:

—Николай, нәкъ менә бүген мәҗбүримени соң бу?—диде.

Малай аңа әрнү тулы күзләрен күтәреп карап алды да, Федор Софронович кулын гына селекте. Аңа үз коллекциясе кызганыч түгел иде. Ул онығының үз мавыгуын дәвам итәчәгенә сөенә генә. Алай да, үзенең байлыгын чит кулларга бирмәсә дә, барыбер башкалар кулына тапшырган коллекционер җанын аңларга була иде.

—Минем сары саквояжымны ал, анда алар чат кына сыеп бетә.

Шәһәр урамы бабасы белән онығын җылы һәм кояш белән каршы алды. Төнге яшенле яңгырның эзе дә калмаган. Талгын җил тирә-якка чаң тавышларын тарата. Үзенчәлекле бу хор репетициясендә Иванов мәйданы кыңгыраулары өстенлек итә, аларга Зур Проломный, Воскресенский, Грузин урамнарының кыңгырау тавышлары кушыла.

—Пасха да түгел... Кара син аларны, ни кыландыралар!—дип сукранып алды Федор Софронович.

Алар тар урам буйлап елгадан шәһәргә таба күтәрелделәр. Николай саквояжын тоткан бабасы кулына ябышып атлады һәм төнге коточкыч хәлләрнең, шомлы иртәнең һәм күз алдының йомшак яктылыгы белән тулы яхшы август көненең һәм чиркәү манараларыннан агылган ягымлы нәфис кыңгырау тавышларының бер-беренә тәңгәл килмәүләренә гаҗәпләнде. Каршыга очраган кешеләр дә матур һәм бәйрәмчә киенгәннәр иде.

Хвостовның шәм кибете янында аларның юлын бернинди сәбәпсез ике рус офицеры һәм мөлаем йөзле генә күзлекле әфәнде бүлде.

—Бу ул!—дип шатланган тавыш белән кычкырып куйды кинәт хатын-кыз тавышы белән күзлекле әфәнде, Федор Софроновичның күкрәгенә төртеп.—Ул, ул...

—Эш нәрсәдә?—дип гаҗәпләнде бабасы.—Сез кемне күздә тотасыз?

—Нәкъ ул, кызылкай, еврей танавы!—дип тәмам котырынды күзлекле.—Качарга өлгермәгән!—Ул Федор Софроновичның сюртук җиңенә үк килеп ябышты.—Тотыгыз аны!

—Сез мине кем беләндер бутыйсыз. Мин—икенче гильдияле купец Забродин.

—Әһә-ә, купец! Ышанганнар ди! Нәрсә белән соң сез, и-п-п-тә-ә-әш купец, шулай булгач, комиссарлар лавкасында купецлык иттегез, ә?

—Купецлык итмәдем, ә эшләдем... азык-төлек бүлегендә... бухгалтер булып...

Ләкин инде аны башка тыңлап тормадылар, малайдан йолкып алдылар да, шундук килеп җиткән пар атлы экипажга төрткәләп утырттылар.

—Николай!..—дип Федор Софронович нидер әйтергә җыенган иде, өлгерми калды—аның башына суктылар һәм ул арба артында югалды.

—Ә-ә-ә!—диде күзлекле, тешләрен ыржайтып.—Николай! Ә синең саквояжда нәрсәләр бар анда?

Картны эләктергәндә малай тотынып барган саквояж аның кулында калган иде.

—Открыткалар,—дип сыгып чыгарды Николай.

Офицерларның берсе, поручик, бер сүз дә әйтмичә, аның кулыннан саквояжны тартып алды да, аннан бер уч открыткалар тартып чыгарды һәм аларны жилпәзә шикелле читкә тотып бәрде; аннары тагын бер уч алды, тагын читкә ташлады, шуннан соң, сүгенеп, саквояжны капка төбенә ыргытты. Николай авызын ачарга да өлгермәде, поручик атларны камчы белән сызгыртып алды да, алар урыннан капыл гына кузгалып, экипаж китеп тә барды.

Кызыксынучан халык төркеме: «Шул кирәк ана...», «Шундук стенага терәргә иде аны...» дигән сүзләр белән ашыкмыйча гына таралышты. Малайда беркемнең берниндн дә эше юк иде.

Николай нишләргә дә белмәде. Экипаж кереп югалган тыкрыкка хәтле чапты, ләкин моннан ни файда иде инде? Төшендәге сыман, капка янына кире кайтты да, үксеп елаудан буыла-буыла бабасының таш түшәлгән урамга чәчелгән открыткалары янына тезләнде.

Николай Алмалыдагы өйләренә бары тик кичкә генә кайтып житте. Башта Засыпкин урамына төшеп менде әле. Ләкин анда бер жан иясе дә юк, түтәйләре каядыр китеп барган, бабасы әйләнеп кайтмаган иде. Капка төбендә юкка гына басып торды.

Эшнең нәрсәдә икәнен белеп алганнан соң, әле кичә генә үзе дә шул ук азык-төлек бүлегендә йомыркалар әзерләү буенча вәкил булып эшләгән әтисе комендатурага ашыкты. Бу аның үз гомеренә янаган дуамал адымы иде. Кизү торучы рус офицеры аны башта, киеме буенча, ягымлы гына каршылады, ә ни өчен килүен, кем булуын ачыклагач, аны бик әдәпле генә итеп бер бүлмәгә озатып куйды. Ә анда исә аны үләр хәлгә житкәнче кыйнадылар. Саксыз вәкил үзенең гомере ахырыннан, аннан соң өйдәгеләренә сөйләвенчә, зур очраклылык аркасында гына котыла. Аны ул ишеккә төртеп кертмиләр, юк, киресенчә, артында чираттагы корбаны көтеп торучы канлы стеналы ишегалдына чыга торган ишеккә түгел, ә биек булмаган чуен койма белән әйләндереп алынган тыныч бакчага чыга торганына төрткәләп кертеп жибәргән булганнар. Ә аның аша чыгу ирекне сизгән кешегә, гәрчә бик каты кыйналса да, һич тә авыр булмаган.

Ә Федор Софронович шул китүеннән кире әйләнеп кайтмый. Кешеләрчә жирләү өчен аның үле гәүдәсен дә тапмыйлар. Югалды кеше, бернинди эзсез юкка чыкты. Тик аның открыткалары белән сары саквояжы гына Алмалыдагы өйгә кайтып төште. Хезмәт итәргә... Юк, якты хатирә буларак түгел, ә шул куркыныч август көнен хәтерләтеп торучы дәлил булып.

## ДҮРТЕНЧЕ БҮЛЕК

### Туй

Гайнан Фазлыгаллэм улы гомерне бер тиенгә дә санамады. Төгәл кемнекендер дә һәм шәхсән үзенекен дә түгел, ә гомумән алганда. Ничек кенә уңышлы килеп чыкмасын, ләкин барыбер ничек кенә боргалама, ул—вакытлы нәрсә, диде ул, һәм шуңа күрә мәгънәсез дә. Гомернең бернинди уңышларын да якорьга куеп булмый, бернинди хаклы хезмәтең белән дә үлемнән котылып кала алмыйсың. Гомерләр һава шарлары шикелле шартлый. Аларның да зәңгәрләре дә, алсулары да шартлый бит.

Мыгырдык кеше иде ул. Шул ук вакытта ихтыярлы кеше дигән тәэсир дә калдырды. Һәрхәлдә беренче вакытларда. Ә бу сүзләр аның авызыннан аннан соң чыктылар.

Ул безнең тормышка булдыклы кешенең сыгылмалы адымы балтырыннан ике якка киткән купшы галифе күренеп торган хром итекләре белән

шыгырдап килеп керде.

Мин, ул Шәехкә шундук ошамаган, дип әйткән идем инде. Миңа исә ул, аның кызарган йөзенә карамастан, болай ярыйсы күренде, ир кеше ир кеше шикелле инде... Аны шулай дип күз алдына китерергә аның тимер сыман нык, нәкъ Поль Робсонныкы кебек түбән тавышы тәэсир итте. Ул ашыкмыйча, чын күңелдән сөйләшә, ә мин аның сугышта дошман канонадасыннан катырак кычкырып тавыш ярыларын өзүен һәм карлыккан тамагыннан чыккан «Ура» белән сугышчыларны атакага күтәрүен күз алдыма китердем.

Ай чамасы ярәшкән егет булып йөргәннән соң, Гайнан абый безнең күрше хатынга рәсми рәвештә тәкъдим ясады. Тантаналы итеп, Шәех һәм минем әти-әни алдында.

Безнең якта август—бай вакыт. Жимеш һәм яшелчә бакчалары үзендә хезмәт куючыларның һәр тамчы тирләренә патшаларча түли. Зур гаилә тантаналары бездә гадәттә менә шушы вакытка туры китереп уздырыла да инде.

Ул елның августы да сынатмады, заказ буенча диярсең, уңдырышлы, жылы, аяз килде. Рәшидә апа, туй ясарга жыенмыйм, ә якыннар өчен тыйнак кына итеп өстәл әзерлим дә шуның белән шул житкән, диде.

—Пироглар пешереп, салатлар турыйм. Үзебезнекеләр өчен тагын ни кирәк?—дип сөйләнде ул.

Ләкин колачын жәеп жибәрү өчен шушы уңай очрактан файдаланып калмаса, Рәшидә апа һич тә Рәшидә апа булмас иде. Бөтен урам ук булмаса да, яртысы Шакировларда кунакта булды. Монысы—хак. Туйны бик зурлап үткәрделәр. Мин моны сизмәгән дә булыр идем, ләкин йокларга ятканда әни әтигә, шулкадәр итне бернинди бәйрәмдә дә күргәнем булмады, дип әйтте. «Барысы да аныкы,—диде әти,—кияү кешенеке».

Кияү туйда канатланган шикелле иде. Жырлады да ул, биеде дә, дөрес, бик оста итеп түгел, ләкин чын күңелдән. Мәзәкләр дә сөйләде, аның монысы яхшырак та килеп чыкты әле, һәм ул һаман-һаман агылучы кунакларны да колачын жәеп каршы алып торды. Ул үзләренә Николай Сергеевичны да алып керде, тик анысы бераз гына утырды да тиздән чыгып китте, чөнки үзенең аралашмаучанлыгы өчен дә оялды, бәйрәмчә вакыт уздыруга да күнекмәгән ул. Жырламый да, биеми дә, сүз белән компанияне дә тотып тора алмый. Котлады да бәхет теләде, тагын ни кирәк?

Аның каравы башкалар яхшы күңел ачты. Кем генә юк иде монда! «Керосинка» сатучысы да, гастрономның склад мөдире дә, управдом да һәм, хәтта кешеләр белән аралашмаучы, үзендә иллеләп мәче асраучы (ул аларның барысының да исемнәрен белә һәм кичләрен аларның берәрсе күренмәсә, озак һәм ялварып: «Мурка, Мурка... Барсик, Барсик...»—дип чакыра), беренче катта яшәгән Милочкага тикле бар иде. Соңыннан Шәех усал гына шаяртып, туйда барысы да булды, тик Милочканың мәчеләре генә чакырылмаган иде, диде. Ул моны әнисенә дә әйтте, ә ул: «Тынычлан, мәчеләрен дә сыйладым, аларга да эләкте күчтәнәчләр»,—дип жавап бирде.

Гайнан абый урам аша каршыда гына яшәгән күршесе, участок милиционеры лейтенант Хәниф абый Хәкимовка икеләтә игътибар белән бик илтифат күрсәтте. Алар ни турындадыр кызып-кызып сөйләште, дөресрәге, кияү элеккеге балтыйкчыга бик тырышып нәрсәдер аңлатып маташты, тик тегесе нәрсәнедер аңлап житкерми иде сыман. Хәниф абый бик яхшы егет иде, ул безне, жирле малайларны, еш кына Алмалы буенча үзенең коляскалы, ике цилиндрлы кара мотоциклына утыртып жилдертә. Бер тапкыр, беренче Май демонстрациясеннән соң, әле шәһәр транспорты

йөри башламаган иде, ул безне, бер көтү малай-шалайны, берьюлы утыртып Божрадан тауга (без яшәгән урам калкулыкта урнашкан) кадәр алып кайтты. Шәхсән мин үзем, рульгә тотынып, бензин багында утырдым. Калганнары—кем ничек туры килде, шулай. Акылга сыймаслык хәл! Миңа аларның барысын да мин алып кайткан шикелле тоелды. Мондый хәл онытылмый. Сүз унаенда әйтеп китим, май аенда минем чак кына батып үлмичә калуым турында ул әти-әнигә дә тишмәде. Безнең участок милиционерының тагын бер зур мактауга лаек эше бар иде. Ул елларда, туй булган елда түгел, элегрәк, илленче елларда, күгәрченнәрне шәһәрнең дошманы дип белдергән ниндидер указ чыкты. Кемнеңдер уенча, әллә алар йогышлы авыру тараталар, әллә үзләренең туймас тамаклары аркасында ашлык әзерләүне өзәләр дип санадылармы, белмим, ләкин күгәрчен кетәкләрен бар җирдә дә тыйдылар. Шәехнеке өчен безнең лейтенант шелтә эләктерде, ләкин барыбер йолып калды. Бары тик, урамнан күзгә ташланмасын өчен, күгәрченнәр очып китә, кайтып утыра торган такта яссылыгын—лавасын гына икенче якка борып куярга туры килде.

Хәниф абый туйга килгәндә формадан түгел иде, тик барыбер спиртлы эчемлеккә кагылмады, каядыр барырга җыена иде бугай.

—Безгә прапискага керәсезме инде хәзер, Гайнан абый?

—Нәкъ шулай!—дип хәрбиләрчә җавап бирде Гайнан абый.

—Ә кысан булмасмы икән?—Хәзер Хәниф абый үзе сораштыра һәм үзенең яшьләрчә аппетиты белән оста гына итеп (ник бер йөзем ашъяулыкка төшсен!) күп катлы гөбәдия кисәге белән көрәшеп маташа иде.—Ә загста язылдыгызмы соң инде?

—Шушы көннәрдә язылышабыз. Кая ашыгырга?

—Җәен болай ярыйсы, Шәех сарайда яши.

—Куна,—дип төзәтте аны Гайнан абый.

Шунда Хәниф абый бер такмаза хәтерләп алды:

—Нишләп кызылайдың?—Өйләнәсе килә.—Нишләп болай яшел?—Өйләндем!

Икесе дә көлеп куйды һәм моңа каршы Гайнан абый үткен җавап кайтарды:

—Әй-йе... Сугышка һәм өйләнергә кыю барырга кирәк. Үзең өйләнгәнме соң?

—Әлбәттә! Тылда ике сугышчым да бар инде!—диде Хәниф абый.

—Иртә өйләнде безнең участковый, иртә,—дип Киләленең әнисе Гөлфия апа сүзгә катнашты. Белмим, кайсы яктан килеп чыккандыр ул бу туйга?! Кияү ягыннанмы икән әллә? Мин моны соңрак кына белдем...

Тиздән туй шау-шу белән ишегалдына чыкты. Август кояшы юмарт кына җылыта. Җәй бетеп барганда кешеләрдә нинди кайгы-мәшәкать булсын? Җитмәсә, ял көнне, җитмәсә, туйда. Типтер-бие, аяксыз гына калма. Безнең ишегалды иркен, бары тик сарай янында гына сирень куаклыгы һәм дә уртасында имән үсеп тора, ә аның янында өстәл һәм менә хәзер гармунчы килеп утырган эскәмия бар. Гармунчы җилкәсен имәнгә терәде дә Шәех гармунының төймәләренә кагылып алды һәм җитез генә аның мехларын каерып җибәрде. Кунаклар сискәнеп куйды, йөзләре балкып китте, биюләр башланды, җырлар агылды, татарча да, русча да...

Юк, барыбер туй түгел иде бу. Кияү дә карадан киенмәгән, кәләш тә кар шикелле актан түгел. Читтән караган кеше моның ни сәбәпле бәйрәм икәнен дә аңлый алмас иде. Ләкин монда күңел ачучы кешеләр барысын да яхшы аңлыйлар. Алар тормышта күпне күргән күршеләренә, соңарып булса да, Алмалыда яңа кеше белән рәхәт күрсен, аз булса да бәхетле булсын, дигән теләкләр теләделәр. Ни әйтсәң дә, өйдәге ир-ат—бу сиңа җылы мич

тә, тактадан эшләнгән капка да дигән сүз.

Боларны бары тик Шәех кенә аңламады. Ул көнне ул иртән үк балыкка чыгып сызган иде. Өенә аннан соңарып, инде августның аяз көне кара, яшенле төн белән алышынгач кына кайтып керде.

Мин ул төндә йокларга террасада түгел, ә өйдә яткан идем. Тәрәзә артында яктырып-яктырып китте, шатырдады һәм мин яшен яктылыклары белән күк күкрәү арасындагы вакытны санарга керештем. Чөнки безне яшеннеңерактамы, түгелме икәнен шулай билгеләргә өйрәткәннәр иде. Мин абый белән идәндә (безгә нәрсә—ни әйтсәң дә, без—ир-атлар, апа диванда йоклый, ә әни белән әти шкаф артындагы караватта), ул да әйләнгәләп ята һәм мин аңа, күк яшен артыннан ук күкри, димәк, без яшен уртасында, дип пышылдадым. Йокла, акыллы баш, дип җавап кайтарды абый. Ләкин минем шигем тикмәгә генә булмаган икән бит.

Тәрәзә төбендә яңгыр тамчылары шыбырдаша башлады, капка ишегенең келәсе җиңелчә генә шакылдап, күгәне шыгырдап куйды һәм, нәрсәгәдер эләгеп, велосипед педале тырылдады.

«Шәех кайтты»,—дидем мин үз-үземә. Һәм шундук тәрәзәне куркыныч яшен яктыртып алды.

Миңа бу ахырзамандыр, яшен сугудан җир ярылды һәм аннан без география дәресләреннән белгән сыек утлар үзәге ташып чыккан сыман тоелды. Бүлмәдә төш вакыты кебек ял-якты булып китте. Күк бомба ярылган шикелле күкрәде. Менә күзләрне тагын караңгылык катламы каплады һәм мин шуннан соң урнашкан тынлыкта безнең һәрберебезгә якын булган имәнебезнең ауган, шул чакта ничек барлык ботаклары белән берьюлы сузып ухылдаган тавышын ишеттем.

Шәех күлмәк белән туган икән—ул ауган баһадирның юеш ботакларында зарар күрмичә үк диярлек булмаса да, ләкин тере килеш ята иде. Кармак сабы сынган, велосипед рамасы дуга кебек бөгелгән... Ә аның бары тик бите генә сыдырылган, күлмәге ертылган һәм велосипед руле белән аягын авырттырган. Ул аягына баса алмый иде.

Шәехне әсирлектән әти белән абый коткарды. Мин дә булыштым. Янәшәдә пычкы һәм балта белән Гайнан абый да бәргәләнде. Шунда ук Рәшидә апа уфылдады.

Икенче көнне, безнең имәнне бушлай утынга кискәндә, ирләр: «Шөкер, малай да исән калган, янгын да булмады!..»—дип гаҗәпләнде.

Агач, ботакларын куллар сыман җәеп, ишегалдын тутырган, хәтта койма аша иелеп, урамны да япкан иде. Ауган баһадирның куәтле гәүдәсе буйлап бала-чага йөгереште. Ә яшеннең эзе дә юк.

Ирләр бик җитез эшләде. Ике көннән соң безнең нык-таза дустан бары тик базык төп кенә утырып калды.

## Кайда күрдем соң мин сезне?

Гайнан абый безнең өйгә бик тиз ияләште. Җитди салмак кыяфәте һәм үзенең чиркәүле-органлы тавышы белән ул янәшәсендәгеләрдә ышаныч тудырды. Аңа, гаиләле ир-атка, кайбер яшьләр дә тартылды. Мин аны әле Киләле, әле Жбан белән бергә очраткалый идем...

«Хезмәт резервлары» стадионында ул Александр Пичугин белән дә танышкан. Аларны нәрсә якынайтты икән соң? Футбол түгелдер бит инде! Гәрчә Гайнан абый «бик көчле, каршы торып булмый торган унлы» адресына (Пичугинның футболкасында, Пеленеке шикелле, шушы номер сугылган иде) мактау сүзләре сиптерсә дә, бу җанатарның үз күңелендә тагын нәрсәдер яшеренүе ачык иде. Ачык иде...

Хәер, әле ул чакта, Гайнан абый күчеп килеп тора башлагач, Шакировларның туклырак яши башлавыннан бүтән, берни дә ачык түгел иде.

Шәехнең яңа әтисе циркта склад мөдире булып эшли. Нинди хезмәт хакы, нинди паеклар булсын ди инде анда? Ләкин, безнең кат буенча ул чактагы гомуми кухнябыз өчен сирәк күренеш булган тәмле исле парлар чыгарып, хәзер ул күршеләр кастрюлендә һәркөн саен яңа гына суелган сыер ите кайный иде.

Рәшидә апа үзе дә күз алдында үзгәрә төште, тагын да сөйләшергә яратучанрак булып китте. Шул ук вакытта ягымлы, йомшак һәм хәтта чырае белән дә бераз үзенә тартып тора диярлек иде. Ул яңа эшкә—азык-төлек кибетенә сатучы булып урнашты. Гайнан абый урнаштырды. Алай да Рәшидә апа моңа карап тәкәбберләнеп китмәде, элеккечә үк бөтен катны һаман саен итлерәк, кызарганрак була барган өчпочмаклар белән сыйлавын дәвам итте. Аның үзенең, гел акчасызлыктан һәм төрле авырулардан аптырап-йөдәп беткән кешенең, барлыкка килгән яңа киемнәрдән башка яңакларында тереклек төсләре дә пәйда булды. Ул язмышының көтелмәгән шундый борылыш ясавына бик тә шатланды һәм кинәт кенә иртәләрен гармун уйнаудан туктаган, ә туйдан соңгы беренче көнендә үк үги әтисе көн саен диярлек эшеннән алып кайткан кисәкләрдән әзерләнгән итне ашаудан баш тарткан малаеның бойкотына игътибар да итмәде. Ул малаеның үҗәтлеген белә, ләкин шул ук вакытта тышкы читләшкәнлеге артында аны—үзенең авыру әнисен ярату хисе яшеренгәнен дә бик яхшы чамалый иде. Барысы да дөрес, дип уйлады ана, өйдәге яңа хуҗа, яңа әти кеше, ягъни үги әти, кемгә ошасын, ләкин тора-бара вакыт үзенекен итәр, ир-атлар үзара уртак тел табарлар әле.

—Бер генә кисәк булса да аша әле,—дип кыстады ул малаен,—сиңа аерым әзерләп булмый ич инде.

—Ялынма да,—дип җавап бирде Шәех,—бу ит арыслан һәм юлбарыслар өчен.

—Нинди аерма булсын, сыер ите бит! Югары сорт.

—Сыер ите түгел, ә урланган ит ул,—дип үҗәтләнүен белде Шәех.

— Кара, нинди кисәкләр!—диде әнисе, сокланып.—Кибеттәгедән яисә хәтта базардагыдан да яхшырак.

—Менә, менә!..—диде Шәех ачу белән һәм үзенең күгәрченнәр кетәгенә чабып чыгып китте.

Рәшидә апа аның артыннан:

—Урланган түгел бу, ә паек,—дип кычкырып калды.

Мондый әңгәмәләр вакытында берничә мәртәбә Гайнан абый да килеп чыккалады һәм хатынына:

—Әкрен син, нәстә бөтен дөньяга акырасың!?—дип ысылдады.

—Ашамый бит...

—Ачыкса, үзе йөгереп килер әле.

Ләкин Шәех әйләнеп кайтмады. Ул чорда помидор-кыярлар, бәрәңге җитәрлек булды. Ә аннары Рәшидә апа җаен тапты. Аңа почмакта яхшылык эшләүче Гайнаны алып кайтып биргән шул ук итне «базардан сатып ала» башлады.

Әйтергә кирәк, Гайнан абый, чыннан да, арысланныкы хәтле «паек» ала иде. Ул кайбер таныш-белешләренә дә өлеш чыгаргалады. Минем әни дә аннан бер-ике тапкыр пилмәнгә дип ит сатып алган иде. Ләкин бер мәртәбә төнлә әти-әни арасында, аларның шкаф артындагы «кабинет»ларында, җитди сөйләшү булып алды. Һәм шуннан соң әнигә кеше хәленә керүче күрше хезмәтеннән баш тартырга туры килде. Әти Гайнан абыйны яратмый

иде. Житмәсә, ул бик көнче дә. Ул вакытта миңа бу сөйләшүнең төп сәбәбе дә шул көнләшү булды сыман тоелды.

Безнең йортка сумка белән Киләле дә ешлады. Беренче чакларда ул Гайнан белән туп-туры кухня чоланында очрашты. Күзгә табарак ул эшлекле очрашулар урыны, Шәехнең ничек кенә каршы килүенә карамастан, инде аның шәхси резиденциясе булуыннан туктаган сарайга күчте. Хәзер еш кына аннан балта чапкан тавыш ишетелә һәм елмайган Киләленең ишегалды аркылы авыр сумка күтәргән килеш чыгып баруын күреп була иде. Кайчак аның әнисе Гөлфия апа да килгәләде.

Иткә бер Николай Сергеевич кына ваемсыз булып калды. Ул аңа һәрчакта житмәгән вакытын шактый ук янга калдыра торган концентратлар белән туклануын дәвам итте.

Бернәрсә белән дә үзенә каратып булмаган галим күршесен Гайнан абый икенче нәрсә белән алды. Сөйләшүе белән. Ул аңа сентябрь ахырында ешлады. Моңарчы циркның склад мөдиренә ялгыз яшәп яткан күршесе кызыклы түгел кебек тоела иде. Хәер, аңа кергәләп йөрергә ул чакта вакыты да булмады: яңа йортны, фатирын үзләштерде, торырга жайлаштырды, иялэште... Иялэшеп житкәннән соң Николай Сергеевичтан да кызыклы, сәер кеше дөньяда юк икәнен күрде.

Танышканда Гайнан абый аны гади генә Гена дип йөрергә кушты, янәсе, аның исем-фамилиясен әйтүе жинел түгел.

—Ә нигә,—диде Николай Сергеевич,—Джавахарлал Неру дип әйтә алабыз бит, Гайнан Фазлыгалләмович дип тә әйтә алырбыз.

—Сез, әлбәттә, галим кеше инде,—диде Гайнан абый.

«Хәрби майор»ны белемле дип әйтеп булмый иде. Алай да аның үз философиясе бар. Тормыш турында сафсата сатканда ул бөек кешеләрнең, күпчелек очракларда полководецларның, алар арасыннан күбрәк Наполеонның үзе кайдадыр ишеткән, кайдандыр алган хикмәтле сүзләрен әйтергә ярата иде. Кайчакта хәтта гажәпләндереп тә куйгалый... Акылы белән түгел, ә акылының тапкырлыгы белән. Соңыннан ачыкланганча, бөекләрнең хикмәтле сүзләрен китергәндә ул ялгыша, берсенең сүзен икенчесенеке дип саный, кайчак аларны үзе дә уйлап чыгара икән. Үзенең акыллы сүзләре белән ялтырап алганын яисә әңгәмәдәшен тәмам почмакка китереп терәгәнен сизгәч, ул һәрвакыт: «Акылым кечкенә булса да, үземнеке», яисә: «Иң мөһиме—интуиция, ә эрудиция түгел. Попугай да эрудит булырга мөмкин»,—дип кабатлый торган иде. Соңгы фразасы Николай Сергеевичка, шулай ук башка «бик грамоталы»ларга кагыла инде.

Бер тапкыр кәефе күтәренке, «философларныкы» кебек чакта Гайнан абый:

—Берүзегез генә ничек яшисез сез, Николай Сергеевич?—дип сорады.—Һич анлый алмыйм. Күнелсез бит. Ни дусларыгыз, ни дус хатыныгыз...

—Минем дусларым житәрлек,—диде аңа бик тиз генә Николай Сергеевич, күзен китапларына таба күтәреп.

—Со-он, бу... Бу—суррогат.

—Бу—тормыш,—дип каршы төште аңа Николай Сергеевич.

—Суррогат, кызганычлы ясалма нәрсәләр,—диде аңа Гайнан абый.—Чын тормыш сюжетларыннан да гүзәлрәк тагын ни булырга мөмкин! Менә минем нәрсәләрем генә юк иде, нинди генә хәлләргә тармадым, моңа бер язучының фантазиясе дә житмәс. Кайсыдыр бер зур каләм остасы минем баштан үткәннәрне язарга алынса!.. Шундый роман, шундый эпопея килеп чыгар иде—«Граф Монте-Кристо»ң бер якта торсын.

Николай Сергеевич ярым яткан килеш эшли иде, кулында—карандаш,

кулъязма. Ул берьюлы берничә эш белән шөгыльләнә ала. Ләкин шулчак кәгазьләрен күкрәгенә салды да карандашын колагы артына кыстырды.

—Һе, һич тә сер түгел, әгәр кеше менә сезнең шикелле зур язмышлы, тарих барышына йогынты ясый ала торган икән, алар тәэсирләләр. Ә менә шушы эш-хәрәкәтне анализлаучы һәм хәтта алдан әйтеп бирүче кешеләр дә бар бит дөньяда. Һәм аларның һәрберсе үзенең халкына һәр кешегә ми кирәк булган шикелле үк кирәк.

—Галимнәрме алар?—дип сорады Гайнан абый.

—Мәжбүри түгел. Еш кына шагыйрьләр дә алдан күрүчән була.

Гайнан мангаен җыерып куйды.

Бу Николай Сергеевич игътибарыннан читтә калмады. Ул кулын югары күтәрде дә тәэсирләнеп сөйли башлады:

Бик нык ялгыштык сыман тоелды,
Юк, без яшәдек бик озын гомер.
Кайтып кердек—танымадылар да—
Каршыламады ватан сөенеп.

Аннары кулын төшерде дә тирән итеп сулап алды, әйтеп куйды:

—Блок... Александр Блок. Ул бу шигырьләрендә, беләсезме, чагыштырмалылык теориясен бастырып чыгарганчы бер ел алдан ук аның төп фикерен биргән. Ә Велимир Хлебников—ул безнең университетта укыган—әле унөченче елда ук, аена тикле төгәл итеп, Октябрь революциясен фаразлаган. Китаплар... Алар бит—кешеләр, алар бит галактикалар. Эйнштейн ни өчен, Достоевский ана Гаусска караганда күбрәк бирә, дип әйткән? Чөнки алар икесе дә—галим дә, язучы да неевклид дөньясының, бу яшәешнең парадоксаль гармониясе җырчылары. Икесе дә. Ләкин бөек физикны әдәбиятчы, язучы рухландырган...

—Ә кем ул Гаусс?

—Галим. Математик, астроном...

—Бу, бу... Беләсезме нәрсә, геометрик нисбәтләр бөгелгән пространствода үзгәрәләр...

—Кара урман!

—Ә нигә кара урман?

—Сез төгәл, төгәл итеп, бармакларыгыз белән аңлатыгыз!

—Төгәлме? Мәсәлән, параллель сызыклар кисешә.

—Параллель булып та... кисешәләрме? Абракадабра! Мәгънәсез сүзләр бу!

Николай Сергеевич кушеткасыннан торды да, килеп, тәрәзәдән карады. Анда инде уңыш җыеп алынган, бары тик бик ботаклы алмагачта гына авыр алмалар агарып күренеп тора һәм ярым шәрә калган бакчаны сентябрь киченең караңгылыгы чолгап алып маташа иде.

—Антоновка...—диде Николай Сергеевич әкрен генә. Аннары инде катырак тавыш белән дәвам итте:—Менә Достоевскийда Иван Карамазов та кискен рәвештә: «Ярар, параллель сызыклар кисешсен дә, моны мин үзем дә күрәм, күрәм һәм, кисештеләр, дим, ә моны барыбер кабул итә алмыйм»,—ди. Алай да ул энесе Алешага: «Мин ышанам, газап чигүләр үтәр һәм онытылыр, кеше каршылыкларының барлык хәтер калдырырлык көлкелеге кызганыч мираж, кешелекнең Евклид акылы атомы шикелле юкка чыгар. Ниһаять, дөнья финалында, югары гармония мизгелендә шулкадәр дә кыйммәтле булган, бар күңелләргә дә җитәрлек нәрсәдер барлыкка килер»,—ди.

—Коммунизм килерме әллә соң?

—Уйлагыз. Безнең барыбызга да уйларга кирәк.

—Мин Эйнштейн түгел бит, миңа нәрсә...—диде Гайнан абый.— Аннары әйбер өчен карчыкны үтереп тә, шунын өчен тырышкан нәрсәсен ни өчен алмавын да аңлый алмыйм мин. Логикага нигезләнмәгән бу, хе-хе, минем Евклид пространство сферасыннан читтә тора.

—Достоевский да, Эйнштейн да—бөек тәҗрибә ясаучылар. Аерма бары тик шунда гына: берсе—фәндә, икенчесе үзенең геройларында, аларның, валлаһи, бәлки үзеңнең бүгенгегә караганда да артык ышандыра торган тормышларында тәҗрибә ясаган.

—Монда эш бөек язучыларда түгел, ә безнең үзебездә. Сезнен, Николай Сергеевич, кәгазь галактика һәм китап геройлары арасындагы ялгыз тормышыгызны тулы мәгънәдә чын дип әйтүе авыр бит. Ачыклыгым өчен гафу итегез, әлбәттә. Тормыштан... тормыш фарватерыннан сез, ышаныгыз миңа, бик ерак арада торасыз.—Гайнан абый теләктәшлек белән китаплар торган киштәләргә күз төшереп алды да көрсенеп куйды һәм кыскача нәтиҗә ясады:—Тынлык сезнең монда, о-хо-хо, тынлык һәм күңелсез, ямансу.

—Кадерле Гайнан Фазлыгалләмович, сез юкка кайгырасыз, минем тормышым да, сезнең каһарман һәм төрле хөрмәткә лаек булган тормышыгыз үзегезгә күңелсез тоелмаган кебек, миңа да алай тоелмый. Үз фарватерынны, үз тормышынны уй-фикер барлыкка китерә.

—Уй-фикер тормышны барлыкка китерә, дисез... Сезнеңчә, фантазия чынбарлыктан өстен булып чыгамыни? Фантазия—ул башын комга яшергән тәвә кошы. Фантастик кечкенә дөньягызда үзегезне эгоист итеп сизмисезме? Үзегез теләгәнчә яшисез. Укыйсыз, язасыз, хыялланасыз, кайчандыр безнең фәкыйрь яшәешебезне үзгәртеп корачак марсианнар турында хыялланасыз. Ә үзегез соң, үзегез ничек? Үзеңне якындагыга—чынбарлык булган кешегә, ә кешелеккә түгел!—багышламау, бала да үстермәү, агач та утыртмау... Телисең—йокла, телисең... Эшкә дә атнасына бер тапкыр гына. Рәхәт, фантастика!

—Ләкин мин өйдә эшлим. Менә монда, хәзер... Шулай көйләнгән инде. Мин обсерватория тапшырган эшне башкарам. Мин й-йокламыйм д-диярлек. Т-тәүлегенә ө-өч- д-дүрт сәгать...

Николай Сергеевич артык дулкынланып китте, тик бу мәгълүматсыз кешегә хәтере калмады. Барысын да аңлатып бетереп булмый. Моннан ярты ел элек кенә аның алтылап лаборантка кызы, тәҗрибәле ике һөнәрие бар иде. Ләкин теманың киң колачлы булуы аркасында аны ябарга тырыштылар, ә аннары бөтен бүлекне башка тармакка күчерү белән чикләнделәр. Житәкче түбәсе, хезмәттәшләре әйтмешли, ул болытлар артындагы йолдызларга терәлгән тау итәгендә ялгызы гына калды. Ләкин шунын белән дә канәгать иде ул.

—Тәүлегенә өч-дүрт сәгать... Ахырында мин юлга да вакыт әрәм итмим.

Шулчак ишек шакыдылар.

—Мөмкинме?

Үзенең бик тә модалы ак плащы белән кыштырдап, Кыям абый Мөхәммәтшин килеп керде. Шәех аны Николай Сергеевич белән җәй башында таныштырган иде һәм шуннан соң элеккеге артист галим янына килгәләп йөри.

Шәехнең үги әтисе белән Кыям абый таныш түгел иде. Николай Сергеевич аларны үзара таныштырып алганнан соң элеккеге артист, кавалерист, инвалид, алмагач ботагының тәрәзәгә шомлы итеп суккалаган тавыш тутырган паузадан соң:

—Минем сезне кайдадыр күргәнем бар шикелле тоела,—дип куйды.

—Әгәр дә сез элеккеге цирк артисты икән, мин дә цирк хезмәткәре,—диде Гайнан абый, елмаеп.—Ә безнең кешеләр бер-берсен белергә тиеш.

—Туры килгәндә әйтеп куйыйм, Гайнан Фазлыгалләмович та фронтовик,—дип шатлык белән белдерде Николай Сергеевич.

—Кайсы фронтта сугыштыгыз?

—Әй-й! Кайда гына якалашмадым мин, Кыям абый! Мине язмыш кая гына ыргытмады да, ни генә кыланмады минем белән! Чумырып эчтем, чумырып...—Гайнан абый каты бармакларында «Казбек» папиросын әйләндергәләде.—Кирза итек белән эчтем! Башта көнбатыштан көнчыгышка тәпиләдек, соныннан көнчыгыштан көнбатышка. Житәрлек эләкте... Ә сез үзегез кайда сугыштыгыз?

—Смоленск өлкәсендә сугыштым, Мәскәү янында сугыштым...

—Ә-ә, юк, менә мин, әйтергә кирәк, нәкъ аларда булмадым. Юк, булмадым.

—Алай да кайда күрдем икән соң мин сезне?

—Менә,—диде шунда Николай Сергеевич,—Гайнан Фазлыгалләмович, китаплар—суррогат алар, ди.

—Минем онык та шуны ук әйтә. Нәрсә инде синең бу картиналарың, ди. Левитан, Айвазовский, Урманче нәрсә инде, ди. Чын урман, чын дингезләр, тере кешеләр белән хозурлану күпкә яхшырак, янәсе... Юк, мин сезне, чыннан да, кайдадыр күрдем бит!..

Кыям абый Николай Сергеевичта шактый озак утырды әле, ә Гайнан абый артык тоткарланмады.

—Комачауламыйм, комачауламыйм...— диде ул.—Өч кеше—әңгәмә түгел инде.

«Кайда күрергә мөмкин икән ул мине?»—дип баш ватты ишегалдына чыккач папирос төтәтеп жибәргән Гайнан абый. Һәм хәтерендә казына башлады, тик һич тә исенә төшерә алмады.

## Дезертир

Гайнан Фазлыгаллә́м улы Субаев үз гомерен бәяләп бетерми, аның кадерен белми иде. Һәрхәлдә ул үзе шулай ди. Галим күршесе белән бәхәсләр вакытында ул урынлы да, урынсыз да тәмләп кенә:

—Гомер ул, хөрмәтле Николай Сергеевич, тиен генә...—дип кабатлады.—Гомер, кадерлем минем, ул бары тик аның мәгънәсезлеге белән көрәш кенә.

Бер тапкыр Николай Сергеевич аңа аптырап каршы килде:

—Ә ничек соң сез фронтта?..

—Юк нәрсә!—дип жавап бирде ана «хәрби майор».—Уен!.. Бар нәрсәнең дә кирәксез икәнлеге турында уйламас өчен чыгарылган олы ир-атлар уены. Менә миңа ике ел элек операция ясадылар. Жәрәхәт иде. Ярты ашказанын кисеп аттылар. Шуннан соң мин бер тәүлек уяна алмадым...наркоздан. Ә өнгә килгәч, беләсезме, иң беренче булып нәрсә турында уйладым? Тагын яшәргә, үлем юлында тагын шушы газаплану! Уянмасаң яхшырак буласы икән. Аягыңны бер ел алдан сузасыңмы, әллә бер ел соңгаракмы—нинди аерма? Аннары, үлгәннән соң, бернәрсәнең дә кирәге калмый бит. Анда сиңа тиешле еллар хезмәт иткән өчен зиннәтрәк фатир бирмиләр.

—Зиннәтлерәк,—дип төзәтте аны Николай Сергеевич әдәп белән генә.

—Хәтта шулай булса да, барыбер тими ул. Әгәр дөньяда Алла белән Аллаһ бар икән, алар иң кешелексез залимнәр. Алар кешене якты дөньяга чыгарып куялар да, борыны белән төртәләр. Янәсе, менә тормыш ничек

татлы, авыз итеп кара... Һәм аны тагын—караңгылыкка, капчыкка. Мин үлемнән курыкмыйм. Кайда булганбыз, шунда ук әйләнеп кайтабыз да. Анда моннан начаррак булмас.

Әнә шулай дип саный иде Гайнан Фазлыгалләм улы Субаев.

Ләкин егерме ел элек, сугыш башланганда һәм аның фамилиясе Ашаров, ә исеме Бослюд булган чакта ул бөтенләй алай дип санамады. Аның исеме «бытие определяет сознание людей» («кешеләр аңын яшәеш билгели») дигән сүзләрдән алынып ясалган. Ләкин ул үз исеменең андый мәгънә белән тулыландырылган булуын белми. Әтисе аны ана, унҗиденче елда туган малайга, «босой люд» («яланаяклы кешеләр») хөрмәтенә биргән дип раслый иде.

Кырык беренченең июнендә мобилизация чакыруы алгач, Бослюд Аширов, Кызыл Армия бу изге сугышта ничек тә аның ярдәменнән башка да җинәр, дигән карарга килде һәм, ул кәгазьне ертып ташлады да, шул ук көнне Пенза өлкәсендәге туган авылы Аксеновкасыннан, Каширдан—тугыз һәм Мәскәүдән туксан тугыз чакрымда булган кечкенә генә Ступино шәһәренә китеп барды. Ступинода аның аңа элек кунак булырга да һәм бераз эшләп алырга да туры килгән начальник абзыйсы яши иде. Җирле масштабта санаганда зур кеше иде ул анда.

Ул чакта Аширавка егерме дүрт яшь иде. Артта—җиде класс белем, өчьеллык совет партия мәктәбе, авыл мәктәбендә укытучылык итү. Инде ике малае да бар, ә хатыны әле беренчесе генә иде.

Абзыйсы ярдәме беләнме, Ходай булышлыгы беләнме, Аширов җирле совхозга җиңел генә хисапчы-нормировщик, ә аннары эшче тәэминат бүлегенә экспедитор булып урнашты. Эше һич тә авыр дип зарланырлык түгел иде. Торак белән дә булышты абзыйсы—аны элеккеге хезмәттәше, бухгалтер, ярым сукыр Игнатий Сильвестровичка прописката кертте. Бүлмәсе яртылаш чарлакта диярлек, аның каравы моннан бөтен тирә-юнь күренеп тора һәм кереп-чыгып йөрү урыны да аерым. Изге китапта әйтелгәнчә, яшә һәм үрчи бир. Әмма бу рәхәтлек тиздән куркыныч астында калды: Дәүләт оборона комитеты илле яшькә кадәрле барлык инвалидларга да яңадан комиссия үткәрү турында белдерү ясады. Аширов нәселле үгез шикелле сау-таза һәм җанын пинжәк кесәсендәге дүрткә бөкләнгән, монда, Ступинода кулга төшергән үпкә туберкулезы белән авыруы турындагы медицина белешмәсе җылыта иде. Ләкин ул белешмә, барлык абруйлы мөһерләренә карамастан, Дәүләт оборона комитетының шушы указы нигезендә буш кәгазьгә әверелеп кала. Аширов шундук кулыннан бөтен нәрсә килә торган абзыйсы янына йөгереп килде. Ә ул командировкада булып чыкты.

Рухы төшәрлек хәл иде бу.

Сократныкы шикелле маңгаен җилпәзә сыман итеп ясалган тәрәзәнең пыяласына төрткән килеш, Аширов уйлана-уйлана тирә-юньне күзәтә бирде. Нинди тишек соң бу Ступино? Башкала да якын диярлек, шулай да монда батып калырга Ходай язмасын. Ул яңа гына бер стакан көмешкә эчкән иде. Тик теләгән исереклелек килмәде. Аның ике ярты аракысы да бар иде барын, ләкин ул «энзе» шул. Әле алда чишәргә туры киләчәк проблемалар аз булырмыни?! Аширов аның ыгы-зыгылы кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне җайлаучы хәйләкәр көчен белә һәм аны тереклек суы белән чагыштыра: үлгән эшкә (әйе, эшкә—гәүдәгә түгел!) сип син аны, ул шундук хәрәкәтләнә башлый.

Кич җитте. Аның күңелендә дә эңгер-меңгерле иде. Аширов йорт хуҗасының сукырларча вак һәм сак адымнар белән өйгә таба якынлашып килүен нәфрәт белән күзәтеп торды. Аның иртән яңадан комиссия үтәргә

Каширга жыенуы исенә төште. Шунда кинәт аңа кайнар су сипкән шикелле булып китте. Туктале, монарчы ничек башына килмәгән соң бу?! Уйлап бетермәгән ләбаса. Шунда ул бер шешә көмешкәне эләктереп алды да... хәер, юк, болай түгел, монда аракы, нәкъ аракының үзе кирәк! Ярты янына бер кисәк дуңгыз мае—сало, бер банка томалап пешерелгән кәбестә алды һәм баскыч буенча аска йөгереп төшеп китте.

—Игнатий Сильвестрыч, исәнмесез! Йә, ничек анда Каширда? Симуляциядә фаш итмәделәрме үзенне?

—Шулай булмый соң! Ишектәге йозакны да күрмим бит мин. Булыш әле!—дип хуҗа кеше үзендә вакытлыча фатирда торучысына лупага охшаш күзлеге аша зур булып күренгән күзләрен күтәрде дә ачкычын сузды.

—Булдырабыз без моны!—диде Аширов һәм мизгел эчендә эленмә йозакны ычкындырып та куйды.—Ә мин, минем хуҗам бу хәрби комиссияләрдә йөреп интегеп беткәндер, бүре шикелле ачыккандыр, дип уйладым. Ә өендә, әйтегез, буйдакны кайнар кәбестә ашы белән кем көтеп тора?! Менә кайбер нәрсә эләктердем мин монда... Энгер-меңгерне компаниядә уздыру үземә дә күңелле булыр.

Игнатий Сильвестрович бер сулышта эчеп җибәргән беренче стаканыннан ук исерә төште.

—Әһә!—дип куйды яшь квартирант, буш стаканын иске өстәлгә шап итеп куйган хуҗасына хөрмәт белән карап.—Мин алай житез булдыра алмыйм.— Аширов бер-ике мәртәбә йотып алды да йөзен җыерды һәм, сулыш та алмыйча, авызына кәбестә кабып җибәрде.—Сыйланыгыз, Игнатий Сильвестрыч, менә май, их, ничек рәхәт тә инде аракыдан соң! Ә-ә?!

—Дуңгыз мае, дуңгыз мае... Мин аларга: «Бәлки, кайдадыр икенче эшелонда булса да кирәгем чыгар»,—дим, ә алар: «Сезгә, әткәй, бу күзегез белән өегезгә кайтып житәргә язсын»,—диләр.—Игнатий Сильвестрович дуңгыз маеның чәйнәлгән тиресен идәнгә төкерде.—Менә Каширда яна күзлек сатып алдым әле. Очраклы гына. Алай да минем элеккесеннән яхшырак күрсәтә.

—Мөмкинме карарга?

—Мә.—Ул тәмам туйдырып бетергән нәрсәне алган шикелле күзлеген борыныннан салдырды да, сукыр килеш яңа кисәк май эзләп, кулы белән өстәлдә капшанырга тотынды.

Аширов күзлекне киеп куйды.

—Берни дә күрмим.

—Менә шулай шул!—диде Игнатий Сильвестрович, урындыгыннан күтәрелеп. Аннары кулларын алга сузды да, ишек артындагы кадакка элеп куйган пинжәгенә таба кыштырдады. Аннан папирос алып, кабызып җибәрде.—Биш ел элек авылда бәрәңге алганда идән астына барып төштем... Шуннан бирле күпме?.. Һәм менә... Башта ерактан начар күрү юк кына нәрсә шикелле тоела иде... Ә хәзер бөтенләй күрмим диярлек. Син минем алда бары тик тап сыман гына шәйләнәсең . Әйдә сал әле тагын...

Аширов аңа күзлеген кире кайтарып бирде һәм, үзенекеннән дә өстәп, аның стаканын тутырып куйды.

—Беләсеңме, ничек төз ата идем мин?—дип исерек килеш сулкылдап елап җибәрде Игнатий Сильвестрович.—Ва-арашилов ату-учысы м-мин! Аңлыйсыңмы? Ә-ә хәзер нәрсә инде!..—Һәм тагын берьюлы эчеп җибәрде.

—Сезгә анда, Каширда, нинди булса да кәгазь бирделәрме соң? Белешмәме анда, котылу турында?

—Барлык мөһерләре белән! Бөтенләй чиста итеп калдырдылар. Менә...

Шушы кәгазь белән берсекөнгә ак билет язып бирергә тиешләр,—дип ул чалбарының арткы кесәсеннән бумажнигын алды да, аннан берниндн ялгышсыз җыйнак кына итеп бөкләнгән бер бит кәгазь чыгарды. Аны куллары белән яза төште, тик аннары, андагы танымаслык итеп сырланган медицина язуына төшенә алмыйча, өстәлгә ташлады. Аширов ул кәгазьне әләктереп алды:

—Әйе, мөһерләре матур. Кем суга инде аларны анда?

—Юбкалы бер сержант анда теркәп торучы... Күз табибына күренгәннән соң, аның нәтиҗәсе буенча терки.

—Ә ул ничек тикшерә, күз табибы?

—Берничек тә. Мин аның янына таба килгәндә сукырлыктан урындыкларны аударып барам икән, аның нәрсәсен тикшерәсең? О-хо-хо...—Игнатий Сильвестрович башын учларына салды, күзлеге өстәлгә шуып төште... шундук бүлмә буенча авыр, гырылдаган тавыш җәелде.

Икенче көнне төштән соң медицина комиссиясе эшләгән Кашир тулы булмаган мәктәбе бинасыннан, кул таягы белән баскыч басмалары буенча шакылдатып, лупага охшаш күзлек кигән, бераз гына бөкрәйгән бер ир килеп чыкты. Әле ул һич тә карт түгел иде, ләкин аның хәрәкәтен сукырлык тоткарлап тора, аның зифа буена кыюсызлык өстәп һәм бу кешегә карата кызгану хисе тудырып, адымын кечерәйтә сыман иде. Аңа юл аркылы чыгарга булыштылар, кая ничек барасын аңлаттылар, ләкин ул таныш булмаган шәһәр урамнары буйлап, сөртенә-сөртенә, вак-вак атлап, шактый озак йөрде әле.

Бу Бослюд Аширов иде.

Бер сәгать элек, ярым чишенгән килеш бер бүлмәдән икенче бүлмәгә, бер табибтан икенче табибка күчә-күчә йөргәндә ул үзенең яшь, сау-таза гәүдәсе белән балкый иде. Аны алай да, болай да әйләндереп карадылар, бармаклары белән дә каккалап-суккалап алдылар, күкрәген, йөрәген тыңладылар... Үз чиратында ул үзе дә тирә-ягына күз салгалады, тыңлаштырды... «Егет»нең «күрү сәләте йөз процент» дип тапкан окулисттан соң кичә кичен исерек Игнатий Сильвестрович белешмәсеннән фотографик төгәллек белән күчереп алган ялган нәтиҗә белән, барган көйгә авыр күзлек кысаларын колак артына кыстыра-кыстыра регистратура-теркәү өстәленә томырылды, һәм «сукыр» килеш юбкалы сержантның күкрәгенә килеп бәрелде. Ә тегесе исә шундук ялган документка мөһер сугып куйды.

Аннары шатлыктан ул бу уенга бирелеп үк китте, хәтта аны урамда җитәкләп йөртүчеләр дә табылды.

Ул вакытта ул үзе өчен бик тә әһәмиятле булган нәтиҗә ясады: симуляция симуляция белән, ләкин бүтән берниндн хәйләкәрлек тә ялган документлар шикелле көчкә ия түгел икән. Русьта хәзерге көндә изге тәрегә түгел, ә мөһерле кәгазьгә табыналар.

Ул Ступинога көн ахырында кайтып керде. Игнатий Сильвестрович югалган күзлеге өчен бик кайгырып утыра иде.

—Өр-яңа иде бит!—дип өстәл астында шуышты ул.—Кая гына куйдым икән соң мин аны кичә?

—Менә бит алар, комодта ята, көзге артында,—дип көлеп җибәрде Аширов, күзлекне кесәсеннән чыгарып.—Шәт, кичтән яшереп куйгансыз да, ә иртән онытткансыз.

—Менә рәхмәт! Мин бит ансыз, ни...ни шикелле...

—Монысы дөрес инде: әйе, шикелле...—Аширов чүмеч белән чиләктән су чумырып алды да эчеп җибәрде.—Тфү, җылы икән!—Һәм ул үзенә, югарыга менеп китте.

Көзгә таба Ступинода йортлар бөтен кварталлары-кварталлары белән

хужаларсыз калды. Эвакуация: кешеләр көнчыгышка таба агылды.

Сильвестрыч чарлагында тагын атна чамасы торганнан соң Аширов шәһәр читендәге аулак чокыр буенда ташлап калдырылган тактадан әмәлләгән бер йортка күченеп килде. Кесәсендә—«ак билет», эше белән араны өзде, хәлнең ачыкланганын (газеталарга, радиога ышанмый иде) өмет итеп, абзыйсының командировкадан кайтуын көтте, ләкин ул суга төшкән шикелле юкка чыкты.

Аны талчыктыргыч эшсезлектән базар ыгы-зыгысында (каян киләдер бу хәтле халык?!) брезент итек сатарга маташкан хужалык взводы старшинасы белән танышлыгы коткарды. Аширов аннан ул итекне сатып алды да, аны юарга дип, ул хәрбине үзенә чакырды. Тегесе каршы килмәде. Аракы шешәсе янында бик тиз уртак тел таптылар. Сөйләшә торгач, кунак, итеккә күрсәтеп, анда мондый тауарның күп булуы, тик менә аны кемгә һәм ничек төртергә икәнлеген белмәве турында да әйтеп куйды.

—Тауары булса, алучысы табылыр,—дип ышандырды аны Аширов.

Инде монысы көмешкә булган икенче шешә янында куллар кысышып килештеләр: старшина кием-салым—киелгән гимнастерка, эчке киемнәр, урын-җир әйберләре, штатский киемнәр (мобилизация тулы көчкә бара, ә кешеләр сугышка өйдән ялангач китмиләр бит) алып килергә алынды, ә Аширов аларны сатып җибәрергә вәгъдә бирде.

Аshировның сугышка кадәрле җыйган акчалары да бар иде әле. Кулай хакка ул арбасы белән ат кисәге сатып алды. Аның уйлавы буенча, алдагы эш уңышлы барып чыгарга тиеш. Аны кулдан ычкындыру ахмаклык булыр иде.

Кооператив эшли башлады. Старшина, үзара килешкәнчә, часть өчен мунча көне булган пәнҗешәмбеләрдә килешенгән урынга килеп йөрде. Аннары инде бер дә яшеренмичә, турыдан-туры өйгә үк килә башлады. Килә дә «тауар»лы капчыгын өйалдындагы бәрәңге әрҗәсенә ташлый һәм, компаньонын көтеп тормыйча, китеп тә бара иде.

Аширов шәһәрдә сату итмәде, ә үзенең җигүле транспорты белән якындагы авылларга чыкты. Бер үк җиргә ике мәртәбә беркайчан да кагылмады. Яхшы гына табыш алды, кайчагында көмешкәгә, ашамлыкка алыштырырга да чирканмады, чөнки ул елларда крестьянда нинди акча булсын! Ләкин барыбер төшкәли иде. Валчыкларын, ягъни аз өлешен, аны җыйнаксызлыгы өчен әрли-әрли, старшина белән бүлеште. Чөнки ул ничектер бер тапкыр үзе белән хәтта бер солдатны да ияртеп килде, үзенә генә капчык күтәрү авыр, имеш!

Шулай бер мәртәбә, эшләре җайлы гына барганда, сүрән октябрь кичендә, Аширов чираттагы сәфәреннән кайтып, атын яңа гына туарган һәм арып-талчыгып өенә кергән генә иде, капка төбендә машина тормозы тавышы ишетелде. «ЗИС», дип билгеләде Аширов һәм шунда тәрәзәдән карады да өнсез калды: грузовик кабинасыннан җиргә каешы аяк астыннан эләктереп куелган фуражкалы старлей сикереп төште, ә кузовыннан җиргә винтовкалы солдатлар сибелде. Ә алар артында каешсыз, пилоткасыз, чәчләре тырпайган, тузып беткән иске, ертык киемнән старшина-компаньон калыкты...

—М-м, хәшәрәт, саткан!—дип кипкән тамагы белән төкереген йотып җибәрде Аширов һәм, өеннән атылып чыкты да, ярым ауган читән аша сикереп, чокырга ташланды.

Үзе белән берни дә алмады. Хәтта бу турыда уйларга да өлгермәде. Үзе дә күзе генә килеш очып чыкты. Шөкер, очып чыкты бит! Тик өендә тузанлы бер авылда бер карттан тишелеп беткән иске итеккә алыштырып алган, барабанында өч патроны булган наган гына кызганыч калды. Менә хәзер

ул наган кемгә эләгер, аны матрас астыннан кем алыр да төргән чүпрәген кем сүтеп җибәрер...

Аширов үзендә утлы коралга тартылу гадәтенең кайчан барлыкка килүен үзе дә белми иде. Бәлки, БГТО нормасын тапшырганда кулында өч линияле винтовка тотканнан соңдыр, ә бәлки, аннан алданрак, күрше Гена-башкисәр самопалыннан каргаларга атканда үзенең кулын пешергәннән соңдыр. Әлбәттә, старлейга да, солдатларга да атарга җыенмаган иде. Ләкин барыбер «пушка» белән яшәве—ышанычлырак тормыш инде ул! Теләмисең, теләмисең дә, ә менә телисең икән—атасың да үтерәсең.

Солдатлар төз лапас астындагы авыр тәртәләр белән шалтыр-шолтыр килгәннән соң, бераз америка өрәңгесе һәм аю баланы сырып алган чокыр караңгылыгына караштырып тордылар...

—Дөм-караңгы...

—Ник пычагыма китми шунда!

Алай да чокырга төшә башладылар. Ләкин шунда берсе:

—Ая-а-ак!—дип уфылдап куйды.

—Сындырдыңмы әллә соң?—дип сорады берсе.

—Кем белгән аны!

—Шайтаным да күренми, иртәрәк чыгарга кирәк булган безгә.

Шунын белән кире чигенделәр дә.

Көзнең сукыр төне пәрдәсе астында, тып-тын калып, засада юкмы икән дип тыңлый-тыңлый, Аширов чокырдан күтәрелде дә Ступинодан чыгып китте.

## Татлы тормыш

Оча очкалак шәһәрдән шәһәргә, авылдан авылга сикерә-сикерә, фамилияләрен, шәхес таныклыгын, сыеныр, ашау урыннарын, сугыш вакытында тагын да тиз ышанучанрак булып калган гади хатын-кызларны алыштыра-алыштыра. Оча һәм җил аңа бары тик бер генә якка—көнчыгышка таба гына исә. Аширов Казанга килеп чыкканда инде сугышның өченче елы бетеп килә иде.

Аны канатларын кагына-кагына чыркылдашкан чыпчыклары белән март иртәсе каршы алды. Төнге суык чиратып алган карның һәр бөртегендә кояш нуры ялтырый. Аширов таныш булмаган, ләкин ул санаганча, туган, кайчандыр куәтле ханлыкның башкаласы булган бу шәһәрнең өйләрен, тыкрыкларын, кешеләрен күзәтә-күзәтә аяк астында шытырдаган бозлы юлдан вак-вак атлап бара. Ул, Бослюд Аширов та, шушы шәһәрнең бер кан тамчысы бит. Ярар, аның тормышы еракта узсын-аксын ди, ярар, йомыркадан да Алла белсен кайда чыккандыр ул, ләкин Ашировлар—моңа Ходай шаһит!—ыруларының башы—ватаны булган бу шәһәрне һәрвакыт өзелеп сагынып яшәделәр, һәрвакыт монда күчеп килү турында хыялландылар. Монда кайчандыр туганнары да—әтисенең ике туган абыйсы, кайсыдыр апасы яшәгәннәр... Хәзер кайда инде ул абый-апалар, бар, табып кара син аларны монда! Казан... Ка-за-ан! Аның ерак әби-бабайлары рухы белән тулган һавасы гына да ни тора!

«Юк,—дип уйлады Аширов,—барлык эшләрне аннан соң әмәлләргә өлгерермен, берәр җаен табармын, башта монда, һичшиксез, шушында эләгеп калырга кирәк. Житәр арлы-бирле бәргәләнеп йөрү, моннан соң шушы туган җирдә тамыр җибәрермен, ләкин беренче эш итеп Кремльгә үтеп керергә, легендар патшабикә Сөембикә һәйкәленә баш иярга кирәк булыр... Ул манараны авып бара, дип әйтәләр... Әти, Иван Грозный гаскәрләре крепостьны алгач, гүзәл патшабикә ин биек манараның

гөмбәзенә үк менә дә шуннан аска ташлана, дип сөйли иде. Үлгән, ләкин дошманга бирелмәгән. Менә ничек! Һәм манара шушы көнгә тикле аның исемен йөртә. Әйе, беренче эш итеп Кремльгә, Кремльгә...»

Аширов аксый-аксый тайгак урам буйлап шәһәр чите районы булган Бишбалтага таба атлады. Товар поездыннан ул шәһәргә берничә чакрым кала сикереп төшеп калды. Состав ташбака адымы белән генә бара сыман иде, ләкин барыбер барган көенә сикереп төшү—бу сиңа кәс-кәс кенә басып перронга төшү түгел инде. Шулай да тезен авырттырды әнә, рельс читендәге кар астында шпалга килеп бәрелде.

Борынына хәтле диярлек боз белән капланган су колонкасы янында яланаягына галош, өстенә тезенә хәтле житкән солдат сырмасы кигән, күзенә кадәр төшкән, төсен дә анлап булмаслык дәрәҗәдә унып беткән яулык япкан бер хатын көянтәсе белән чиләкләрен эләктереп маташа иде. Аширов ана житәрәк адымын әкренәйтә төште.

—Сәлам, әбекәй!—дип дәште ул хатынга.

—Нинди әби булыйм ди мин сиңа!—дип ачулы гына ырылдап куйды хатын, көянтәсе белән тураеп.

Күнеккән күзләре белән Аширов аның сүзеннән башка да, ерактан ук суга яшь килен килүен күреп алды алуын, ләкин аның күнелендә үз нияте бар иде.

—Гафу итегез, гүзәлкәй, ялгышканмын. Сусау күзне томалаган, эчәргә бирче!

—Чиләктән түгел бит инде...

—Ә ни булган? Мин авыру кеше түгел.

—Соң, су боз шикелле бит!

—Син үзең саклан,—диде Аширов, аның ялангач балтырларына ымлап,—салкын тидерерсең дә, аннары иреңне дә күтәреп алалмассың.

—Анысы синең кайгы түгел.

—Минеке түгелен минеке түгел дә, ләкин барыбер безнең ише солдат туганныкы. Һәркайсын буйдак итеп калдырырсыз да, булыр аннары эшләр.

—Солдат табылган!—дип, яшь килен үзенең кызыксынучан карашы белән таныш булмаган кешене баштанаяк капшап чыкты.

—Син минем драп пальтодан булуыма карама, инде елдан артык фашист бомбасы тарафыннан госпитальләр буенча жибәрелгән кеше мин. Заманында мондый киемнәр генә кимәдем. Йә, эчәргә бирәсеңме соң инде?

—Киттек әйдә, кешеләрчә булсын...

—О! Менә монысы бөтенләй икенче эш! Кая, хезмәт фронты вәкилләренә булышыйк әле, ачык йөзле солдат хатынына ярдәм итик,—дип Аширов чиләкле көянтәне үз иңенә алып салды.—Свердловскидан кайтып килеш, госпитальдән. Шуннан качтым дияргә була, ауный-ауный тыл матрасларын изәргә түземлегем калмады. Минем дуслар сугыш кырында гомерләрен аямыйча кан коялар, ә мин... Юк, житте!

—Эчкерсез гафу итегез! —дип яшь хатын фронтовикны алга уздырды.—Үзегез дә инде... Индә солдат сырмасы икән, мәжбүри рәвештә солдат хатыны дигәнме?—«Әбекәй» турында искә алмады.—Саграк булыгыз, тая монда,—дип кисәтте ул инде бөтенләй дусларча һәм сукмак борылышында сырмасының озын җиңе белән селтәнеп алды:—Әнә минем капкалар, әнә тегеләре...

—Каерылып ачылганымы?

—Каерылып ачылмаган, бөтенләй юк ул. Шушы көннәрдә иртән чыксам, карыйм, җил алып киткән шикелле. Кемгә нигә кирәге чыккандыр? Менә хатын-кызга ничек авыр, әгәр дә ирен...—Ул әйтеп бетермәде, яулыгы

почмагы белән авызын каплап, йөткереп куйды.

—Хәбәр иттеңме соң?

—Нәрсә?

—Югалган капка турында кирәк җиргә җиткердеңме, дип сорыйм?

—Кешеләр көлдерергәме? Сугыш бара, ә мин моның белән... янәсе, диверсантлар капканы сыпырганнар!

Аширов кар күмеп киткән ишегалдына килеп кергәч, сарайчыкка һәм бер якка авышкан бәдрәфкә таба сузылган ялтыравыклы сукмакларга карады да үз-үзенә: «Менә шушында ябышып калам мин»,— дип куйды. Ә ишетелерлек итеп, кызганып:

—Әйе, хуҗабикә, синең монда ирләр рухының исе дә юк икән бит,— диде.

—Каян килергә ди аңа, ирләр рухына! Абый белән әти кырык беренчедә үк үле хәбәрләре белән сәламләделәр...

—Ә ирең?

—Ә-ә!..—булды аның җавабы. Алай да ул Ашировка үзеннән дә яхшы итеп: «Бар да әйбәт, картлач, син монда үз өеңдә шикелле бул, һич тә ялгышмадың—язмыш яхшы ярдәмчең икән синең, ә үзең бик тә шәп һәм кире кагып булмый торган»,—дип әйтеп бирде.

—Исемең ничек синең, гүзәлкәй?

—Ә синеке?

—Минеке—Иван Петров.

Хуҗабикә җиңеннән ачкычын чыгарды да өйалды ишеген ачты.

—Узыгыз!

Их, син, тиз ышанучан һәм йомшак, киң күңелле Россия-анакай! Юләр белән бертуган син! Сине ат урынына җигеп, су гына ташырга, әй! Изге гадилек иясе Мария, моннан өч ел элек дәүләт куркынычсызлыгын саклаучы төрле оешмалар урнашкан Черек күлдәге йорт чекистының карлыккан тавыш белән алдагы көндә кулга алынган иренең шпион һәм Ватанны сатучы булуы турындагы сүзләренә ышанган кебек үк, балалар беркатлылыгы белән, фронтовик Иван Петровның яралануына да ышанды.

Аширов соңыннан, фронтта алган авыр контузиядән һәм ничә еллар буе госпитальләр буенча сәяхәт иткәннән соң хәрби хезмәттән азат ителгән эпилептик Иван Петров булып Казанда янадан туып алгач, Татар бистәсендә яшәп ятучы ирсез, эчкерсез, өстенә солдат сырмасы кигән, кешегә ышанучан бер рус хуҗабикәсе Мария булып чыккан бу яшь киленнән эчәргә су сорарга уйлап һич тә ялгышмавына сөенеп туймады. Хәер, Аширов өчен—рус хатынымы ул, татармы, чуашмы,—моның бернинди аермасы да юк иде. Аның бай хезмәт дәфтәрендә тегеләре дә, болары да һәм дүртенчеләре дә бар иде инде. Гомумән алганда, ана Иван Петров документлары белән ниндидер Мәрьямгә караганда Мария пристанена тукталу уңайлырак, гадирәк тә булыр дип уйлады ул. Мария аның документлары белән кызыксынмады да. Хәер, сугыш вакытында ялгыз хатынга шундый бәхет—куллы-аяклы ир тәтегәндә, кем сорап маташа инде аларны! Ул үз куышына «кырык беренченең беренче хәтәр көннәрендә үк бөтен гаиләсен—хатынын, балаларын, туганнарын югалткан» бәхетсез ирне сыендырды, канат астына алды. Үзләренең кияве—апасының ире, анда хәрбиләштерелгән сак командирының урынбасары булып эшләгән чатан Костя Обухов Иванга элеваторга эшкә урнашырга да булышты. Мария Обуховларга бернинди вак-төяк үтенечләр белән дә көчләп тагылмады, ул, өй чикерткәсе шикелле, мич артындагы үз урынын яхшы белә иде. Нигә фәкыйрьләнеп беткән кешегә башкаларның шома, мул гаилә тормышына кереп маташырга! Кырык беренче елның кышында аның ике яшьлек

Антошкасы үлгәндә дә булышмадылар бит. Нәрсә инде... Ә менә монда аякларына тезләнде, үз уставын, горурлыгын үзе бозды.

Шулай итеп, Мариянең яна иренә Обуховлар уйламаганда-көтмәгәндә ярдәм кулы суздылар. Янәсе, «халык дошманы түгел, фронтовик бит!» Көчкә-көчкә генә, майлап-жайлап кына булса да, ашлык склады мөдиренең урынбасары итеп этеп-төртеп керттеләр. Монарчы башка шәһәр һәм авылларның төрле типтагы склад хезмәтләре белән аралашу буенча зур практикасы булган Аширов (ялган документлар белән үзенә һәм «артельчы» дусларына ашлык, он, азык-төлек яздыра иде ул), үзеннән-үзе аңлашыла, бу законлы эшендә дә кимен куймады. Өрене беренче көндә үк, гарип куллы ир заты, таза гына хатын һәм күңелгә ятышлы, ләкин бигрәк тә тынгысыз булган ике килбәтсез татар ир-аты алып килгән беренче колоннадан ук жыеп алды. Ул диндәшләр, элеваторда яңа һәм кыяфәтенә караганда сантый булган яңа кеше— «начальник Иван»нан курыкмыйча, үз телләрендә бертуктаусыз бәхәсләштеләр. Ашировка арбада бер капчык артык бодай ятуын күрергә дә кирәк түгел иде. Такылдык кабиләдәшләр кайсы олауның нормадан артык икәнен үзләре үк сиздерде. Сантый урынбасар, тәжрибәсезлеге өчен гафу үтенеп, йөкне янадан үлчәде... Йөкчеләр ах-вах килделәр, тавык кебек кытакладылар, гарип куллысы шунда аңа бер чирек аракы белән тавык тәкъдим итте. Тик Аширов алай сай йөзә торган затлардан түгел иде. Аның хакы: бер капчык бодай өчен—ике мең сум! Тегеләрне күндереп маташырга да туры килмәде. Бригада акчалата жыемны түләде дә, начальник кире уйлаганчы дип, һәр арбага берәр туры килгән жиде сул капчыкны тиз генә алып чыгып китте. Аширов башка бригадалар белән эш итмәскә булды. Ходай, сакланганны саклармын, дигән.

Колоннаны чыгарып кына жибәрде, шунда тиргә баткан склад мөдире чабып килде. Станциядә ашлык белән тулы состав бушатканны көтеп тора, ә тимер юл үлчәүләре юк икән. Аширов аңа: «Аны үлчәмичә генә кабул итәргә кирәк,—диде.—Әгәр дә бөтен составны капчыкларга тутыра башласаң, бер атна вакыт үтәчәк»,—диде. Шуннан соң аның шефы үзенең начальнигына таба титаклады. Бераздан кире әйләнеп килсә, кулында: «... номерлы состав йөген үлчәмичә кабул итәргә...» — дигән телефонограмма иде.

Их, Россия-анакай, нәкъ миллионер-сәүдәгәр хатын, ваемсыз патшабикә шикелле, исәпсез-хисапсыз байлыгыңны бөтен гасырлар буе унга-сулга сибеп килдең син! Шул коточкыч сугыш вакытында да саранлануны һич белмәдең. Әрәмтамакларны үтләгәнче ашатып яттың. Тамакларыннан кире килерлек итеп ашады алар, ләх булганчы эчтеләр, үзләренең мунчаларындагы кайнар күмерләргә шешәсе белән сыра сиптеләр. Ә халык, дөньяда сөт һәм май дигән нәрсәләрне онытып (әйтерсең алар дөньяда бөтенләй булмаган да), сөялле, бөрешкән кулларындагы ипи карточкалары белән очы-кырые күренмәгән чиратларда таптанды...

Иван Петров ашлык составын кабул итте...

Бер айдан соң аны, намуслы һәм ышанычлы хезмәткәр буларак, он складына күчерделәр. Инде Костя абыйның булышлыгы кирәкми иде, үзебез дә беләбез, үзебез дә мыеклы, янәсе. Петров-Аширов Сталинныкы сыман мыек үстереп жибәрде, ул мыегы кунган оннан һәрчак ак иде, хезмәт эшчәнлеген маршал колачы белән жәелдерде. Склад мөдире спиртлы эчемлекләрне бик ярата һәм ярдәмчел урынбасарына чиксез ышана иде. Аширов онның капчыгын—биш мең, ә проходнойдан чыгар өчен язып бирелә торган пропуск өчен ун мең сум исәбеннән «шудырды». Ул Казансу артындагы Кәжә бистәсендә мунчалы йорт сатып алды, анда хатыны Марияне пропискага кертте. Шулай итеп, хуш исле һәм байларча тормыш корып жибәрде. Аңа кем, дезертир, карак, спекулянт, дошман,

дисен хәзер! Юк, аны хөрмәт итәләр һәм кунакка да ялангач корсаклы бетлеләр түгел, ә абруйлы завмаг белән завгарлар чакыра. Ә складтагы үз кешеләр турында әйтеп торасы да юк инде. Үзләре дә кунак булырга сорап торалар. Кире кагып бетерерлек тә түгел—чиксез күп иде алар, чөнки Иван Петровта күркәм кешеләр генә җыелган мәҗлес, соклангыч сый һәм дә күңел ачу буласын яхшы беләләр. Нинди катлаулы вакытта яшәүләрен бары тик анда гына онытып торалар да. Мария дә бик шат: менә аның ире нинди, элеккегесе шикелле түгел инде! Ул күз алдында чәчәктәй балкып, тазарып китте, инде йөрми, ә ботларын тирбәлдереп, көймә сыман йөзә. Кырык беренченең декабрь аенда ничек итеп шәһәр тирәсендә лом белән төн җир казыганын, ирсез, ярдәмчеләрсез, кулындагы ике яшьлек баласы Антоша белән ничек ач-ялангач яшәвен, зәңгәр күзле ул йөрәк парәсенең шәм сыман көннән-көн сүрелә баруын, аннары аны, каберенә тәре дә, таш та куймыйча, Архангель зиратына ничек күмүен, чәчләрен йолкый-йолкый ничек үксүен дә бөтенләй онытты. Әле малае исән вакытта шулай бер тапкыр ул, кулын сузып, Обуховларга йөгереп килгән иде. Ләкин ни эшли ала иде алар? Жизни кеше яңа гына култык таягы белән госпитальдән кайтып төште, ә сәкеләрендә үзләренең дә дүрт ач күзе утыра. Соңыннан, инде ул элеваторга эшкә кергәч, Обуховлар аякка басты, әлбәттә. Ә Мария исә—тормышында Иван пәйда булгач кына. Жизнәсе, әлбәттә, булышты Иванга, ләкин Иван тормышларын ансыз да күпләр көнләшерлек итеп җайлый алган булыр иде, чөнки зирәк башлы ул! Менә хәзер Константин Константинович иелгән башы белән инде Иван алдында бөтерелә, аңа ярарга тырыша, акчамы, онмы сорана, ә үзе һаман фронттан соңгы хезмәт биографиясен башлап җибәргәндә баҗасына күрсәткән игелеген хәтерләтеп-хәтерләтеп куйгалый. Әйе, Обухов аны, моның закон буенча тиеш түгеллеген белә торып (Иван Мария белән язылышмаган) һәм Мариянең аннан ана булырга җыенуын сизмичә, ярарга тырышып кына баҗай дип йөри иде.

Бер дә бер көнне Мария иреннән үзен берәр атнага Обуховларга җибәрүен үтенде. Апасы балаларын карап торырга сораган, үзе исә авылга әниләре янына җыенган икән. Ләкин апасының авылга кайтуы барып чыкмады, һәм кояштай балкыган, шатлыклы Мария менә хәзер ул үзенең сөйкемле Иванын иркәләр, ашатыр (ул ансыз начар ашый иде) дип уйлый-уйлый күңеленә якын булган капка төпләренә очынып кайтып керде. Кулында—базардан сатып алган беренче кыярлар салынган челтәр сумка... Кече капканы ачып керсә, туган ишегалдында—көянтә эләрлек төтен! Дүрт аяклы мангал өстендә тимерчыбыкларга тезеп куелган ит кисәкләре ыслана, тирәсендә ниндидер хатыннар, ир-атлар йөренә, үзләре ихахайлап көлешәләр. Житмәсә,шул вакыт мунчадан башына сөлгедән ясаган чалма һәм кендегеннән аста торган киң чалбар кигән кып-кызыл йөзле... Иваны килеп чыкты. Исерек килеш елмая. Аның артыннан— Мариянең халатын киеп алган юеш чәчле бер яшь хатын...

Алар өендә күңел ачулар элек тә була торган иде болай. Ләкин монысы... монысы бөтенләй башка...

Ул кече капкаларын каты итеп япты да чыгып китте. Куып житәр дип уйлаган иде. Юк. Шулай итеп, яңадан апасына кире әйләнеп килде. Аңлатулар кирәк булмады—килгән икән килгән, ярар, балалар карарга кеше булыр.

Ике көннән соң Иван аларга берни дә булмаган шикелле килеп чыкты, тик бераз йөзе генә шешенгән дә яңакларындагы кан тамырлары ачыграк беленеп тора, ә болай каһарман шикелле! Күчтәнәчләр салынган сумкасын өстәлгә куйды да сөйгән Мариясенең бармагына йөзек кигезде.

Кичкә таба Мария өйләренә аның белән бергә кайтып китте. Юлда

Иван аңлатуынча, алар ул мәҗлесне бик тә гаҗәп яхшы пешкән бер хезмәт чарасы унаеннан оештырган булганнар икән...

—Ә мунча турында әлләни уйлама, кунаклар өчен мунча алачыгына сыра гына кертkән идем мин, ә шунда минем кадерле кунагымның хатыны чыгып килә... Ул үзе, Алмаз Фатыйхович, юына калган...

Ышандымы моңа Мариясе, юкмы, әллә булачак балалары хакынамы яисә сукыр мәхәббәте аркасындамы, кем белә аны, ләкин дәшмәде. Бары тик:

—Синең акылың, Иван, ике ындыр табагы хәтле, тик кара аны, араларында кала күрмә!—дип әйтеп куйды.

Аның сүзләре дөреслеккә туры килде. Төнге беренче яртыда өйләренә хәрби кешеләр килеп керделәр дә, әле йокыдан күзен дә уып ачмаган ирен «эт тартмасы»нда (Иван рәшәткәле кечкенә тәрәзәле фургонлы машинаны шулай дип атый иде) Казансу артына, бистәдәгеләр әйткәнчә, шәһәргә алып киттеләр.

## Качу

Аширов-Петров авыл дисәң авыл, бистә дисәң бистә булмаган Караваевоның язмыш һич тә бөтенле ипиләр белән сыйламый торган гомуми төрмәсендә үзенең үткәндәге татлы тормышы турында айдан артык ямансулады, бик тә сагынды аны. Ай ахырына Ашировның Казанга булган ачуы бөтенләй кабарып житте. Балачактан ук бик күп нәрсә ишеткән һәм аның турында Мәккәгә бару турында хыялланган зиярәт кылучы сыман хыялланган бу шәһәрдә үткәргән җәннәт көннәре турындагы хатирәләре бу баракның каты сәкесендә бик тиз очып юкка чыкты, башына идәндә йөгерешкән тараканнардан да начар уйлар килде. Беренче чиратта нигәдер хәтерендә Мария белән сөйләшүләре янарды. Алардан ул легендар патшабикәнең һич тә манарадан ташланмавы, ә үзе белән малаен алып, тыныч кына җинүчеләр белән Мәскәүгә китеп баруы турында белгән иде... Тфү! Бөек максатлар җимерелде. Чираттагы сорау алу вакытында Полуаполлончик дигән көлкеле фамилияле тикшерүче аннан йөзенче мәртәбә: «Дезертирмы?»—дип сорагач, Аширов: «Юк, мин ышанычы какшаган кеше!»—дип җавап бирде.

Ә Мария койрыгын боргаламады, передачаларны төгәл китереп торды. Ул аңа акчаны алдан ук яшереп куйган иде, ләкин киндер билбауга тегелгән һәм стенаның сәндерә өстендәге уемына яшерелгән кагылмаслык запас—алтын хакында гына Мариягә бер сүз дә әйтмәде. Петров Иванны штрафбатка билгеләп куюларын һәм «оештыру-җыену» өчен аны атна арасында шәһәргә җибәрергә тиешләр икәнен белгәч, Аширов чирек аракыга хатыны белән күрешү хокукы сатып алды һәм аңа, Савиновадагы элеккеге Кизич монастерында йорт сатып алырга кушып, «алтын фонд»ның кайда саклангынын әйтеп бирде. Кемгә һәм ничек мөрәҗәгать итәргә, учына күпме төртергә икәнен, иң мөһиме—ул йортны консервациядә, ягъни кирәге чыкканга кадәр запаста тотарга, үзенә аның янында бик күренеп йөрмәскә, ул теләсә кайчан шунда килеп яшеренер өчен, ачкычын болдыр янындагы чүп-чар чиләге астында тотарга кирәклеген аңлатты. Ул йорт бик уңайлы җирдә иде. Янәшәсендә генә—ташландык зират, Мария торып калган Кәҗә бистәсендәге элеккеге йортына да ун минутлык кына юл. Аширов Мариянең үзен аңа эт шикелле сатмаячагын белә иде, чөнки ул аның аркасында матур тормышка иренен тидереп карады һәм, ахмак чабак балыгы сыман, ул инде кармакка эләккән, анда нык утыра, аннан һич тә ычкына алмый. Аның андыйлары элек тә бар иде, тагын да булыр. Ә «алтын билбау» белән каядыр ераккарак китеп үзе файдаланырга акылы

да, ихтыяр көче дә җитмәс. Ул «ахмак чабагы»ның йөрәге астында аның баласын йөрткәнен белми иде әле.

Военкоматның Каравайныкыннан йомшаграк булмаган сәкесендә кунган беренче төндә үк аның төшенә үлгән этисе керде. Аширов, бер дә йокламаган сыман, сикереп торды да, аякларын салындырып, эзәрлекләнгән ерткыч шикелле, караңгыда күзләрен челт-челт йомгалады.

Шундый төшләр була, күрәсең, тик аның төш икәнен дә белмисең. Ә шундыйлары була, әйтерсең күргәнең чынбарлыкта да нәкъ шулай кабатлана торган була. Соңгысы, мөгаен, шундыйлары, юш килә торганнарыннан булгандыр. Ул төндә Аширов сәкесенә менә шуларның берсе очып төште дә инде. Имеш, элеккеге, яшьлегендәге шикелле үк куе-калын чәчле һәм калку яңаклы этисе, аны бармагы белән үзенә чакыра, һәм рядовой Аширов, үзенең озын шинель итәкләрендә бутала-бутала, буйсынып, аның артыннан бара, үзе дулкынлана. Алар зират капкасына килеп җиттеләр, шунда этисе борылып карады да, капканы ачып, аның артына кереп югалды, ә ул бу якта калды һәм шунда уянып китте.

Аширов салкын идәнгә торып басты, тагын бер мәртәбә тыңлап торды. Әгәр дә колак тондыргыч гырылдауны санамаганда—тынлык. Нәрсәдер эшләргә кирәк! Йә хәзер, шундый илаһи төштән соң, каһәр суккан каберләр артка чигенгәч, йә беркайчан да...

Дневальный постына җитәрәк, Аширов тәрәзәләре күптәннән, мөгаен, Иван Грозный Казанны алган чордан бирле үк коелган бәдрәфкә таба юнәлде. Каравайдагы шикелле үк бер катлы, тик таштан салынган барак иде бу. Ул ишегалдына чыкты да тәмәке кабызды (Марияс төрле юлларын табып, аны бөтен нәрсә белән тәэмин итеп тора иде) һәм почмак артында фанер флаглары белән шыгырдаган капкага таба китте. Җәйге куе күктә ай да, йолдызлар да күренми. Почмактан карады, капка төбендә фонарь яктылыгында винтовка тоткан часовой бөрешкән. Аширов кире караңгылыкка кайтты, бераз бормалана-бормалана йөренеп алды, шунда кирәк нәрсәсен—егетләр йодрыгы хәтле чуерташ тапты. Баллы булып тоелган тәмәке төтенен суырып куйды... Эш итәргә!

Часовой аяк тавышына борылып карады да:

—Чава шляисся?—дип сорады.

Аширов аның сөйләменнән алдында күңеленә якын булган милләттәше торганын, аның белән туган телдә сөйләшергә кирәклеген аңлап алды.

—Тартасы килде менә,—диде ул татарча.—Әгәр теләсәң, син дә тартып җибәр, сыйлыйм мин.

—Тартмыйм,—дип мыгырданып куйды часовой.

— «Казбек» минем.

—Барыбер тартмыйм.

—Ярар алайса, ә мин үземнекен сагызлап бетерим инде. Күптән хезмәт итәсеңме?

—Нәстә бәйләнден? Тартырга тарта торган урынга бар. Миңа синең белән сөйләшеп торырга ярамый.

—Ярыймы, ярамыймы, часовой кеше түгелмени, иртәнгә кадәр әле дәшми торып арып бетәрсең, җансыз капка белән сөйләшерлек булырсың. Ә син нигә аксыйсың?

—Контузия... Бар кит әле син моннан, кулга алганчы!—Солдат, әле яңа гына мобилизацияләнгән юеш борынны ясалма усаллык белән күзеннән кичереп алды да, үз будкасына таба борылды. Ләкин бер адым да атлап өлгермәде, Аширов, бөтен көчен җыеп, таш белән аның башына китереп сукты.

## БИШЕНЧЕ БҮЛЕК

### Бар, артыңа карама

Без—мин, Шәех, Кыям абый ашыкмыйча гына Николай Сергеевичта сөйләшеп утыра идек. Тәрәзә артында, биек күктә йолдызлыклар ялтырап яна. Сентябрь ае алтынга манчып алган алмагачның саргылтым ботагы тәрәзә пыяласына кагылып-кагылып куя. Өстәл лампасыннан төшкән яктылыкта ул ботак күренеп-күренеп тә китә, чөнки Николай Сергеевичның тәрәзәсендә бернинди пәрдә дә юк иде.

Шунда Шәех кинәт кенә:

—Кызык, үзенең тормышны ничек белә башлаганын кем ничегрәк хәтерли икән?—диде.—Беренче хатирәләр нинди? Иң ине, иң ине?..

—Кһем,—дип йөткереп куйды Николай Сергеевич. Кыям абыйның килүе уңаеннан ул күктәге кушеткасыннан какшаган венский урындык кырыена төшеп утырган иде.—Кһем, чын-чынлап мин үземне дүрт яшьтән генә хәтерлим. Хәтеремә сенеп калган иң беренче картина: Новогоршечная урамындагы хастаханә йортында—хәзер анда Галимнәр йорты— гаять зур, бөтенләй буш дип әйтерлек бүлмә, шунда ак халаттан кара кашлы оператор, халык йөрткәнчә, жирле атаклы кеше, профессор Геркен һәм мин—металл раковина өстенә иелгән кечкенә кеше... Минем тамактан кан сиптерә. Гажәп, авыртуны сизүем хәтердә калмаган. Бу минем гаять зурайган анкау бизләремне алдырып маташуым иде. Унышсыз маташу...

—Минем исемдә калганнар да күнелле түгел,—дип, мин Соловьевның Екатерина Икенченең Казанга килүен бик кызыклы итеп сурәтләгән «Россия тарихы» томын ябып куйдым.—Гафу итегез, мин сезне бүлдермәдемме, Николай Сергеевич?

—Юк, юк...

—Кыш көне өйалдыннан гомуми ишек ачкычын алдым да (без аны бераз вакыт почта тартмасында тоткан идек) ялап карарга булдым. Балалар бар нәрсәне дә авызга таба тарта бит, ә өйалдында урамдагы шикелле салкын. Шундый зур ачкыч иде ул,—дип аңлаттым мин.—Тел очына гына тидергән идем, ул чагып ук алмасынмы! Ташларга телим, ә ул ябышып ук калды. Акырдыммы, еладыммы икән? Бары тик шунысын гына хәтерлим, өйгә, дөресрәге, кухняда мич янында кайнашкан әни янына йөгереп кердем, үзем бер сүз дә әйтә алмыйм, чөнки телемдә ачкыч асылынып тора бит.

Шәех көлеп куйды:

—Сиңа ничә яшь иде соң?

—Хәтерләмим инде хәзер... Ләкин бер дә көлке булмаганы гына истә калган.

—Ә минем хәтеремдә башта бу... бу—ачлык,—дип көрсенде Кыям абый. Ул бүлмәдә берданбер булган кәнәфигә жай гына чумган иде.

—Әйе, Кыям абый, сез үзегезнең балалык чорыгыз турында сөйләмәдегез бит әле,—дип сискәнеп китте Шәех. Мин шунда дустыма карап алдым. Ул, карт сөйләвеннән аның киләчәк язмышы хәл ителергә тиеш шикелле, бар күңелен биреп тыңларга әзер иде. Шунда, хөрмәтле кунак ни әйтер дип, Николай Сергеевич та бар игътибарын аңа юнәлтте. Ул башын, гадәттәгечә, күкрәгенә төшерде, авторучкасыз һәм кәгазьләрсез күрүе сәер тоелган бармакларын үзара күкрәгендә эләктереп куйды.

—Менә нәрсәне хәтерлим...—диде Кыям абый.—Генералның жимеш бакчасы киртәсе янында басып торам. Аның хуҗасы безнең помещик, отставкадагы генерал Дурасов иде. Һәм такталар арасындагы шактый киң ярыктан минем белән бер яшьтәге генерал малаеның алма ашаганын күзәтәм. Инде ничә көн мин авызга мәк бөртеге дә капмаган, ә ул алма

кимерә, алма суы аның иягенә дә чәчри. Ә мин әле ул чакта агачларда үсүче ул алсу бәрәнгеләрнең тәмен дә белми идем. Бары тик аларның җәннәт җимешедәй баллылыгын күз алдыма гына китерә алам. Шулчак мин ул малайга: «Бер алма бир әле!»— дип дәштем. Ул тирә-ягына карангалап алды да, алмасын тагын бер тешләп куйды һәм калдык кисәген миңа ыргытты. Ул ярык янындагы тактага килеп тиде. Аның минем янга очып төшмәвенә ничек үкендем мин шул чакта! Әй, Алла, балачак, балачак!.. Ул кешедән өлгергән җимеш агачтан өзелеп төшкән шикелле аерылып кала һәм безнең һәркайсыбыз үзенең алсу йөзле алмасын карый-карый, күрсәнә-күрсәнә бары тик кулында гына әйләндерә.

Кыям абый купшы штиблетын селкетеп алды. Ул матур киенергә ярата иде, хәер, ни әйтерсең—артист!

—Ничек шулай килеп чыккандыр,—дип дәвам итте ул,—белмим, минем әти, өйдә шәригать буенча да дөрес булган, соңрак авыл советында да теркәлгән сау-таза үз хатыны утыруына карамастан, безгә гел янадан-яңа хатыннар алып кайта иде. Бер тапкыр әни түзмәде, мескен. Ул аны каргады: «Аякларың корысын, күзләрең үзеннең соңгы көненә тикле минем күзләремә ялынып-ялварып карасыннар иде»,—диде. Коточкыч һәм кире кайтарып булмый торган нәрсә икән ул каргыш... Чыннан да әтинең аяклары йөрмәс булды һәм инде ул бүтән беркемгә дә күз салмады, бары тик үзенең хатынына—минем әнигә генә карады. Без Башкириядә, татар авылында яшәдек. Арыслан дип атала иде ул авыл. Егерменче елның җәендә безнең авыл буенча янгын уйнады. Ул безнең өйгә килеп җиткәч, әни безгә—өч балага (алар арасында мин—иң олысы идем) өйдән чыгарга кушты, ә үзе шунда, үзенең каргалган ирен, ягъни безнең әтине алып чыгарга дип өй эчендә калды. Ул аны яна торган өйдән кючкә-кючкә генә күтәреп ишегалдына алып чыкты, аннары кычыткан һәм куаклар баскан койма янындагы түбеннән сап-салкын, көчле чишмә бәреп торган уйсулыкка алып килеп утыртты, ә үзе кулына чиләк алып, кереп китте... Утырдык, өскә су сибештек. Янәшә генә торган ике хуҗалыкны чолгап алган ут бераздан баш өстебездә тере чатыр-гөмбәз булып бергә кушылды. Кайдадыр янган урам ахырында яшереп куелган сугыш кирәк-яраклары гөрселдәде. Ә әни, кабызган машина сыман, чиләк белән һаман-һаман боз шикелле суны чумырып-чумырып ала да әле әти өстенә, әле безгә, әле үзенә сибә... Шулай итеп котылдык. Ә өебез янып бетте, исән бер генә утын агачы да калмады. Бөтен җәй буе туганнар буенча кунып-төнеп йөреп газап чиктек. Көзен нindидер бер иске сарайга кереп урнаштык. Салкын. Әти авырый. Декабрь аенда әни, мин әтине хастаханәгә алып бару өчен, кулак Галимҗаннан карт атын сорап торды. Аның өчен аңа эшләп түләргә вәгъдә итте. Әни, булдыра алган кадәр, әти белән икебезне дә төрендереп чанага утыртты һәм менә мин, унбер яшьлек малай, бүрексез, аның урынына әллә ниткән тишек-тошык шәл бәйләгән килеш, әтине салкын көндә күп чакрымнарга табибларга дип алып чыгып киттем. Юлда, район үзәгенә ике-өч чакрым ара калганда, арык ат барган җиреннән тотты да егылды. Мин шунда очраган олаулы кешеләрне алып килдем. Алар әтидән: «Бу ат белән нишләргә: суяргамы яисә бернинди файдасыз үлсенме?»— дип сорадылар. Нишлисең, суярга туры килде. Һәм барысы да файдасыз, барысы да, барысы да... Әй, безнең ул сәяхәтебез! Хастаханәдә урын табылмады. Ат белән килеп чыккан трагедия турында әти танышлары аша Галимҗанга хәбәр итте. Ә ул дусты Тимербай белән, давыл шикелле, шундук килеп тә җитте. Икенче көннең иртәсендә үк. Алар ат итен каядыр алып киттеләр, ә авыру әтине минем күз алдымда тотып кыйнадылар. Намаз укыдылар да кыйнадылар. Кыйнагач эткәләп-төрткәләп чанага салдылар, аның янына мине дә

укмаштырдылар һәм симез ике ат безне кире Арысланга таба алып китте. Көн кояшлы, салкынча. Сүзсез генә элдерәбез. Ә урман эченә үк кергәч, Галимжанның дусты: «Нигә аларны тиккә утыртып, атларны ардырып йөрергә?!»—димәсенме! Галимжан җавап бирмәде, бары тик өрәк сыман сары күзләре белән әтигә кырын гына карап алды. Күпме барганбыздыр, кинәт атлар, пошкырышып алдылар да, туктап калдылар. Галимжан безгә таба борылып карады: «Туңдыгызмы, кошчыклар? Йөгез әле, төшегез! Ә-ә, сез булдыра алмыйсыз, аһ, сез авырумыни?.. —дип сөйләнде.—Ә минем аргамакны, инвалид, үтергәнче куаларга булдырдыңмы?» Ул әтине эләктереп алды да чанадан карга өстерәп төшерде һәм типкәли башлады. Мин аларга ташландым, Галимжанның зур итекле аякларын эләктердем дә, мөгаен, монарчы беркайчан да булмаганча, бик-бик каты итеп кулларым белән кысып алдым. Үзем: «Галимжан абый, кирәкми алай, кирәкми!»—дип кычкырам. Галимжан шунда аягы белән агачка эләккән шикелле, карга килеп төште дә: «У-у, шайтан баласы!»—дип улады һәм йодрыгы белән миңа шундый итеп китереп сукты, аякка басып, мин тәртәләр арасына, ат койрыгы астына барып төштем. Аннан ничек кирәк алай чыктым, ә дусәшнәләр инде, әтинең яхшы йортта аяк астына да салмый торган бишмәтен салдырырга дип, селкеп маташалар. Ләкин сез Галимжанны белмисез. Ул шунда минем башымнан сыерылып төшкән әнинең ертылып-тишелеп беткән шәлен дә алып куйды. «Кат шунда эт шикелле!»—дип типте ул соңыннан әтигә. «Ә монысы белән нишлибез?» —дип Тимербай миңа таба ымлады. «Утыр чанага!»—дип кизәнде миңа Галимжан. «Әтине дә алыгыз, мин аннан башка китмим»,—дип җавап бирдем мин. Кирәк идеммени мин аларга! Галимжан мине эләктереп алды да башым белән карга тыгып куйды. Суганны түтәлгә утырткан шикелле.

Кыям абый кыска гына итеп көрсенеп алды да сүзсез туктап калды. Без дә дәшмәдек, сөйләүчене куркытудан шикләнеп, хәтта селкенмәдек тә. Ул бер-берсенә атландырган тезләрен алыштырып куйды да янадан штиблетларын селкетеп алды...

—Без әти белән, бер-беребезгә сыенып, агач астында карда утырдык. «Урман, урман,—дип мыгырданды шунда әти.—Кара урман». «Кара түгел , ә ак,—дип бүлдердем мин аны.—Йә, әти, нишлибез инде хәзер?» Мин аны урманнан алып чыга алмый идем. Әти миңа бер кап шырпы сузды. Мин коры ботаклар җыйдым, әмма учак ягып җибәреп булмады—туңган кулларда шырпылар һаман сынып карга оча тордылар, мәгәр кабынып китсәләр дә, шундук сүнделәр. Соңгы шырпы да чыжылдап алды да шундук сүнде. Һәм әти миңа: «Калдыр мине, бар!»—диде. Мин аны кочаклап алдым. «Бар, кадерлем,—диде ул һәм башыннан Галимжан алырга җирәнгәнме, әллә күрмәгән-сизмәгәнме керләнеп беткән киез бүреген салып миңа сузды.—Мә, ал, ул сиңа кирәгрәк». Мин урынымнан кузгалмадым. «Кире район үзәгенә бар»,—диде ул. Мин һаман багана шикелле басып тора бирәм... Ничектер минем, кеше үлгәннән соң да әле озак еллар яши, дип укыганым бар. Аны белгән кешеләр исән чакта һаман яши бирә икән кеше. Аның турында аны белгән кешеләрдән ишеткән кешеләр булганда да яши икән. Анда, урманда, мин ул каһәрләнгән вакытта, үзем белән алып китү өчен, үземнең яшь, үсә баручы һәр күзәнәгем белән әтине хәтеремә суырдым. Юк, әлбәттә, мин хәзер генә шулай уйлыйм, ә ул чакта бары тик еладым гына һәм нишләргә дә белмәдем. «Бар инде, шайтан алгыры!»—дип гырылдады ул һәм үзенең башлыгын кулыма төртте. Мин шунда аннан: «Әнигә ни әйтергә соң?»—дип сорадым. Ул күзләрен йомды да башын гына селкеде: «Берни дә әйтмә». Шулай итеп, мин китеп бардым. Бераздан борылып карадым. «Бар, улым, бар,—дип кул селтәде ул,—борылып карама!»

Мин әтиемә ярдәм итә алырыма ышана идем әле. Район үзәгенә төнлә килеп життем. Башым белән (туңып күшеккән куллар һәм аяклар тыңлаусыз иде) юлда очраган беренче ишекне шакыдым. Керттеләр мине, жылыттылар, ашарга бирделәр. Ләкин ул кешеләр, ничек кенә мәрхәмәтле булсалар да, башкасын эшли алмыйлар иде. Иртүк мин әтине калдырган урманга кире кайтып киттем.

Ул... агачка сөялеп, мин калдырып киткән урында ярым ятып тора. Әйтерсең мин килгәнче бераз черем итеп алырга уйлаган. Бары тик шешенке иренендә суыкта оешып каткан кан төере генә күренә. Һәм бераз кар белән каплана төшкән төрле якка таралган чәчләре. Маңгаенда да кар. Эреми торган кар. Мин аларны сыпырып төшердем, чәчләрен рәтләп, аларны башлыгы белән капладым. Беләсезме, безнең «Кара урман»—«Дремучий лес» дигән халык жыры бар. Яхшы, күңелгә тия торган әчкерсез жыр. Әмма хәзер мин аны тыңлый алмыйм. Тыңлый алмыйм...

Үзебезнең авылга кичен кайтып кердем. Кемнәндер вакытлыча калган безнең ярым жимерек торакта әни күренми иде. Суык мич башында энекәш белән сеңелкәш кенә туңып утыра. Мин мичкә ягып жибәрдем, чиләк белән су алып кердем дә кайнатырга куйдым. Шунда йоклап киткәнмен. Күрше уятты, әниегез бездә, диде ул. Мин әтине урманда калдырып ярдәм эзләп йөргән вакытта Галимжан белән Тимербай, Арысланга кайтып, әнине кыйнаганнар да, буш ат абзарында асып куйганнар икән. Ләкин ул үлмәгән. Галимжанның малае Мифтах (менә бит ничек тә була дөньяда!) әтисе белән дусты чыгып китүгә, елт итеп безнең ишегалдына кереп абзарга үтә дә бауны кисә. Шулай итеп, әнине үлемнән коткара.

«Мич башында ул»,—диделәр миңа, мин күршеләр өенең ишеген ачып кергәч. Аягымнан салдым да әчкә үттем... Әни аңсыз килеш чак кына сулый. Башы артка каерылган, чәчләре оешып куерган кара кан белән оеп каткан, ниндидер мамыкта, каурыйларда...

Әйе, исән калды ул. Исән калды...

Ә менә энекәш белән сеңелкәш егерме беренче елның жәендә үлделәр. Ачлык иде. Халык, беләсезме, нәрсә ашады? Алабута белән чүгендер түбе... Алып чыктык туганкайларымны әнине үтерә язган теге ат абзарына, һәм алар берничә көн шунда ятты. Иртәләрен чыга идем дә, минем туганкайларым уянмадылармы икән, дип карый идем. Юк, уянмады алар. Мәетләрне авыл буенча олау жыеп йөри иде. Анда атны безнең бер туганыбыз жигә иде. Энекәшем белән сеңелкәшемне ул алып китте һәм соңыннан әнигә (ул бик каты авырый һәм урыныннан тора алмый иде) гомуми кабердә аларга яхшы урын эләкте, дип сөйләде. Өскә сеңелкәшемне салганнар, ә аның өстенә башка беркемне дә куймаганнар, ә энекәшнең урыны янәшә, чокыр кырыенда булган. Үземне шушы көнгә тикле кичерә алмыйм... Бер мәртәбә энекәшем мин кайдандыр юнәткән бер кисәк күгәргән кара ипи кисәген сораган иде. Ә мин баш бармагым белән аның маңгаена төртеп алдым, бирмәдем. Хәзер ашарга дип өстәл янына килеп утырган саен ипи кисәге тамагымнан үтми, таш булып килә дә тыгыла... Өстәл өстендә жаның теләгән һәр нәрсә бар, тик янәшәмдә минем кечкенә энекәшем генә юк...

Жәй ахырында әни белән без урманда, землянкада яшәдек. Әни үзен начар хис итә, аны яхшырак ашатырга кирәк. Үземә дә кырмыскалар һәм тамырлар белән генә яшәү татлы түгел иде. Кая барасың, караклык итәргә туры килде. Тулы мәгънәсендә түгел, ә болай вак-төяк кенә. Кайчак ялангач сукбай дуслар белән качып-посып йә баерак кешеләрнең өйалларына үтеп керәбез, йә кайчак амбарларын басабыз. Бер тапкыр базга төштем. Баз түгел, ә чокыр, такталар белән тышлап алган зур булмаган чокыр, ә анда ипи—тау хәтле. Түгәрәк ипиләр, түгәрәк ипиләр!.. Сикереп төштем дә күпме

алалганча эләктердем, ә чыгарга буй җитми, кечкенә чак бит әле. Аннары ипиләрне бер-берсе өстенә пирамида шикелле куйдым да, шуларга басып чыктым. Әле дә хәтерлим, бер бөтен ипине, кисәкләп, әнигә атна буе алып кайттым. Бөтен килеш алып кайтырга ярамый, чөнки ул хәерне бөтенле ипиләтә бирмәгәннәрен белә бит. Алып чыккан икенче ипине шулай ук ачлыктан шешенгән дусларым Салих белән Кәримгә бирдем. Алар миннән олырак та, ләкин мин аларга караганда елдамрак идем.

Эләккәнем дә булды, әлбәттә. Кыйналдым да. Бер тапкыр Покровка дигән рус авылында кулымдагы балык белән тотып алдылар. Мин әйдә шунда: «Речка поймал, речка поймал»,—дип акланып кычкырырга! Шушы тозлы балыкны!..

Җибәрделәр. Әллә ышандылар инде?..

Покровка нәкъ генерал Дурасов утары урнашкан авыл инде ул. Ифрат зур гәүдәле иде ул генерал. Юан гәүдәле, мыеклы, кыскасы, тиешле булганча, чын генерал. Соңгы тапкыр ул Покровкага уналтынчы елда, көз ахырында килде. Төп-төгәл өч көн булды да хатыны һәм малае белән кире китеп барды. Шуннан бирле башка бер дә күренмәде. Исән дип сөйлиләр. Парижда яши ди. Хәер, дөрес түгелдер бу. Инде аның малае да минем шикелле карт булырга тиеш.

Генерал Дурасовтан башка Покровкада үз дурасовлары, үз ротшильдлары калды, шуңа күрә безне анда аркан белән тарткан сыман тарта иде. Хәзер дә күз алдымда... Ятабыз шулай бер тапкыр Покровкадан бер чакрымдагы артында ташландык чиркәү торган каенлыктагы кыр буенда. Тамаклар тук—ротшильд Овсовның базына төшеп, туйганчы каймак ашап, сөт эчеп чыккан һәм үзебез белән берәр бөтен ак бодай ипиен дә эләктергән идек. Мин кечкенә булганга, тәрәзә аша кереп, тәрәзә янында ук йоклаучы ирле-хатынлы Овсовлар өстеннән атлап үттем дә—өйалдына! Һәм инде бераздан миңа ничек-ничек эшләргә кирәклеген өйрәткән, тәрәзә төбенә менгергән, тышта түземлелек белән көтеп торучы олырак дусларым алдында ишек бикләре дә ачык иде. Ятабыз, кояш җылыта, кошлар сайрый. Рәхәт! Шунда мин оеп, бөтенләй изрәп йоклап киткәнмен. Кинәт акырган тавышка уянып китсәм, юк, шундук, әле уянганчы ук сикереп тордым бугай да, кемдер әйтмешли, аякларны—кулга. Бер сулышта чиркәүгә барып җитеп, коймасы аша сикердем дә чыктым. Биек койма иде ул. Гаҗәп, ничек сикерә алдым икән мин аның өстеннән? Барыбыздан да буйлырак булган Кәрим дә булдыра алмады. Шул койма янында тотып алдылар да инде аны.

Ә безне кычкыруы белән Салих уятты. Аны беренче булып эләктерделәр.

Винт шикелле әйләнечле баскычтан мин чиркәү түбәсе астына ук менеп җиттем. Юк, түбә астына—монысы сүз шомарту өчен генә, ул чакта инде ул манараның түбәсе җимерелгән иде. Күрәм: биш таза яшь ир-ат минем дусларның кулларын каера һәм алардан нәрсәдер таләп итә. Нәрсә? Ипиләрен тартып алдылар... Бик тиз аңладым: аларны бер-берсе белән сугышырга мәҗбүр итмәкчеләр икән. Бай малайларының әтәчләр сугышын карыйсылары килгән. Ә тоткын дусларым карыша, аларны итекләр белән типкәлиләр, таяклар белән төрткәлиләр, һәм бераздан алар, башта җинелчә генә, ә аннары, торган саен усалрак итеп, бер-берсенең авызларына суга башладылар һәм ахырында канга батканчы сугыштылар. Аннары мин аларны төрле үләннәр кайнатып эчертеп көчкә рәткә керттем, яраларына әрекмән яфрагыннан компресслар куйдым. Бигрәк тә Кәримгә каты эләккән иде. Теге ата дуңгызлар аның җилкәсенә таяк белән кундырганнар һәм ул, бичара, ничектер ямьсез кыяфәттә бөгәрләнеп кырын яткан килеш бик каты ахылдады. Без Арысланга хәтле ничек өстерәлеп кайтканбыздыр—и-

и!—моны бер Аллаһы Тәгалә генә белә... Ярым тере Кәримне туганнары район үзәгенә, хастаханәгә илттеләр. Бер атнадан соң аны үле килеш кире алып кайттылар. Тик мин үземнең хатирәләрем белән артыгын бугай...

Кыям абый бик җәһәт кенә торып басты да, бүлмә буенча үтеп, тагын кәнәфие янына килде. Без ул үзенең хикәятен сөйләвен дәвам итәр дип уйлаган идек, ләкин Кыям абый ничектер түбәнчелек белән игътибарын шундук минем дуска юнәлтте.

—Шәех, без синең сорауга җавап бирдек, ә үзең?.. Синең хатирәләрең ничек соң, ә-ә? Син үзеңне ничек төшенә башладың?

—Ә әниегез тереләдеме ул чакта?—дип сорады Шәех аннан.

—Әйе, кышка таба аягына басты һәм йөри башлады... Һәм оныкасын карады. Роза үзенең дәү әнисен әле дә хәтерли... Кызыклы язмыш... Ничек булса да бер сөйләрмен әле. Тыңлыйбыз сине, Шәех... Синең дөньяга беренче тәрәзәң ничек ачылды? Ә-ә?

—Мин хәтеремдә нинди мизгелнең беренче булуын белмим дә. Төгәл генә әйтүе кыен.

—Ә үзе безне аптыратты... Һәм без сөйләп тә бирдек.

—Беренче тәрәзә... Минем тәрәзәләр, Кыям абый, якты булды. Менә әти белән мунчада коенабыз...

—Юынабыз,—дип төзәттем мин.

—Юк, коенабыз. Һич югында, мин—коена идем. Әти минем өчен мунчага махсус тимер ялгаш алып килә иде. Утырам шунда һәм челем аша сабын куыклары җибәреп уйныйм. Алар бик кечкенә килеп чыга һәм бик тиз ярылалар да. Әти минем тырышлыгымнан көлеп куйды да, кулларын сабынлап, баш бармагын—баш бармагы, имән бармагын имән бармагы белән тоташтырды да, уч төпләрен язып җибәреп, әкрен генә өрә башлады, аннары катырак итеп... Һәм шунда түшәмгә карбыз зурлыгындагы шар очып менеп китте. Мунча рәтләрен кечкенә, тоныкк лампочка яктырта иде. Ә шар... ул ялтырый, яктырта. Ул иртәнге кояш шикелле күтәрелә. Мин авызымны ачып, үз-үземне онытып карап торам. Менә шар лампочкага якынлашты, аннары аның белән тигезләнде һәм янәшәдә генә түшәмгә ябышып калды. Ярылмады. Күрше эскәмиядә юынып утырган ир-атлар, юыну турында онытып, башларын өскә күтәрделәр... Ә аннары нәрсә булганын хәтерләмим дә инде, тәмам онытып җибәргәнмен.

—Шуның белән беттеме?—дип сорадым мин.

—Бетте.

—Ялганлыйсың син... Мунчада шар югарыга очмый.

—Ә очты бит менә!

—Тормышта ни генә булмый!—диде Кыям абый.— Ярылмады, димәк?

—Ярылмады.

—Яа-ахшы төш, тормышың якты булачак синең, уща-мараха түгел, юкка ярылмас.

—Төш түгел, ә чын бу...—диде Шәех.—Балачак...

—Ә-ә... хәзер ул төш шикелле инде,—дип Кыям абый бармаклары белән әллә нинди хәрәкәтләр ясады да, буялган кара чәчләрен түземсезлек белән артка сыпырып җибәрде. Сөйләшүнең темасы аны кызыксындырудан туктады бугай.—Николай Сергеевич, сез мина романыгызны укырга биреп торырга вәгъдә иткән идегез.

—Кайсысын?

—«Яшьлек эликсиры»н.

—Зинһар, зинһар,—дип Николай Сергеевич аның үтенечен үтәргә ашыкты. Киштәдә казынганнан соң кәгазь өемнәре арасыннан калын гына бер папканы тартып чыгарды.—Менә ул, алыгыз.

Кыям абый урыныннан егетләрчә сикереп торды да, папканы алып, култык астына кыстырып куйды.

—Ярый, яхшы... Сау-сәламәт булуыгызны телим.

—У-ту-ту. Кая ашыктыгыз? Сөйләшеп утырыйк, безнең һәрберебездә шундый кызыклы нәрсәләр бар икән, ә без аларны һаман үзебезнең күңелләрдә йөртәбез...

—Юк, юк, сау булыгыз! Чау-у!

## АЛТЫНЧЫ БҮЛЕК

### Томанлы яшьлек дустым

—Тау белән тау гына очрашмый, ә чүлмәк белән чүлмәк бәрелешә,—диде Аширов.

—Бослюд?!—дип гаҗәпләнде Генка-башкисәр.

—Ә кем булсын тагын?—Аширов күп эчүдән аның йөзе күгелҗем күренсә дә, күз төпләре шешенгән булуына карамастан, шундук таныган балачак дустын кочып алды.—Нәрсә кангырап йөрисең тыл буенча? Сугыштан качып йөрүеңме әллә? Яисә ниндидер эштәме син монда? Нинди җилләр ташлады сине Идел буена?

—Кара син аны, нинди елгыр! Әле монысын әйт, әле тегесен чыгарып сал. Үзең соң? Үзең ничек?..—дип җавап бирде Генка.

Кыска хатын-кызлар сырмасы кигән Генка белән чагыштырганда, өстенә ике якка төймәләнүле, әле тузмаган пинҗәк, башына фетр эшләпә кигән һәм шома гына итеп кырынып та алган Аширов фон-барон шикелле күренә иде...

Хәрби комиссариаттан төнге качуыннан соң аның язмышы бик яхшы гына җайланды. Савиновкадагы тавыш-тынсыз өй яна хуҗасын герле сәгатьнең тигез текелдәве, ипи-тоз, өстәлдәге пешерелгән бәрәңге һәм биек тимер караваттагы йомшак, чиста урын-җир белән каршы алды. Ул рәхәтләнеп яхшы, сыйфатлы тәмле ашамлыклар чәйни-чәйни, сәгатьтәге ата мәченең күзләрен ничек анда-монда йөртүен күзәтеп ята бирде һәм керосин лампасын өреп сүндермичә йокыга да китте. Иркенәеп калды, уңышсызлыклар, борчулар артта калуына тәмам ышанган иде инде.

Таң атканда Аширов тирә-якны әйләнеп чыкты. Янәсе, кирәге-ние чыга калса, «кладовщик Иван Петров» уңышсызлыкка очраса, дип язын ук күзе төшеп, әйләнә-тирәсенә беренче рекогносцировка ясаган һәм аның күршедә яшәүче хуҗасы белән сату-алу турында сөйләшүләр алып барган бу ярым җимерек өй тирәсендә аннан бирле берәр төрле үзгәреш килеп чыкмаганмы. Юк, монда берни дә үзгәрмәгән иде. Янәшәдә генә шул ук зират, түбәсез калган манаралы монастырь, тынлык...

Күргәненнән канәгать калып, Мариясе янына китте. Тәрәзә төбендә куркынычсызлык турында хәбәр итәргә тиешле әрекмән яфрагыдай чәчәк үсеп утырган чүлмәкне күреп, аның тәрәзәсен чиертте. Мария ишекне киң итеп, каерып ачты һәм, үзен сөйкемлесе белән очрашуга ничек кенә әзерләп куйган булмасын, тыела алмыйча, барыбер каты итеп: «Ой!»—дип кычкырып җибәрде.

—Әкрен, ахмак!—диде аңа Аширов һәм өй эченә узды.

Аның янында ун минуттан артык тормады. Бераз үпте-кочаклады, аннары кайбер күрсәтмәләр бирде дә чыгып та китте.

—Кая киттең син?—дип сорады хатыны.

—Эшләр көтә.

Бер сәгатьтән соң ул инде трусиктан гына шәһәр үзәгендәге азык-төлек конторасының касса бүлмәләре буенча «эш» өчен кирәкле кәгазьләр сайлап

һәм аларга кирәкле мөһерләр сугып йөри иде. Тышка, саф һавага, картон һәм фанер әрҗәләр белән тулган буш ишегалдына да (эш башланырга әле шактый вакыт бар иде) үзе конторага көч-хәл белән генә сыйган шул ук форточкадан чыкты. Әрҗәләрнең берсендә аның яхшы итеп төреп куелган киемнәре ята иде. «Бер яманлыкның бер яхшы ягы да була,—дип уйлап алды Аширов.—Арестант сохариенда ябыгып кондициягә җиттем, әнә нинди форточка аша үтәрлек булып калганмын!»

Бу форточканы ул әле кладовщик Иван Петров булып эшләп йөргәндә үк күреп алган иде.

Аширов өенә кайтып житкәндә кояш Казансу янындагы Рус Швейцариясе калкулыклары артыннан күренеп кенә килә иде әле. Ул стенадагы сәгатьнең герен күтәреп куйды да салкынча урын-җиргә кереп чумды. Алай да йокыга китә алмады, кайнарланган чуены (ул үзенең башын шулай дип атый иде) бернигә карамый пешерүен дәвам итте һәм аны берничек тә суытып булмый иде. Шулай бер минут та йоклый алмыйча, урын-җирен изеп-туздырып, мендәрен кыйнап бетергән Аширов, сөйләшүләре буенча нәкъ сәгать сигездә килергә тиешле Мариягә ишек ачарга дип чыгып китте.

Йокысызлыктан күзләрендәге нindидер комнар чәнчүенә карамастан, ул сөйгәнен ягымлы каршы алды. Беренчедән, аның киндер сумкасыннан итле кәбестә ашы исе килә иде, ә икенчедән, ул бу иртәдә вак-төягенә хәтле уйлаган планы астына сызык сызып куйды. «Эш» кә әзерлек өчен, исәпләве буенча, нибары бер атна чамасы вакыт кына кирәк иде.

Тик өстендә сорау билгесе торган бердәнбер нәрсә—җинаятьтәш иптәш табу мәсьәләсе. Аңа кул астында булган кеше кирәк иде. Ләкин кайдан казып аласың ди аны?

Һәм менә, бәхеткә, көтмәгәндә генә Гена-башкисәр килеп чыкты. Менә дигән ассистент—моннан уңаен уйлап та табалмыйсың! Аширов аны яңа йортына кереп урнашканнан һәм азык-төлек конторына ясалган уңышлы походыннан соң Түбән пристань янында туры китерде. Ул, утыннар әрҗәсе артына басып, ач күзләре белән баржага арыш ипиләре төягәнне күзәтеп тора иде. Агач әрҗәләргә салынган ипи кирпечләрен олаулардан дебаркадер аша ташланган селкенеп торган күперчекләр аша хатын-кыз йөкчеләр ташый. Бер арба янында винтовкалы солдат басып тора. Гена кыл сыман сакал баскан ияген кашып алды да, Аширов стенасына эленгән сәгатьтәге ата мәче сыман, әрле-бирле йөргән хатын-кызлар артыннан күзәтеп, яшел күзләрен шул якка юнәлтте. Бары тик стенадагы мәченең генә күзләре ваемсыз, ә моныкылар ач бүренеке шикелле яна иде. Аширов белән дә шул йөкче хатыннардан күзен алмыйча гына сөйләште. Әйтерсең аларның кайсы булса да берсе менә хәзер әрҗәсеннән ялгыш кына бер кирпеч ипиен төшереп җибәрергә һәм бу турыда Гена-Геннадийны кисәтеп куярга тиеш иде.

—Төкрекләреңне җый!—дип елмаеп куйды Аширов, тәмәке кабызып. Һәм бер мәртәбә төн белән бөтен иртәне елгада колхоз каравылчысы Ерофей мылтыгыннан атылган арт ягындагы тозны юып үткәргән томанлы яшьлек дустының йөзенә төтен җибәреп.

—Кая төйиләр алар моны?—дип авызын кыегайтты Гена.—Шәһәрдә—карточка буенча, а монда—олаулар, баржалар белән...

—Каялар тавына. Тартасыңмы?

—Бир,—диде Гена, карашын йөкчеләрдән алып.

Таулар фонында җайдаклы абрек сурәте төшерелгән зәңгәр каптан папиросны бармагы белән кагып, Аширов, бер дә читләтеп тормыйча, аңа:

—Акыл белән эш иткәндә ипине бу мескен олауларның барысын бергә

кушканнан да күбрәк кулга төшереп була,—диде.—Җитмәсә, бик гади генә.

—Шаяртасың?—дип төтененә тончыгып куйды Башкисәр.

—Һич тә.

Гена анын бик купшы, көяз кыяфәтенә, эшләпәсенә, пинжәгенә, ботинкаларына, зәнгәрләнеп ялтырап торган иягенә әле генә игътибар итте һәм сукбайның яшел күзләре аңа хөрмәт белән ялтырап китте.

Аның сукбай һәм дезертир икәнен Аширов бик тиз аңлап алды. Шуңа күрә сөйләшүне озакка сузмыйча, шундук һәм ачыктан-ачык алып барды. «Юк, һич тә үзгәрмәгән син,—дип уйлады Аширов эченнән, «эш» турындагы уен дәвам итеп.—Синең белән кайбер нәрсә пешерергә була». Ул Башкисәрнең физик яктан да, акыл ягыннан да һәм башка яклардан да мөмкинлекләрен яхшы белә иде. Хәер, аның алары әлләни кызыгырлык түгел иде түгелен дә, ләкин нишлисең, бу хәлдә аның өчен барыбер ул да табыш иде.

Аширов балачак дустын, хәзер инде компаньоны да, үзенә Савиновкага алып кайтты һәм беренче эш итеп аның тышкы кыяфәте белән шөгыльләнде. Примуста бер чиләк су кайнатты, аңа бер кисәк сабын бирде, кулына кырыну пәкесе тоттырды...

—Кырындырганчы, сине ут белән көйдерүе җиңелрәк бугай,—дип көлде ул.

—Бераз үсте шул.

—Әй, ничек сасыттың син!

—Сугыш башланганнан бирле юынганым юк шул.

Бер чиләк су гына аз булып чыкты. Ярый әле, шулчак Мария килде. Ул коедан су ташыды да примусны шундый итеп рәтләп җибәрде, хәтта ул әкияттәге Змей-Горыныч шикелле гөрелди үк башлады. Бераздан хатын ашамлыклар алып килергә дип чыгып чапты.

Гена куркыныч пәкене яңаклары буенча йөртә-йөртә гамьсез генә искә төшерде:

—Хәтерлисеңме, самопалдан каргаларга аткан идек? Ә-ә, Ашира-Кашира? Ул чакта кулың ярыйсы гына пеште бит синең. Аның каравы хәзер син бөркет шикелле. Хәер, нәрсә инде монда... Кемгә кем булырга язган булган, шулай килеп чыккан да. Бары шулай гына. Һәр кошның үз җилпенүе була...

Кинәт аның артында:

—Хенде хох!—дигән тавыш яңгырады. Гена, шаккатып, борылып караса, аңа пистолет көпшәсенең кара авызы карап тора иде.

—Ташла шаяруыңны!—диде ул, көчкә телгә килеп.

—Мин шаярмыйм,—дип сүзеп чыгарды Аширов.—Мин соңгы мәртәбә кабатлыйм: синең алдыңда майор Егоров, Виктор Васильевич. Оныт Ашировны. Аңладыңмы?

—Аңладым, иптәш майор! Шылды!

—Үзегезнең туалетыгызны дәвам итегез,—дип рөхсәт итте аңа «майор Егоров», ТТ пистолетын тупа башы белән кесәсенә төшереп.

Гена тәкерегеп йотып куйды, пәкесе белән сабынланган битеннән үткәрде дә тагын борылып карады.

—Карале, болай суелырга да мөмкин иде бит, актыгында вакытын чамала син. Кулымда пәке икәнен күреп торасың бит.

—Сине болай тиз генә суеп булмый,—дип Аширов тезе белән ягымлы итеп аның җилкәсенә йомшак кына төртеп алды. Тәмәке кабызып җибәрде. Өстәл янындагы тумбочка янына үтте.

—Менә сиңа яңа эчке киемнәр—күлмәк, пинжәк. Алар бик яңа ук түгел,

әлбәттә, ләкин синең өчен яңа әле болар. Эшләп акча алгач түләрсен. Ул шунда стаканга спирт-чимал салды да эчеп җибәрде, йөзен җыерды:

—Фу, сасы нәрсә!

—Ә мина?—дип Гена бугаз төенен аска-өскә йөртеп алды. Анын бугаз төене зур, очлы, кырынганда ул беренче чиратта шуннан башлый. Геннадий әле бик кечкенә чакта анда үз теләге белән бармаган озак сроклы урман кисүдән кайткан абзыйсы—әнисенең абыйсы очраганда аңа: «Алкаш булырсын»,—дигән.—«Нигә?»—дип сораган малай.—«Бугаз төенең туры килеп тора»,—дип җавап биргән абзыйсы.

—Ә мина?—дип кабатлады Гена.

—Өлгерерсең. Менә дус хатын кайткач кичке аш ашап алырбыз. Син кайда тукталдың? Әллә кайда туры килсә, шундамы?

—Хәзергә синдә бит әле.

—Миндә ярамый. Киенерсен, ашарсың, документлар алырсың да ать два моннан! Аңладыңмы?

—Аңладым.

—Аңладым түгел, ә есть, иптәш майор!

—Есть, иптәш майор!

Чиста итеп кырынган Гена, урындыктан сикереп торды да, яшьләрчә киң итеп елмаеп честь бирде.

—Буш башка кулны куймыйлар.

—Ышандырырга батырчылык итәм, иптәш майор, ул күренгәнчә алай ук буш түгел.

—Мин ябылмаган башны күздә тоттым, бүкән,—дип Аширов карашы белән компаньонын, тегүче үзенең заказчигын караган сыман, баштанаяк күзе белән өтеп чыкты һәм эченнән: «Сүлпәннең сүлпәне, ничек булган, шулай калган да бу»,—дип уйлап алды.—Ә кычкырып:—Бер яктан бу яхшы да,—диде.

—Нәрсә яхшы?—дип сорады кунак, аңламыйча, ябык, төксез аякларын яңа эчке ыштан балагыннан чыгарып.

—Икенче яктан, бик үк яхшы да түгел... Ләкин икенчесен рөхсәт итмәбез. Киен, киен,—диде Аширов һәм тәрәзәгә ымлады:—Әнә минем гүзәлем кайтып килә.

...Бөтен дезертирлык елларында беренче мәртәбә ашказанын шулай бик төпле итеп тутырып, бар нәрсә турында сөйләшеп һәм, ул, ягъни нииндидер Г.Н.Трофимов фронтка чакырыла диелгән чакыру кәгазен алып, Гена—яңа гына барлыкка килгән призывник, тәмам караңгы төшкәч, ашыкмыйча гына пычрак Савиновкадан шәһәргә, үзенең инде өченче атнасын яшәгән подвалчыгына таба чапылдатты. Күңелендә тынычлык: чакыру кәгазе аның булмаган паспортын күрсәтүдән котылу мөмкинлеге бирә иде.

## Тегермән комбинатында

Алар ике көннән соң очраштылар. Гена аһ итте: аның алдында Аширов түгел, ә погонлы, кобура авырлыгы сизелеп торган чын гвардия майоры басып тора! Һәм дә иң гаҗәпләндергәне—ул коляскалы мотоциклда иде.

—Иблис!—дип куйды Гена, калтыравыклы тавыш белән.

—Йә, йә, эмоциясез генә,—дип кырт кисте Аширов,—әйдә утыр. Юк, артка түгел, ә коляскага. Тиз бул!

Ниндидер чүплеккә кереп туктадылар. Анда Аширов Генаны солдат киемнәре кияргә мәҗбүр итте.

—Әй, шайтан, әй, татар!—дия-дия караштырды ул үзен ияләнмәгән киемнәрдә—гимнастеркада, итекләрдә... Дәүләт мина бу киемнәрне кигезә

алмады, ә син—бер, ике һәм менә—әзер дә!

—Нәкъ капчык шикелле утыра,—дип сүгенеп алды Аширов,—бераз каешынны кыса төш.

—Ә ничек?

Яна гына солдат хезмәтенә алынган Гена майорның билендәге каешы белән нишләгәнен дә сизми калды, шундук күкрәк читлегеннән аста тимер бөжра белән кыскан шикелле булды.

—У-у, авырта бит!

—Түз!—дип Аширов аны этеп җибәрде һәм Гена шап итеп мотоцикл коляскасына килеп төште.—Һәм тынла. Хәзер Печищега тегермән комбинатына элдертәбез...

—Кайда соң ул?

—Монысы сине борчырга тиеш түгел. Иделнен теге ягында. Кыскасы, мин директорга керәм, ә син тачка янында каласың. Һәм, кара аны, сүнә күрмәсен!

Аширов бөтенесен дә алдан уйлап куйган. Анын күкрәк кесәсендә, шәхес таныклыгы эчендә, анын өстендә барыннан да бигрәк үзе баш күтәрмичә эшләгән һәм ана «Кызыл туендыручы» тегермән комбинатыннан хәрби часть өчен 50 /илле/ тонна он алырга рөхсәт итә торган накладной ята. Ул тиешле махсус бланкта, тиешле мөһер белән, менә дигән итеп эшләнгән! Аңа исә интендант хезмәте начальнигы майор Егоров исеменә бирелгән ышаныч язуы да теркәлгән.

Илле тонна! Аз да түгел, күп тә түгел. Монда инде барлык шикләр дә читтә калып торсын. Әгәр биш капчык кына булса, аны тикшерергә генә түгел, ә кабат-кабат тикшерергә мөмкиннәр, ә ярты йөз тонна икән, монда нинди шик булырга мөмкин? Ләкин Аширов, кирәк була калса дип, мотоциклны әзер тотарга кушты һәм пистолетын да саклагычтан алды. Арт санынын бер ягында торган кобурасы да очраклы рәвештә генә чишелгән иде...

Ләкин барысы да имин үтте. Директор—буби тузына охшаган шундый бер җирән, мәһабәт кыяфәтле кеше—гвардия майорын Америка сигареты белән сыйлады. Тыл шәһәрендәге җитәкче өлешенә төшкән, ләкин, мөгаен, һич тә фронттагыннан җиңел булмаган авырлык турында сөйләп алды һәм бер селтәнү белән анын күнелендәге тынычсызлыгын сызып ташлады.

—Хәзер—бухгалтерга, иптәш майор,—диде ул.

Бухгалтер дигәне бик юан гына хатын-кыз булып чыкты. Ул бернинди артык сүзсез генә күчергеч кәгазь аша өч данә накладной язып бирде. Анын бер данәсен шундук үзенең папкасына салып куйды, калган икесен:

—Берсе үзегезгә, икенчесен чыкканда капка төбендә проходнойда калдырырсыз,—дип Ашировка сузды.

—Димәк, пропуск шикелле...—дип ачыклады Аширов, бик кирәкле бу кәгазьләрне сак кына алып.—Ә сезнең исемегез ничек?

—Ә нәрсә?

—Юк, болай гына... Берәр чибәр хатын-кыз күрсәм, гел анын исемен белергә тырышам. Исем бит туры килергә тиеш...

—Светлана Петровна.—Бухгалтер хатынның таш сыман булган йөзе кинәт дымлы елмаюда эреп китте. —Туры киләме соң?

—О-о! Туп-туры нәкъ үзегенә! Мин фронтта чакта безнең полк командиры: «Хатын-кызның бар җире дә матур булырга тиеш,—йөзе дә, исеме дә, киеме дә»,—дип кабатларга ярата иде. Беләсез бит, фронтта ничек, буш минутларда бар сүзләр дә бары тик сезнең хакта гына. Чыгаралар да ирләр үзләренең җанкай-җанашларының фотоларын, аларга сокланып-сокланып карыйлар, бер-берсенә күрсәтешәләр һәм

Люба, Вералары яисә менә йөрәге янындагы Светланасы белән сугышка керәләр...

—Күренеп тора, күпне күргән икән сез,—диде Светлана Петровна, майордан күзен алмыйча.—Тик минем фотокарточкам белән беркем дә сугышка керми.

—Нишләп?

—Шулай килеп чыкты инде. Мин үземнең егетемне очратырга өлгерми калдым. Каһәр суккан сугыш аркасында!

—Тиздән күкрәп туктый ул сугыш, аннары солдаткайлар кире кайтып керерләр,—диде Аширов. Ләкин ашыга төште, бу юан хатын белән сөйләшеп торырга вакыты юк иде. Башка вакытта, бүтән урында булса бер хәл иде...

Ләкин бухгалтер хатын әле бу фронтовик майор алдында үз бурычын үтәлмәгән дип санады бугай, аны документларында онның сортын, дымлылыгын күрсәтергә тиеш булган лабораториягә озатып куярга алынды.

Ишегалдында, нервыланып, мотоцикл тирәсендә Гена йөренә. Ул «командир»ны юан хатын белән күреп, урынында катып калды.

Аширов аның яныннан үтеп барышлый ана:

—Моторны сүндер, тәмәке тарта тор!—диде.

Лабораториядә Аշировның онны бүген үк алып чыгарга тиешлеге ачыкланды.

—Ләкин бүген минем транспортым юк!—диде ул, кайгырып.

—Бүгенге число белән яздырылган икән, димәк, ул комбинат капкасы аша да бүген үтәргә тиеш,—диделәр аңа.

Шунда Светлана Петровна тагын ярдәмгә килде. Ул майорның терсәгенә җиңелчә генә кагылып алды да, күзләре белән: «Кайгырмагыз!» дигәнне аңлатты.

Кабат ишегалдына чыккач, бухгалтер хатын аңа мондагы авыл кибетенә сугылырга киңәш итте. Әгәр дә аларның складлары буш була калса, алар белән аны вакытлыча файдаланып тору турында килешергә кирәк, янәсе.

—Телисезме, шунда мин дә сезнең белән барып киләм?

Аширов эченнән генә, эш бетте, кəлтә генә җыясы калды, дип сөенеп куйды. Ул кулындагы сүнгән төпчеген юлның икенче ягындагы чүп савытына ыргытты һәм ул туп-туры аның ачык авызына ук барып төште. Яхшы билге иде бу.

Чыннан да кибет мөдире, уңган гимнастеркадан булган бер күзле сумса, үзен үгетләгәнне көттермәде, әле гвардия майорына, әле бухгалтер хатынга ихтирам белән карап: «Рәхим итегез, безнең амбарда яздан бирле җил генә уйный»,—диде. Хәтта шундук ачкычын да чыгарып бирде. Аширов, аның бу хезмәте өчен күпме тиешле булуын ачыкларга тырышуына каршы мөдир тик кулын гына селтәде: «Нинди чут?!»—янәсе.

—Менә булды,—дип шатлыклы елмайды Светлана Петровна, аннан кире кайтканда. Ләкин гвардия майоры күңелсез иде.

—Ул илле тонна онны кибет складына ничек ташып куярга соң миңа?! Мотоциклдамы?—дип сорады ул борчулы йөз белән.

—Нишләп мотоциклда булсын?.. Директорга керегез, безнең бит атларыбыз да бар. Телисезме, бергә керәбез?

Җирән туз баягы майор белән үзенең баш бухгалтерын ачык каршы алды. Кыенлыкның нидә икәнен белгәч, башын алгы бүлмәгә таба тыкты да каты тавыш белән:

—Атлар паркы начальнигын дәшегез миңа!—дип боерды.

Көрән эш халатыннан, башына кепка кигән, колак артына карандаш

кисәге кыстырып куйган чал чәчле карт—атлар паркы начальнигы үз эшен яхшы белә торган кеше булып чыкты. Шунда ул туп-туры: «Директорның майорга булышырга дигән боерыгы яхшы нәрсә анысы, ярар, булышырбыз, тик атлар кешеләр түгел, алар бушка эшләргә өйрәнмәгәннәр шул»,—дип белдерде. Аннары, операциягә—жиде олау, алты олаучы, удар хезмәт өчен—биш капчык он, дип килештеләр. Атлар он ашамыймы? Әй, ничек кенә ашыйлар әле!

—Көпә-көндез талау бу,— дип бәяләде моны гвардия майоры, ләкин башка чара юк иде.

Атлы-жигүле гвардия жыенып маташканда Аширов янадан Светлана Петровна янына килеп керде.

Хатын май аендагы сары гөл шикелле кызарып чыкты. Майор үкчәләрен бер-беренә бәреп куйды да сәламләп башын түбән иде дә шушы көннәрдә фронтка китеп барачак бөтен хәрби часть исеменнән үз вазифаларына бик житди караган өчен аңа рәхмәт белдерде һәм кичен яхшы оештырылган бу эшне билгеләп үтәргә тәкъдим ясады.

Хатын жавап бирмәде, ләкин анын риза икәнлеге болай да ачык күренеп тора иде. Шундук шатланырга гына оялды бугай ул, ә болай бу минутны бик озак, бәлки, бөтен гомере буе көткән иде шикелле. Бу минутның чыннан да нәкъ аныкы, ул көткән минут, ә бу кеше нәкъ шул, аңа күктән индерелгән бердәнбере икәнлегенә шиге юк иде.

—Һәм соңгы үтенечем, хөрмәтле Светлана Петровна, миңа үземнең ярдәмчем һәм мотоциклым белән кайда тукталырга мөмкин булыр икән? Мөгаен, иң катлаулы мәсьәлә шушыдыр...—дип күзләрен кыса төшеп карады аңа Аширов.

—Бәй-й, шушындый кадерле кунакларга бездә һәркайда шат булырлар. Борчылмагыз, баш өстегездә түбә дә булыр, башкасы да...—диде аңа Светлана Петровна, элеккедән дә артык кызара төшеп.

Йөкчеләр кичкә тикле эшләде.

Авыл кибетенең складына булып хезмәт иткән бүрәнәдән салынган амбарга соңгы капчык онны китергәндә караңгы төшкән иде инде. Аширов кыйшаеп беткән авыр ишекне йозак белән шартлатып бикләп алды да, борчылып тәмәке кабызып жибәрде. Инде ишегалдында төн, ә Светлана Петровнадан сәлам дә, бернинди хәбәр дә юк... Алдадымы икән әллә?

Янында Гена калган мотоцикл тирәсендә тавышлар ишетелде. Аширов текәлеп караңгылыкка карады. Анда ярдәмчесе ниндидер гүзәл белән басып тора һәм кулы белән складка таба ишарә ясый иде. Гүзәл көлеп жибәрде, Гена да шаркылдап көлеп куйды. Гвардия майоры гимнастеркасының каешы астындагы жыерчыкларын тигезләп алды да, ашыкмыйча гына мотоциклга таба атлады. Барысы да тәртиптә, Светлана Петровна элемтәчесен жибәргән булган икән.

Икенче көнне Печищедән кайтып барганда Аширов юл буе көр күңел белән көлә-көлә кайтты. Махмырдан ярым исән Гена гына колясксада юлдагы һәр түмгәк саен, андагы жанын саклап калырга тырышкандай, күкрәгенә тотынды һәм моның белән шефының кәефен китерде. Аширов көлә һәм аның күңелен күтәрмәкче була:

—Зарар юк, төшкә рәтләнерсең.

—Бир инде баш төзәтергә,—дип аптырата башлады Гена, балачак дустының тавышында хәленә керүне сизеп. Ләкин тегесе кырт кисте:

—Ярамый! Кайтып житсәк—бер хәл, ник шунда баш түбәннән чуммыйсың.

Аштировның башы махмырдан авыртмый иде. Ул бүген төнлә йокламады, дөрес, аз эчте, чөнки аңа икенең берсен сайларга туры килде: йә аракы,

йә хатын-кыз. Ә хатын-кыз... Ә Света-конфетка искитәрлек татлы булып чыкты. «Шулай да хатын-кызлар, бездән аермалы буларак, онытылуга сәләтле»,—дип уйлап алды Аширов, узган төннең дәртен ваклыкларына тикле исендә яңартып һәм үзалдына елмаеп куйды. Менә шушылай беренче очрашуда ук мәхәббәт, сөю турында чынлап торып әйтергә мөмкин микәнни? Алар бит барысы да ихлас күңелдән, алар аның шикелле алдамыйлар... Алар алданалар гына. Һәм файда артыннан файда күреп ул—галиҗәнап князь Аширов аларны алдый, алдап йөртә, алар белән туйганчы юана. Акылга сыймаслык нәрсә: аның былбыл булып сайравына ышаналар бит! Ул аның—«үзенең» Светка-конфеткасы артыннан төгәл ике атнадан соң кайтырга вәгъдә бирде, ә тегесе авыз ачып тыңлап торды. «Көтәрмен»,—диде аңа хатын саубуллашканда һәм битләреннән ике кулы белән борчак-борчак күз яшьләрен сөртә-сөртә елады. Мөгаен, фронтка әтисен дә болай озатмагандыр, ә мине... Аширов «мине» дигәч, үзенә «сөйгәнен» димәкче иде дә, кинәт « мине, дезертир һәм аферистны» дип куйды. Һәм рәхәтләнеп шаркылдап көлеп җибәрде.

Паром янында, түбәләре каплаулы хәрби йөк машиналарын үткәрә торгач, шактый тоткарланырга туры килде. Мотоцикл артына милиция «кәҗәсе»—тент белән ябылган «ГАЗ-67» машинасы килеп туктады. Аны күреп, Башкисәр курка калды, хәтта аның махмыры да бик тиз күккә очты бугай. Ул коляскадан төште дә, кызганыч кыяфәттә елмаеп, куаклар арасына кереп китте. Янәсе, кече йомышы белән.

—Ерак китмә!—дип калды Аширов аның артыннан. Үзенең тышкы кыяфәтеннән дә, документларыннан да, тегермән комбинатында да чиста эшләвенә шикләнмичә, мотоцикл моторын сүндерде дә тәмәке кабызып җибәрде. Ә төнге типтерүләре турында бары тик авыл кибете мөдире, юан Света һәм аннан соң компания төн кунган аның дусты Глафира гына белә иде. Гена, әлбәттә, анда бераз артыгын такылдады, ләкин барыбер—унга-сулга лыгырдап йөрүдән хатын-кызларга да, сату итүче иргә дә мәгънә юк. Гена алай да Глашаның күңелен яуларга өлгерде, үгетләп күндерде. Иртән Глаша капчык сыман гимнастеркадагы үзенең кәтелмәгән бәхетен кызганып куйды, аңа кыяр тозлыгы эчерде. «Кемне иркәләгәннәрен белсәләр икән болар,—дип уйлап алды Аширов.—Хәер, ә белгән булсалар, шуннан нәрсә? Бәлки, бары шунда гына кирәгенчә, чынлап торып, хатын-кыз күңеленең бөтен барлыгы белән бәяләрләр иде, ә-ә?! Ярар, болай да инде!..»

Яр буена буш паром килеп туктады. Чуар колонна хәрәкәткә килде, дөбердәде, кычкыртты.

—Геныч, чык!—диде Аширов әкрен генә, тартып бетермәгән папиросын еракка чиртеп.

—Нәрсә? Киттекмени?—дип, йөзенә изге кеше кыяфәте иңдереп, шунда булышчы куаклар арасыннан килеп чыкты.—Бераз җиңеләйде бугай, иптәш майор.—Һәм пилоткасына кулын куеп алды.

—Честь бирмә әле син, бүкән! Утыр... Һәм бертуктаусыз як-ягыңа каранма. Бу этләр барыбер махмырдан төзәлергә бирмәс сиңа...

—Секундка гына, иптәш майор, бер генә секундка.—Башкисәр коляскага кереп утырды да милиция машинасының түземсез рәвештә үкергән тавышына таба тагын бер мәртәбә карап алды, аннары колга шикелле турайды.—Кузгал.

—Кузгал, кузгал... Кабынмый әле, кабахәт!—Аширов ватарлык итеп стартерга басты, сүгенде... Милиция «кәҗә»сенең акайган карашы астында аның салкын канлылыгы юкка чыкты. Машина ишеге шулчак шыгырдап куйгач һәм аннан маңгаена бик түбән үк итеп батырып кигән кыр фуражкасы астындагы дуңгызныкы шикелле аксыл керфекле нык, таза капитан килеп

чыккач, аңа бөтенләй начар булып китте.

«Мильтон да түгел...—дип үз-үзенә билгеләп куйды Аширов, каушап калып.—Энкавэдэ, энкагэбэ, патрульме, әллә бу «кәҗә»нең очраклы юлдашы гынамы?.. Шайтан белгән!» Капитан барлык гаскәрләр өчен гомуми булган аерымлык билгеле кысан гимнастеркадан иде. Гәүдәсе каешлар белән аркылы-торкылы эләктерелгән, бер ягына авыраеп торган кобура тагылган.

—Кабынмыймы, иптәш майор?—дип сорады ул, эшлекле кыяфәт белән.

—Шайтаныма олагасы нәрсә бу!—дип бик эчкерсез сүгенеп куйды Аширов.—Иске-москы! Күптән ташларга вакыт югыйсә. Нигә азапланамдыр?

—Анысына һәрвакыт өлгерергә була. Каягыз әле, карыйм,—дип капитан рульне алды да газ ручкасын боргалады, итеге белән стартер рычагына бик каты итеп басып алды һәм «иске-москы» үкереп җибәрде.

Дуслар, Иделнең сул ягына чыгып, милиция «Газ»игы үз юлы белән авыл юлына төшеп борылып киткәч кенә тынычланып калдылар. Ә менә паромда чыкканда куркудан котлары алынды. Анда кысан гимнастеркалы, кыска муенлы, аксыл керфекле капитан эчкерсез сөйләшүләр башлап җибәрде дә сораулар яудырды: «нәрсә?» дә «кайчан?», «нигә?» Хәтта аларга паром урынында туктап калган шикелле тоелды. Аширов аның миенә пудраны мөмкин кадәр тыныч булырга тырышып сипте сибүен. Ә тегермән комбинаты турында ләм-мим. Капитанның үзе турында нибары аның фамилиясе Дубов икәнен генә белә алды. «Органнардан бу...—дип нәтиҗә ясап куйды Аширов.—Аның ялтыравыклы алдавычына эләгергә Ходай язмасын».

Ләкин янаган кебек тоелган куркыныч үтеп китте.

Каршыга тыныч кына кырлар, тау битләре, сирәк агачлар йөгерешә. Мотоцикл да башка чыгымчыламады, тигез һәм тыңлаучан гына бара бирде. Елга аша чыкканда телсез калган Башкисәр тагын җанланып китте:

—Алай да без кичә аракыдан соң ниткән шакшы нәрсә эчтек?—дип сорады ул.—Шул нәрсә, анасын саткыры, әлегә тикле чарлакны шешә бөкесен ача торган бораү шикелле бораулап тора.

—Без түгел, ә син...—дип җавап кайтарды Аширов, ачуланмыйча гына.

Инде ул уенда Печище оныннан алыначак табышны исәпләп бара иде.

## «Маэстро» ассистентлардан уңды

Аширов, шушындый имзалы документ белән килүче кешегә шунда күрсәтелгән кадәрле он бирергә тиешлеге турында килешеп, авыл кибете мөдиренә үзенең сырлы-сырлы, катлаулы имзасы үрнәген калдырган иде. Мөдир аны хәрбиләрчә ачык итеп: «Үтәлгән булыр!»—дип әйтеп алды. Шуны раслагандай, ул бердәнбер күзен кәнди сыман түгәрәкләндереп куйды, икенчесе кара тукыма «күзлек» белене белән капланып, тыгыз итеп бәйләп куелган иде. Төнлә өстәл янында эчеп утырганда ул эчпошыргыч итеп, үзенә чират житкәч (тыңлаучылар, тыңлап бетермичә, алышына тордылар), барысына да ниндидер Занозовка, әллә Зазнобушка тирәсендә барган сугыш, шул сугышның чынында иттурагыч машинасы кебек булуы һәм аны—үзенең гвардиячеләрен атакага күтәргән отделение командирын, ничек итеп фашист минасы күккә чөеп атуы турында сөйләде. Дөрес, ул сөйләгәндә, Зазнобушканы, Светлана Петровнаны кочаклаган килеш, шаярып, Аширов кыстырып куйды һәм шуның белән барысының да күнелен күтәреп җибәрде, хәтта, аңа үпкәләмичә, сөйләүче үзе дә шаркылдап көлде. Төнге өчләргә аракы белән көмешкә, ниһаять, мөдирне колаклы кисмәккә әвереләрде һәм ул әле бер, әле икенче якка кыйшая-кыйшая «өйгә, хатын катына» кайтырга дип чыгып китте. Ә

иртән ул—сәер күренеш!—кемдер әйтмешли, чак кына тозланган кыяр шикелле чиста, кырынган, ялтырап торган йөзе белән, барысы да тәртиптә булыр, дип, ил сагы хезмәткәрләрен бик җылы гына озатып калды.

Их, Россия-анакай, юаш ат шикелле син. Синдә су ташырга иде, су!..

Аширов үзенең Савиновкадагы уңайлы-җайлы өендә әле генә кайбер финанс исәп-хисаплары ясап алган карандашы белән гимнастеркасының күкрәк кесәсе төймәсенә суккалый-суккалый җыеп куелган урын-җир өстендә аунап ята. Өстәлдә капкачлары ачылган консервалар камалышында башланган аракы шешәсе тора, өстәл астында инде атылган сыра шешәләре батареясы. Чын ләззәт.

Ә кемнәрдер окопларда аркаларын өшетә, дип уйлады ул канәгатьлек белән. Нәрсә, өшетә генәме?! Күпме булдыклы солдатлар Россия кырларында череп ашламага әйләнделәр, күкләрдә яндылар, упкын-чоңгылларда баттылар, дөнья буенча көл булып сибелделәр инде! Аның каравы алар—каһарманнар! Кайберләре. Әйе, барысы да каһарманнар түгел, бары тик кайберләре генә. Күпмесе хәбәрсез булып билгесезлеккә күчте, күпмесе болай гына, хәтта күзе белән дошманны да күрмичә, үз өлешенә тигән кургашынын алды һәм—аля-улю, бетте-китте, туганнар! Улыгыз яисә ирегез урынына чын күңелдән язылган: «Батырларча һәлак булды!» дип язылган кәгазь кисәге көтегез. Ә менә ул исән. Исән! Һәм, шөкер, ничек кенә әле! Майор дәрәҗәсенә тикле житте, ха-ха, наркомның йөз граммын түгел, ә җаны теләгәнчә эчә һәм кайчан теләгәнчә, күпме теләгәнчә ашый. Кабымлыкка—Америка тушенка-консервасы, ә җинелчә махмырдан чыгу өчен шешәле сыра. Рәхим ит. Гомер бит ул кешегә бер генә тапкыр бирелә... Һәм анда кем ничек булдыра ала инде: кемдер, көтүдәге сарык шикелле, тимер учакка барып керә, ә кемдер, гафу итәсез, җебегән хайван булырга теләми, кемдер үзен шәхес дип саный һәм моны үзенең һәр адымы белән раслый тора.

Тәрәзәгә шартлы рәвештә кагып алдылар. Геннадий килде. Ике көндә ул, аны балачактан ук ялкау һәм аңгыра алдакчы буларак белгән шефын житезлеге белән гаҗәпкә калдырып, алты машина он сатты. Дөрес, кайчак анын анынын бик яктырып киткән вакытлары да булгалады. Мәсәлән, жиденче класста укыганда бер машина мәктәп күмерен сатты һәм, шөкер, эләкмәде. Ләкин Гена үзенең аның ише кыланмышлары өчен кирәген еш кына тулысы белән ала килде: еш кыйналды һәм суктырылды. Аңа акыллы шеф-өйрәтүче кирәк иде, шул чакта гына нәрсәдер кулыннан килә аның. Менә хәзер, Печищедәге шикелле. Һәм менә шуннан соң да бара эшләр, һәм Гена тәҗрибәле житәкче кул астында, интендат хезмәте начальнигы майор Егоров кул куйган документлар белән яллаган полуторка машиналары кузовларына он төйи дә капчыгын бишәр мең сумнан сатып җибәрә.

Аширов татлы гына итеп «Казбек» папиросы суырып алды.

—Нигә ишек төбендә мыштырдыйсың? Кер әйдә,—диде ул Генага.

—Мин монда өйләрне бутадым. Ялгыш синең күршеләреңә очып барып кергәнмен, шуңа күрә атлар алдыннан каранам менә хәзер.

—Кем булса да күрдеме сине анда, юкмы?

—Бала-чагалар... Бер көтү. Өстәл янында утыралар, ә олысы савытларга баланда салып маташа. Беләсеңме, ул аш дигәне нәрсәдән? Бәрәңге кабыгыннан. Әниегез кайда, дип сорыйм. Эштә, диләр. Ә әтиегез? Фронтта һәлак булды. Флонтта—берсе дөрес итеп әйтә дә алмый әле.

—Олылар өйдә юк иде, дисең, алайса?

—Ю-у-к, берсеннән-берсе кечкенә бала-чагалар гына. Аның каравы күзләре—менә! Чөмерәләр... Өстәлләрендә валчык ипи заты да юк. Ишетәсеңме, әйдә ташлыйк бераз аларга. Бәрәңге дә...

—Ә иң яхшысы—тушенка белән сыра.

—Актыгында бик аз гына булса да он, ә?—диде Гена, үтенгән тавыш белән.

—Юләрләнденме әллә син?

—Ә нәрсә була? Тонналар белән эш итәбез бит, аннан гына кимемәс.

—Юләрләнденме әллә, дип сорыйм. Алар өйалдыннан туп-туры Черек күлгә, капитан Дубовның бер чынаяк чәенә эләгергә телисеңме? Игелек күрсәтүче табылган, ананны сатыйм... Миллионер. Әниләре кайтыр да, кайдан килде бу күчтәнәч, дип кызыксыныр. Күлшеләл кителде, диярләр шунда аңа... Нинди күршеләр? Кайдан килгән аларга шулкадәр азык? Һәм, гомумән: «Нинди, кайдан килгән күршеләр алар, нишләп фронтта кан түкмиләр, ә тылда тыгынып яталар?»—дип төпчenә башларлар. Шундук—тиешле җиргә! Бетте диген аннары.

—Балалар кызганыч бит.

—Алдалама. Кызганыч булса, фронтка китәр идең дә, бәлки, шунда аларның әтиләре урынына башыңны салыр идең. Кара син аны, үзеннән артканыннан игелек кылырга һәм яхшы булып күренергә уйлаган! Бир акчаларны, миллионер!

Башкисәр сүрелеп, күңелсезләнеп калды, инде берничә көн аннан аерылмаган, кайдадыр алыштырып алган кирза сумкасын чиште дә аннан бау белән бәйләнгән акча төргәге тартып чыгарды.

—Монда әле биш капчык өчен җитми...

—Ничек инде ул—әле?—дип күтәрелде Аширов урын-җиреннән.

—Иртәгә бирел бетерергә тиешләр. Минем бер танышым ул... Иртәгә төп-төгәл сәгать унга вәгъдә итте...

—Таңга калдырасың син мине. Егерме биш менне кайсыдыр танышына, аның билләһи дигәненә ышанып, бурычка бирдеңме?!

—Курыкма, су болгата торганнардан түгел, ул миңа полуторка машинасы белән булышты.

—Анысы синең эш, син күбрәк тә бирел тора аласың, тик үз өлешеңнән генә.—Аширов төргәкне алды да, бавын да чишмичә, куенына тыгып куйды.—Үз өлешеңне калган акчаларны китереп биргәч алырсың.—Ул кечкенә стаканга аракы салып эчеп җибәрде дә артыннан суган шытырдатып алды.—Кайчан барасың?

—Хәзер үк китәм. Документка кул куй да.

—Капкалап ал. Йә-йә, тик монсыз гына!—дип туктатты ул шешәгә сузылган компаньонын.—Бер йотым аркасында эшне бозып, куркыныч астына куярсың.

Үз кул астындагы кешесенә он алырга дигән яңа накладнойга кул куеп, аны файдалы саклык киңәшләренә караганда сугү һәм янау күбрәк булган теләкләр теләп озаткач, Аширов, папиросы белән төтенләп, кабат урынына килеп ятты. Нигәдер һаман Мариясе күренми әле. Ул әчеткән кәбестәдән пешергән щи алып килергә тиеш иде, чөнки гел-гел тушёнка ашау да тәмам туйдырып бетерде аны! Инде вакыт төшкә якынлашып килә, ә ул һаман юк. Аширов бу хатынның соңгы ике атнада ничектер түгәрәкләнеп, тыгыз симезлек белән өретелеп китүен сизде. Әллә авыраюымы икән соң? Мария белән булган бу бәйләнешеннән ул бала булдыруны һич тә планлаштырмый иде. Кая монда бала белән?.. Хәтта тыныч вакытта да артык мәшәкать ич бу. Ходай сакласын! Ә монда... Аксак шайтан Обухов, бу проектның авторы инде күптәннән рәшәткә артында түгел икәнен белеп, шундук титаклый башлар. Ни әйтсәң дә, бертуган түгел, бажай кеше генә. Һәм кабат төрмәгә утыртып куярга да күп алмас. Теләмәсә дә утыртып куяр. Аның теле бит!.. Аннан соң үз теләге беләнме, юкмы, ниндидер сер ишеткән колак автоматик рәвештә телгә әйләнүчән бит. Һәм бу телнең кемгә кайчан нәрсә ычкындырачагын, Алла белән Аллаһка гына түгел, хәтта шул яман тел

хуҗасының үзенә дә билгесез.

Аширов тәрәзәдән урамга карап алды. Күлләвек өсләрен шадраландырып, Савиндагы сары яфрак өемнәрен туздыра-туздыра көзге җил исә. Ничек кыска монда җәй! Нindидер мескен өч ай, хәтта ике ай. Көньякка, көньякка кузгалырга кирәк, дингезгә якынрак! Хәзер анда бәрхет сезоны, немецлар ташлап чигенделәр, яшәве җәннәттәгечә булырга тиеш. Он буенча комбинат белән эшне ахырынача очлап бетерәбез дә һәм, сау булыгыз, хатыннар, бәҗәйлар, компаньоннар!..

Аширов күз алдыннан сугышка кадәрге журналларда күргән кипарислы, пальмалы, зәңгәр дулкыннарны ярып баручы әкияти пароходлар, пляжда башкалар янәшәсендә түгел, ә аның үзе, калын киндер кәнәфидә чайкалып утыручы һәм ак кар сыман йөзгән акчарлакларга дип дулкыннарның ак күбегенә бисквит ыргытып утыручы князь Аширов янәшәсендә пляжда кызынучы гүзәлләр белән тулы картиналар йөзеп китте.

Аннан соң тик торганда гына кичә манарасының очы-башы җимерелгән Кизич монастыре һәм аның артындагы зиратта очраткан карт күз алдына килде. (Бу—элеккеге монастырь, әлбәттә, элеп куйган язуына караганда, хәзер анда нindидер контора урнашкан.) Ул карт бу зиратта Лев Толстойның бабасы һәм тагын нindидер күренекле кешеләр күмелүе турында сөйләде. Шулай ук ул, монда Җир шары тирәли дингез сәяхәте ясаган һәм Антарктиданы ачкан бөек астроном күмелгән дип, аның кабере өстенә куелган ташны да күрсәтте. Әллә Антарктида, дидеме шунда? Ә бәлки—Арктикадыр... Бер-берсенә охшаш булган бу исемнәр аның башында тәмам буталышып беттеләр. Аннары ярым йокы аралаш уйлары да тәмам үзара катнашып-аралашып, чуалып калды һәм бөтенләй куркыныч төшкә әверелә башлады. Имеш, зиратта очраган ул карт теге астроном-сәяхәтче үзе икән, имеш, ул кабереннән чыккан да, аның ачуы кабарган: ничек инде Антарктиданы Арктика белән бутарга мөмкин! Һәм, гомумән, ди, ничек сине, дезертирны, җир йотмый?! Һәм аны кулыннан эләктерә дә, астында куркыныч кара тишек җәйрәп яткан кабер ташына таба өстери...

—О-о! Авырта бит, җибәр!—дип кычкырды Аширов һәм артка каерылган кулының чыннан да авыртуыннан уянып китте.

Һәм инде төшендә түгел, ә өнендә:

—Каршылык күрсәтмәскә, гражданин Егоров, торыгыз!—дигән тавыш яңгырады.

Шунда ул буш кулы белән үзенең бердәнбер ышанычлы дусты, Болак артында бер чая малайлардан алты йөз сумга сатып алган яңа ТТ пистолеты яткан мендәр астына тыгылды, ләкин коралы урынында юк иде.

Аширов тагын бер тапкыр ухылдап куйды, чөнки шулчак аның артка каерылган кулын, үзеннән-үзе килеп чыккан һәм, гомумән алганда, бу мизгелдә барыбер файдасыз булган пистолетын алу омтылышына җавап итеп, кинәт шундый каты итеп өскә таба күтәрделәр, әйтерсең аны судсыз һәм тикшерүсез үрә торган килеш асып куярга җыендылар. Ятып тора алмыйсың инде монда, теләмәсәң дә сикереп торырсың.

Бүлмәдә алар өчәү иде. Икесе аны тотып тора, өченчесе, штатский киемдәгесе һәм, күренгәнчә, аларның бу төркемендә өлкәне, имән бармагында Ашировның пистолетын әйләндерә-әйләндерә өстәлдә ярым утырып тора.

Ишек ачылып китте. Бусагада сөртенеп, автоматчы тарафыннан этелә-төртелә ишектән Гена килеп керде. Аширов идән тактасына төкереп куйды: җай чыгып кына тора бит, маэстро ассистентлардан унды да инде! Барысы да сатлык җаннар, вак кешеләр, беркемгә дә ышанырга ярамый. Нишлисең, ярар инде, кабахәт, соңында балачак дустын түгел, майор Егоровны саткан.

Аширов моны үзен гражданин Егоров дип атагач ук сизеп алды.

—Аякларыгызга киегез, хөрмәтле Виктор Васильевич, аякларыгызга киегез! Нигә төкеренергә инде хәзер?—диде ана штатский киемдәге начальник.

«Алай да сез Ашировны түгел, Егоровны тоттыгыз»,—дип Аширов үзен берничә мәртәбә күңеленнән тынычландырып алды.

Андый чакларда ул теләсә нинди мөшкел хәлләрдә дә үзенә юаныч таба белә иде. Ничек сәер тоелмасын, оптимист кеше иде ул.

Ул файдасызга аягы белән итегенең балтырына төрткәләде.

—Жибәрегез әле сез кулны, качмам мин аякка кимичә.

Инде фанера белән капланган грузовикның рәшәткәсе аша ул кулына сумка белән бидон тоткан кыртлаган тавыгының үзенең өенә таба атлавын күрде. «Щи алып килә,—дип ачу белән мыгырданып куйды Аширов борыны астыннан.—Сонга калдың. Ач килеш китеп барам менә».

Ярым карангы кузовта алай озак селкенеп барырга туры килмәде. Гена, акланып, бәйләнешсез генә нидер мыгырданды. Имеш, бер клиентларының күршесе барып әләкләгән. Аширов анлап алганның иң мөһиме—аны бары тик алты капчык он өчен генә гаеплиләр. Ул рәшәткә аша күренеп калган урам һәм тыкрыклар буенча аларны кая алып баруларын чамаларга тырышып карады, ләкин барыбер аңлый алмады. Бераздан нindidер подъезд төбенә килеп туктадылар һәм—ать-два!—хәтта ул учреждениенең эленмә тактасын да карарга өлгермәде.

Гена белән аны коридор икегә аерылган төштә, бусага төбендә үк аердылар. Башкисәрне каядыр арырак алып киттеләр, ә Ашировны үзен сюрприз көтеп торган бүлмәгә төртеп керттеләр. Өстәл янында теге, кичү янында ана мотоциклын кабызырга булышкан, ә аннары паромда төрле сораулар белән аптыраткан капитан Дубов утыра иде. «Тау белән тау гына очрашмый, ә чүлмәк белән чүлмәк очраша. Менә бу әйтемнең дә әйтеме инде!»—дип уйлап алды ул эченнән.

Аны капитан да шундук таныды.

—Ә мин уйлыйм-уйлыйм: Егоров, Егоров... Кичүдә танышкан теге майор түгелме икән бу, дип баш ватам. Нәкъ үзе икән бит, ә?—диде ул ашыкмыйча гына.

—Минем сезне беренче күрүем,—дип тәкәллефсез генә җавап кайтарды Аширов. Үзе исә эченнән, капитанның кыска гимнастеркасы да һәм итекләре дә шул ук—бик зурлар, өстәл астына сыймыйлар, дип искәреп алды.

—Нахал,—диде капитан арыган кыяфәт белән.—Ярар соң, син әйткәнчә булсын, алайса янадан танышырга туры килер. Сөйлә, Егоров, барысын да тәртип буенча сөйлә!

—Нәрсә сөйләргә соң?

—Фамилиян, исемен ничек? Тик чыннарын гына әйт, әлбәттә. Безгә гастрольләргә кайсы яклардан килеп чыктың?..

—Мин берни дә сөйләмим, мин исерек, сорау алырга хокукыгыз юк. Өреп караргамы?

—Нигә? Синнән болай да бер чакрымнан анкып тора. Теге чакта мотоцикл белән кайдан кайтып килә идегез?

—Мин әйттем бит инде: мин ангыра хәзер, көчле исереклек стадиясе астында. Менә хәзер әллә ниткән фантазияләр әйтеп ташлармын да аннары онытырмын. Ә сез миңа ябыштырып та куярсыз.

—Алып китегез!—дип боерды Дубов кыска гына.—Иртәгә сөйләшербез, май-ор...

—Әйе, майор. Шуна күрә минем белән тиешенчә сөйләшегез, формада булмавыма карамагыз,—дип Аширов гайрәт чәчә башлаган иде дә, ләкин инде аның белән беркем дә сөйләшергә теләмәде. Конвойчы исә кулын

артына каерды да бүлмәдән алып чыгып китте.

Ашировны ниндидер вак угрылар белән бергә гомуми камерага яптылар. Компаньоны анда юк иде. Ул мондагылар белән аралашырга да чирканды. Житмәсә, махмырдан башы авырта. Ул буш сәкегә менеп ятты да мизгел эчендә йокыга да талды.

Иртән аны тагын Дубов янына алып килделәр.

—Айныдыңмы?—дип сорады аннан Дубов.

—Айныдым шикелле.

Капитан алдында яткан кәгазьгә нидер язып бетерде дә кулъяулыгы белән тирләгән муенын сөртеп алды һәм, артык кереш сүзсез генә, күзләре белән аның күзләренә карап:

—Кем син?—дип сорады.

—Сезнең кулыгызда бит минем документлар.

—Ялган алар.

—Моны расларга кирәк әле.

—Раслап торасы да юк, синең монда сырланган хәрби часть дөньяда бөтенләй юк. Дезертирмы син?

—Һич юк! Мин а-а-выру кеше. Бума зәхмәте миндә. Соңгы формасы.

Аширов, акылдан язган кешенеке сыман, күзләрен акайта башлаган иде, тик капитан аннан өлгеррәк булып чыкты:

—Аны күрсәтергә уйлама да! Тиз акылга китерербез,—диде ул аңа.

Телефон шалтырады. Дубов трубканы алды. Аерым-аерым фразалардан һәм теше авырткан чактагы кебек җыерылган йөзеннән аның начальствосы белән сөйләшүе һәм бу әңгәмәнең аңа ошамавын аңларга була иде. Ул башка кабинеттагы начальствосына каршы төшәргә маташкан иде дә, ләкин чыбыкның теге башында бу юлы аның фикеренә мохтаҗ түгелләр иде бугай, аны ярты сүзендә бүлдерделәр. Һәм ул: «Есть!»—дип тамак кырып алды да трубкасын урынына куйды.

—Кызганыч, миннән алалар сине, Е-го-ров, ә мин монда синең җаныңны көнбагышны кабыгыннан чистарткан шикелле чистарткан булыр идем.

—Кая алалар?—дип сорады Аширов, кирәгеннән артык аек акыл белән кызыксынуын яшерә алмыйча.

—Курортка, туганкай, курортка...

Бу хәбәр аңа һич тә ошамады. Аширов: «Ул курорт дигәне Черек күлдәме?»—дип кармак та салып карады. Ләкин капитан Дубов аңа җавап бирмәде. Хәер, инде күкрәк авызының чәнчешеп куюыннан ук Аширов үзенең моннан соңгы киләчәге һич тә кызыгырлык булмаячагын, аны кесә караклары белән генә шөгыльләнми, ә ялган майор Егоров кыланмышлары турында күбрәк белә, димәк ки, аны Светочка-конфеточка, комбинат директоры, авыл кибете мөдире зарыгып көтеп торган һәм илле тонна он турындагы эшне тикшерәчәк башка ведомствога бирүләрен аңлап алды.

*Дәвамы киләсе саннарда*



Нәҗибә
Әминева

# ДОГАМ

## Горур тойганга

**Зур хаталарын кичердек.
Безне кичермәделәр.
Вак ялгыш өчен дә күпме
Агу эчермәделәр!
Исән калсак, кичерербез—
Әйдә «Җиңдек!» дисеннәр!.
Тик көчләләр киң күңелле—
Белмиләр. Белмәсеннәр!..
Кичерәбез үзебезне
Горур, көчле тойганга—
Дошманына миһербанлы
Патша төсле тойганга!..**

## Сизмәм

**Хәлемне аңламый гөлләр—
Торалар гел шатланып,
Өзгәләнеп, өсләренә
Еласам да капланып...
Теләр идем хыянәтне,
Нахакларны сизмәскә.
Мин дә берчак булырмын бит
Үлән, тузан йә чәчкә?..
Өзелмәс ул чак үзәгем,
Башканыкын да өзмәм,
Түшләренә кадасыннар,
Йә таптасыннар—сизмәм...**

*Нәҗибә ӘМИНЕВА — шагыйрә; татар һәм башкорт телләрендә дөнья күргән унга якын китап авторы. Башкортстанда яши.*

* * *

Көчле канатларым булса,
Әй биек очар идем!
Зәңгәрлекләр иңләр идем,
Болытлар кочар идем!

Горур караш ташлап кайчак
Түбәнлеккә,ваклыкка,
Талпынып карыйм киңлеккә,
Биеклеккә, сафлыкка.

Әмма сайлар, ваклар уяу—
Сакта тора тирәмдә...
Сүреләм, канатларымның
Каерыласын күрәм дә...

* * *

Күрәм бит: яшьтәшләремнең
Арткан саен яшьләре,
Салмаклана адымнары,
Көмешләнә чәчләре.

Ә минем соң, минем һаман
Яшьлектәге йөземме?
Мин дә бит шулар яшендә
(Онытканмын үземне!).

## Җитми шулар

Аллана дөнья:
Яшь Кояш
Уянып торып килә.
Тәпи басыйм дип,
Тауларга
Таянып торып килә...

Тәпи басарга өйрәнә,
Таулар көч биреп тора.
Әтәченә кадәр җирнең
Мактап кычкырып тора.

Бер күтәрелә дә Кояш
Таулардан күпкә биек,
Үләнен дә күреп җирнең,
Тора җылытып, сөеп.

...Җир һәм Кояш тормышында
Юк хәйлә, алдашулар.

Гел бер-берсен яклашу бар,
Беткәнче аңлашу бар.
...Их, кешеләр тормышына
Җитми нәкъ әнә шулар.

## Сүз матурлыгы

«Талга басып, тал тибрәтеп
Сайрый сары сандугач.
Җырлау түгел еларсың да,
Өзелеп-өзелеп сагынгач».

«Сандугач», «сагынгач» дигән
Сүзләр бигрәк пар икән.
Сагынуларның сандугач күк
Сары төсе бар икән.

Сагыну төсе...
Халкым күңеле
Тойгандыр ничек аны...

Күргәч тә җырның сүзләрен
Тоям яшем чыкканны.

Сагынган чак.
Җыр сүзләре
Йөрәккә ятты шуңа.
Сагынуларым—яратудан,
Күз яшем якты шуңа.

Сары-сары сагышның да
Бар шул үз матурлыгы.
...Керфегемдә якты яшьләр...
Әй, бу сүз матурлыгы!...

Локман Закир

# СӘЯСИ ПАРЧАЛАР

## Безнең корыч полководец

Легендар полководец, Берлинны алуда зур маһирлык күрсәткән Жуков турында, аның хәтәр кеше икәнлегенә бәйле имеш-мимешләр күп була, бу уңайдан хәтта Үзәк Комитет Политбюросында яшерен хат та саклана икән.

АКШның экс-президенты Эйзенхауэр мемуарында безнең полководец белән сөйләшүләренең берсе хакында кызыклы мәгълүмат бар. Кыскача гына әйтсәк, 1945 елның язында Берлинга таба Эйзенхауэр—бер яктан, ә аңа каршы яктан Жуков гаскәрләре ыргыла. Кайбер чыганаклар әйтүенчә, сугыш азагында безнең яктан ун меңнәрчә солдат һәм офицерлар рәхимсез кырыла. Берлинга барасы һәм керәсе юллар бик нык миналанган була, Эйзенхауэр үз юлындагы миналарны арчу белән шөгыльләнгән арада Жуков инде Рейхстагка кызыл флаг элеп куярга да өлгерә. (Искә төшерик, Рейхстаг түбәсенә иң беренче булып флагны татар егете—сержант Гази Заһитов кадый, ләкин моның данын Егоров һәм Кантария өстенә «аударалар»).

Берлинауганнан соң, маршалның өлгерлегенә сокланып, Эйзенхауэр сорап куя: «Кыска гына арада Сез ничек итеп шул тиклем территорияне миналардан чистарта алдыгыз?» Жуков горурлык белән җавап бирә: «Мин иң алдан пехотаны җибәрдем». Әйтәләр, шушы очрашудан соң генерал Эйзенхауэрны берничә көн очкылык тоткан, имеш. Совет Армиясендә штрафбатлар барлыгын белгәч кенә күпмедер тынычланган ул.

Жуков мәсьәләсендә Сталин һәм Берия шактый кыен хәлдә калалар: чөнки дәһшәтле сугыш героен Солженицын артыннан «шарашка»га җибәреп тә булмый, аны инглиз шпионы дип атавы да кыен. Хәйләкәр Сталин аны үзеннән ераккарак—Свердловскига, Урал хәрби округы башлыгы итеп җибәрә. Шунда ул, күргән кешеләр сөйләвенчә, хәрби парад вакытында атыннан егылып төшә. Күрәсең, сөрелгән Жуковның нервылары сынаткандыр һәм ул генсек Хрущев властька килгәннән соң гына 1956 елда Советлар Союзы герое дигән дүртенче йолдызны ала.

## Хәйләгә каршы хәйлә

Нанотехнологлар уйлап тапкан инглиз йозаклары Россиягә килеп кергәннән соң аны гап-гади җайланма белән ача белүче «осталар» пәйда була. Аннары—янмый торган сейфларның да «телен» чишә белүчеләр. Танылган совет криминалисты Олег Шейнин, казна малын урлаучыларны гаепләсә дә, аларның осталыгына соклануын яшерми. Аның хикәяләвенчә, зур срокта утыручы әнә шундый «медвежатник»ны башкаладагы эре бер партработникның сейфын ачар өчен төрмәдән алып чыгалар. Иреккә чыккан шундый осталарның берсен исә ачкыч югалтучылар сейфын ачар өчен еш файдаланалар.

Әдәби герой дәрәҗәсенә күтәрелгән әлеге кул осталары зур ачыш ясамаган, билгеле, алар техник яңалыкның юлына аркылы төшкәннәр һәм үзләрендәге сәләтне төзүгә түгел, җимерүгә таба юнәлткәннәр. Иҗади казанышка тискәре ижат белән җавап бирүләр хәтта югары даирәдә—Кремльдә дә булып торган. Әйтик, Сталинның «кибернетика—ялган буржуаз фән» дигән догматик сүзләре бу өлкәдәге үсешне ярты гасыр буе диярлек томалап торган. Элгәрге осталар тыйнак кыланса, бүгенгеләр исә хәтта политехнологларны да төп башына утырта. Ничекме? Дөнья базары шартларында Россиянең күпчелек автозаводлары банкротлыкка чыкканнан соң, хакимият белән берләшеп, алар иномаркаларны гаделсез юл белән базар сафыннан алып ташлау җаен уйлап тапканнар. Матбугат әһелләре язганча, бездә чыккан һәм электрон кабынуның ни икәнен дә белмәгән иске автомобильләргә «чурт» та булмый, ә менә электрон «каракლар» эре автосалоннардагы иномаркаларны күз ачып йомганчы сафтан чыгаралар икән. Исең китәрлек: безнекеләр файдасына бер дигән реклама, табыш! Ләкин, тотылмаган карак—карак түгел дигән гыйбарәне искә төшерсәк, мәгълүм кино герое капитан Жегловның тыелган алымыннан файдаланырга гына каладыр...

Ә бит кайчан гына әле чит илдә эшләнгән автомашиналарда урлашуга каршы ышанычлы электрон җайланма куелган, хәтта моторны дистанцион идарә аша гына да кабызырга мөмкин, дип шау килделәр. Ә нигә, начармыни бу? Караватта яткан килеш кенә двигательне кабызасың, киенеп чыгасың да машинаңа киләсең—аның моторы эшләп утыра, тышта утыз градус салкын булуга карамастан, эчендә исә өйдәге кебек җып-җылы.

Без, совет автомобильчеләре, озын кышларда машина моторын кайнар су һәм учак ярдәмендә кабызу өчен бер-ике сәгать чамасы азаплана идек. Кабина эчен һәм алгы пыялаларны җылыту хакында мәзәк-анекдот сөйләп, антисоветчиклар рәхәт чигә иде.

## Авыр үлчәүдәгеләр

Бөекбритания—Нобель премиясе лауреатлары белән генә түгел, үзләренең чамадан тыш авырлыгы белән рекорд куйган кешеләре белән дә дан казанган ил. Күптән түгел безнең телевизион каналлар аша шундыйларның берсен күрсәттеләр. Ул эре саналган аюлардан да уздыра, авырлыгы 240 килограмм, үзенең зур бүлмәсеннән менә 8 ел инде беркая да чыга алмый икән. Аның үзенә атап ясалган махсус караваты, бәдрәфе бар, аяк һәм өс киемнәре турында әйтеп тә торасы юк инде. Ашаудан зарланмый, бер утыруда өстәл тулы югары калорияле азыкны өч литрлы җиләк-җимеш согы белән бергә ялт иттерә. Тартмый, эчми, яшь булуына карамастан, хатын-кыз кавеменә исе китми. Шунысы кызык, туганнары һәм якыннары булуына карамастан, ул тулысынча дәүләт кайгыртуында. Шушыңа киткән сумманы әйтсәк, безнең бик күбебезне шундук очкылык тота башлар иде. Лауреат та, хезмәт яки сугыш ветераны, халык артисты, орден һәм медальләр иясе дә түгел үзе, безнең карашлар буенча ул бернинди дә социаль яклауга мохтаҗ түгел.

Кыскасы, социализм дип шапырынган Россиягә (СССР) караганда капиталистик Англия көнләшерлек дәрәҗәдә социаль ил икән. Аларның казнасында гадел җыелган акча һәрвакыт табыла, чөнки чиновниклар коррупция белән шөгыльләнми, акча урламый. Авырлыгы арткан саен бу кешегә тотылган чыгымнар да арта бара, шунлыктан аңа—зур суммалар тотып—бирәнлеген киметү нияте белән катлаулы булмаган (?) операция ясарга җыеналар. Тар карашлы кеше буларак фикер йөртсәк, юкса бит бу кешегә диварларны ватып, күтәрү краны ярдәмендә фатирыннан чыгарып, махсус транспорт белән больницага илтергә дә эвтаназия (үз теләге белән укол алып, бакый дөньяга күчү) ясаудан да яхшысы булмас иде кебек...

Юк, социаль капитализмда әхлак нормалары бүтәнчәрәк һәм без «тау чаклы» бу кешенең өч кешелек караватта селкенми диярлек ятуын, аның американнарча шат күңелле итеп елмаюын берничек тә аңлый алмыйбыз. Күрәсең, безнең зур илдәге күп кенә атказанган яисә халык исемен йөрткән зыялылар дус саналган Кубага түгел, нәкъ менә Англиягә барып сыеналар.

Сүз уңаеннан, үзебезнең авыр үлчәүдәге Казан кешесен дә искә алып китик әле. Аның авырлыгы 140 килограмм гына. Аның каруы, чирләре бик күп, йөри алмау сәбәпле инвалидлык белешмәсеннән дә мәхрүм. Ярдәм сорап,

телевизор башлыкларына мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр була ул, чөнки инвалидлык таныклыгыннан башка кешегә социаль ярдәм күрсәтелми икән. Чөнки бу гражданин ни лауреат, ни ветеран түгел.Ерактагы инглиз «кардәше»ннән аермалы буларак, ул алагаем караватта ятмый, диванда утырып тора һәм, авырулары гел борчып торганга күрә, елмаймый да. Үзенә тиешле инвалидлыкны алу бәхетенә ирешсә, һичшиксез, елмаер ул—шикләнмим.

Әмма пессимистик кыяфәтле бу кеше телевизор караучылар белән оптимистик рухта саубуллашты: инвалидлык таныклыгы алганнан соң авылга күчәм һәм авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү белән шөгыльләнәчәкмен, диде. Ходай аңа саулык һәм уңышлар китерсен!

## Таймырда—свастика?

Себердәге Таймыр ярымутравы җитмешенче киңлектә урнашкан. Популяр җырда әйтелгәнчә, Обь һәм Енисей елгалары коя торган Карск диңгезе сулары белән юыла. Норильск, Воркута, Салехард кебек шәһәрләр шушы мәңгелек туң якларында урнашкан. Таймыр турында Россия кызылэзтабарлары Өченче рейхка бәйле фактларны ачканнан соң гына еш сөйли башладылар. Безнең аңлавыбызча, фрицлар бит суыктан ифрат нык курыкканнар һәм Суык-генералның сугыш тарихына кереп калуы бер дә юктан түгел. Бактың исә, Ватан сугышына кадәр үк немецларның хәрби-диңгез базалары менә шушында урнашкан була. Ленд-линз буенча союзникларның СССРга җибәрелгән хәрби йөкләре нәкъ менә шушыннан киткән су асты көймәләре тарафыннан батырыла. Кызганыч, һәлак булган күп кенә суднолар һәм аларның командасы игътибардан читтә кала һәм әле дә булса арктик диңгез асларында мәңгелек йокыда.

Сорау туа: ни өчен соң әле Ватан сугышы бетеп, дистә еллар буена әлеге хәрби-диңгез базалары яшертен рәвештә сакланып калган? Сәбәбе бик гади—алар сугышка кадәр үк Гитлер белән Сталин союзник булган елларда ук төзелә, бирёдәге җир асты файдалы казылмаларын Германиягә сатып җибәрү өчен. Бер диктаторның икенче бер диктаторны алдавын инде хәзер мәктәп укучылары да белә. Ачы фактлар тагын да җитәрлек. Безгә каршы сугышучы немец aслары, Сталин бөркетләре белән бергә, совет авиамәктәбендә самолет йөртү һәм һава сугышы серләренә өйрәнә. Фюрерның иң яраткан генералы, танкист Гудерман сугышка кадәр Казан танк училищесында подполковник-инспектор булып хезмәт итә. Гитлер һөҗүм иткәннән соң да Кубань ашлыгы эшелоннардан көнбатышка әле һаман бушатыла тора... Ни гаҗәп, россияннарның күбесе бу хәлләрне белми яисә белергә теләми. Халыкның битарафлыгы, хәтта Таймырда свастика барлыгын да таныргa теләмәүләре Сталин файдасына була. «Халыклар атасы» үзенең әлеге хатасын, тагын бик күп җинаятьләрен үзе белән кабергә алып китә. Юкса, ул тәүбәгә килсә-килмәсә дә, немецларның хәрби базалары халыкка, киң җәмәгатьчелеккә фаш ителсә, бу нәрсә Нюренбург процессыннан ким булмас иде.

Беренче ранг капитаны, «Таймыр өстендә свастика» дигән китап авторы, отставкадагы Сергей Алексеевич Ковалев Югары хәрби-диңгез училищесын тәмамлаганнан соң Төньяк флот субмариналарында хезмәт итә. Ул бәлки антисоветчиктыр, ләкин аңа—су асты көймәсендә йөзгән кешегә,—антипатриот тамгасы сугу кыен. Шушы китабында ул әлеге хәрби базаларның кайда урнашуын, сәяси сәбәпләр аркасында су асты көймәләренең кат-кат исем үзгәртүләрен, андагы командир һәм офицерларның исемлеген язып чыга. Базаларда свастика гына түгел, хәтта немец тушенкасы, шоколад һәм 70 ел элек эшләнгән коньякка хәтле табыла. Алар мәңгелек туң шартларында сыйфатларын югалтмыйча сакланган була.

Бөек Ватан сугышы ветераны, Красноярск өлкәсенең Овсянки авылында яшәгән күренекле язучы Виктор Астафьев узган сугыш турында безнең бик саран, өстән-өстән генә белүебезнең сәбәпләре турында еш сөйли торган иде. Ул хаклы булган, күрәсең.

## Сөембикә

Үзгәртеп кору елларында татарлар, безгә килеп җиткән риваятьләрне күздә тотып, Казан ханбикәсенең өлгесен табарга тырышты. 1990нчы елларда, Сөембикәгә охшарга омтылып, күп кенә татар апалары һәм кызлары башларына

яулык ябып йөри башлады. Хәтерләсәгез, арадан берсен әле, рухи дәрткә бирелеп, кулларында күтәреп тә йөрттеләр. Ә инде йөзендә ханбикә чырае булмаганнар яулыкларын салдылар да тора-бара эзсез югалдылар.

Казан ханбикәсе образын хакимияттәгеләргә иң беренчеләрдән булып «Азат хатын», хәзер инде үсәннән-үсә барган «Сөембикә» журналы җиткерде (Бакый Урманче эше). Ханбикә роленә дәгъвалаучы хатын-кызларга әллә мимика, әллә эчке дөньялык җитмәде булса кирәк, ә менә Татарстан вице-премьеры ханбикә булырга күп яктан туры килә иде, әмма аның беркайчан яулык ябынганы булмады. Республика Дәүләт Советында баштарак яулык бөркәнүче яисә түбәтәй киюче депутатлар күренгәләде, тик андыйлар Путин вакытында җил искәндәй бик тиз юкка чыктылар. Күрәсең, бу очракта Путинның Казан сабантуенда үзенә бүләк ителгән түбәтәйне (Мәскәүгә алып китмәс өчен!) тиз арада кимонога алыштыруы да сәбәп булгандыр...

Әмма менә АКШ дәүләт секретаре Хиллари Клинтон, узган ел Казанга килгәч, үзен бик тә үзенчәлекле итеп тота белде, толерантлык үрнәге күрсәтте. Безнең гореф-гадәтләр үрнәгеннән чыгып караганда, ул Казан ханлыгы ханбикәсенең кинообразы роленә тиң булырлык иде. Сөйкемле, Сөембикәнеке сыман бераз моңсурак күзле Клинтон ханым, әгәр «Мисс-Татарстан» конкурсында катнашса, үз яше буенча 10 баллны, һичшиксез, җыяр иде. Кол Гали мәчетенә килгәч, ул ислам диненең барлык кануннарын үтәде: күркәм ясалган чәче өстеннән яулык япкан иде, мәчеткә керер алдыннан туфлиен салып, җиңел аяк киеме киде. Үзе католичка булса да, Хиллари тәре такмаган иде, чыннан да, исем-дәрәҗә яулап, халык арасында еш була торган кешеләр үзенең нинди дә булса дини конфессия вәкиле икәнлеген күрсәтмәскә тиештер. Искә төшерүебез гаеп булмас, безнең Камил Исхаков каршында утырганда Алла Пугачева муенына Патриархныкыннан ким булмаган зур тәре таккан иде. Ике олуг хатын-кызның гамәлләрен чагыштырып карасак, рус һәм америка культурасы арасында тирән ярыклар барлыгын чамалау кыен түгел.

## Аксак ат

Аксак атларның гомере озын булмый, чөнки сугышта аларны аталар, тыныч вакытта исә иткә җибәрәләр. Әгәр аксак атта адәм акылы булса, үз-үзен ничек тә үтерер иде, чөнки ул хуҗасына инде кирәксез. Хәтта кыргый атлар өерендә дә аларның язмышы күңелсез тәмамлана. Пермьдә төнге клуб һәм аңа йөрүчеләр, һич югы, бәхетсез атның шушы вәзгыятен истән чыгармаска тиеш иделәр, гәрчә клуб һәм атлар кайгы өчен түгел, шатлык китерү өчен туа.

Домна мичедәй янгын эчендә 160 кеше һәлак була (авыр туфраклары җиңел булсын). Исән калып та шифаханәгә эләккән авырулар да кызганыч, әлеге дә баягы, кайчакны алар аксак аттан көнләшеп куярга да мөмкин. Әгәр әлеге трагедияне Россиянең империячел менталитеты яссылыгыннан чыгып карасак, без—төнге клуб тамашаларыннан ерак торган кешеләр—анда булып үткән хәлләрне өстән-өстән генә беләбез, билгеле. Асылда кайбер сәбәпләр нәкъ менә өстә ята да инде. Моңа төшенү өчен исемле сәясәтчеләр һәм руханиларның әйткән сүзләренә колак салу да җитә, ә инде Россия православие чиркәүләренең хәтта Мәскәү Кремленнән дә уздырып җибәрүләрен күрсәң!.. Алар һәр фаҗига уңаеннан диярлек, мәрхүмнәрне күмү этикасын бозып, пафос белән тәкрарлауны алга сөрәләр. «Без бердәм», «Кайгы Россияне бердәм туплый» кебек урынсыз патриотизм хәтта фетнәле бер фикергә этәрә: күзгә күренмәс ниндидер бер көч, кешеләрне бергә туплау өчен, фаҗигаларны әллә махсус оештыра микән? «Халык—сарык» дигәндәй, гади кешеләрнең бик күбесе шушы сүзләрне якын кабул итә. Кайбер госчиновниклар кеше кайгысы хисабына рейтингларын күтәрергә омтыла икән, бу—әхлаксызлык билгесе.

«Аксак ат» клубындагы фаҗигане, Пермь өлкәсендә татар һәм башкортларның күпләп яшәвен истә тотсак, педартларга түгел, терактка сылтарга да мөмкин булыр иде. Әмма шәригать утлы очкыннар һәм исерткеч куллана торган мондый ял йортына мөселманнарның йөрүен тыя. Ә бәлки сөмсез-сүрән бәндәләр күңел ачучылардан көнләшкәндер? Гаепләләр арасында татар фамилияләре дә бар, тикшерү барышында ваһһабичылар «табылу» да ихтимал. Казынучы юристлар төнге клубның атамасына, ай-һай, игътибар итә белерләр микән? Кызганыч, Пермьдә «Сбитый летчик» дип исемләнгән янә бер төнге клуб бар икән әле...

Кем белә, «салкын» педартлардан кабынган кайнар янгын Россиядә төнге клубларны ябу-куркыту нияте белән эшләнгәндер? Сталин вакытында ул нәрсәләр бөтенләй булмаган ич, гәрчә Политбюро еш кына махсус дачада төнкәта бәйрәмнәр үткәрергә яратса да...

## Кәрлә утрауның зур эшләре

Эфирда ят бер сүз-исем ишетеп, баштарак радиоалгычны сүндереп куймакчы идем, мавыгып китеп, аннары ахыргача тыңлап бетердем. Чөнки сүз минем өчен билгесез булган экзотик бер дәүләт турында бара иде.

Аңлавымча, Науру—кәрлә дәүләт, мәйданы 21 кв. километр, халкы 15 мең кеше (чагыштыру өчен: Теләче районында шулай ук 15 мең кеше яши), Аны дәүләт дип атарга тел дә әйләнми, чөнки—БМО әгъзасы булуга карамастан, хәтта армиясе дә юк. Аңа армия тоту кирәкми дә, фосфат һәм кораллардан башка берниндн файдалы казылмалар булмау сәбәпле, бу бәләкәч илгә һөҗүм итәргә җыенучы да юк. Тын океандагы бу утрау—дәүләт күршеләреннән 400 чакрым ераклыкта урнашкан. Аңа бердәнбер куркыныч янавы мөмкин—әгәр дөнья океаны сулары чамадан артык күтәрелә калса, аңа ярдәмгә килүнең хаҗәте юк.

Науруда ирек сөючән, өске киемсез генә яшәүче, диңгез продуктлары белән тукланучы папуаслар яши. Комментатор аңлатуынча, Науруга очып килеп җиткән кошлар сирәкнең дә сирәге икән. БМОда тулы хокуклы член буларак, ул да бөек державалар сыман хәлиткеч бер тавышка ия. Науру президенты Маркус Стивен, әлеге хокуктан файдаланып, Абхазия һәм Төньяк Осетиянең суверенитетын яклап тавыш биргәннән соң, дуслык кредиты сыйфатында байтак акча каерды. Һәр җан башына 3,5 мең долларны тәшкил иткән бу ярдәм хәерчелектә калган россияннарның төшенә дә керми. Чөнки бездәге бик күп байлык һәм акча сугыш кораллары ясауга китә.

Берничә еллар элек Науру Тайваньның мөстәкыйльлеген танымаган өчен коммунистик Кытайдан зур суммалар ала. Аннары соңрак Тайваньның суверенитетын яклап тавыш биргәне өчен дә зур акчаларга ия була. Азат Абхазия һәм Осетиянең азатлыгын вәгъдә биреп тә танымаган күрше (союздаш!) Белоруссиягә караганда Науру Россиягә якынрактыр. Чөнки һәр белоруска 3,5 мең доллар бүлеп бирә башласаң, ил кесәсенең нык кына такыраеп каласын көт тә тор.

Утрауның «зирәк» хуҗалары чираттагы кредитны ашап бетерсәләр дә куркып калырга җыенмыйлар: әнә бит, булачак өр-яңа дәүләтләр—Көньяк Украина һәм Төньяк Казакъстан БМОның ишеген шакырга торалар. Зур Россиягә исә бәләкәй стратегик партнерлар эзләргә кала, фәкать акчаң булсын...

**Рашат НИЗАМИ** *тәрҗемәләре.*



*Матбугат йортындагы (Бауман, 19) Тукай клубында очрашу. Сулдан уңга: Нәби Дәули, Нәкый Исәнбәт, Нил Юзиев. 1980 ел.*



*Сугыш ветераны, шагыйрь-сатирик Маннур Саттаров (1920).*



*Туган як турында китап әзерләнә. Язучы Мирсәй Гариф (Марсель Гарипов) һәм табиб Рөстәм Бакиров. 2010 ел.*



*Иҗатташлар. Сулдан уңга: драматург Хәй Вахит, композиторлар Сара Садыйкова, Рәшит Гобәйдуллин. 70нче еллар башы.*



*Шагыйрь Рөстәм Мингалимов (1937).*



*Мәскәүдә очрашу мизгеле. Айдар Хәлим (сулда) һәм Миргазиян Юныс. 2010 ел.*

Фәнис
Яруллин

# ХӘТЕР ТӨПЛӘРЕНДӘ УТЛЫ КҮМЕР

КӨНДӘЛЕКЛӘР

1970 елда Куйбышев өлкәсендәге «Серноводский»га, 1975 елда Сакига, Кара диңгез буена Нурсөя белән барып дәваланып кайттык. Ана кадәр Латвиядә «Юрмала»да ике тапкыр дәваланган идек. Латвия безгә бик ошады. Нурсөя мине коляска белән урманнарга алып бара. Урманнардагы матурлык безнең яклар белән һич чагыштырырлык түгел. Анда кәкре-бөкре булып үскән яки корып сынган агачларга да әкиятләрдә генә була торган төрле сыннар ясап куелган. «Мәхәббәт имәне» үзе бер могҗиза. Караган саен яңа төсмерләр табасың. «Ни өчен бу имәнне «Мәхәббәт имәне» дип атадыгыз?»—дигән сорауга: «Бу—мәхәббәт кебек мәңгелек агач. Аны җил-давыллар да аудара алмый. Ул, сәясәт үзгәрсә дә, үз кыяфәтендә кала. Кешеләр генә һәр үзгәрешкә яраклашырга тырыша»,—дип җавап бирделәр.

Урманнарны айкап бетергәч, Нурсөя мине коляска белән диңгезгә алып китте. Юрмаладан ерак икән ул. 8-10 чакрым. Диңгез миңа ике төрле тәэсир итте. Беренчедән, зурлыгы белән. Йөзеп кереп китсән, арып су төбенә китәр иден. Икенчедән, диңгезнең елга кебек агып ятмавы ошап җитмәде. «Бөтен байлыгын үзенә җыеп утырган Карун бай кебек»,—дигән уй килде башка.

Мин йөргән шәһәрләрне санасаң, шактыйга җыела: Ташкент, Дүшәнбе, Орджоникидзеабад, Янгиюль.

Мин коенган елгалар—Ык, Дим, Идел, Зәя, Аму-Дәрья, Сыр-Дәрья, Канский, Енисей һәм башкалар. Хәзер уйлап карыйм да, иң чиста сулы елга Енисей белән үзебезнең Ык булган икән. Аму-Дәрья, Сыр-Дәрьяләр болганчык, суы соргылт төстә булып, йөзеп йөргән балыклар күренми. Ярларында безнең Ык буендагы кебек таллар-өянкеләр үсеп утырмый. Ул якларның туфрагы да соргылт комлы.

Тажикстан башкаласы Дүшәнбе шәһәрен икегә аерып торган елга да болганчык сулы. Ләкин шунда форель балыклары үрчеп ята. Шәһәр халкы шунда су коена, балык тота. Дүшәнбедән безне Нурек ГЭСына алып киттеләр. Анда юллар текә тауларны кисеп салынган. Юл читендәге ташлар өстеңә ишелеп төшәр төсле. Монда юл салучылар бик акыллы булганнар: текә таулы юлда машинаңның тормозы тотмаса, читкә борылып керергә асфальт юллар салынган. Ул тыкрыклар барган саен югарырак күтәрелеп, ватык машинаң 200-300 метр баргач, үзеннән-үзе туктый. Һәм шунда машинаңны төзәтергә мөмкинлекләр тудырылган. Нурек ГЭСының төзелеп яткан чагы. Машиналар агымы көчле. Юлда туктап тамак ялгарга теләсәң, 3-4 чакрым саен кафе. Кафеда тукталырга вакытың тыгыз икән, юл читендәге олы ташлар арасында шашлык пешерүчеләр йөгереп каршыңа чыга. Шашлыкларын машинаңны туктатып тормыйча, ачык тәрәзә аша гына аласың да акчаңны сузасың.

*Дәвамы. Башы узган санда*

Чөнки андый текә юллардан менгәндә машинанны туктатырга ярамый, туктасан, артка тәгәри башлыйсың.

Сукыр күп күрә, аяксыз күп йөри дигән гыйбарә бар бит. Дүшәнбедә икәнлегебезне ишетеп безне Ордженекидзебад шәһәренә кунакка алып киттеләр. Анда бер татар гаиләсенә бик шәп фатир биргәннәр икән. Кая барсак та минем күзем иң беренче китап шкафына төшә. Боларның китап шкафлары шактый бай. М. Җәлил, Һ. Такташ китаплары арасында үземнең китапларымны да күргәч, күңел сөенде. Яңа фатирны котларга татарлар гына җыелган икән. Татар гармуныннан әкрен генә агылып торган моңга җырлар кушылды. Аннары ярыша-ярыша шигырь сөйләү башланды.

—Безгә татар китаплары сирәк килә. Шуңа күрә укый-укый ятлап бетерәбез. Ә сезнең безгә килүегез тарихи вакыйга,—диделәр.

Алар белән (кызганыч, хуҗаларның исеме онытылган) кабат-кабат фотога төштек.

Без Дүшәнбедә йөргәндә безгә Ташкенттан ерак булмаган Янгиюль шәһәреннән телеграмма килә. Без белмәгән кешеләрдән. Алар безнең Таҗикстан якларында сәфәр кылып йөрүебезне каян белгәннәрдер. Телеграмма Таҗикстан Язучылар союзына килгән. Без Дүшәмбегә килүгә Язучылар союзына тукталып, үзебезнең координатларны калдырып киткән идек. «Без сезне шундый-шундый көнне Ташкент аэропортында көтәбез!»—диелгән иде телеграммада.

Без чакырган җиргә бара, куган җирдән китә торган кешеләр. Телеграммада күрсәтелгән көнне Ташкентка очтык. Ниндидер сәбәпләр аркасында самолет берничә сәгатькә тоткарланды. Күңелне бер сорау кимерә: «Безне кем каршылар, алар безне каян беләләр икән?» Безне каршы алучы миннән бер-ике яшькә өлкәнрәк бер ир кеше, исеме Әнис икән. «О-о, сезне көтә-көтә арып беттек. Әни анда нишләргә белми йөридер инде»,—дип каршы алды ул.

Безне «Волга» машинасы көтә иде. Ташкентның төзеклегенә, фонтаннар күплегенә сокланып йөрдек. Фонтанны мин җир астыннан бәреп чыккан сихри чәчәк дияр идем. Өскә кинәт тамчылар көлтәсе күтәрелгәндә салават күпере балкуы бу чәчәккә яңа ямьнәр өсти. Гомумән, суга мин битараф карый алмыйм. Ык буенда туып-үскәнгәдер инде,елгалар-күлләр, диңгезләр минем өчен гади бер табигать күренеше генә түгел, ә һәрберсендә ниндидер фәлсәфә яшеренеп ятадыр сыман. Елгалар, мәсәлән, дулкынланып агышы белән күзне ял иттерә, күңеленә җыелган уйларыңны тарата. Суның әле ярсып, әле әкренәеп агуы гомер этапларының ниндидер бер чорда бик тиз, ниндидер чорда әкренәеп алуын чагылдырса, диңгез-океаннар дөньяның чиксезлегенә ишарә кебек тоела.

Ярый, судан бераз читкәрәк китик. Әле бит безнең барасы юл шактый: Ташкенттан 30-40 чакрым. Кайта-кайта Әниснең кем икәнлеген белдек. Безне чакыручы Ямал апа икән. Әнис—аның улы. Мебель фабрикасында цех башлыгы.

Без барып кергәндә өстәлләр төрле-төрле сыйлардан сыгылып тора иде. Миңа караватка урын җәелгән. Юлда бик арыганлыктан, табынга утырганчы бераз ял итеп алдым. Ямал апа минем янга кереп сөйләшеп утырды. Ул 1918 елда Оренбургтан Ташкентка килгән. Ташкент җир тетрәү нәтиҗәсендә бөтенләй диярлек җимерелеп беткәч, гаиләсе белән Янгиюльгә күчкән. Ямал апаның ире шоколад фабрикасында баш бухгалтер икән. Кызлары Дания мәктәптә рус теле укыта. Барысы да русча, татарча, үзбәкчә әйбәт сөйләшәләр. Татар, башкорт әдәбиятын яраталар. Күп кенә язучыларның китаплары кулдан-кулга йөреп укыла-укыла таушалып, күп битләре яңадан ябыштырылган, төпләнгән. Шул исәптән минем китаплар да бар.

Безнең килүебезгә алар бик шатланды. Ишегалларында розалар чәчәк атып утыра, бакчаларында тәлгәш-тәлгәш йөзем җимешләре асылынып тора. Тамак ялгап алгач, мине верандага йомшак диванга чыгарып салдылар. «Шунда хозурланып ятып тор, тиздән мунча өлгерер»,—диделәр.

Ямал апа инде пенсиядәге кеше. Әнис белән Гадениянең (киленнәре) ике кызлары бар. Алар Нурсөяне бакчадагы чәчәкләр белән таныштырырга алып чыгып киттеләр.

Ямал апаларның кызлары Даниянең дә ике кызы үсеп килә икән. Алар, шәһәр

фатирында торганлыктан, бераз сонрак килделәр.

Бераздан безне мунчага алып киттеләр. Мине Әнис күтәрде, Нурсөяне Дания житәкләде. Мин мунчаны үзебездәгечә такта эскәмияле, тигезле-тигезсез җәелгән идән итеп күз алдына китергән һәм ябылыр-ябылмас җәрәхәтләрем каты ләүкәдә чабынып өр-яңадан ачылыр дип куркып барган идем. Мунча эченә кергәч исем китте. Мунча сәкеләрендә, ләүкәдә калын-калын ап-ак паралоннар. Бөтен җирдә чисталык, тәмле үлән исләре. Мунчаны үзебез кертешәбез дип Әнис белән Дания янибыздан китмиләр.

—Бар әле, кит, әнигә табын әзерләш. Авыру кешегә хатын-кыз кулы кирәк,— дип Дания Әнисне куып җибәрде. Мунчада төрле савытларда төрле үлән сулары. Һәрберсеннән үзенә генә хас хуш ис килә. Күпме вакыт үткәнен дә сизмисең. Йөрәккә дә авыр түгел. Юынып чыккач, йомшак җәймәгә төреп, күтәреп алып кайтырга Әнисне чакырдылар.

Дания мина ни өчендер больницалардагы шәфкать туташы булып тоелды.

Без мунчадан кайтуга безнең бүлмәгә бәллүр вазага тажларында чык тамчылары җемелдәп торган розалар кертеп куйганнар иде.

Янгиюльдә татарлар күп икән. Табын, әлбәттә, мул. Шоколад фабрикасыннан коньяк, шампан шәрабларын әрҗәсе-әрҗәсе белән генә китереп ыргыталар. Колбаса, сыр, чикләвек төсле итеп ясалган, моңарчы без күрмәгән ризыклар кабуга авыз эчендә эри. Шоколад, вакланган чикләвек төше. Анда яшел чәй генә эчәләр. Коньяк, шампан шәрабы өстәлнең һәр почмагында. Кыстап-кыстап эчерәләр. Дания гел минем янда. Минем күз кайсы ризыкка төшкәнен әллә күреп, әллә эчке бер тоем белән сизеп ала да, нәкъ шул ризыкны алга китереп куя. Әкрен-әкрен күнелгә кереп бара бит бу чибәр хатын. Янда гына Нурсөя утыра югыйсә. Миңа кыен да, рәхәт тә.

Мәҗлес дәвам итә. Даниянең ире бик матур җырлый икән. Нурсөя аның җырлавына мөкиббән китеп утыра. Бераз кызып алгач, парлап танцевать итүләр башлана. Әнис Нурсөяне уртага чакыра. Нурсөя дә ялындырып тормый. Бию ыгы-зыгысы арасында Дания мине үзенең буяулы иреннәре белән үбеп куя һәм салфетканың почмагын шәрабка батырып үзе калдырган ирен эзләрен ялт кына сөртеп ала. Кунаклар биеп туйгач, тагын табынга утырышалар. Кемдер җырлый, кемдер аны хуплап кул чаба. Җырдан шигырьгә күчәләр. Минем Ямал апаларда алты китабым бар икән. Күп кенә шигырьләрне яттан сөйләүләренә исем китте. Татарча җырлар китабы да өстәлдә ята. Теләсә-кайсы битен ачып җырлап җибәрәләр. Китап киштәләрендә Әнгам Атнабаев, Мостай Кәрим, Хәсән Туфан һәм башка бик күп шагыйрьләрнең китаплары бар. «Азат хатын» тегелмәләре, «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналлары шкаф өстенә өелгән.

Без бу кунакчыл гаиләдә бер атна тордык. Үземне Үзбәкстанда түгел, Казанда итеп тоя башладым. Көн саен мунча ягыла. Кайбер көннәрне Ямал апа Нурсөяне шәһәр кибетләренә алып чыгып китә дә, озаклап йөриләр. Ә Дания гел минем янда: кайбер көннәрне мунчага мине күтәреп алып бара да сәгатьләр буе юындыра. Бу хәлне, әлбәттә, өйдәгеләр белә, ләкин кунак хакына белмәмешкә салышалар. Даниянең ире Кытайдан килгән уйгыр (исеме хәтердән чыккан). Монда качып килгән. Кытайда институт бетергән, математик. «Монда килгәндә ни русча, ни үзбәкчә бер авыз сүз белми идем. Хәтта анкета тутырганда үземне «неграмотный» дип язганмын»,—ди. Берничә ай эчендә үзбәкчә өйрәнеп, үзбәк балаларына математика укыта башлый. Мәктәптә укытканда алар Дания белән танышканнар. Дания аны русча, татарча сөйләшергә өйрәткән. Бу Кытайдан килгән уйгыр егете шундый шәп итеп татарча җырлый иде ки, ул җырлый башласа бөтен мәҗлес тын кала. Җырның, шигырьнең халыкларны берләштерү көче барлыгына мин шунда ышандым. Читтә яшәүчеләрне татар шигырьләре, татар моңы берләштерә икән дигән фикер күнелемдә ныгыганнан ныгый барды. Бер атна эчендә бу кунакчыл гаилә белән тәмам дуслашып, үз кешеләр булып беттек.

Бер атнадан соң безне Сыр-Дәрьяга алып киттеләр. Анда тагын шундый ук сый, шундый ук хөрмәт. Кунакта йөреп без тәмам арыдык, өйгә кайтасы килә башлады. Анда Зөлфия апалар, Әлфия апалар: «Сез Янгиюльдә бер атна торгансыз, без дә

сезне бер атнасыз жибәрмибез»,—дип чат ябыштылар. Әлфия апалар кирпечтән бик зур яна өй житкергәннәр икән, өй туйларында булырга туры килде.

Казанга тагын Янгиюль аша кайттык. Данияләрнең бер дусты безне аэропортка үз «Волга»сы белән илтте. Китәр алдыннан, әлбәттә, мул табын әзерләнгән иде. Коньяк, шампан шәраблары белән чын мәгънәсендә коендык. Мин исереп үк беткәнмен. Безне озата барган Дания дә миннән ким исермәгәндер. Юкса аэропортка барып житкәнче ул мине помадага буяп бетермәс иде.

Дания әле безне озак вакыт онытмады. Һәр елны минем туган көнгә посылка сала иде. Ә анда бер шешә коньяк, чикләвек һәм тагын әллә нәрсәләр була торган иде.

Безгә кунакка килергә дә жыена иде, ләкин инфаркт алып, көтмәгәндә-уйламаганда бу дөньядан китеп барды. Урыны ожмахта булсын.

Самолетта экипаж ял итә торган якта өч урынга сузылып яттым. Казанга кайтып төшкәч кенә уяндым. Мин йоклаганда Нурсөя минем битләрне, муеннарны ирен буяуларыннан чистарткан. Өйгә арып-талып кайтып кердек. Тегендәге әллә ничә бүлмәле, жимешләр һәм чәчәкләр белән уратып алынган зур йорттан соң үзебезнең ике бүлмәле хрущевкабыз миңа шыксыз күренде. Совет власте элек артта калган Тажикстан, Үзбәкстан кебек республикаларны нык үстергәнлеген үз күзем белән күреп кайттым. Анда әдәбият та алга китте. «Дружба народов» журналы союздаш республикаларда яшәп ижат итүче язучыларның әсәрләрен даими бастыра килде. Ә бу журналда чыккан барлык әсәрләр аерым сериягә тупланып, калын-калын китаплар булып илгә таралды. Ә безнең кебек автоном республикада яшәүче әдипләр рус теленә тәржемә ителмичә озак ятты. Шуның аянычлы нәтижәсе буларак, бездә язылган күп кенә әсәрләрнең сюжетлары нинди юллар белән башка әдәбиятларга барып керде. Ә безнең әсәрләр, рус теленә тәржемә ителгән очракта да, инде кемнәрнедер кабатлау булып чыкты.

Бер кызык та, кызганыч та булган хәлне «Литературная газета» язган иде. Ничәнче ел икәнлеге хәтердә калмаган. Мәскәүдә М. Мәһдиевнең «Без кырык беренче ел балалары» дигән повестен русчага тәржемә итеп чыгарганнар. Ләкин типография ялгышы белән китапның тышлыгына А. Чехов хикәяләре дип куйганнар. Ул чорда дөнья һәм рус классикларының әсәрләрен чират торып алалар иде. М. Мәһдиевнең китабын да бик тиз алып бетергәннәр. Әлбәттә инде, соңыннан чыгарып ташлаганнар. «Литературная газета» бу хәлдән көлеп, «Магдиеву повезло»,—дип язып чыкты. Юкса М. Мәһдиевнең әлеге әсәре А. Чехов хикәяләреннән калышырлык түгел. Бу вакыйга «өлкән агай»ларның татар әдәбиятына кимсетеп карауларын күрсәтүче бер мисал гына.

Минем «Жилкәннәр жилдә сынала» повесте дә русчага тулы вариантта басылып чыкмады. Башта ул үзебезнең китап нәшриятында Имбовиц тәржемәсендә «Упругие паруса» исеме белән дөнья күрде. Бераз соңрак шул ук тәржемәдә Мәскәүнең «Советская Россия» нәшриятында, бернечә хикәя дә өстәлеп, «Первая борозда» исеме белән басылды. Повесть исә элеккечә «Упругие паруса» исеме белән, ләкин тагын да ныграк кыскартылып., татарча варианттагы фәлсәфи уйланулар, телнең сыгылмалылыгы бетерелеп, бары тик сюжетны гади телдә сөйләп чыгуга гына калдырылган иде.

Күп кенә тәнкыйтьчеләр бу повестьны Н. Островскийның «Корыч ничек чыныкты» әсәре белән янәшә куеп бәяләде. Мин «Корыч ничек чыныкты» әсәре начар, ә минеке шәбрәк дияргә жыенмыйм. Минем «Жилкәннәр»дә бөтенләй башка проблема күтәрелә. Анда авырлыкка очраган һәм табиблар тарафыннан үлемгә хөкем ителгән гап-гади авыл малаеның күкрәгеннән жанын умырып алып, аның матурлыгын кешеләргә күрсәтүе, имгәтелгән рухның ничек ныгый, чыныга баруы, яшәгән саен күнел күзенең ачыла, әсәр героеның офыклары киңәя баруы сурәтләнә. Ә Н. Островскийның Павелы—сәясәт корбаны. Бу әсәрнең авторы аны яшерми дә. Дусларына язган хатларында: «Башта партия, аннан соң гына гаилә»,—дип яза.

Авторларның язмышы охшаш булганга карап кына әсәрләрне бер яссылыкта күрү дөрес түгел. Павел белән Фәнияр дөньяга икесе ике төрле карый. Фәнияр рухи үсештә, туктаусыз эзләнүләрдә сурәтләнсә, Павел үзенең үткәннәрен, революция

өчен көрәшеп йөрүләрен исенә төшерә һәм сәламәтләнә калса тагын шул юлга басарга омтыла. Бу ике әсәрне бер яссылыкка куеп тикшерүчеләр, үзләре дә сизмәстән, татар әдәбиятының алтын фондына кергән «Җилкәннәр җилдә сынала» повестен икенчел әдәбият дип бәяләргә мәҗбүр булалар.

Руслар безне тәрҗемә иткәндә безгә икенче сортлы халык дип карыйлар. Халкыбызның гореф-гадәтләрен, канатлы сүзләрен, бер үк сүзнең әсәрдәге вәзгыятькә карап төрле мәгънә алуын исәпкә алмыйлар. Шунлыктан безнең әдәбиятыбыз аларныкыннан түбән килеп чыга.

Минем үземә дә шактый гына тәрҗемә эше белән шөгыльләнергә туры килде. Житмешенче елларда булса кирәк, миңа әзәрбайҗан шагыйрьләренең бер көлтә шигырьләрен бирделәр. Әзәрбайҗан әдәбияты тирән тамырлы, бай әдәбият. Университетта укыганда миңа әзәрбайҗан әдәбияты турында курс эше язарга туры килгән иде. Шунлыктан мин үземә бирелгән шигырьләрне тәрҗемә итәргә курыкмыйча алындым. Безнең Татарстан Язучылар Союзы әзәрбайҗан шагыйрьләренең шигырьләрен татарчага тәрҗемә итеп, «Каспий дулкыннары» исеме белән күмәк җыентык бастырып чыгарырга әзерләнә иде. Мин бөтен көчемне һәм сәләтемне салып үземә бирелгән шигырьләрне татарчага тәрҗемә иттем. Тәрҗемәгә җаваплы карасаң, ул үзең иҗат итүдән дә авыррак. Үз иҗатыңда син иркле, ә тәрҗемәдә билгеле бер калыптан читкә чыга алмыйсың. Син тәрҗемә иткән халыкларның әдәбиятын, стиль үзенчәлекләрен, телдә йөргән канатлы сүзләрнең үзебезнең телдә нинди вариантлары барлыгын, кыскасы, тагын бик күп нәрсәләрне хәтер аша, акыл аша уздырасың. Төшенеп җитмәсәң, ул халыкларның классикларын укыйсың. Ә «өлкән агайлар» безнең кебек «вак-төяк» халыкларның гореф-гадәтләрен, яшәү рәвешләрен, һәр сүзнең төбендә ни ятканлыгын тикшереп тормыйлар шул. Боларга ничек тә ярый дип карыйлар.

«Каспий дулкыннары« Язучылар Союзында безнең тәрҗемәләрне тикшереп чыкканнан соң гына дөнья күрде.

Үз иҗатым тукталып торган чакларда берәр яраткан шагыйремне тәрҗемә итә торган идем. С. Есенинның «Восточные мотивы» дип аталган циклын тәрҗемә итеп, «Казан утлары»на җибәргән идем. Ул вакытта журналның поэзия бүлегендә эшләүче Нури Арсланов, Есенинны тәрҗемә итүчеләр синнән башка да күп дип, тәрҗемәләрне дөньяга чыгартмады. Ләкин мин тәрҗемә итүдән туктамадым...

Тәрҗемә көчне һәм вакытны күп ала. Миңа үз әсәрләремне язарга кирәк. «Әнә килә автомобиль» пьесасын язып ятам. Бу—1973 ел. Дөресен әйткәндә, пьесалар язарга мине Туфан Миңнуллин «котыртты»:

—Менә син шигырьләр язып, мәче теле чаклы китаплар чыгарып ачлы-туклы яшәп ятасың. Синең бит каләмең бар. Әнә бөтен кеше ябырылып укырлык повесть яздың («Җилкәннәр җилдә сынала»ны әйтүе). Шундый повесть яза алган кеше рәзе пьеса яза алмый. Тагын шунсы бар: үзеңнең язганыңны халык ничек кабул иткәнен күреп-ишетеп утырасың. Ә синең шигырьләреңне берәр кыз трамвайда укып бара да онытa.

—Бәлки, онытмыйдыр.

—Ну малай, онытмаган очракта да аңа синең шигырең ничек тәэсир иткәнен белмисең бит. Аннары шунсы бар: шигырь язып тамак туйдырып булмый.

Без Туфан белән еш кына бәхәсләшеп алгалый идек.

Шушы сүздән соң мин пьеса язу турында уйлана башладым. Бик актуаль тема кирәк иде. Күршеләрнең «Москвич» алулары, драматург Сәет Шәкүровның һәм үзебезнең чакрым саен сүнеп аптыратучы «Запорожец» пьесама тема табарга булышты. Халыкның инде тамагы туеп, байлык артыннан куа башлаган чагы. Ә иң зур байлык—машина. «Москвич»яки «Жигули» алып җибәрсәң, син танышбелешләрең алдында бер баскычка күтәреләсең. Ниһаять, пьеса язарга тотындым. Мин аның бер кисәген язган саен Туфанга укытам. Ул укый да минем язганнарымны пыран-заран китереп ташлый. Шулай шактый җәфалана торгач: «Ярар, минемчә, ару гына әйбер килеп чыккан. Марсель Сәлимҗановка күрсәтеп карармын. Ул нәрсә әйтер тагын»,—дип, Туфан пьесаны алып китте. Башта аның исеме бүтәнчәрәк иде. «Әнә килә автомобиль» дип Туфан атады. «Моның өчен синнән бер коньяк инде, малай»,—диде ул.

Пьесаны М. Сәлимҗанов та, артистлар да ошаткан һәм аны озак тозлап яткырмыйча 1974 елда Г. Камал театрында М. Сәлимҗанов үзе куйды. Спектакль озак еллар Г.Камал һәм К.Тинчурин театрларында гел аншлаг белән барды. Һәм чынлап та ул минем кесәне шактый калынайтты.

Дәрт сүрелгәнче тагын бер пьеса яза башладым. Ләкин миңа ул пьесаны туктатып торырга туры килде. Чөнки театрдан заказ килде. Миңа В. Шукшинның «Энергичные люди» әсәрен сәхнәләштереп тәрҗемә итәргә кыштылар. Алынганда бик җинел булып тоелса да, эшли башлагач шактый кыенлыкларга очрарга туры килде.

Беренчедән, В. Шукшинның теле төрмәчеләр, жуликлар жаргоны белән шыплап тутырылган. Андый жаргон сүзлекләрдә дә юк икән. Безнең өйдә гомумән сүгенүләргә, тәмәке тартуларга табу салынган булганлыктан, татарча да сүгенә белми идем. Дөрес, бер дә сүгенү сүзе ишетергә туры килмәде дип әйтә алмыйм. Бар иде ул безнең заманда да исереп сүгенеп йөрүчеләр. Ләкин алар бөтенләй башкача сүгенәләр. Алар Шукшин сөйләмен белмиләр. В. Шукшин сүзләрен бераз йомшартыбрак, үз телебезгә якынайтыбрак бирергә туры килде. Аның язу стиленә төшенү өчен «Сельские жители», «Там, в дали», «Характеры», «Красная калина» әсәрләрен укып чыктым. Шунсы кызык тоелды: В. Шукшин да минем белән бер чорда яза башлаган икән. Бу «Энергичные люди» әсәре дә 1974 елда сәхнәгә куелган. Сүгенә-сүгенә язган Шукшинга Ленин премиясе бирелде. Безнең агай алай язса, аны матбугатка да чыгармаслар иде.

Тәрҗемә иткәндә икенче авырлык ни проза, ни сәхнә әсәре булмаган катнаш жанрны тамашачы карарлык, артистлар рәхәтләнеп уйнарлык пьеса итүдә иде. Анда кайсы персонажның сүзләре икән бу дип уйланып утырырлык җирләр күп иде.

Көч күп түгәргә туры килде. Җитмәсә, режиссер ашыктыра: бу сезонда куярга кирәк, ул безнең планга кергән, ди.

Тырыша торгач, «Энергичные люди» әсәрен тәрҗемә итеп, сәхнә әсәре итеп ясап чыктым. Исемен «Әшнәләр» дип куйдым. Чөнки әсәр көчле кешеләр турында түгел, әшнәлек, астыртын рәвештә урлашу турында бара иде.

Бу спектакль әллә бер, әллә ике ел барды. Тамашачы: «Үзебезнең исерек ирләребездән дә гарык. Монда килеп, аларны акча түләп карап утырасыбыз килми»,—дип, спектакльне карап бетермичә чыгып китә башлагач, аны туктаттылар. Бәлки, тәрҗемәсе дә бик шәп булмагандыр. Ә. Гаффар да әнә: «Спектакль шәп, ләкин тәрҗемәдә бераз җитешсезлекләр бар»,—дип язып чыккан иде.

Аннан соң да «Иностранная литература» журналындагы үземә кызык тоелган кайбер әсәрләрне татарчага тәрҗемә итә идем. Бу тәрҗемәләр акча да, дан да китерми иде. Аларның күбесе үземә каләм шомарту өчен генә булды.

Китап җене кечкенәдән кагылган иде миңа. Җәй көне ишегалдын себереп чыгара идем дә, мичкә тәгәрәтеп пешерелгән бәрәңгене кабыгы-ние белән ашый-ашый, ишегалдындагы яшел чирәмгә ятып, йә Том Сойерга, йә Робинзон Крузога әвереләм. Ялгыз утрауда яшим. Кәҗәләр асрыйм. Кәҗә димәктән, безнең үзебездә дә алар шактый иде. Чөнки кәҗә сөтенә налог юк. Ә сыерыныңның 300 литр сөтен бушлай хөкүмәткә тапшырырга кирәк.

Бераз читкәрәк киттем бугай, сүзем китаплар турында иде бит. Мин инде 4-5 сыйныфларда ук авыл китапханәсендәге барлык китапларны укып чыккан идем. Ж. Вернның хыялый шарына утырып Айга очкан чаклар да булды. Ге де Мопассанның «Милый друг»ын укып аның чибәр сөяркәләрен тартып алулар, Л. Толстойның ире була торып сөяркә белән типтерүче «Анна Каренина»сын «кыйнап» ташлаулар, А. Пушкинның «Капитан кызы»н эзләп йөрүләр. Кыскасы, күп иде безнең маҗаралар. Китаплар мине кәлҗемәле, чабаталы дөньядан аерып Ж. Верннның «Серле утрау»ларына, Достоевскийның кан кардәш Карамзиннарына, «Юләрләр йорты»на, тагын әллә кайларга алып китә. Кеше күңелен бер генә нәрсә дә китаплар кебек баета алмый. Китап ул акыл аша синең эчеңә кереп кан тамырларын буенча ага башлый: тетрәнәсең, сокланасың, яратасың, нәфрәтләнәсең, хыялланасың. Ә хыял реаль дөньядан югары күтәрә. Хыял канатларында Айга, йолдызларга менеп, тишек чабаталарыңны эләсең. Хыял ярдәмендә ел үсәсең ай үсәсең, үсмер малайдан

житкән егеткә әверелеп, кызлар кочагына керәсең. Китап сине һәм физик, һәм рухи яктан үстерә. Мин хәтта монтер булып эшли башлагач та көндез ашарга дигән ипи янына бераәр китап сала торган идем. Бәлки мине язучы итәргә әнә шул «китап жене» булышкандыр.

Гомумән, мин яшьтәшләремнән тизрәк житлектем. 14 яшьтән «ябалак куа» башладым. Безнең якта кызлар белән йөрүне «ябалак куу» дип атыйлар иде. Хәзер яшьләр арасында бу атама онытылып бара. Хәер, хәзер авыл яшьләре рухи яктан деградацияләнә, таркала. Безнең китапханәләрдә, клубларда газета-журналлар өелеп тора иде. Клубка барып шырды-бырды уеннардан кызык тапмаучылар газета-журналлар укый. Мин «Совет әдәбияты»н чәлдереп тә кайткалый идем. Чөнки ул бер генә булмый. Күп булгач, бер журналның югалганын сизмиләр иде бугай. Ә бәлки, ул газета-журналларны кеше өенә алып китеп укысын өчен дә күпләп яздырганнардыр әле.

Безнең авылда ике китапханә бар иде: берсе—мәктәп, берсе—авыл китапханәсе. Шулай ук клуб та икәү: мәктәп һәм авыл клублары. Мәктәпнеке «Пионер клубы» дип атала һәм анда укучы балалар төрле спектакльләр куя, ә ул спектакльләргә колхоз эшеннән арып кайткан ата-аналар килә. Һәр ата-ана үз баласының ничек уйнавын күрергә тели. «Бишле»гә укучы буларак, ул спектакльләрне пионервожатый белән мин оештырырга тиеш. Чөнки мин инде беренче класстан башлап класс старостасы, өлкән сыйныфка күчкәч, учком председателе. Хәзер учкомнар мәктәпләрдә юк бугай инде. Ә учком председателе мәктәптәге тәртип өчен дә, укырга килмәгән балалар өчен дә җаваплы. Җаваплы эш кешене тәртипкә өйрәтә. Безнең мәктәп зур, һәр класста 32шәр бала. Утыз икене икегә тапкырласаң, шактый җыела. Нигә икегәме? Чөнки бер сыйныфта укучылар күп: аларны икегә бүләргә туры килә: «А» һәм «Б» классларына.

Тәртипсез укучыларны бераз тәртипкә китерер өчен үземә ярдәмче итеп бер класста өч ел утырып калган Карамны сайладым. Аның йодрыклары мунча ташы кебек каты, әти-әнисез үссә дә, бик көчле иде. Житмәсә, тәмәке тарта. Мин аңа: «Карам, син миңа ярдәм ит, ә мин сиңа дәресләреңне әзерләргә булышырмын»,—дидем.

—Укып мулла булмассың, чукып карга булмассың дип әйткән ди безнең әбекәйнең әбисенең әбисе,—диде ул.

—Син бит көчле малай,—дидем Карамның салпы ягына салам кыстырып.—Мәктәптәге бөтен малайлар синнән куркып тора.

Бу сүздән соң Карам кукрәгән киереп куйды:

—Һы, курыкмый карасыннар!

—Шундый бөтен мәктәпне дер селкетеп торган малай неужели «2» ләрне генә җиңмәс икән?

—Һы, «2» бит ул тигәнәк кебек, чалбар балагыңнан алып ташласаң, жингә ябыша.

—Без аларны икәүләп чүпләрбез.

Карам озак кына ыгы-мыгы килеп, карышып маташты. Аннары:

—Миңа нишләргә соң?—диде.

—Иң беренче үзеңнән башла.

—Үземне нишләтим соң мин?

—Тәмәке тартуыңны ташла.

—О-о, ансы булмас, дускай. Аннары мин бит себерке яфрагы гына тартам. Тәмәке алырга акчам да юк минем.

—Алайса, бигрәк шәп. Себерке яфрагы тартып, шырпы әрәм иткәнче ташладың да куйдың.

—Тәмәке ул, беләсең килсә, егетлек!

—Синеңчә, Фәйзылбарыйлар, Мәзһапләр егетме?

Бу сүзләр Карамны бераз уйга калдырды. Аннары ул:

—Әйттең сүз,—диде.—Аларны мин бер йодрыгым белән икесен бергә егам, селәгәйләр.

—Шулай бугач, син аларны да тәмәке тартудан туктата аласың.

—Аларны туктатып булыр, ансы. Бер аулак тыкрыкта изеп ыргытсаң, тәмәке сүзен онытырлар. Үзем генә... Белмим.

—Син бит көчле егет.

Карам йодрыгы белән койма тактасына китереп сукты. Кулын авырттырып, авырткан җиренә өреп торды.

—Беләсең килсә, минем туйганчы бәрәңге дә ашаганым юк. Мин бит мәктәпкә тамак туйдырыр өчен генә йөрим.

—Ничек? Мәктәптә ашатмыйлар бит.

—Ә мин кызларның көндез ашарга дип алып килгән ипиләрен урлап ашыйм.

Мин аның урлашканын белә идем. Ләкин кызлар анардан куркып бу хакта укытучыларга әйтми иде.

Ул көнне мин Карамга берни әйтә алмадым. Барыбыз да ярата торган Миннур апага гына Карамның хәлләрен сөйләдем. Миннур апа бу мәсьәләне педсоветта күтәреп чыккан. Бик ярлы кешеләрнең балаларына ярдәм итү өчен мәктәпнең махсус фонды бар икән. Карамның абыйсы Кабиз районда ниндидер эштә эшләгәч, Карамны бу исемлеккә кертмәгәннәр. Миннур апа сөйләшкәннән соң гына Карамга көндезге аш урынына күпмедер ипи бирә башладылар. Карам үзенең ипиенең беразын гына ашый да, калганын сумкасына салып куя иде.

—Ипиеңне нигә ашап бетермисең?—дидем ана.

—Т-с-с!—диде ул бармагын ирененә куеп.—Өйдә минем әбекәй бар. Ана да ипи кирәк...

—Ә абыең?

—Аның эшләгәне үзенә дә җитми. Аның бит бер күзе юк. Шуңа рәтле эшкә алмыйлар.

Карамның бу сүзләре мине тетрәндереп җибәрде. Ярый әле безнең әни бар дип сөендем.

—Рәхмәт сиңа, дускай,—диде Карам, җилкәмә сугып.

—Нигә?—дигән булдым мин.

—Ипигә,—диде Карам.—Ә тәмәкене ташлыйм мин аны. Вакыты җиткәч, тәмәке тартмый да егет булырбыз әле.

Мин Карамга текәлеп карадым. Ул инде чынлап та егет булып килә түгелме соң? Уналтыны тутырды бит инде. Тиккә генә кызларны почмакка кысрыклап, кабара башлаган түшләрен күлмәк аша тешләмидер. Сугыш елларында укырга кергәнлектән, бер сыйныфта укучыларның яшь аермасы 2-3әр ел иде. Җиденче классны бетерүгә колхоз аларны рәхәтләнеп эшкә җигә башлый. Билгеле, мондый кызларның, ачлы-туклы яшәүләренә карамастан, түшләре кабара, күңелләре алгысый. Шуңа күрә малайлыктан егетлеккә күчеп баручылар белән бераз шаяргалап алу алар өчен кызык кына булгандыр.

Дәрестән соң без, тәмәкечеләр һәм мин, бергә җыелдык. Карам нишләр икән дип уйлап торам. Ә ул букчасыннан бер дәфтәр, кесәсеннән уылган яфрак чыгарып, зур итеп дәфтәр битенә тәмәке төрде. Фәйзылбарыйның кесәсеннән ялт кына шырпы тартып алды да тәмәкесен кабызды. Аннары аны тирән итеп берничә тапкыр суырды. Шуннан соң тәмәкесен җиргә салып таптады.

—Менә, күрдегезме?

—Күрдек, күрдек.

—Күрсәгез шул: бу минем соңгы тапкыр тартуым. Ә хәзер сез дә шулай итегез...

Малайлар бер-берләренә карашып кесәләреннән учларына тәмәкеләрен бушаттылар. Карам аларга үзенең дәфтәр битен сузды. Фәйзылбарый белән Мәһәп телләре белән кәгазьне чылата-чылата тәмәке төрделәр. Һәрберсе тончыга-тончыга бер суырганнан соң тәмәкеләрен җиргә салып таптады һәм: «Инде нишләргә кушасыз?»—дигән сыман әле Карамга, әле миңа карадылар.

—Бүгеннән тәмәке тартуны ташлыйсыз,—дидем.—Күрәсезме, Карам ташлады. Ә ул сүзендә тора торган егет.

Үзен егет дип атагач, Карам янә бер башка үсеп киткәндәй булды. Мин кайсыдыр китапта: «Кешене усаллык белән җинеп булмый. Иң начар кешедә дә яхшы

сыйфатлар яшеренеп ятарга мөмкин. Аның шушы сыйфатын ачып үзенә күрсәтергә кирәк»,—дигән сүзләр укыган идем. Бу очракта шул сүзләрдән файдаланып:

—Сез бит яхшы егетләр!—дидем.

Мин бу сүзләрне нык ышанып һәм тегеләрне дә ышандырырлык итеп әйтергә тырыштым.

—Безнең тәти егет булып йөрисебез килми. Минем кызларның әллә кай җирләрен умырып тешлисем, аларны билләре өзелгәнче кочасым килә,—диде Фәйзылбарый.—Ә синең?—диде ул Мәзһәпкә. Мәзһәп бер сүз дә дәшмәде.

—Селәгәй!—диде аңа Фәйзылбарый.—Кызлар исе синең борыныңа кермәгән әле.

—Туктагыз әле, егетләр,—дип сүзгә кушылдым.—Монда бит без кызлар турында сөйләшергә җыелмадык. Тәмәке тарткан кешедән әшәке ис килә. Ә үзегез кызлар дигән буласыз,—дидем.

—Бик акыллы булып киттең әле син,—диде Мәзһәп.—Әллә укытучы булырга җыенасыңмы?

—Укытучыларның ялчысы бит инде ул,—диде Фәйзылбарый һәм күкрәккә йодрыгы белән кундырды. Тыным кысылып куйды. Кабыргага Мәзһәп чәпәде. Юаш малайдан моны көтмәгән идем. Үзеннән кече малайлар башына сугып киткәндә дә җавапсыз кала торган Мәзһәп синең кабыргаңа китереп чәпәсен әле. Бик каты ачу килде. Мәзһәпнең арт ягына табаны куба башлаган ботинка белән бөтен көчемә китереп типтем. Ул авып китте. Бу хәлләрне моңарчы сүзсез генә күзәтеп торган Карам:

—Життеме сезгә, калай әтәчләр. Әгәр җитмәсә үзем өстим,—диде.

Карам өч көнгә бер генә юыла торган кулларын йодрыклап теге малайларның касыгына менеп төште. Сугышканда ул кешенең иң авырткан җиренә суга белә иде. Малайларның кикрикләре шиңде. Фәйзылбарый көчкә-көчкә тын алып:

—М-менә үзең тартмассыңмы әле,—диде.—Син тартсаң, без дә тарта башлыйбыз.

—Менә моны күрәсезме?—диде Карам, кысылган йодрыгын Фәйзылбарыйның борын төбенә китереп.—Менә моннан нәрсә исе килә?

—Тәмәке исе!—диде Фәйзылбарый.

—Бу синең соңгы тапкыр тәмәкене иснәвең булыр.

—Карарбыз әле. Кемнеке соңгы булыр.

—Нәрсә карарсыз?—Карам малайларның ияк asларына менеп төште. Мәзһәп телен тешләде, ахры, кан төкерде.

Шушы сөйләшүдән соң безнең мәктәптә тәмәке тартучы булмады.

Еллар үтеп, мине Красноярск хәрби госпиталеннән район больницасына кайтаргач, безнең палатага Карам килеп керде. Өсте-башы бик пөхтә.

—Нишләп сине монда Урыссу болнисына китереп тыктылар? Монда бит кандала, таракан оясы. Әнә, көпә-көндез стеналардан үрмәлиләр,—дип башлады Карам сүзен.

—Соң, үзең беләсең бит: мин армиягә киткәндә безнең авыл Ютазы районына керә, ә районның болнисы Урыссуда иде.

—Чукындырып яталар шунда. Баулының борын төбендәге Кызыльяр авылын Ютазыга кертеп. Аналарын себерим... Йә, ярар, кадалышып бетсеннәр бөтенесе бергә. Үзеңнең хәлең ничек?

—Ял итеп ятам әле.

—Менә мин дә ялга кайттым. Мин колхоздан качтым. Карагандага китеп, шахтага эшкә кердем. Акчаны пачкалап бирәләр, малай. Ипигә ак май ягып колбаса белән ашыйм.

Карам кесәсеннән бер пачка акча чыгарып тумбочка өстенә ыргытты.

—Мә, кирәк нәрсәңне алырсың.

—Юк, кирәкми, дускай! Монда бит безнең ашау байдан, үлем Ходайдан.

—Үлем турында сөйләмә әле син. Менә минем монда әҗәл даруым бар.—Карам пинжәгенең түш кесәсеннән юка шешәле коньяк китереп чыгарды.—Әйдә, тиз генә моны юк итик әле. Кем әйтмешли, нәселе корысын.

Карам минем ай-ваема карамый тумбочкадагы алюмин кружкага бераз коньяк агызды да үзе эчеп куйды.

—Менә күр, агу түгел.

Ул кружканы крандагы су белән чайкап миңа да коньяк салып бирде. Мин кыстатып тормадым, эчеп куйдым. Эчми эчкәнгәме, бик тиз башка китте. Без укып йөргән вакытларны искә төшереп алдык.

—Тәмәке белән эшләр ничек?—дип сорадым.

—Шуннан бирле авызга алган юк.

—Фәйзылбарыйны күргәнең бармы?

—О-о,—диде Карам,—аны хәзер танырлык та түгел, нефтькә эшкә кергән. Өстендә хром пальто, тотып карадым. Каймак кебек. Начальник диярсең.

Без Карам белән озак сөйләшеп утырдык. Ул инде элекке атаман Карам түгел, акыл утырткан. Чыгып киткәндә ул болай диде: «Мин бераз акча туплау белән авылыбызга кайтып йорт салам. Безнең Ык буйлары, аръяктагы Өемташлар гына ни тора! Шахтада акчаны күп бирәләр бирүен, ну мин җир астында эшләргә яратмыйм. Үлгәч тә өлгерербез әле анда эшләргә.

Карам шул китүдән кайта алмады. Аны шахта басты. Ә Фәйзылбарый белән очрашырга туры килде. Мине шигырьләр язган өчен район больницасыннан куып, туган йортыбызга кайтарганнар иде. Көннәрдән бер көнне шәп тукымадан тегелгән аксыл-соргылт костюм кигән бер егет килеп керде. Тынлаусыз сары чәчләрен шома итеп артка тарап куйган.

—Әллә танымыйсың инде? Мин Фәйзылбарый бит. Син тәмәкене ташлаттырган Фәйзылбарый.—Ул яныма килеп җилкәләремнән сыпыргалап куйды.

—Мин сине берәр начальникмы әллә дип уйлаган идем.

Фәйзылбарый көлеп куйды.

—Кая инде ул безгә начальник булу! Нефте чыгарабыз. Читтән килгән егетләр эш авыр дип зарланалар. Миңа авыр түгел. Безнең җилкәләр ач колхозны күтәреп өйрәнгән. Монда ичмасам уч тутырып акчасын аласың.

Фәйзылбарый ишек төбендә калдырган сумкасын минем янга алып килеп, өстәлгә күчтәнәчләр тезә башлады.

—Әйдә, дустым, сыйлан. Сине больницада ашатмаганнар, ахры, бик ябыккансың.

Әни табын әзерләде. Без күчтәнәчләр белән сыйландык. Ашап-эчеп табыннан кузгалгач, Фәйзылбарый сумкасыннан мичкә тәгәрәтеп пешергән ике бәрәңге алып өстәлгә куйды.

—Бусы нәрсә тагын?—дидем аптырап.

—Бусы минем әҗәт.

—Нинди әҗәт?

—Бер көнне мин мәктәпкә ач килеш барганыем. Әбекәй күршеләрдән бер бидрә бәрәңге биреп тормассызмы, көз көне ике бидрә итеп түләриек, дип сораган. Ләкин күршеләр: «Сез хәерчеләрнең утыртырга бәрәңгегез дә юк бит, көз көне каян алмакчы буласыз ул ике бидрә бәрәңгене?»—дип әбидән көлгәннәр. Шул көнне син үзеңә дип алып килгән ике бәрәңгенең берсен миңа биргәниең.

Мин бу вакыйганы оныткан идем инде. Шулай да Фәйзылбарыйга:

—Ә нигә ике бәрәңге? Мин бит сиңа бер генә бәрәңге биргәнмен,—дидем.

—Әбекәй: «Әҗәт алсаң, икеләтә итеп түлә»,—дип әйтә торганые.

—Ни өчен икеләтә?

—Берсе сиңа авыр чакта ярдәм иткән өчен, икенчесе рәхмәт йөзеннән.

Фәйзылбарый белән сөйләшеп утыра торгач, күңелләр йомшарып китте. Икебез дә еш-еш күзләрне сөрткәләдек.

Озакламый мине Казанга больницага алып киттеләр. Казанга кемнәр ярдәмендә китүне «Сөенечләр бүлешү» дигән китабымда язган идем, кабатлап тормыйм.

Минем бит сүз башым көндәлекләр турында иде. Көндәлекләрем ни өчендер 1981 елдан гына башлана. Дөресрәге, шуңа калдәргеләре юкка чыккан. Шулай дип ышанып әйтүем шуннан, чөнки 1981 елгы көндәлек җөмлә ахырындагы ике сүз белән башланып киткән. Ә икенче җөмлә баш хәреф белән язылган. Ләкин кызыл

юлдан түгел. Димәк, фикернең дәвамы булган, башы юк.

Көндәлекләремне ничәнче елдан яза башлавымны тәгаен әйтә алмыйм, әмма 1981 елга кадәр һич югы берничә дәфтәр язылган булырга тиеш. Чөнки мин әдәбиятка килгән 60нчы еллардан соң 20 ел вакыт узган. 20 ел эчендә күпме кешеләр белән очрашылган, Язучылардан тыш—Башкортстан, Әстерхан, Семипалатинск, Үзбәкстан, Казакъстан һәм башка төбәкләрдән килгәннәр белән. Семипалатинскидан килгән Антонина исемле бер ханым ике тапкыр безгә килеп атналар буе кунак булып яткан иде. Аның йөрәгенә операция ясаганнар һәм ул бездә ял итеп ятмакчы икән. Нурсөя дә, мин дә аның зарлануларыннан гарык булдык. «Мин тулай торакта яшим. Миңа аерым фатир кирәк. Сез берәр министерствога язсагыз, бәлки, фатир бирерләр иде. Сезне бит бөтен Советлар Союзы белә»,—дип, минем салпы якка салам кыстырып караса да, мин беркая да язмадым. Чөнки Генеральный секретарьга язсам да берни эшләмәячәкләрен белә иде. Мона кадәр үзебезгә телефон кертә алмыйча дистәләрчә министрлыкларга, хәтта Политбюро исеменә язып та берни кыра алмаган идем. Бездә Совет чорында да һәм хәзер дә бер начар гадәт яшәп килә. Берәрсе өстеннән шикаять язсан, югарыдагы түрәләр, «рассмотреть» дигән сүзне өстәп, хатынны мондагы түрәләргә җибәрәләр. Ә мондагы түрәләрнең һәрвакыт җавабы әзер: «Нет технической возможности». Гаделлек дигән нәрсә Россиядә беркайчан да булмастыр. Юкса урын өстендә яткан һәм инде Союзкүләм танылып килгән язучыга телефон кертә алмаслар идеме? Күрше-тирәдәге начальстволарда бар бит. Алар өчен «техническая возможность» табылып тора.

Шунсы кызык: совет власте бетүгә «техник мөмкинлекләр» дә табыла башлады. Чит илдән кешеләр кесә телефоннары алып кайта башлады. Совет властеның күп кенә яхшы яклары булса да ул печән өстендә яткан эт кебек иде. Эт печән ашамый, кәҗәгә дә ирек бирми. Елына миллионнан артык «Жигули», шулар өстенә «Волга», «Москвич», «УАЗ» кебек машиналар чыгарган СССР ның үз халкы унар ел машинага чират торып, ахыр чиктә тиенләп җыйган акчасын учмарлап теге дөньяга алып китә иде. Машиналар социализм төзеп ятучы чит илләргә бүләк ителә яисә бик арзан хакка сатыла иде.

Мин, шушы «иң бәхетле, иң гүзәл» илнең гражданины буларак, кандалалы, тараканлы больницаларда череп яттым! Бу больницаларда яту да әле зур бәхеткә санала иде. Власть алышынгач, больницада хәлләр тагын да хөртиләнде. Ашарга кашык, тәлинкә, бокал ише нәрсәләрне үзең алып керәсең. Бәлки, тиздән караваm, матрас ишеләрен дә үзеңә алып керергә туры килер. Бушлай дару дигән нәрсә юк инде.

Гомумән, Россиянең киләчәге бик томанлы күренә. Жырдагыча:

Унга карасаң да юк,
Сулга карасаң да юк!

Илнең киләчәге нинди буласын беләсең килсә, картларга кара, диләр. Ә картларны күреп торабыз: урам тулы бомжлар. Йортлар күбрәк салынган саен фатирсызлар, икмәк күбрәк булган саен хәерчеләр арта.

Менә шундый парадокс.

Көндәлекләремнең кереш өлеше озынга сузылды. Истәлекләр формасында язылса да алар барыбер шул ук көндәлекләр. Ләкин мондагы вакыйгалар—хәтер аша сөзелеп чыкканнары гына. Шунсын раслап әйтә алам: монда уйлап чыгарылган вакыйгалар юк. Киресенчә, озынга китмәсен дип күп нәрсә төшереп калдырылды. Хәтер тузаны астында калып онытылганнары да күптер.

**P.S.** *Югалган көндәлекләр, белмим, табылырмы? Әлегә сакланган кадәресен укучыларга тәкъдим итә торырга булдык. Бәлки, алар минем белән кызыксынучыларга шәхесемне аңларга ярдәм итәр.*

*Дәвамы киләсе саннарда*

# БӨЕКЛЕК БАСКЫЧЛАРЫ

## 1911 ел

**1911 ел эчендә.** «Золым» исемле шигырен яза (үзе исән чакта басылмый).

«Кечкенә музыкант» шигырен яза (үзе исән чакта басылмый).

**1 гыйнвар.** «Ялт-йолт» журналының чираттагы 20 нче санында «Борын» шигыре «Шүрәле» имзасы белән, «Кушмый ишәк жырлый» шигыре «Түнтәреф» имзасы белән басылып чыга.

«Бу шигырь элекке Малмыж өязе Түнтәр авылының (хәзерге Татарстанның Балтач районы) иске фикерле, кадимче мулласы Ишми ишан—Ишмөхәммәт Динмөхәммәтов турында. Тукай аның хәл-теләкләрен үзеннән сөйләтә. Шуның өчен дә имзаны аның исеменнән «Түнтәреф» дип куя».

Шул ук санда («Төркия янгын эчендә: монда ут һәм анда ут...») шигыре рәсем асты рәвешендә имзасыз басылган. Рәсемдә фәсле, мыеклы бер төрек басып тора, аның тирә-ягы ут, төтен, ялкын белән чолгап алынган.

«Әстерхан мөзакәрәләре» исемле фельетоны «Телсез телеграф хәбәрләре» рәвешендә басылып чыга.

**15 гыйнвар.** «...га» (Шома тормыш...) шигыре басылып чыга. «Пушкиннән мокътәбәс» дип куелган. Әсәр А. С. Пушкинның «Когда твои младые лета» исемле шигыре тәэсирендә язылган.

**22 гыйнвар.** Күптән төзелгән жырлар дәфтәренең кульязмасын бастырып чыгару максаты белән Шәрәфләр нәшриятына тапшыра. Г. Ибраһимов исемендәге институт мирасханәсендә Тукайның үз кулы белән Уральскида ук төзелгән жырлар дәфтәре саклана. Дәфтәрнең тышына Тукай русча «Тетрадь для списывания ученика 1-го класса А. М. Тукаева» дип язган. Жыентык 27 битлек тексттан гыйбарәт. Дәфтәрнең титул битенә «Контора 1-го т-ва Бр. Шараф и К°. Казань» дигән язулы түгәрәк мөһер сугылган. Уртасында «22 января 1911 г.» дигән дата бар.

**10 февраль.** «Йолдыз» газетасы: «Милли шагыйремез Габдулла әфәнде Тукаевның соң көннәрдә басылып мәйданга чыккан әсәрләре: «Юаныч», «Балалар күңеле», «Алтын әтәч», «Халык әдәбияты», «Халык моңнары», «Күңелле сәхифәләр». Тиздән «Күңел жимешләре» дигән мәжмугасы да басылып чыгачак»,—дип хәбәр итә.

**11 февраль.** Усад авылындагы Сәгыйть Сүнчәләйгә хат яза. «Күңел жимешләре»—вакыйгән матур исем. Аны тапканга үзем дә каефләндем... чыккач та сиңа жибәрәмен»,—дип, «Сабах» көтепханәсенә бастырырга биргән жыентыгы турында яза.

**2 мартка кадәр.** Ф. Әмирхан белән фотога төшәләр. Әмирхан бу рәсемне «Вафага. Ф. Әмирхан, Г. Тукай. 2 март, 1911 ел»,—дип язылган автограф белән В. Бәхтияровка бүләк итә. Бу фотоның оригиналы саклана.

**4 нче мартка кадәр.** «Мияубикә» исемле әсәрен язып бетерә.

1911 ел башларында Тукайның үпкә авыруы көчәеп китүен белеп, Сәгыйть Рәмиев нык борчыла һәм аны кымыз белән дәвалау, доктор Нариман Наримановка күрсәтү өчен үз янына Әстерханга чакыра.

*Дәвамы. Башы 8 санда*

Тукай, бу чакыруны кабул итеп, апрель аенда Әстерханга барырга карар кыла.

**4 март.** Сәгыйть Сүнчәләйгә хат яза. Анда ул Г. Ибраһимов мәкаләләренең «шактый гына төпле чыгу»ларын, ләкин кайберләрендә «нәфасәт вә мәһарәт» күрмәвен әйтеп уза да, үзенең уй-фикерләре белән уртаклаша: «Бер поэма хакында башымда әнвагъ төрле хыяллар йөри. Гайяи хыялым—татарча, татар рухында, татар геройлары белән дөньяга бер «Евгений Онегин» чыгарудыр... Язын беренче пароход илә Әстерханга Сәгыйть Рәмиевкә кунакка китмәкче булам, вә аннан икәүләшеп кыргыз арасына кымызга бармакчы булабыз. Ният җәй буе Идел өстендә йөрү, мөмкин булса, Истамбулга да бер-ике атнага заглянуть...

Мин бу арада балалар өчен «Песи Г. Җамал» яки «Песибикә» исемле бер рәсемле рисалә язып бетердем. Шактый муаффәкыятьле чыкты...» дип, «Мияубикә» исеме белән дөньяга чыккан (12 июнь, 1911) китабы турында яза.

**4 март.** Казаннан Әстерханга Сәгыйть Рәмиевкә хат яза.

Татар тормышында шушы арада булган, әле сүнеп тә өлгермәгән иҗтимагый-сәяси вакыйгага мөнәсәбәтен белдерә.

**26 март.** «Күңел җимешләре» исемле китабы басылып чыга. *(Казан, «Сабах» көтепханәсе, И. Н. Харитонов литотипографиясе, 46 б., 6000 данә.)*

Апрель. Нәҗип Гасрыйның «Современник» журналында басылган «Россия татарларының уянуы һәм аларның әдәбияты» дигән мәкаләсендә күп кенә татар шагыйрьләре арасыннан «бары икәү—Габдулла Тукаев белән Сәгыйть Рәмиевнең аерылып торуы» әйтелә, алар иҗатындагы кайбер характерлы сыйфатлар күрсәтелә.

**23-24 апрель.** Г. Тукай Казаннан «Самолет» ширкәте «Тургенев» исемендәге пароходының өченче классына утырып, Әстерханга сәфәргә чыга.

«Тургенев» пароходы Саратов шәһәрендә тукталыш ясый. Бирелә шагыйрь үзен көтеп торучы Мәүсәфә Яраева җитәкчелегендәге кызлар мәктәбенең бер төркем укучылары белән очраша. Кыз балалар ана чәчәк бәйләмнәре бүләк итәләр. Тукай аларга рәхмәт әйтеп: «Тырышып укыгыз. Халкыбыз өчен файдалы кешеләр булып үсегез»,—ди.

**Апрель азагы.** Әстерханга килеп төшкәч, ул «Люкс» кунакханәсенә урнаша.

Бу шәһәрдә торган чакта (апрель азагы—6 июнь) ул дуслары, танышлары һәм бирелдәге интеллигенция белән аралашып яши.

Ерак булмаган Балык Базары авылына барып, кымыз эчеп берникадәр сәламәтлеген рәтли, иҗат эше белән дә шөгыльләнә. Азәрбайҗанның күренекле җәмәгать эшлеклесе, доктор һәм язучы Нариман Нариманов белән очраша (Нариманов бу вакытта патша хөкүмәте тарафыннан Бакудан Әстерханга сөргенгә җибәрелгән була). «Идел» газетасы редакциясендә хәреф җыючы булып эшләүче Габдерәхим Утабалиев истәлегенә караганда, Тукай Әстерханга килеп төшкәч тә иң элек дусты Сәгыйть Рәмиев янына—«Идел» газетасы редакциясенә килә.

**29 апрель.** «Идел»дә Тукайның Әстерханга килеп житүе турында белдерү басылып чыга: «Мәшһүр шагыйрьләремездән Габдулла әфәнде Тукаев шәһәремездә мөсафирдыр».

**Май башы.** «Идел» газетасы хезмәткәрләре бакчага чыгу оештыралар. Сәмәк авылына Латыйп Үмәров бакчасына баралар. Аларга Тукай да кушыла. Бирелә доктор Нариман Нариманов та катнаша һәм 1 Май бәйрәменең тарихы турында сөйли.

Сәгыйть Рәмиев Тукайны «Люкс» номерыннан үзе яшәгән квартирага—көймәләр күтәрүче конопотчы эшчеләр бригадиры, прогрессив карашлы, үзе дә спектакльләр, төрле җәмәгать чаралары оештыруда катнашып йөрүче Даут Мөхәммәдевләр өенә, үзе янына күчерә. Тукайның авыру икәнен күреп, Д. Мөхәммәдев белән С. Рәмиев аны доктор Н. Наримановка алып баралар. Нариманов аның авыруын карагач, кымыз эчеп көч җыярга киңәш бирә.

Тукай Әстерханда да иҗат эше белән шөгыльләнүдән туктамый. Төрле жанрда әсәрләр яза. Кайберләрен «Идел»дә бастыра, беришеләрен Казанга җибәрә. Бу хакта И. Нуруллин болай дип яза: «Әстерханга килеп төшүгә,—«Идел» редакциясенең үтенече беләнме, әллә инде бу газетада эзен калдырырга теләпме, Мәҗит Гафуриның «Хәмитнең хәяты» исемле повестен укып чыга да рецензия яза.

Сатирик шигырь һәм мәкаләләрен, «Кечкенә сәяхәт» исемле юмористик очеркын яза һәм Казанга озата». «Идел»дә «Яңа әсәрләр» («Хәмитнең хәяты») басылып та чыга (10 июнь).

**1 май.** «Шигърият һәм нәсер» шигыре «Сөенче Алаев» имзасы белән басылып чыга. Тукай бу шигырен иҗатының башлангыч чорында тормышның матур, шигъриятле якларын гына сурәтләргә яраткан шагыйрь С. Сүнчәләйгә (1889—1941) пародия итеп язган. Сүнчәләй шигырьләрендәге кайбер җитешсез якларны тәнкыйтьләгән.

**10 май.** «Идел» газетасында «Яңа әсәрләр» (Хәмитнең хәяты) исемле мәкаләсе урнаштырылган. Хезмәт Мәҗит Гафуриның «Хәмитнең хәяты, яхуд Ләйлә вә хәятым» дигән исем белән 1911 ел башында Уфада чыккан китабына рецензия-бәяләмә рәвешендә язылган. М. Гафуриның бу әсәре шәкертләр тормышын, хәлен, укыту системасындагы схоластиканы тасвирлауга багышланган.

**13 май.** «Иһтида» исемле шигырен яза.

Идел аръягында Шәһит Гайфидә атна-ун көн ял иткәннән соң, Тукай янадан Әстерханга С.Рәмиев янына әйләнеп кайта.

Истәлекләрдә Тукайның С. Рәмиев һәм аның иптәшләре белән Яңа Гаскәр авылына баруы әйтелә. Бу сәяхәтне моторлы көймәдә Д. Мөхәммәдев оештыра. Сәяхәт күнелле булып, Тукай аннан бик риза кала.

Вәлит Алиев истәлегендә Әстерханда Тияк бистәсендә Г. Тукайга багышлап әдәби кичә үткәрелүе турында әйтелә. Залда халык тулы була. Тукай бу кичәдә халык әдәбияты турында сөйли. Аннан соң артистлар Габдерәхим Адаков (1894—1918), Барый Әминев, Әҗдәр Моратов һ. б. Тукай шигырьләрен укыйлар, Тукайны бик олылап тәбриклиләр.

Әстерханда «Аркадия» исемле җәйге бакчада (хәзер Карл Маркс исемендәге культура паркы) Сәгыйть Рәмиев һәм Даут Мөхәммәдевләр белән бергә җырчы Мәрьям Искәндәрова концертын карый. Концерттан соң Мәрьям Искәндәрова Тукай һәм аның дуслары утырган өстәлгә килеп, Тукай белән таныша, сөйләшә.

Тукай Әстерханнан китәр алдыннан, аның шәрәфенә Кышкы театрда Зәйни Солтанов җитәкчелегендә зур кичә үткәрелә.

Кичәдән соң Зәйни Солтанов җитәкчелегендәге Татар драма түгәрәге члennары белән берлектә фотога төшәләр. Уртада З. Солтанов, Г. Тукай һәм С. Рәмиев. Өченче рәттә Ш. Гайфи.

**25 май.** Казан университеты типографиясе эшчесе Әхмәтвәли Әхмәдуллин өендә тентү була. Донос кәгазендә Әхмәдуллинның тыелган китаплар саклавы турында әйтелгән. Беркетмәдә тасвирланган 88 басма китапның беренчесе итеп «Габдулла Тукаев шигырьләре» (4 нче дәфтәр) язылган.

Май-июнь башы. Әстерханда ялгыз гына фотога төшә. Чәче кырып алынган бу фотосының өстенә түбәндәге юлларны язган:

*Кайтмады уч, бетте көч, сынды кылыч—шул булды эш:*
*Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым.*

**6 июнь.** Г. Тукай Әстерханнан «Василий Лапшин» исемле пароходка утырып (беренче класста, аерым каютада), Казанга кайтырга чыга. Бер төркем дуслары аны озатып калалар. Истәлекләрдә аның килгәндәгедән күп үзгәргәнлеге, кымыздан соң тазарганлыгы әйтелә.

**12 июнь.** «Мияубикә» исемле китабы басылып чыга. («Мәктәп көтепханәсе»ннән 1 нче китап. «Сабах» көтепханәсе, И. Н. Харитонов литотипографиясе. Рәсемле, 24 б. 6000 данә.)

**15 июнь.** «Иһтида» исемле шигыре басылып чыга.

**25 июнь.** «Аз гына төзәтү» исемле мәкаләсен яза.

**26 июнь.** «Яшен яшьнәгәндә» исемле шигырен иҗат итә (яисә акка күчереп яза):

*Куркытма син, Алла, яшен белән,*
*Барыбер мин куркъмыйм, яши белəм!*

*Куркытсаң да—куръкмыйм, аязымны*
*Сатып алдым аһым, яшем белән!*

Ләкин ул аны беркайчан да бастырмаган. «Яшен яшьнәгәндә» дигән бу шигырь С. Рәмиевнең «Мәжит сүзе» тәэсирендә язылган дип расларга мөмкин.

**14 июль.** «Читен хәл» шигырен яза.

**Җәй.** Шәехзадә Бабич «Габдулла әфәнде Тукаев» исемле шигырен яза:

*Дөньяда бик аз булыр чын шагыйрь Габдулладай,*
*Ул караңгы төндә яктырган матур, ак тулган ай.*

*Ул бөек, нечкә хис тәкъризләргә бик бай, диям,*
*Бар урыннардан аның урынын кадерле, дәү, диям.*

*Бакыр эчендә көмешләр ялтырап яткан кебек,*
*Ап-ачык, ап-ак булыр тик ак күңел аккан кебек.*

*Күп китапларның арасында китаплары—*
*Ап-ачык нурлар чәчәр, күренеп тора һәр яклары.*

*Алса, укыса халык шигърен аның, истә кала,*
*Һәм аның шигъре халыкның күңеленә зур хис сала.*

*Галидер Габдулланың хәзер Казанда мәскәне,*
*Ул уяткыч, ул юаткыч, ул терелткеч хәстәне.*

*Билгеле, безнең ма биһилифтихар ул, мөхтәрәм,*
*Зур шагыйрь, мәшһүр шагыйрь бар бездә дә, дип шатланам.*

*Тәсбих вә тәһлил итеп җырлап йөримен җырларын,*
*Җырлаганда нечкәрә күңелем, эри һәр җирләрем.*

**Август.** «Болгар» номерларының 40 нчы бүлмәсендә шагыйрь Сәгыйть Сүнчәләй белән очраша. Августта Сүнчәләй Казанга килгәч, ай буе алар еш күрешәләр, сөйләшәләр, күп вакытларын икәү бергә үткәрәләр. Кайбер көннәрне Сәгыйть шагыйрьнең бүлмәсендә кунып та кала. «Төннәрдә күбесенчә сөйләшмилыкылдамый утыра идек. Тик утыра идек. «Сөйләшмик,—ди торган иде йә җырлый иде»,—ди истәлегендә С. Сүнчәләй.

**1 август.** «Яшен ташлары» исемле китабы (Беренче җөзьэ. Авторы: Шүрәле. Нашире: Су анасы. Казан, «Өмид» матбагасы. 23 б. 3000 данә) басылып чыга. Китап авторның кереш сүзе белән ачыла.

**15 август.** «Ялт-йолт» журналының 26 нчы саны дөнья күрә. Биредә шагыйрьнең «Шүрәле» имзасы белән «Өч баш» исемле мәкаләсе, «Гакыллылар фәлсәфәсе» дигән шигыре, «Гөмберт» имзасы белән «Русчадан дөрест тәрҗемәләр» дигән мәкаләсе һәм «Төрекчәдән» («Эзләдем, филлаһ...») икеюллык шигыре урын алган.

**30 август.** «Вакыт» газетасы: «Шагыйре мәшһүр Габдулла әфәнде Тукаевның «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре»—иң мәшһүр әдипләремезнең әгъла әсәрләреннән җыелып язылмыш кыйммәтле китабы чыккач ук Казан мәдрәсәләренә милли әдәбият өчен дәрес китабы итеп кабул ителде»,—дип хәбәр итә.

**11 сентябрь.** «Ялт-йолт» журналының 27 нче саны дөнья күрә. Биредә «Иблиснен гайде фитыр тантанасы» («Рамазан гаетендә Иблиснен шайтаннарына хитабы») шигыре «Шүрәле» имзасы белән басылып чыга.

**15 сентябрь.** «Сайфия» шигыре басылып чыга. Шагыйрьнең Идел буйлап пароход белән Әстерханга сәяхәте вакытында күргәннәрнен тәэсире белән язылган тирән реалистик шигырьләреннән берсе.

**29 сентябрь.** Көннәрнең суытуыннан, «Болгар» кунакханәсенең номеры

ягылмавыннан һәм шуның аркасында авыруы көчәеп китүеннән зарлана: «Мин быел 29 сентябрьдән ук салкынлыктан зарлана башладым. ...Мина шул якмый торган арада бизгәкнең шәбе эләккән. Бинаән галәйһи мин, жылылык-фәлән сизмичә, көне-төне тунуда идем». Бу турыда «Мич башы кыйссасы»ннан укып беләбез.

**12 октябрь.** «Толстой фикере» исемле шигыре имзасыз басылып чыга.

**20 октябрь.** Сәгыйть Сүнчәләйгә хат яза. Бу хаттан Тукайның житди авыруы аңлашыла. Шулай ук аның Парижда 1908 елда ук чыга башлаган «Мусульманин» журналына Оренбургтан торып язышкан шагыйрь һәм журналист Мирсәяф Кырымбаев белән очрашканлыгы да ачыклана. Шушы елның апрель аенда Петербургта чыга башлаган «В мире мусульманства» газетасын да ул кызыксынып, хәтта язышырга да исәп тотып укып бара. Ләкин әлеге органнарның төп идеяләре аны сагаерга мәжбүр итә. «Мусульманин»ның нашире һәм редакторы М. Хажи-Теләши һәм «В мире мусульманства»ның редакторы А. Г. Датиевлар турында ул Сүнчәләйнең дә фикерен беләсе килеп: «Син аларны кемнәр дип таныйсың? М. ул кавказлыларга алданып йөрмиме икән?»—дип яза.

**29 октябрь.** Бу вакытта «Болгар» кунакханәсендә яши, инде көннәр бик суык булуга да карамастан, номерлар жылытылмый. Шагыйрь суыклыктан зарланып бәет яза. «Мин быел 29 сентябрьдән үк салкынлыктан зарлана башладым. Шуннан бирле икәнлеге язып ташлаган бер бәетемнең төбендәге тарихыннан беленде»,—дип күрсәтә:

*Номер салкын, якмыйлар бит, арка туңа,*
*Иртә берлән, киям дисәң, яка туңа;*
*Авыр да соң иртә белән тышка чыгу,*
*Чыкмый хәл юк, чыгасың шул ката-туңа.*
*Жәйләр үтте, җиттек инде октябрьгә,*
*Жылылык юк җирдә һәм дә күктә бер дә.*
*Сентябрьдә син дә бер, мин дә бер, ди,*
*Миһманнарның якмаучыга үпкә бергә.*
*Хөкем итмим, Ходай кыйлыр үзе судын,*
*Кайгырмый бай, күтәргән дә ята ботын;*
*Акчам янга калыр, ди ул, якмый торсам,*
*Барыбер бит җәһәннәмгә үзе утын.*
*Туңучы.*

**3 ноябрь.** Матбугатта Тукайның каты авыруы хакында хәбәр бирелә.

**7 ноябрь.** Балкайдагы Италия-Төркия сугышлары мөнәсәбәте белән 1911 елда («Ялт-йолт», 12 октябрь) язылган «Тәмсил» дигән шигыре янадан басыла.

**8 ноябрь.** «Вакыт» газетасы Казанда «Сабах» көтепханәсе тарафыннан «Балалар күңеле» исемле айлык әдәби журнал чыгарылачагын, редакторы Г. Тукай булачагын хәбәр итә. Журналда балалар өчен әдәби әсәрләрдән үрнәкләр бирү, тәрбия һәм укыту мәсьәләләрен тикшерү планлаштырыла, танылган язучылар катнашачагы әйтелә. Ләкин властьлар Тукайның бу теләгенә каршы төшәләр, журнал чыкмый кала.

**13 ноябрь.** «Көзге жилләр» шигырен яза. Шигырь 1910—1911 елларда Урта Иделдә хөкем сөргән ачлык фажигаләре тәэсире белән язылган.

**26 ноябрь.** Казан Эчке эшләр министрлыгының матбугат эшләре комитеты, «Габдулла Тукаев шигырьләре»н (4 нче дәфтәр, 1909) тәржемәсе белән бергә теркәп, Казан Суд палатасына рәсми кәгазь (отношение) жибәрә. Комитет анда аерым шигырьләрдә жинаять билгеләре табылуын һәм китапка арест салынуын хәбәр итә. Суд палатасыннан арестны раславын, жыентыкның авторын хөкемгә тартуын үтенә.

**28 ноябрь.** Казан Матбугат эшләре комитеты Петербургтагы Матбугат эшләре буенча Баш идарәгә «Габдулла Тукаев шигырьләре»нә (3 нче дәфтәр, 1907) арест салу һәм авторын хөкемгә тарту турындагы фикерен һәм Казан Суд палатасына киткән отношениесенең күчермәсен жибәрә.

**Ноябрь—1912 елның апреле.** Цензура комитетының Тукайны эзәрлекләве дәвам итә.

Авыруы җитдиләнә, күбесенчә урын өстендә ята. Тукайның авыруы һәм, гомумән, аның хәле турында «Вакыт»та басылып килгән белдерүләргә таянып, Петербургта рус телендә чыккан «В мире мусульманства» газетасы 9 декабрь санында шагыйрьнең хәле турында: «Авыру Тукай бернинди караусыз һәм тәрбиясез «Болгар» номерларында ята»,—дип хәбәр бирә.

Тукайны күреп белгән Фоат Саллави истәлегеннән аның белән даими рәвештә аралашып, авырганда хәлен белеп килеп йөргән дусларын, аны хөрмәт иткән даирәне күрәбез: «Без «Болгар»дагы Тукай абый яшәгән бүлмәнең каршысындагы номерда тора идек. Габдулла абый инде ул вакытта бик авыру иде. Минем әнием... һәрвакыт Тукайның хәлен белешеп тора иде. Еш кына Тукай янына олы гәүдәле, гөрләп торган көчле тавышлы Габдулла абый Кариев, Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, Гөлсем Болгарская, Хөсәен Ямашев белән Хәдичә апа, китап нашире Шиһап Әхмәров белән хатыны Әминә Әхмәрова, ...Закирә апа белән ире журналист Борһан Шәрәф, нашир Гыйльметдин Шәрәф белән хатыны Рәхимә апа киләләр иде. Тукайның хәлен белешергә татар кызларыннан беренче булып гимназия тәмамлаган апалы-сеңелле Әминә, Мәдинә Терегулова һәм Габитовлар да киләләр иде. Гөлсем Камалова, Гайшә Богданова, Зәйнәп Хәсәни, Әминә Мөхетдинова, Заһирә Әхмәрова, татар кызларыннан беренче булып югары белем алган Мәрьям Акимбетова һәм соңыннан гражданнар сугышында беренче татар бригадасы составында Урта Азиядә басмачыларга каршы сугышларда катнашкан һәм икесе дә Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнгән апалы-сеңелле Мәрьям белән Гайшә Саиновалар (Мулланур Вахитовның туганнан туган сеңелләре)—болар барысы да Тукайны олылаучы, килеп даими рәвештә аның хәлен белешеп торучылар иде».

**Декабрь урталары—1912 елның март башына кадәр.**

Авыруы көчәеп, хәле бик авырлашу сәбәпле, Тукай әнисе Мәмдүдәнең туган авылы Өчилегә (Татарстанның Арча районына керә) үги әбисе Латыйфә белән бабасы Зиннәтулла улы Кәшфелкәбир Әмиров (1885—1938) йортына кайта. Биредә ул кышны үткәрә һәм ял итә.

Истәлекләрдән күренгәнчә, К. Әмиров һәм аның хатыны Рабига каты авыру Тукайны яхшы каршы алалар. Үзләре яшәгән өйдән тыш, аларның кышын ягылмый торган кечкенә генә өйләре булган. Тиздән хуҗалар аны җылытып, Тукайны шунда (кечкенә генә, нараттан салган, сандык шикелле җыйнак, матур бер өй) урнаштыралар. Ул көненә ике мәртәбә ягыла, һавасы да Тукайга бик хуш килә. Җиңгәсе исә һәркөн үрдәк шулпасы пешереп кертә, алдында һәрчак җылы сөт. «Монда бер 15 көн эчендә 29 сентябрьдән бирле күргән салкын михнәтләре һәм юлда килгәндәге адашулар, тунулар—барысы да онытылды»,—дип яза ул бу турыда «Мич башы кыйссасы»нда. Туганнарыннан, үзен тикшерәләр дип уйлап, өйгә килгән кешеләргә аның кайтуын белгертмәскә үтенгән Тукай. Бераздан, хәле әйбәтләнә төшкәч, урамга чыгып йөри башлый, авыл мәктәбенә барып, балаларның сабак укуын күзәтә, ә төн утырып иҗат эше белән шөгыльләнә. «Җан азыклары» җыентыгына керәчәк шигырьләрнең күпчелеген, юл очеркларын ул шушы айларда яза. «Ялт-йолт» журналына әсәрләрен җибәреп тора, дуслары, танышлары белән хатлар алыша.

**Печән базары**

*Сатирик әсәрләр конкурсы*

Сәйлән

## АВЫЛ МӘКТӘБЕН ЯПКАЧ, МӨГАЛЛИМНӘРЕ НИ ДИЛӘР?

*Күп яттык без*
*Мәдрәсәдә,*
*Аңламадык бер нәрсә дә.*
***(Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?)***
Габдулла Тукай

Күп укыттык
мәктәптә без,
черәшкәнбез
гел тәккә без.
Исем булды—
укытучы
«Берле» белән
куркытучы.

Чистарсын дип
шакшы дөнья,
нинди хәлгә
кермәдек без.
Пакьләнмәде,
әмма җиһан,
тик үзебез
керләндек без.

Имансыз ил
төзеттеләр,
мәчет ябып—
мәктәп ачып.
Тик Алланы
ташламадык,
укыдык без
намаз качып.

Кушкач нишлик,
ач халыктан

«Урааа!» әйтеп
җыйдык заем.
Акчасы юк—
сорап алдык
йон, йомырка,
итен, маен.

Сөйләттеләр:
«Безнен ил ул—
дөньяның иң
шәп иле!»—дип,
Хәзер бездән
Бар да көлә;
«Укытучы
шыр тиле!»—дип.

Ял көнендә,
ферма өчен
ылыс, күмер,
миннек җыйдык.
Семинарга
әзерлек дип
букка баткан
сыер юдык.

Җәй башыннан—
чөгендергә,
ахырында—
амбар эше!

Ничек инде
эшләмисен,
Укытучы
анлы кеше!

Бәйрәм саен
доклад укып,
жырла,бие,
концертын куй...
«Монсын эшлә,
ансын эшлә!»—
тынычлык юк
мәнге бакый.

Ял көнендә
ярминкәдә
сөт, май, күкәй
саттырдылар.
Түрә килсә,
рәхмәт әйтеп,
озаклап кул
чаптырдылар.

Сайлау житсә—
Безгә инде,
комиссия
әгъзасы да,
бюллетеньнәр
бозасы да,
ялган процент
язасы да.

Тамак өчен
төн йокламый,
кайттык салам
бурлыгыннан.
Иртәгесен
дәрес бирдек
читкә карап
хурлыгыннан.

Әнә шулай
түбән төшеп
терәлдек без
мескенлеккә.
Ә мескеннең
тәрбиясе
булмый анын
өч көнлек тә.

Мескеннән тик
мескен туа!
Шуны дәүләт
анламыймы?
Шуңа микән
әллә безне
укучы да
санламыймы?

Ник санласын,
бер хокукы
булмаган без
мәхлук жанны?
Кемнәр генә
мыскыл итми,
кемнәр генә
сукми аны?

Безне сүгә
түрәсе дә,
һич югында
бер эшсез дә.
Без күптәннән
йөрәксез дә,
без телсез дә,
без тешсез дә!

«Укытучы
елы» имеш,
Нинди хөрмәт?
Нинди зурлау?
Узса узсын!
Булмагандыр
бу елгыдай
безне хурлау?

Шулмы «ел», ә?
Бер тиенгә
арттыралма
хезмәт хакын!
Шул булдымы
зурлау анын
«Укытучы»
дигән атын?

Ел башыннан
азаккача
тикшерү дә,
тикшерүче!
Бетәр микән
эшләмичә,
гаеп эзләп
тик йөрүче?

Безнең өстән
гаеп эзли
районның бар
эте-бете.
Йә мәгариф
бүлекчәсе,

Йә башкарма
комитеты.

Прокурор да,
милиция,
йә эпидем
станция,
электригы,
пожарнигы,
башка бик күп
инстанция.

Ин яманы—
Департамент!
килсә җанны
алып китә.
Әйтерсен без
ил талаучы!
зур штраф
салып китә.

Без гаепле
сыйныфларда
бала саны
тулмаса да.
Ир йә хатын
кысырлыктан,
балалары
булмаса да...

Без гаепле
килешмичә,
гаиләләр
таркалса да.
Кызлар кияү
тапмаса да,
ир-егетләр
тол калса да.

Без гаепле
җинаять һәм
үлем-китем
артуга да.
Кем әйтмешли,
Исландия
вулканнары
атуга да.

Бу илдәге
бар бардакны
кирәктер бит
сылтар кеше.
Кем гаепле?
Укытучы!

Бу бары тик
аның эше!

Шуна аннан
ирләр китте,
Укытучы—
гел хатын-кыз.
Тиздән шырпы
яндырып та
табалмассыз
ир затын сез.

Янача дип,
«җан башына
карап түләү»
керттерделәр.
Болай да аз
хезмәт хакын
ваклап-бүлеп
бетерделәр.

Хезмәт хакы
гына җитсен,
табалар бит
талар юлын,
күтәртәләр
бездән район
«Яңа елын»,
«Сабантуен».

Акча җыю—
«хәйрия» дип,
«Укытучы
елы»дип тә.
Безнең өстә
икән әле,
өч тиенлек
бар гәҗит тә.

Акча җыя
профсоюз да,
Кире кайта
азы гына.
Күп өлеше
түрәләрнең
әйләнә буш
азыгына.

Кемнәр генә
яшәп ятмый
мөгаллимнең
киң сыртында.
Безнең өстән
күтәртәләр

Салаватның
концертын да.

Укытырга
вакыт калмый,
отчет белән—
утырталар,
бар нәрсәне
портфолио,
ноутбукка
тутырталар.

Алгарышка
зур этәргеч,
имеш,бушлай
ноутбук та.
Яңалыктан
ни файда соң?!
Мәгариф бит
нокаутта!

Биш ел саен
башка бәла—
аттестатка
сынау бирү.
Инфарктка
житәр-житмәс
дер калтырап
чабып йөрү...

Безнең баштан
узмадылар
нинди генә
«акция»ләр:
Реформиза-цияләр,
Модерниза-цияләр,
Профориен-тацияләр,
Специали-зацияләр,
ВУЗ белән коопе-рацияләр,
Компьютери-зацияләр,
Интернети-зацияләр,
Унитари-зацияләр,
Инвентари-зацияләр,
Информати-зацияләр
Интернационали-зацияләр,
Социали-зацияләр,
Аккреди-тацияләр,
Реструктури-зацияләр,
Кат-кат аттес-тацияләр.
Оптими-зацияләр
Тагын-тагын әллә нинди
Мыскыли-зацияләр.

Авылга да,
мәктәпкә дә,
калды соңгы
санкция—
«списать» дип
акт язып
бары ути-лизация!

Инде менә
мәктәп ябып,
калдыралар
эшсез безне.
Телне тешләп
түздек әле!
Түзик кысып
тешебезне...

# ТАТАР МАТБУГАТЫНЫҢ АВЫР ХӘЛЕ

## 30НЧЫ ЕЛЛАР МАТБУГАТЫНА КҮЗӘТҮ

1917 елгы Октябрь революциясе вакытында һәм аннан соң большевиклар үзләренең хакимиятен ныгытуда иң әһәмиятле, хәлиткеч юнәлешләрнең берсе итеп алар белән килешмәүчән матбугатны юкка чыгаруны санныйлар һәм аңа каршы аяусыз көрәш җәелдерәләр. Совет хөкүмәтенең 27 октябрьдә үткән беренче утырышында ук матбугат турында махсус декрет кабул ителә. Әлеге декрет нигезендә Россиянең төрле төбәкләрендә большевистик булмаган йөзләрчә газета-журнал ябыла, аларның наширләре һәм мөхәррирләре кулга алына, басмаханәләре, кәгазь һәм акча запаслары конфискацияләнә. 1918 елның көзенә кадәр, мәсәлән, совет хакимияте тарафыннан татар телендәге 40тан артык матбугат басмалары чыгудан туктарга мәҗбүр ителә: «Вакыт», «Ил», «Корылтай», «Тормыш», «Хөррият», «Сарай», «Йолдыз», «Кояш» газеталары, «Шура», «Сөембикә», «Аң», «Ялт-Йолт» журналлары һәм башкалар.

Шул ук вакытта, большевистик булмаган прессаны юк итү белән беррәттән, Совет хакимиятенә хезмәткә күп телле партия-дәүләт матбугатының киң челтәрен төзү процессы да җәелдерелә. Бу мөнәсәбәттә В. И. Ленинның большевизм таңында ук нигезләгән: газетаның коллектив пропагандист, агитатор һәм оештыручы булуы турындагы концепциясеннән чыгып эш ителә.

Совет матбугаты үз эшчәнлеген илдәге хакимиятне беркем белән дә бүлешмәгән большевиклар партиясе съездлары, конференцияләре һәм Үзәк Комитетының директив күрсәтмәләре кысаларында гына алып барырга мәҗбүр ителә. Шуңа күрә ул марксизм-ленинизм рухы белән үтә нык сугарыла һәм анык сыйнфый-пролетар позициядә тора. Мондый куелыш газета һәм журналларның исемнәрендә дә турыдан-туры чагылыш тапкан. Аларның күбесе «Коммунист», «Коммунизм», «Социализм», «Ударник», «Эшче», «Колхозчы» һәм башка шундый ортодоксаль-сыйнфый терминнарны йөртә.

Матбугат совет илендә социализм төзүне сынап карауда, совет кешеләренең, беренче чиратта, үсеп килүче яшь буынның аңына илнең якты, социалистик киләчәгенә ышаныч хисләре сеңдерүдә үтә актив файдаланыла. Аның сәхифәләрендә индустрияләштерү, авыл хуҗалыгын күмәкләштерү һәм культура революциясе мәсьәләләренә даими игътибар бирелә. Газета һәм журналлар көннән көнгә индустрия һәм энергетиканың яңа зур корылмалары, колхозлар тормышы һәм мәдәният өлкәсендәге үзгәрешләр, эшчеләр, колхозчылар арасындагы социалистик ярыш һәм ударниклык хәрәкәте, планнарның вакытыннан элек үтәлүе турында күтәренке-мактанучан рухтагы хәбәрләр урнаштырып тора. Ләкин шул ук вакытта, совет җәмгыятендә, әлегәчә тарихта күрелмәгән тирәнтен, күп очракларда ирексезләп, көчләп үткәрелә торган үзгәрешләр барышында, халыкның бихисап матди югалтуларга, физик һәм рухи газапларга, кайгы-хәсрәтләргә дучар ителүе турында бернинди дә мәгълүматлар бирелмәгән диярлек.

1930 елларда чыгып килгән газета-журнал битләре илдә үзенең чикләнмәгән хакимиятен урнаштырган И.В.Сталин адресына гадәттән артык мактау сүзләре, аның фоторәсемнәре белән тулган. Ул чактагы матбугат Сталинның: совет илендә социализм ныгый барган саен сыйнфый көрәш тагын да көчәячәк һәм шуңа күрә социализмга каршы чыгучы халык дошманнарын рәхимсез бастырырга кирәк дигән тезисын киң пропагандалап килә. Ул шулай ук халыкка каршы, дошманнарча эшчәнлектә гаепләнгән, партия һәм совет дәүләтенең билгеле эшлеклеләре өстеннән

оештырылган ачык, сәяси суд процесслары материалларын да яктыртып бара. Тик, шул ук вакытта, большевистик хакимият совет матбугатына, ул елларда илдә үткәрелә торган бихисап сәяси репрессияләр һәм алар нәтиҗәсендә нахакка гаепләнгән меңнәрчә һәм меңнәрчә корбаннар турында язарга рөхсәт итмәгән.

1930 елларда Советлар Союзында, сәяси репрессияләр белән беррәттән, милли матбугатны эзәрлекләүнең яна дулкыны уза. Бу кампания турыдан-туры Сталинның совет илендә руслаштыру сәясәтен тагын да көчәйтүгә юнәлдерелгән эшчәнлеге белән бәйләнгән була. 1930 елда булып үткән ВКП/б/ның XVI съездында, Сталин: киләчәктә бөтен җир шарында социализм җинәчәк, милләтләрнең озак вакыт үзара икътисади, сәяси һәм мәдәни хезмәттәшлек итү нәтиҗәсендә, йөзләрчә милли телләр арасыннан, башта аеруча баетылган бердәм зональ телләр аерылып чыгачак, ә аннары—зональ телләр нигезендә—аларның иң тәрәккый сүзләрен берләштергән халыкара гомуми тел барлыкка киләчәк, дигән концепцияне күтәреп чыга. *(Сталин И. Марксизм и вопросы языкознания. М., 1953, с.54)* Советлар Союзы күләмендә шундый зональ тел булып, әлбәттә, рус теле калырга тиеш дип санала.

Шушы сталинчыл концепциягә нигезләнеп, илдәге рус булмаган халыкларга рус телен тирәнтен өйрәтүне җәелдерү максаты белән, гамәли чаралар үткәрә башлыйлар. СССРдагы милли республикалар һәм аерым өлкәләрнең барлык мәктәпләрендә мәҗбүри рәвештә рус телен укыту кертелә. Акрынлап, бигрәк тә шәһәрләрдә, милли мәктәпләр һәм мәктәпкәчә балалар учреждениеләре саны кыскара, балаларның һәм яшүсмерләрнең туган теленнән бизүе көчәя бара. Югары һәм махсус урта уку йортларында укыту, тулаем алганда, рус телендә генә алып барыла. Рус булмаган халыкларның барысының да диярлек, шул исәптән татарларның да, алфавиты рус графикасы кириллицага күчерелә. 1920 еллар башында барлыкка килгән һәм егермедән артык милли телдә, һәм шул исәптән татарча да, китаплар, брошюралар чыгарып килгән СССР халыкларының Үзәк нәшрияты 1930 еллар башында яшәүдән туктый. Мәскәүдә рус булмаган халыклар телендә басылып килгән үзәк милли газета-журналларны да чыгарудан туктаталар. Шундый ук чаралар милли диаспоралар яши торган төбәкләрдә дә үткәрелә. Милли матбугат бастыру эше нигездә союздаш һәм автономияле республикаларга күчерелә.

1930 елларда Советлар Союзында татар телендә 300дән дә ким булмаган газета һәм журнал чыгып килгән. Алар арасында гомумсоюз, союздаш һәм автономияле республикалар, крайлар, өлкәләр, округлар, шәһәрләр һәм районнар күләмендәге, шулай ук сәнәгать предприятиеләрендә һәм авыл хуҗалыгы берләшмәләрендә чыгарылып килгән күптиражлы вакытлы матбугат басмалары булган. Шуларның 170тән артыграгы, 1930 еллар дәвамында, үзәк һәм региональ хакимият боерыклары нигезендә чыгудан туктатылган. Бу газета һәм журналларның 100гә якыны Татарстан чикләреннән тыш: Россия Федерациясе, Украина һәм Әзәрбайҗанның төрле төбәкләрендә басылып килгән була.

Советлар Союзының башкаласы Мәскәү шәһәрендә татар телендә нәшер ителгән 7 гомумсоюз һәм 2 гомумроссиячел көндәлек матбугат басмалары (3 газета һәм 6 журнал) яшәүдән туктатыла. Аларның барысы да совет чорында дөньяга килгән була.

Туктатылган гомумсоюз күләмле басмаларның беренчесе—СССР Үзәк Башкарма Комитеты Милләтләр Советы органы—иҗтимагый-сәяси «Эшче» газетасы. 1931 елның 31 декабрендә, унөч елдан артык бертуктаусыз чыгып килгән әлеге газетаның соңгы 2039 саны дөнья күрә. Ил күләмендә киң танылган, зур күләмле һәм күп тиражлы бу басма 1918 елның сентябреннән Казан шәһәрендә, 1918 елның 13 декабреннән Мәскәү шәһәрендә, 1920 елның 2 февраленнән янадан Казанда, 1921 елның 10 апреленнән туктаганчыга кадәр кабат Мәскәүдә нәшер ителгән. Аны чыгаручы партия-совет оешмаларының исемнәре еш кына үзгәреп торган. «Эшче» газетасы чыга башлаганда: Россия Мөселман Коммунистлар (большевиклар) партиясе Үзәк Комитеты һәм Казан комитеты органы, дип аталган. Аннары ул: 1918 елның декабреннән—РКП/б/ның мөселман оешмалары Үзәк бюросы, 1919 елның августыннан—РКП/б/ Үзәк Комитеты янындагы Шәрекъ халыклары коммунистик оешмалары Үзәк бюросы, 1921 елның апреленнән—РКП/б/ Үзәк Комитеты

янындагы төрки халыклар арасында агитация һәм пропаганда Үзәк бюросы, 1922 елның мартыннан—РКП/б/ Үзәк Комитеты һәм Милләтләр эше буенча халык комиссариаты янындагы Татар-Башкорт бюросы, 1923 елның октябреннән—РКП/б/ Үзәк Комитеты янындагы Татар-Башкорт бюросы, 1924 елның февраленнән—РКП/б/ Үзәк Комитеты янындагы Татар-Башкорт секциясенең Үзәк бюросы, 1928 елның гыйнварыннан—ВКП/б/ Үзәк Комитеты янындагы Татар-Башкорт бюросы органы булган. Бу исемлектән күренгәнчә большевиклар партиясе структурасында нинди үзәк татар-башкорт оешмалары булганлыгын күзәтергә мөмкин.

«Эшче» газетасының төрле еллардагы җаваплы мөхәррирләре: Исхак Рәхмәтуллин, Борһан Мансуров, Вәли Шәфигуллин, Сәләх Атнагулов, Хасият Гайнуллин, Садыйк Сәгыев, Мирза Давыдов, Нур Сәйфи, Заһид Йосыпов (Шәркый), Хөснулла Ишбулатов (Ишби), Идрис Агишев. 1931 елда Мәскәү өлкәсенең Подольск шәһәрендә бу басманың Вил Садрый мөхәррирлегендә «Подоль эшчесе» исемле күчмә газетасы чыгарылып килә. 1929-1930 елларда «Эшче» редакциясе, татар язуын латиницага күчерү мәсьәләләренә багышланган, махсус «Белем ачкычы» газетасын кушымта итеп чыгара. Аның 17 саны дөнья күрә. «Эшче» газетасына К. Абрамов, Ш. Әхмәдиев, М. Дулат-Али, Ә. Ерикәй, М. Җәлил, Г. Ибраһимов, Ш. Ибраһимов, Г. Ильясов, Н. Исәнбәт, С. Кудаш, М. Максуд, Ф. Мөбәрәкшин, Н. Нариманов, С. Сәетгалиев, М. Солтангалиев, М. Субхи, Х. Урманов, К. Якупов, Г. Ялымов, Н. Яруллин һәм башкалар язышкан.

«Эшче» үзенең озак чыгуы, гомуми саннары, тиражы, мөхәррирләре, авторлары, хәбәрчеләре, тематик даирәсе һәм таратылыш районнарының күп булуы белән Мәскәүдә төрле елларда татар телендә нәшер ителгән барлык 13 газета арасында («Ил», «Сүз», «Безнең ил», «Чулпан», «Кызыл Армия», «Кызыл байрак», «Эшче», «Яңа ээ», «Яшь эшче», «Кызыл богатырь», «Кызыл наборщик», «Игенчеләр» һәм «Коммунист») беренче урында тора.

«Эшче» газетасы, туктаганчыга кадәр диярлек, саф партия органы була һәм һәрвакыт «Бөтен дөнья пролитарлары, берләшегез!» дигән лозунг астында чыга. Ул, большевиклар партиясенең үзәк газетасы «Правда»ның юлдашы, иярчене рәвешендә, үзенең эшчәнлеген, тулаем алганда, аның үрнәгендә алып бара. «Правда» газетасы кебек үк, «Эшче» дә укучыларын большевиклар партиясенең VIII-XVI съездлары, конференцияләре, Үзәк Комитеты Пленумнарының материаллары, партия җитәкчеләренең андагы чыгышлары белән даими таныштырып тора. Аның сәхифәләрендә партиянең милли оешмалары эшчәнлеге турында да җентекләп хәбәр итә. Мәсәлән, «Эшче» газетасы 1918 һәм 1919 елларда Мәскәүдә булып узган Шәрекъ халыклары коммунистик оешмаларының Беренче һәм Икенче Бөтенроссия съездлары турында тәфсилләп язган. Әлеге басмада большевиклар партиясе Үзәк Комитеты янындагы Татар-Башкорт бюросының төрле еллардагы эшчәнлеге дә киң чагылыш тапкан. Газета шулай ук большевиклар партиясе сафларында бара торган тайпылышлар, бигрәк тә «солтангалиевчелек»кә каршы көрәш тарихын заман рухында яктыртып килгән.

«Эшче» газетасы битләрендә Гражданнар сугышы, илнең халык хуҗалыгын торгызу, яңа икътисад сәясәте, беренче бишьеллык планнары, милли мәсьәләне чишү, аерым алганда, Татарстан һәм Башкортстан автономияле республикаларының барлыкка килүе һәм үсеше турындагы мәгълүматларга зур урын бирелгән. «Эшче» үзен: «көндәлек үзәк татар эшчеләре газетасы» дип атаган һәм, табигый, эшчеләр тормышын, аларның илне индустрияләштерүдә хәлиткеч рәвештә актив катнашуын яктыртуга аеруча игътибар иткән. Газетада авыл хуҗалыгын социалистик үзгәртеп кору һәм культура революциясе мәсьәләләре дә даими яктыртылыш тапкан.

«Эшче» газетасы белән бер көнне диярлек, 1931 елның 30 декабрендә, Мәскәү шәһәрендә, 1924 елның 2 февраленнән бирле, сигез елга якын дәвердә, 516 саны чыгарга өлгергән, махсус авыл халкы өчен билгеләнгән, «Игенчеләр» дигән икенче үзәк гомумсоюз крестьяннар газетасы да туктатыла. Ул РКП/б/ Үзәк Комитеты янындагы Татар-Башкорт секциясенең Үзәк бюросы органы буларак дөнья күргән. 1928 елның гыйнварыннан 1930 елның 6 маена кадәр ВКП/б/ Үзәк Комитеты янындагы Татар-Башкорт секциясенең Үзәк бюросы һәм аннары, соңгы саны

нәшер ителгәнче, СССР Үзәк Башкарма Комитеты Милләтләр Советының басма органы булган.

«Игенчеләр» газетасының баш мөхәррире итеп, СССР Үзәк Башкарма Комитеты рәисе М.И.Калинин тәкъдиме буенча, Борһан Мансуров куелган. Аннан соң төрле вакытта әлеге басманың баш мөхәррирләре булып Мирза Давыдов һәм Гәрәй Әхтәмев тә эшлиләр. 1929 елның 13 ноябреннән 1930 елның 29 апреленә кадәр «Игенчеләр» редакциясе, татар язуын гарәп графикасыннан латин шрифтына күчерү мәсьәләләренә багышланган «Яңалиф сабаклары» дип исемләнгән газетаның 7 санын чыгара. «Игенчеләр» сәхифәләрендә С. Атнагулов, Г. Баязитов, М. Бикбулатов, Ф. Борнаш, Л. Гайсин, А. Гильми, Ә. Ерикәй, Г. Ильяов, Г. Исмагилов, М. Кормаш, Ф. Мансурова, Ф. Мөбәрәкшин, С. Сәгыев, Н. Сәйфи, М. Сөндекле, Х. Хәйри, Л. Хәмиди һәм башкалар язышкан.

Үзәк «Игенчеләр» газетасы авыл халкы өчен чыгарылган. Шуна күрә аны «крестьян газетасы» дип атаганнар. Әлеге басма үзенең төп бурычы итеп, Коммунистлар партиясенең аграр сәясәтен пропагандалауны, аның авыл хуҗалыгын социалистик үзгәртеп кору турындагы директив күрсәтмәләрен һәм гамәли адымнарын яктыртуны санаган. Ул, мәсәлән, укучыларын ана телендә ВКП/б/ Үзәк Комитетының 1930 ел 5 гыйнварындагы «Коллективлаштыруның темпы һәм колхоз төзелешенә дәүләтнең ярдәм чаралары турында» һәм шул ук 1930 ел 15 мартындагы «Колхозчылык хәрәкәтендә партия линиясенең тайпылышлар белән көрәшү турында» дип исемләнгән, тарихта билгеле карарлары белән таныштырган. «Игенчеләр» газетасы үз сәхифәләрендә, заманындагы барлык партия-совет матбугаты кебек үк, авыл хуҗалыгын тоташтан күмәкләштерү нигезендә, кулакны, сыйныф буларак, юк итү линиясен яклаган язмалар урнаштырып килгән. Ул шулай ук, партия күрсәтмәләрен үтәү йөзеннән, колхозларны оештыру—хуҗалыкчыл яктан ныгыту әмәлләрен даими яктыртып торган. «Игенчеләр» хезмәт уңышларына ирешкән алдынгы колхоз һәм аерым колхозчыларны популярлаштыруга да игътибар иткән. Аның битләрендә авыллардагы партия һәм комсомол оешмаларының, культура учрежлениеләре—клублар һәм китапханәләрнең—эшчәнлеге, наданлыкка һәм дингә каршы көрәш турындагы язмалар да урын тапкан.

«Игенчеләр» авыл халкы өчен башка шәһәрләрдә татар телендә нәшер ителә торган көндәлек басмаларга тематик юнәлеш бирүче үзәк газета булган. Ул Казанда чыга торган «Крестьян газеты», аның дәвамы—«Колхоз газетасы», Самарадагы—«Урта Идел», аның дәвамы—«Колхозчы», Пензадагы—«Сабанчы», Нижний Новгородтагы—«Яңа авыл», Уфадагы—«Колхоз ударчысы» газеталарының эшчәнлеге турында, аларның уңай якларын һәм житешсезлекләрен анализлаган, файдалы киңәшләр биргән, эчтәлекле күзәтүләр бастырып килгән. Әлеге газеталар еш кына «Игенчеләр»дә дөнья күргән көнүзәк материалларны күчереп бастырганнар. «Игенчеләр» газетасы илне индустрияләштерүнең барышы турында күп язган, эшчеләр белән крестьяннар арасында үзара ярдәмне һәм элемтәне ныгыту идеясен яклаган. Аның һәрбер саны «Яшәсен эшче-крестьян берлеге!» лозунгысы астында чыккан.

1934 елның 30 декабрендә Мәскәүдәге көндәлек үзәк гомумсоюз иҗтимагый-сәяси татар газетасы «Коммунист»—СССР Үзәк Башкарма Комитеты Милләтләр Советының органы да туктатыла. Ул 1932 елның 9 гыйнварында моңарчы ябылган «Эшче» һәм «Игенчеләр» газеталары урынына чыгарылган. Аның 845 саны пәйда булган. Газетаның күчмә редакцияләре әзерләгән: «Коммунист» Касыймда», «Коммунист» Ялан Катайда», «Коммунист» Ногинскида», «Коммунист» Ленинградта», «Коммунист» Метростройда» исемле аерым саннары да дөнья күргән. «Коммунист» газетасының бөтен яшәве дәвамында баш мөхәррир булып тәҗрибәле журналист һәм публицист Идрис Агишев эшләгән. Аның урынбасарлары—Мирза Давыдов һәм Заһид Йосыпов (Шәркый). Бу басманың әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире һәм күчмә редакцияләрнең берсендә җаваплы мөхәррир булып Муса Җәлил хезмәт иткән. «Коммунист»ның актив авторлары: М. Аит, А. Айдар, С. Батыр, Г. Баязитов, Л. Вәлит, Г. Гәрәй, Г. Ильясов, Х. Мөҗәһитев, З. Насыйров, В. Садрый, Н. Сәфәров, Ф.Уразаев һәм башкалар.

Газета үз игътибарын, беренче чиратта, СССР Үзәк Башкарма Комитеты Милләтләр Советының милли сәясәт өлкәсендәге эшчәнлеген яктыртуга юнәлдергән. Икътисади мәсьәләләрне, илне индустрияләштерү һәм электрофикацияләштерүнең барышын киң яктырткан. Беренче бишьеллыкларның яңа төзелешләре—Беломор-Балтыйк каналы, Магнитогорск металлургия комбинаты, Днепрогэс, Мәскәү метрополитен төзүчеләренең хезмәт казанышлары турында даими язган. Аның сәхифәләрендә Татарстанда реконструкцияләнгән һәм яңадан төзелгән сәнәгать предприятиеләре: Казандагы—«Спартак» фабрикасы, мех комбинаты, синтетик каучук заводы, кинопленка фабрикасы, авиатөзелеш заводы, Зеленодольск шәһәрендәге суднолар төзү заводы һәм башкалары турындагы язмалар да дөнья күргән. Социалистик ярыш, авыл тормышы, колхоз төзелешенә багышлы хәбәрләр, агротехник киңәшләр урын тапкан. Газета шулай ук халык мәгарифенең торышын, әдәбият һәм сәнгать үсешен яктыртып килгән. Н. Баян, З. Бәширева, А. Гәрәй, Ә. Ерикәй, М. Җәлил, М. Зәйни, Г. Ибраһимов, Г. Иделле, Ш. Камал, М. Крыймов, Г. Кутуй, М. Максуд, Ш. Маннур, К. Нәҗми, М. Садри, Д. Фәтхинең әдәби әсәрләрен үз укучыларына житкергән. 1934 елда Мәскәүдә узган совет язучыларының Беренче съезды материалларын җентекләп яктырткан. М. Горький, К. Нәҗми, В. Кирпотин, В. Киршон, А. Таһиров, К. Тинчурин, А. Толстой, В. Ставский, П. Юдин докладларын, Әрмәнстан, Әзәрбайҗан, Башкортстан, Үзбәкстан, Таҗикстан, Төрекмәнстан, Кара-Калпакстандагы әдәбият турындагы чыгышларны урнаштырган. «Коммунист» системалы рәвештә илнең төрле төбәкләрендә татар телендә нәшер ителә торган «Кызыл Татарстан», «Пролетар», «Баку эшчесе», «Социализм юлы», «Ялкын», «Урал кочегаркасы» һәм башка газета-журналларга эчтәлекле күзәтүләр ясап килгән. «Ленинчыл милли сәясәт өчен» исемле рубрикада Татарстан һәм Башкортстандагы иҗтимагый-сәяси, икътисади һәм мәдәни тормыш, милли мәсьәләдә «Партиягә каршы тайпылышлар», вак буржуаз милләтчелек һәм «солтангалиевчелек»кә каршы көрәш турындагы материалларны бастырган.



*«Ударниклар».*

1930 елларда Мәскәүдә ябылган татарча вакытлы матбугат басмалары арасында 4 гомумсоюз журнал да булган.

1932 елның декабрь ае саны басылганнан соң, ВЛКСМ Үзәк Комитеты органы—«Ударниклар» дигән зур күләмле, рәсемнәргә бай иҗтимагый-сәяси, фәнни һәм әдәби айлык журнал яшәүдән туктатыла. Ул 1922 елның ноябрендә Мәскәүдә, РКСМ Үзәк Комитеты янындагы татар-башкорт бюросы органы буларак, «Яшь эшче» исеме белән дөньяга килгән. Әлеге журнал татар-башкорт эшче яшьләре тарафыннан сөелеп укылган, үз гомерендә яшьләрдән матур әдәбият көчләре үстерүдә зур уңышларга ирешкән була. 64 саны чыгып, бераз вакыт туктап торгач, 1930 елның май аенда, «Яшь эшче» журналы «Ударниклар» исемен алган һәм аның тагын 32 саны нәшер ителгән. «Ударниклар»ның төрле еллардагы җаваплы мөхәррирләре—Г. Абдуллаев, Ә. Ерикәй, Г. Ильясов, Г. Әхтәмев һәм редколлегия әгъзалары—М. Җәлил, Б. Мансуров, В. Садрый. Аның сәхифәләрендә Х. Абдуллина, И. Агишев, Ә. Айдар, М. Давыдов, З. Йосыпов (Шәркый), М. Крыймов, Г. Кушай, М. Максуд, З. Мәҗит, Ф. Сәхиуллин, Г. Теләш һәм башкалар язышкан.

«Ударниклар» журналы әдәбият мәсьәләләренә дә зур игътибар биргән. Ул, заман рухында, әдәбият һәм сәнгать үсешенең төп методы дип социалистик реализмны санаган. Аның сәхифәләрендә күпсанлы әдәби әсәрләр бастырылган. Мәсәлән, журналның матур рәсемнәр белән баетылган беренче санында: М. Крыймовның «Ударниклар маршы», М. Җәлилнең музыкага салынган «Комсомол җыры», Ә.Ерикәйнең «Турксиб», Ш. Маннурның «Өзелгән марш» шигырьләре, Ә. Айдарның «Беренче наступление», З. Шәркыйның «Ударниклар» хикәяләре, З. Мәҗитнең

«Днепрострой», В. Садрыйның «Баку», Д. Мирзаның «Миллионлаган шариклар» исемле очерклары урнаштырылган.

1932 елның декабрь аенда Мәскәүдә, 1929 елның августыннан бирле чыгып килгән пионерлар һәм укучы балаларның мәнфәгатен күздә тоткан айлык зур күләмле, күп рәсемле «Октябрь баласы» журналының соңгы 41 саны дөнья күргән. Ул ВЛКСМ Үзәк Комитеты һәм РСФСР Мәгариф халык комиссариаты органы булган. Бер-бер саны 7000данәдә СССР халыклары Үзәк нәшриятында, ә аннары—«Молодая гвардия» нәшриятында бастырылган. Әлеге басманың элгәре—«Кечкенә иптәшләр» журналы 1924 елның мартыннан 1928 елның апреленә кадәр, ВЛКСМ Үзәк Комитеты янындагы татар-башкорт бюросы органы рәвешендә шулай ук Мәскәүдә нәшер ителгән. «Октябрь баласы» журналының җаваплы мөхәррире Муса Җәлил, җаваплы сәркатибе Рабига Садыйкова (Зарипова), соңрак—язучы Әхмәт Фәйзи булган. Журналны нәфис рәсемнәр белән бизәкләүдә тәҗрибәле оста рәссамнар К. Әхмәтов, М. Закиров, Д. Красильников, А. Нигмәтуллин, Ф. Ногманов, С. Орлов шөгыльләнгән. 1930 елның башыннан бу журнал шахтер балалары өчен «Донбасс пионеры» исемле махсус кушымта чыгарып килгән. «Октябрь баласы» сәхифәләрендә яшь язучылар һәм шагыйрьләр Габдрахман Әпсәләмов, Әюп Гәрәй, Нәби Дәүли, Исхак Закиров, Рахман Ильяс, Галимҗан Мөхәммәтшин, Мөхәммәт Садри, Габдрахман Теләшев, Сахаб Урайский әдәби юлга аяк басканнар. Журналда шулай ук төрле матбугат басмаларында даими языщкан, танылган әдипләр Муса Җәлил, Әхмәт Ерикәй, Мансур Крыймов, Шәйхи Маннур, Борһан Мансуров, Төхфәтулла Ченәкәйнең әдәби әсәрләре дә дөнья күргән. «Октябрь баласы» журналында үзләренең язмалары белән йөзләрчә яшь хәбәрчеләр катнашкан. Алар арасында аеруча актив языщкан хәбәрчеләр Вил Гильми, С.Ишмөхәммәт, Зыя Морат, З.Садыйкова, Г.Сәгъди, А.Халит-Донбаслы, Х.Ханнан һәм А.Шәмиев редакциянең кыйммәтле призларына һәм һәрберсенең фоторәсемнәре журнал битләрендә бастырып чыгаруга лаек булганнар.



*«Октябрь баласы».*

1933 елның гыйнварында, Мәскәүдә нәшер ителгән һәм бөтен совет иле буенча таратылган гомумсоюз «Октябрь баласы» журналы урынына, Казанда, автономияле республика күләмендә «Пионер каләме» исемле журнал чыга башлаган. Аның беренче җаваплы мөхәррире итеп Х. Бәдри билгеләнгән. Әлеге басма «Ялкын» исеме белән хәзергәчә чыгуын дәвам итә.

1937 елның ноябрь аенда, 172 саныннан соң, Сугышчан алласызлар союзы үзәк советы органы—«Сугышчан алласыз» исемле рәсемле фән, фәлсәфә журналы чыгудан туктатыла. Ул 1925 елның августында барлыкка килгән. 1932 елның май аендагы 5 (138) санына кадәр «Фән һәм дин» дип аталган. Һәрбер санында «Дингә каршы көрәш—социализм өчен көрәш!» девизы урнаштырылып килгән. Бу басма үзенең озак вакыт чыгуы, нәшер ителгән гомуми саннары, авторларының күплеге һәм фәнни-тематик кинлеге буенча, Мәскәүдә төрле елларда татар телендә дөнья күргән барлык 13 журналлар арасында («Тәрбият-ел-әтфаль», «Кызыл Шәрекъ», «Чаткы», «Очкын», «Юлдаш», «Кечкенә иптәшләр», «Яшь эшче», «Ударниклар», «Октябрь баласы», «Мәгариф эшчесе», «Культура революциясе», «Дин һәм фән»-«Сугышчан алласыз», «Тау эше техникасы») иң күренеклесе булган. Журналның җаваплы мөхәррирләре—Г. Гафуров-Чыгтай, Г. Алтай, М. Наильский, Б. Мансуров,



*«Фән һәм дин».*

И. Агишев. Аның сәхифәләрендә Г. Әхмәтов, Х. Арский, С. Атнагулов, Г. Басыйри, М. Басыйров, З. Бәшири, Ф. Галәви, М. Давыдов, Г. Ибраһимов, Ф. Кәрими, Г. Касыймов, Һ. Килдебәков, М. Максуд, Б. Никольский, В. Садри, С. Сәетгалиев, Т. Салихов, С.Тарханов, Н.Хәкимов, Ш. Шәйхи, Г. Шәрәф, В. Шәфигуллин, Я. Яушев һәм башкалар язышкан.

1937 елнын декабрендәге 57 саны чыкканнан соң, СССР авыр промышленность халык комиссариатының техник-пропаганда секторы һәм Бөтенсоюз фән-техника нәшрияты органы булган бай рәсемле, зур күләмле «Тау эше техникасы» исемле айлык журнал нәшер итүдән туктатылган. 1932 елның октябреннән бирле чыгып килгән әлеге басманың җаваплы мөхәррирләре булып бер-бер артлы Г. Төхфәтуллин, С. Садыйков, Ф. Яһудин, С. Шәфиев эшләгән. Журнал битләрендә галимнәр, югары квалификацияле белгечләр, инженерлар: академик И. Губкин, В. Беликов, Х. Вәлиев, З. Ганиев, П. Герасимов, М.Горшков, В.Здоровенко, А. Зозуля, К. Ибәтуллин, К. Ибраһим, И. Измайлов, А. Илюхин, Х. Кадермәтев, И. Кайбышев, М. Кравцов, В. Лури, Д. Маркман, С. Муратов, К. Насыбуллаев, Ф. Насыйров, А. Пущин, Х. Ситдиков, Н. Шәрифҗанов, Ю. Юнов, В. Яцких һәм башкаларның язмалары дөнья күргән. Анда шулай ук күпсанлы эшче хәбәрчеләр язышкан.



*«Тау эше техникасы».*

1931 елда, гыйнвар ае саны чыкканнан соң, РСФСР Мәгариф халык комиссариатынын татар-башкорт бүлеге органы—«Мәгариф эшчесе» исемле иҗтимагый, педагогик һәм фәнни айлык журнал яшәвеннән туктатылган. Бу басма 1926 елның гыйнварыннан кооператив «Нәшрият» басмаханәсендә, ә аннары—СССР халыкларының үзәк нәшриятендә чыгарылган. Аның 52 саны дөнья күргән. Журналның беренче җаваплы мөхәррире И. Юманкулов, ә ахыргысы—И. Агишев булган. Редколлегия составына И. Агишев, С. Гәляви, Х. Зәйни, Н. Йосыпов, Б. Мансуров, М. Мөхәммәдев, Г. Нигъмәти, Т. Салихов, М.Уразмөхәммәдевләр кергән. «Мәгариф эшче»сендә Н. Аюпов, Г. Баембәтов, Г. Ибраһимов, Г. Салаватов, Ш. Саттаров, Г. Хәбиб, Н. Хәйри, С. Шакулова һәм башкалар язышкан. Журнал даими рәвештә милли мәктәпләрдә уку-укыту һәм тәрбия эшләрен оештыру мәсьәләләрен, алдынгы педагогларның эш тәҗрибәләрен һәм методик кинәшләрен яктыртып килгән. Аның сәхифәләрендә: гомуми, педагогика-методика, тел һәм орфография, сәяси агарту, әдәбият, мәктәпкәчә тәрбия, фән яналыклары, китаплар дөньясында, тәнкыйть һәм библиография бүлекләре булган

1932 елның декабрендә РСФСРның шул ук Мәгариф халык комиссариаты һәм «Яңалиф» Үзәк комитеты нәшир әфкяре булган «Культура революциясе» дип аталган айлык журналның ахыргы, 19 саны чыга. Ул 1931 елның июнь аенда 5000 данә белән барлыкка килгән. Шул елның октябренә кадәр СССР халыкларының үзәк нәшриятендә, ә аннары—Үзәк мәгариф басмаханәсендә басылып килгән. Журналның җаваплы мөхәррире—И. Юманкулов. Актив авторлары—М. Арифуллин, М. Арсланов, Г. Вәлид, З. Гәзиз, Т. Исхак, Х. Мансуров, З. Мостафин, Ә. Талиб, М. Тәржеман, Ә. Фәйзи.

Мәскәү шәһәрендә татар телендә чыгып килгән һәм 1930 елларда туктатылган 9 газета һәм журнал, үзләренең полиграфик эшләнеше, төрле төстәге бизәкле тышлыклар, иллюстрацияләр, күпсанлы фоторәсемнәр һәм пөхтә кәгазь, шрифт һ. б. кебек сыйфатлары белән унай якка аерылып торалар. Әлеге басмалар совет иленең күп төбәкләрендә киң таратылган. Аларны яздырып алдыручылар, Татарстан һәм Башкортстаннан тыш, Идел буе, Урал, Себер, Казакъстан, Кыргызстан, Үзбәкстан, Әзәрбайҗан, Украина, Белоруссия, Ерак Көнчыгыш, Мәскәү, Ленинград һәм башка урыннарда булган. Үзәк газета-журналларның мәҗбүри рәвештә чыгудан туктатылуы татар матбугаты укучыларын Мәскәүдә нәшер ителгән ана телендәге бай эчтәлекле

басмалардан мәхрүм иткән.

1930 еллар ахырына кадәр Мәскәүдә ябылган үзәк гомумсоюз һәм гомумроссиячел вакытлы матбугат басмаларыннан тыш, Әзәрбайҗан һәм Украинада союздаш республика күләмендә татар телендә чыгып килгән ике газета да бастырудан туктатылган.

Аларның беренчесе—«Баку эшчесе» исемле атналык газета. Әзәрбайҗан Коммунистлар (большевиклар) партиясе Үзәк Комитеты, Әзәрбайҗан Үзәк Башкарма Комитеты һәм Профсоюзлар советы органы буларак, 1930 елның 28 апрелендә Баку шәһәрендә чыга башлаган. Төрле елларда аның җаваплы мөхәррирләре булып И. Хәйретдинов, Х. Ризван, Ш. Рәхмәтуллин эшләгән. Бу басма Бакуда һәм аның бистәләрендә хезмәт иткән 18 мең татар эшчеләре өчен билгеләнгән була. 1930 елның җәеннән, өч ел дәвамында, бу газета Әзәрбайҗанда яшәгән үзбәк колхозчылары өчен шул милләт телендә «Зәрбдар колхозчы» («Алдынгы колхозчы») дип аталган махсус сәхифә чыгарып килгән. «Баку эшчесе» редакциясе Украинаның Сталино (хәзерге Донецк) шәһәрендә чыгып килгән икенче союздаш республикачыл «Донбасс эшчесе» (1937 елның июленә кадәр «Пролетар» исемен йөрткән) газетасы белән тыгыз элемтәдә булган. Бу ике газета, даими рәвештә, татар милләтле Баку нефтьчеләре белән Донбасс шахтерлары һәм металлургларының тормышын, эшчәнлеген, бигрәк тә алар арасында бара торган социалистик ярыш нәтиҗәләрен яктыртучы үзара алмаш сәхифәләр бастырып торганнар. Газета битләрендә күпсанлы эшче хәбәрчеләр язышкан. Әзәрбайҗан КП/б ҮК карары нигезендә, 1938 елның 11 мартында, 822 санынннан соң, «Баку эшчесе» газетасы чыгудан туктатылган.

1939 елның 23 февралендә, 1008 саны дөнья күргән, «Донбасс эшчесе» исемле икенче союздаш республика күләмле газета да яшәүдән туктатылган. Ул Бөтенукраина профсоюзлары советы нәшир әфкяре буларак, 1930 елның 29 ноябрендә өлкә үзәге Сталино (хәзерге Донецк) шәһәрендә чыга башлаган. Соңрак газета Украина Коммунистлар (большевиклар) партиясенең Сталино өлкә комитеты органы дип тә саналган. 1937 елның 29 июленә чаклы әлеге басма «Пролетар», ә аннан соң—«Донбасс эшчесе» исеме белән чыгып килгән. Аның беренче җаваплы мөхәррире—Борһан Мансуров, актив авторлары: А. Әхмәтшин, М. Вәлиев, Н. Дәүли, И. Караманай, Х. Маннапов, М. Сөндекле. Басма сәхифәләрендә эшче хәбәрләр Г. Басыйров, Г. Закиров, Г. Нуретдинов, З. Шакиров, А. Яппаров һәм башкалар язышкан.

1930 елларда РСФСРның автономияле республикаларында да күпсанлы татарча газета-журналлар чыгарудан туктатылган. Татарстанда гына 70тән артык шундый вакытлы матбугат органнары ябылган. Аларның 20дән күбрәге автономияле республика күләмендәгеләр булган.

1933 елның гыйнварында, комсомолның Татарстан өлкә комитеты һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының татар-башкорт бюросы органы булган айлык «Колхоз яшьләре» журналы яшәүдән туктаган. Бу басманың башлангычы «Кызыл Шәрекъ яшьләре» исеме белән1922 елның гыйнварында дөньяга килгән. Ул 1924 елның маеннан «Октябрь яшьләре», ә 1925 елның июленнән 1930 елның гыйнварына кадәр «Авыл яшьләре» исемнәрен йөрткән. 120гә якын саны чыккан әлеге журналның мөхәррирләре булып бер-бер артлы М. Парсин, Г. Галиев, С. Фәхри, Ф. Мөбәрәкшин, Ш. Рәмзи, Ф. Исхаковлар эшләгән. Бу зур күләмле фотографик һәм кулдан ясалган рәсемнәр белән баетылган айлык журнал, беренче чиратта, авыл җирендә көн күргән егетләрнең һәм кызларның төрле яклы тормышын яктырту, аларны Советлар Союзында, Татарстанда бара торган иҗтимагый-сәяси, икътисади һәм мәдәни үзгәрешләр, яңалыклар белән таныштырып тору өчен чыгарылган. Басма сәхифәләрендә аеруча зур игътибар үсеп килүче яшь буынны социалистик рухта тәрбияләүгә юнәлдерелгән була.

1935 елның 30 августында ВКП/б/ның Татарстан өлкә комитеты һәм ТАССР Җир эшләре халык комиссариаты органы булган «Колхоз газетасы»ның соңгы 733 саны дөнья күргән. Ул 1924 елның 25 апрелендә чыга башлаган һәм 1930 елның 25 февраленә кадәр «Крестьян газеты» исемен йөрткән. Әлеге басма һәрвакыт Мәскәүдә чыга торган үзәк «Беднота» һәм «Игенчеләр» газеталары тәҗрибәсенә

таянып эш иткән. «Колхоз газетасы»ның төрле еллардагы җаваплы мөхәррирләре— С. Фәйзуллин, Г. Толымбайский, И. Агишев, Г. Кушаев, Т. Имаметдинов, Н. Мансуров, Г. Нәбиев. Актив авторлар арасында И. Бибиков, Ю. Вәлиев, Г. Галиев, М. Гали, М. Парсин, К. Рәхим, Г. Төхфәт, А.Халит, М. Якублар булган. «Колхоз газетасы»нда Ф. Кәрим, С. Рафиков, Г. Теләш һәм башкаларның әдәби әсәрләре, күпсанлы фотоиллюстрацияләр һәм рәсемнәр дөнья күргән.

1936 елның декабрь аендагы 85 санынннан соң, 1932 елның декабреннән бирле нәшер ителеп килгән айлык рәсемле сәнәгати-техник «Техника» журналы чыгудан туктатыла. Аның сәхифәләрендә Татарстанда, заманча техника белән җиһазландырылган элгәре һәм янадан төзелгән заводлар, фабрикалар, электростанцияләр һәм башка сәнәгать предприятиеләре, алардагы эш процессын камилләштерүгә мәслихәт оештыру—техник алымнар турында даими рәвештә язылып килгән. Журнал шулай ук яңа техниканы һәм оештыру алымнарын кулланып, аеруча зур уңышларга ирешкән хезмәт алдынгылары—ударниклар һәм стахановчыларның эш тәҗрибәсен дә киң яктырткан. «Техника» журналының төрле еллардагы мөхәррирләре—инженерлар Гомәр Әлмиев һәм Нур Кукряков, ә җаваплы сәркатибе Абдулла Алиш булган.

1937 елның 5 февралендә, 45 нче саны чыкканнан соң, Татарстан Эчке эшләр халык комиссариатының, милициясенең сәяси идарәсе органы булган «Сакта» («На страже») газетасы яшәүдән туктатылган. 1931 елдан башлап нәшер ителгән әлеге басма сәхифәләрендә материаллар татар һәм рус телендә бастырылган. Аның соңгы санында мөхәррир дип М. Шаһиәхмәтов күрсәтелгән.

1938 елның 8 маенда атнага өч тапкыр чыгып килгән «Кызыл армиес» газетасы туктатыла. Ул башта, Идел буе хәрби округының атналык басмасы рәвешендә, 1924 елның 7 июненнән 15 ноябренә кадәр Самара шәһәрендә нәшер ителә. Ул чакта аның 18 саны дөнья күрә һәм редколлегиясе Ф. Таипов, Х. Курми, А. Шнитковлардан тора. 1925 елның 23 февраленнән ябылганчы Казанда чыгарыла. Биредә аның яңадан 1545 саны пәйда була. 1937 елның маена чаклы ул Идел буе хәрби округының Сәяси идарәсе һәм ВКП/б/ның Татарстан өлкә комитеты, 1938 елның мартына кадәр—ТатЦИК исемендәге Казан укчы дивизиясенең сәяси бүлеге һәм туктатылганчы—бер хәрби берләшмәнең нәшир әфкяре була. Газетаның соңгы саны тулысы белән рус телендә бастырылган. Төрле елларда мөхәррирләре—М. Давыдов, Я. Чанышев, М. Парсин, С. Гилфан, В. Гали, Г. Усманов, Г. Гыйльманов. «Кызыл армиес» редакциясе, кушымта рәвешендә, 1929 елның маеннан 1933 елның гыйнварына кадәр «ОСОАВИАХИМ» (124 санда), төрле елларда—«Кызыл командир» һәм «Военкор» газеталарын, «Октябрь» һәм «Ун ел» исемле зур күләмле әдәби җыентыклар бастырып чыгарган. «Кызыл армиес» газетасы һәм аның кушымталары сәхифәләрендә 1917 елгы Октябрь революциясенең әһәмияте, Кызыл Армия тормышы, аның тарихы, аерым алганда, татар милләтле кызылармеецлар һәм командирларның Гражданнар сугышы фронтларында актив катнашуы, тыныч шартлардагы хәрби һәм сәяси эшчәнлеге киң яктыртылыш тапкан. Әлеге матбугат басмаларында Советлар Союзында, шул исәптән Татарстанда, үтә торган агымдагы иҗтимагый-сәяси вакыйгалар турындагы мәгълүматлар да зур урын тапкан. «Кызыл армиес» һәм аның кушымта газеталарында армия сафларында хезмәт итүче дистәләрчә ихтыяри хәбәрчеләр катнашкан.

1930 елларның беренче яртысында ук туктатылган татар көндәлек матбугат басмалары арасында Татарстан күләмендә нәшер ителгән: «Сугышчан алласызлар» (1929-1933), «Культармеец газеты» (1930-1933), «Совет экспорты өчен» (1934-1935) газеталары һәм «Яналиф» (1927-1932), «Татарстан» (1928-1931), «Ярыш» (1931-1932), «Татарстан Советлары» (1932-1935) журналлары да булган.

Татарстаннан тыш төбәкләрдә үз эшчәнлеген туктатырга мәҗбүр ителгән автономияле республика күләмендәге татар телендәге басмалар арасында Башкортстанда һәм Удмуртиядә нәшер ителгәннәре дә булган.

Мәсәлән, 1933 елның 13 мартында Уфа шәһәрендә Башкортстан Мәгариф халык комиссариаты органы «Колхоз ударчысы» исемле газетаның соңгы 56 саны дөнья күргән. 1931 елның 19 апреленнән бирле чыгып килгән әлеге басманың нәшире

ВКП/б/нын Башкортстан өлкә комитеты органы—«Коммуна» газетасы, ә төрле вакыттагы мөхәррирләре Р. Камал, И. Насыйров, М. Бикбулат, Г. Гузай булган. «Колхоз ударчысы» газетасы төп игътибарын наданлыкка каршы көрәшкә юнәлдергән. Аның сәхифәләрендә даими рәвештә язучы Гайнан Әмири (1911-1982) әсәрләре бастырылып килгән. Шул ук Уфа каласында 1934 елда Башкортстан Мәгариф халык комиссариаты һәм ВЛКСМнын Балалар коммунистик оешмаларының өлкә бюросы органы булган әдәби-нәфис «Пионер» журналы һәм 1936 елда ВКП/б/нын Башкортстан өлкә комитеты органы—«Матбугат ударнигы» журналы, 8 саныннан соң, яшәүдән туктыйлар. 1937 елның февралендә айлык сатирик һәм юмористик «Сәнәк» журналы да нәшер ителми башлый. Ул 1925 елнын июнендә ВКП/б/нын Башкортстан өлкә комитеты һәм Үзәк Башкарма Комитеты органы «Яңа авыл» (хәзерге «Кызыл тан») газетасынын кушымтасы рәвешендә барлыкка килгән һәм анын җамгысы 141 саны чыгып калган була. Журналның ахыргы җаваплы мөхәррире—Имамутдин Насыйров (1898-1942). «Сәнәк» журналында С. Алиш, А. Әмин, Ә. Вәли, Г. Гомәр, С. Жамалиев, Б. Ишемгол, А. Кудаш, С. Кудаш, Г. Дәүләтшин, А. Карнай, Ж. Локман, М. Марат, Х. Наум, Д. Нигмәт, М. Сөндекле, Г. Сәлам, М. Тажи, А. Таһиров, Х. Хәбип, Ә. Чаныш, Д. Юлтый, Т.Янәви, Г.Яһудин язышкан.

1940 елның 6 октябрендә Ижевск шәһәрендә 1933 елның 10 февраленнән бирле чыгып килгән ижтимагый-сәяси «Ленин юлы» газетасының ахыргы 917 саны пәйда булган. Аның соңгы айлардагы саннары рус хәрефләре белән, кириллицага нигезләнеп нәшер ителгән. Бу басма ВКП/б/нын Удмуртия өлкә комитеты һәм Удмуртия Верховный Советы органы булган. Озак вакыт анын баш мөхәррире вазыйфаларын танылган галим һәм журналист Ибраһим Рәхмәтулла улы Бурнашев башкарган. «Ленин юлы» газетасы Удмуртия республикасы халкының, анда яшәгән күп менле татар диаспорасының ижтимагый-сәяси һәм мәдәни тормышын киң яктыртып килгән.

1930 еллар дәвамында татар телендәге крайлар күләмендә чыгып килгән газета һәм журналлар да үз эшчәнлекләрен туктатырга мәжбүр ителгәннәр. Шундый басмаларның беренчеләреннән 1933 елның 25 мартында Горький (1932 елга кадәр Нижний Новгород) шәһәрендә яшәүдән туктатылган ВКП/б/нын Горький край комитеты органы—ижтимагый-сәяси «Яна авыл» газетасы булган. Ул 1930 елнын 5 гыйнварында, ВКП/б/нын Нижний Новгород крайкомынын татар секциясе нәшир әфкяре буларак чыга башлаган. Анын 231 саны дөнья күреп калган.

Ерак Көнчыгышта эшләгән татар шахтерлары өчен чыгарылган «Күмер ударниклары» исемле газетаның да гомере кыска булган. Ул Ерак Көнчыгыш крае профсоюзлар советы, күмерчеләрнен край комитеты берлеге һәм ВКП/б/нын Артем шәһәр комитеты органы буларак, 1932 елнын 27 гыйнварында барлыкка килгән. Тик 109 саны чыгу белән үк, 1933 елнын 23 апрелендә яшәүдән туктатылган да инде.

1935 елнын 12 маенда Әстерхан шәһәрендә, 1203 санынннан сон, совет чорындагы иң өлкән татар газеталарынын берсе—ВКП/б/нын Сталинград крайкомы һәм край башкарма комитеты, ВКП/б/нын Әстерхан шәһәр комитеты, шәһәр Советы, профсоюзларнын шәһәр советы органы—«Ялкын»ны чыгарудан туктаталар. Бу газета 1918 елнын 1 сентябрендә «Ышаныч» исеме белән Саратов шәһәрендә барлыкка килгән. 1920 елнын 12 октябреннән «Ялкын», 1924 елнын 11 гыйнварыннан 1932 елнын 8 мартына кадәр, Әстерхан шәһәренә күчканче, «Идел буе» һәм аннан сон—янадан «Ялкын» дип аталган. Чыга башлаганда әлеге басма Саратов губерна советынын мөселман комиссариаты, 1919 елнын апреле ахырыннан июленә чаклы—Көнчыгыш фронтнын 4 армиясе сәяси бүлеге, 1920 елнын 12 октябрена кадәр—мөселман коммунистик оешмаларынын Саратов бюросы, 1928 елнын 1 сентябрена тикле—татар коммунистларынын Саратов губерна бюросы һәм татар эшләре буенча губерна бүлеге һәм 1934 елнын 31 гыйнварына кадәр—ВКП/б/нын Түбән Идел крайкомы һәм край башкарма комитетынын нәшир әфкяре булган. Газетанын төрле еллардагы жаваплы мөхәррирләре—Ә. Рәжәпев, И. Әюпов, Һәйәт, З. Сүнчәләй, Ж. Йосыф.

1936 елнын 16 февралендә Новосибирск шәһәрендә, ВКП/б/нын Көнбатыш

Себер крайкомы һәм край башкарма комитеты органы булган «Азат Себер» исемле эшче-крестьян газетасының соңгы 1453 саны чыккан. Әлеге басманың нигезе булып, Гражданнар сугышы чорында, 1918 елның 5 декабрендә, Бөгелмә шәһәрендә хәрәкәттәге 5 Кызылармиянең сәяси бүлеге чыгара башлаган «Кызыл яу» дип аталган хәрби газета хезмәт иткән. Ул 1919 елның 23 декабрендә Омск шәһәрендә, РКП/б/ның мөселман оештыру бюросы һәм Омск губерна ревкомы нәшир әфкяре рәвешендә, «Азат Себер» исемен алган һәм анда 1921 елның 21 июленә кадәр басылып килгән. 1921 елның сентябреннән туктаганчыга чаклы Новониколаевск (хәзерге Новосибирск) шәһәрендә нәшер ителгән. «Азат Себер» газетасының төрле еллардагы җаваплы мөхәррирләре: Ф. Әхмәтев, С. Фәхриев, Х. Гайсин, М. Йосыпов, И. Вәлиев, Х. Курмаев. Актив авторлары: Х.Бәдәни, Б.Ибраһимов, Г. Камаев, Ш. Мәхмүт, Г. Нигъмәти, Л. Сабиров, Г. Сәйфи, Х. Рәхмәтуллин. «Азат Себер» редакциясе 1921-1923 елларда «Яшьләр сәхифәсе» исемле кушымта, 1930-1931, 1933-1934 елларда татар язуын латиницага күчерү мәсьәләләрен яктыртучы «Яналифче» журналы һәм «Яналиф походы» газетасы чыгарган.

Самара (1935 елдан—Куйбышев) каласында татар телендә край күләмендә чыгып килгән вакытлы матбугатның ике басмасын: айлык «Комбайн» журналы һәм «Колхозчы» газетасын яшәүдән туктатканнар. «Комбайн» исемендәге массовый, колхоз-производство һәм әдәби-нәфис журнал Урта Идел край җир идарәсе һәм совет язучылары союзының Урта Идел оештыру комитеты тарафыннан чыгарылып килгән. Ул 1922 елның апреленнән 1933 елның февраленә кадәр 11 санда пәйда булган. Журналның баштагы җаваплы мөхәррирләре: Г. Новач һәм Ф. Мөбәр, аннары—Х. Йосыпов. Ул чакта край күләмендә танылган язучылар—К. Арслан, К. Габитов, И. Мансуров, А. Сәйфуллин, Г. Сәляй-Ураллы, Ф. Татлыбай, С. Урайскийларның, күпчелеге колхоз тормышына багышланган, әдәби әсәрләре басылып килгән. «Комбайн» журналы белән Г. Ахунов, К. Әюпов, Л. Җәлал, Г. Йосыпов, А. Фәйзуллин һәм башкалар хезмәттәшлек иткән.

1938 елның 28 мартында иҗтимагый-сәяси «Колхозчы» газетасының соңгы, 1170 саны дөнья күргән. Ул 1928 елның 6 октябреннән 1930 елның 31 декабренә кадәр «Урта Идел» исемен йөрткән. Әлеге басма чыга башлаганда—ВКП/б/ның Урта Идел өлкә комитеты һәм өлкә башкарма комитеты, 1929 елның 27 октябреннән—ВКП/б/ның Урта Идел край комитеты һәм край башкарма комитеты, 1935 елның 30 гыйнварыннан—ВКП/б/ның Куйбышев край комитеты һәм край башкарма комитеты, 1937 елның 17 февраленнән—ябылганчы ВКП/б/ның Куйбышев өлкә комитеты һәм өлкә башкарма комитеты органы булган. Газетаның төрле еллардагы җаваплы мөхәррирләре—И. Исхаков, Ф. Мөбәр, актив язышчылары—Д. Акчурин, Г. Гәбҗәлилев, Н. Кадыйров, Г. Камалетдинов, М. Сәгыйдуллин, Г. Сәйфи, А. Сәлимев. 1928 елның декабреннән 1929 елның августына тикле, газетага кушымта рәвешендә, «Урта Идел» дип аталган айлык әдәби, иҗтимагый-сәяси һәм авыл хуҗалыгы журналы нәшер ителгән. З. Шәркый-Йосыпов мөхәррирлегендә аның 8 саны пәйда булган. 1931-1933 елларда «Колхозчы» редакциясе, нигездә, яналиф кертүгә багышланган махсус кушымта—«Культура фронтында» дигән газетаның 44 санын чыгарган.

1930 елларда большевистик хакимиятләр татарча өлкәләр һәм округларда бастырылып килгән газеталарны да чыгарудан тыйганнар. Мәсәлән, Мәскәү янындагы күмер бассейнында эшләгән татар шахтерлары өчен 1932 елның 16 сентябреннән нәшер ителә башлаган «Мәскәү кочегаркасы» исемле иҗтимагый-сәяси газетаның, 1933 елның 24 июненә кадәр, бары тик 38 саны гына дөнья күреп калган. Ул ВКП/б/ның Мәскәү өлкә комитеты, күмерчеләр профсоюзының өлкә комитеты һәм «Москвауголь» органы булган.

1938 елның 1 апрелендә, 709 саны бастырылганнан соң, ВКП/б/ның Чиләбе өлкә комитеты һәм өлкә башкарма комитеты органы—«Коммунист» исемен йөрткән иҗтимагый-сәяси газета яшәүдән туктатылган. Барлыкка килгән көне—1931 елның 20 декабреннән 1935 елның 6 апреленә чаклы ул «Төзү ударнигы» дип аталган. Бу басма татар телле укучылары—Чиләбе трактор, металлургия, трубопрокат заводлары, Магнитогорск, Златоуст, Копейскидагы сәнәгать предприятиеләре эшчеләре һәм

авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре өчен нигезләнгән була. 1933-1934 елларда «Төзү ударнигы»ның кушымтасы рәвешендә, казакъ телендә «Курылыс экнингичи» дигән газета чыгарылган.

1939 елның 27 февралендә, редакциясенең төп хезмәткәрләре, буржуаз милләтчелектә нигезсез гаепләнеп кулга алынгач, ВКП/б/ның Оренбург өлкә комитеты һәм өлкә башкарма комитеты органы—иҗтимагый-сәяси «Коммунист» газетасы, партиянең өлкә комитеты карары буенча, бастырудан туктатылган. Әлеге басма, Оренбург өлкәсендә көн күргән татар хезмәт ияләре арасында тарату максаты белән, 1935 елның 28 июленнән бирле нәшер ителеп килгән. Газетаның 474 саны чыгып калган, төрле еллардагы мөхәррирләре—Х. Йосыпов, С. Алеев.

1939 елның 28 февралендә совет чорында татар телендә нәшер ителгән региональ вакытлы матбугат басмаларының иң өлкәннәреннән берсе, чыккан саннары, тиражы, язышучы авторлары һәм кушымталарының күплеге белән аерылып торган, ВКП/б/ның Свердловск өлкә комитеты органы—иҗтимагый-сәяси «Социализм юлы» газетасына да чират килеп житкән. Бу көнне аның соңгы 3111 саны (баштагы 27се Вятка шәһәрендә) дөнья күргән. Әлеге басма, Вятка губерна советы башкарма комитеты янындагы татар-башкорт секциясенең нәшир әфкяре буларак, 1919 елның 23 гыйнварында «Коммунист» исеме белән барлыкка килгән. 1925 елның 14 августыннан 1930 елның 18 маена кадәр газета «Сабан һәм чүкеч» дип аталган. 1919 елның 8 апреленнән «Коммунист» газетасы Көнчыгыш фронты 3-армиясенең сәяси бүлеге, 1920 елның 30 гыйнварыннан—Беренче Хезмәт армиясенең сәяси комиссиясе, 1920 елның 9 июленнән—РКП/б/ның Екатеринбург губерна комитеты янындагы татар-башкорт бюросы, 1924 елның 1 гыйнварыннан—РКП/б/ның Урал өлкә комитеты һәм 1925 елның 14 августыннан, «Сабан һәм чүкеч» исемен алганнан соң, 1934 елның 24 гыйнварына кадәр—ВКП/б/ның Урал комитеты органы булган. 1924-1927 елларда газета редакциясе, укучылары арасында шөһрәт казанган, «Шәпи агай» дигән рәсемле әдәби, сәяси, фәнни һәм сатирик журналның 27 санын чыгарган. Ул шулай ук китаплар бастыру белән дә шөгыльләнгән. 1932-1933 елларда «Социализм юлы»ның кушымталары рәвешендә, Свердловск шәһәрендә—«Культура өчен», «Уралмаш ударнигы» һәм Кизел шәһәрендә «Күмер өчен», «Урал кочегаркасы» газеталары нәшер ителгән. Егерме ел дәвамында чыгып килгән газетаның төрле вакыттагы мөхәррирләре: К. Мохтаров, И. Бәхтияров, Ш. Абашев, Х. Ишбулатов, С. Садыйков, И. Галиев, С. Нураев, С. Хәсәнкаев, С. Мөлекев. Актив авторлары: А. Әхмәтев, Х. Биктимерев, М.Брундуков, С Вәлиев, М.Гайнуллин, Г. Гатауллин (Апуш), Н. Динмөхәммәтев, Х. Мәхмүтев, Х. Наумов, М. Уразмөхәммәдев, Г. Үтәгәнов, Ш. Хәбибуллин, С. Хәйруллин, Ш.Хамматов. Газетаның Х. Әминев житәкчелегендәге регуляр чыгарылган «Әдәбият сәхифәсе»ндә башлап язучы әдипләр М. Афзалов, Г. Абдуллин, Х. Быков, З. Зиганшин, Ф. Кәрим-Азналы, М. Рафаил, Ш.Хисамов, Ә. Чинбаев, И. Яһудин үзләренең шигырьләрен һәм хикәяләрен бастырганнар. Шул ук «Әдәбият сәхифәсе»ләрендә соңрак татар дөньясында танылган язучылар һәм шагыйрьләр Газиз Иделле (Госманов), Мансур Крыймов, Шәйхи Маннур, Габдрахман Теләшев, Идрис Туктаров әсәрләре дә дөнья күргән. Бу басма битләрендә йөзләрчә эшче һәм авыл хәбәрчеләре язышкан. Газетаның төрле еллардагы рубрикалары: «Советлар илендә», «Чит илләрдә», «Кызыл Армия хәбәрләре», «Ак гаскәрләр чигенә», «Тиф белән көрәш», «Хезмәт армиясендә», «Эшчеләр шефлыгы», «Крестьяннарга файдалы киңәшләр», «Урал хәбәрләре», «Урал эшчеләре арасында», «Социализм Уралы төзибез», «Татар-башкорт эшчеләре социализм ярышында», «Украина белән Урал ярышы», «Күмер фронтында», «Бишьеллык планын—срогыннан элек!», «Колхоз кырларында», «Ударниклар-колхозчылар», «Артта калган колхозларны—кара тактага!», «Наданлыкны җиңәрбез», «Культура эшләре», «Безнең әдәбият—сыйнфый көрәш», «Фән яңалыклары», «Эшче—авыл хәбәрчеләре язалар», «Хәбәрчеләр эзеннән», «Җавап бирәбез», «Театр һәм музыка», «Тәнкыйть—библиография», «Спорт». Әлеге рубрикалар—бүлекләр исемлеге «Коммунист»-«Сабан һәм чүкеч»-«Социализм юлы» газетасының тематик даирәсе бик киң булуын күрсәтә.

«Социализм юлы» газетасы ябылганчы, берничә ел элек Сведловск шәһәрендә

татар телендә чыгып килгән яшьләр һәм балалар матбугаты да юк ителгән. 1934 елның 15 апрелендә ВЛКСМ Үзәк Комитетының оештыру бюросы һәм ВЛКСМнын Свердловск өлкә комитеты нәшир әфкяре—«Алмашка» газетасынын соңгы 101 саны дөнья күргән. Бу яшьләр басмасы 1932 елның 22 ноябрендә пәйда булган. 1935 елның 5 мартында, 1932 елның язынннан бирле чыгып килгән «Яшь коммунар» газетасы да, 88 санынннан соң, яшәүдән туктаган. Балалар өчен билгеләнгән әлеге газета шулай ук ВЛКСМ Үзәк Комитетының оештыру бюросы һәм ВЛКСМнын Свердловск өлкә комитеты органы булган.

1935 елның 15 августында, 490 саны дөнья күргәннән соң, ВКП/б/нын Магнитогорск округ комитеты, округ башкарма комитеты һәм профсоюзларның округ советы басмасы—«Магнит эшчесе» исемле иҗтимагый-сәяси газетаны чыгарудан туктатканнар. Ул 1931 елның 9 июленнән башлап, СССР кара металлургиясенең иң эре предприятиеләреннән берсе—Магнитогорск металлургия комбинатын төзүдә катнашкан меңнәрчә татар эшчеләре өчен нәшер ителгән.

1930 елларда татар телендәге күп кенә шәһәр газеталары да чыгудан туктатылган. Алар арасында: «Ленинград эшчесе», Пермьдә—«Ленин юлыннан» һәм «Ударник», Пермь өлкәсе Лысьвада—«Очкын» һәм Чусовойда—«Ударник», Свердловск өлкәсе Красноуральскида—«Бакыр өчен» һәм Надеждинскидә—«Эшче», Чиләбе өлкәсе Златоустта—«Большевиклар сүзе», Төмәндә—«Коммунизмга», шулай ук Украинадагы Горловкада—«Ударник», Енакиевода—«Ударник байрагы», Кадиевкада—«Кадиевка пролетары», Макеевкада—«Күмер ударнигы», Чистяковода—«Күмер өчен» исемле шәһәр күләмле газеталар булган.

Шул ук елларда Башкортстанда, Куйбышев, Пенза, Оренбург, Пермь, Свердловск, Чиләбе, Омск өлкәләрендә, Украина һәм Әзәрбайҗанда татар телендәге 30дан артык район газеталары да чыгудан туктаган.

Ябылган күп тиражлы газеталарның саны 50дән арткан. Шулар арасында: Мәскәүдә нәшер ителгән «Метрострой ударнигы», «Метрострой коммунисты», «Мартеновка», «Можрез ударнигы», «Электросталь ударнигы», төньяк башкаладагы—«Ленинград кызыл портовигы» һәм башка басмалар.

Димәк, 1930 елларда—ябылганчыга кадәр—татар телендәге көндәлек матбугат басмалары Советлар Союзының күмер, нефть, тау-руда, металлургия, химия сәнәгате, транспортның төзелә торган һәм хәрәкәттәге предприятиеләре урнашкан күп регионнарда—Донбасс, Баку, Идел буе, Урал, Себер, Ерак Көнчыгыш, Мәскәү, Мәскәү яны һәм Ленинградта чыгып килгән. Әлеге газета-журналлар татар эшчеләренең илне индустрияләштерүдә актив катнашуы турында сөйлиләр һәм бу мөнәсәбәттән фәнни тикшеренүләр өчен әһәмиятле чыганак булып хезмәт итә алалар. Дистәләрчә-дистәләрчә милли матбугат басмаларының чыгудан туктатылуы, аларның укучыларын туган телләрендә мәгълүмат һәм рухи-әхлакый тәрбия алудан мәхрүм иткән. Аларны милләттән биздергән.

1930 елларда, административ-боерыклар буенча ябылган газета-журналлар белән беррәттән, күпсанлы мөхәррирләр, наширләр һәм башка матбугат хезмәткәрләре дә рәхимсез сәяси репрессияләргә дучар ителгән. Тоталитар золым корбаннары арасында татар журналистларыннан: Агиев Фәхрелислам (1887-1938), Атнагулов Сәләх (1893-1937), Бикколов Ибраһим (1884-1938), Гыйсмәти Габдулла (1883-1938), Кәрими Фатих (1870-1937), Кушаев Гобәйдулла (1902-1937), Насыйри Имай (1898-1942), Нигъмәти Галимҗан (1897-1941), Рәмзи Шакир (1898-1937), Рәхмәтуллин Исхак (1897-1937), Сәгыйдев Габделкәрим (1888-1939), Сәйфи-Казанлы Фатих (1888-1937), Фәхретдинев Габдрахман (1887-1937), Хәлим Ягъкуб (1877-1938), Шәфигуллин Вәли (1894-1939), Йосыпов Муса (1896-1937) һәм башка бик күпләр бар.

Әйе, Рәсәй патшаларының чын йөзе 1930 елларда аеруча ачык күренде.

**Талгат НАСЫЙРОВ,**
*тарих фәннәре кандидаты, доцент.*

# ТӨРЕК-ТАТАР ӘДӘБИ БАГЛАНЫШЛАРЫ

Дөнья әдәбиятлары тарихында әле бер халыкның, әле икенчесенең төрле казанышлары әйдәүче көчкә әверелә. Нинди дә булса бер әдәбиятның көчәюе һәм башка әдәбиятларга тәэсир ясавына карамастан, әлеге бәйләнешләрнең ике яклы, катлаулы күренеш булуын кире кагып булмый. Әдәбиятыбыз һәм сәнгатебез, иҗтимагый аң үсешебез турында сөйлибез икән, төрек һәм татар халкы арасында булган багланышларның әһәмиятенә дә игътибар итми кала алмыйбыз.

XIX гасырның икенче яртысында үсә башлаган төрек драматургиясе вәкилләре Шәмсетдин Сами (1850-1904), Әбүззыя Тәүфикъ (1848-1913), Рәджанзадә Мәхмүд Әкрәм (1847-1914), Әхмәд Мидхәт (1844-1912), Самипашазадә Сәзаи (1858-1936) һәм башкаларның әсәрләрендә без төрле әдәби юнәлешләрнең, стиль һәм жанрларның үзара үрелешен күрәбез. Классицизм дигән иҗат методына буйсынган трагедияләр һәм романтик драмалар (Г. Хәмиднең «Сәйди Яхъя» (1875), Ш. Саминең «Гавә» (1877)) белән берлектә мещаннар тормышын яктырткан тормыш-көнкүреш драмалары да үсеш ала. Төрек драматургиясе әле яралган гына чорда авторлар күбрәк тарихи пьесалар иҗат итәләр, әсәрләр тарихи яки легендар сюжетка корыла. Г. Хәмид һәм Ш. Саминең алдарак аталган пьесалары да әнә шундыйлардан. Әлеге әсәрләрдә социаль тигезсезлек, гаиләләрдәге таркаулык, гаделсезлек, кешенең хис-кичерешләре белән санлашмау кебек мәсьәләләр күтәрелә. Мәгълүм ки, конфликтның чишелеше дә трагик төс ала: бер-берсен яраткан кыз белән егет үз-үзләрен үтерә. Н.Кямалның «Кызганыч бала» (1873), Ә. Тәүфикъның «Каргышлы үлем» (1873), Р. М. Әкрәмнең «Вуслет яки кыска вакытлы шатлык» (1875) пьесаларындагы ерак Көнчыгыштан килә торган сюжет алга таба татар драматургларының әсәрләренә дә күчә.

XIX гасырның житмешенче елларында исә төрек драматургиясендә сәяси янгырашлы романтик драма өстенлек итә. Әлеге жанрда иң күп эшләгән Н. Кямал да, Ш. Сами, Р. М.Әкрәм, Ә. Тәүфикъ та үз әсәрләрендә идеал—унай герой тудырырга тырышалар, аны гади халык арасыннан эзлиләр. Мәсәлән, Ш. Саминең 1875 елда язылган «Бәя яки антка тугрылык» пьесасы шундыйлардан. Әлеге омтылыш күпмедер дәрәҗәдә Көнбатыш Европа классикларының әсәрләрен тәрҗемә итү, аларчарак язуга булган омтылыштан да килә. Шул рәвешле, Р.М.Әкрәмнең «Атала» (Шатобрианның «Атала» повесте буенча) пьесасы, Ә.Тәүфикъның «Гашыйк кыз яки эчкерсез мәхәббәт» (Гюгоның «Анджело» әсәренең ирекле тәрҗемәсе) һәм башкалар иҗат ителә.

Нәкъ шушы елларда француз әдәбияты йогынтысында мөстәкыйль жанр буларак мелодрама барлыкка килә. Ибраһим Шинасиның «Шагыйрьнең өйләнүе» әсәре белән башланып киткән милли комедия унышлы гына үсә башлый. Халыкчан, сәяси жирлеккә корылган комедияләрдә миллилек үзен шактый көчле сиздерә, аларда яшерен уен-тамашалары белән мәгълүм «Карагөз» һәм «Урта уены» театрларына хас гадилек ярылып ята. Ә әлеге халык театрларының уеннарында итальян сәхнә сәнгатенә хас алымнарны күрергә була. Мәсәлән, уйнаучыларның төрле битлекләр киюе, шамакайлык, импровизация һәм башкалар.

Тәүге комедияләрнең тууына, әлбәттә, француз драматургы Мольерның пьесаларын тәрҗемә итү этәргеч бирә. Бу эшкә беренчеләрдән булып тарихчы һәм театр эшлеклесе Әхмәд Вакыйф-паша (1823-1891) алына һәм төрек теленә

Мольерның уналты пьесасын тәрҗемә итә. Бу төрек театрының оешып китүенә дә сәбәп була. Бер-бер артлы Али бәйнен «Куып җибәрелгән кунак» (1871), «Күп сөйләшә торган сакал кыручы» (1873), Хәмди бәйнен «Ике карбыз бер култык астына сыймый» (1871), Р.М.Әкрәмнен «Күп белгән күп ялгыша» (1875) кебек оригиналь комедияләре языла башлый. Җинел рухлы әлеге пьесалар күп очракта мәгърифәтчел төсмердә.

Драматургиянең төрле жанрларында эшләгән Габделхак Хәмиднен әсәрләре дә мәгърифәтчелек реализмы кысаларында языла. «Хисчән кыз» дигән (1875) социаль-көнкүреш драмасында ул хатын-кызның җәмгыятьтә ир-атлар белән тигез хокуклы булырга тиешлеген проблема дәрәҗәсенә күтәрә, «Нәстерен» (1876) сәяси трагедиясенең идеясен колбиләүчелеккә каршы чыгуга, кешеләрнен үзара тигез хокукларга ия булырга тиешлеген раслауга кора. Аллегориягә нигезләнгән «Либертә» (1876) шигъри драмасында исә Колбиләүче тарафыннан зинданга ябылган Ирек, Либерал ярдәмендә аннан котылып, сөйгән халкына ашыга, халкының ирекка чыгачагына нык ышана.

Көнбатыш Европа әдәбиятына йөз тоткан Г. Хәмид үзенең сәяси трагедияләрен француз классицизмына, төгәлрәк итеп әйткәндә, Расин һәм Корнель әсәрләренә яраклаштырыбрак яза. Әлеге әдипләрнең сюжет кору, әсәрнең идеясен булдыру, сәнгать чараларыннан оста файдалану тәҗрибәсенә таяну төрек драматургиясенең формалашу чорында әһәмиятле фактор була. Чит ил драматургларының, бигрәк тә француз язучыларының әсәрләрен укып, төрек әдипләре бер-бер артлы оригиналь пьесалар иҗат итә башлыйлар.

Мәсәлән, Н. Кямал драматургиясендә, төрекләрнең милли карашлары белән Европа әдәбиятларына хас мәгърифәтчелек идеяләре тыгыз бәйләнештә бирелә. Төрек сәхнә әдәбиятына нигез салучыларның берсе буларак, ул Ж. Ж. Руссо, Монтескье, К. Ф. Вольней кебек әдипләрнең фикерләрен уздыра. Төрек язучыларының традицион алымнарын, традицион халык уеннарын, ягъни халык театрын кире кагып, дөнья әдәбияты орбитасына тартылырга чакыра. Шул рәвешле, төрек сүз сәнгатенә Европа мәгърифәтчелек әдәбиятына хас фикерләр үтеп керә.

Н.Кямал алты пьеса иҗат итә. Әлеге әсәрләр күбрәк романтик драма жанрына тартым. 1873 елда язылган тәүге пьесасы «Ватан яки Силистра»да 1828-1829 елларда барган рус-төрек сугышы тасвирлана. Ул патриотик идеяләр белән сугарылган. Төп герое—төрек армиясе офицеры, символик исем белән аталган Ислам бәй. Автор аның аша укучы-тамашачыны үз карашлары белән таныштыра, туган төбәгенә дан җырлый.

1873 елда иҗат ителгән «Зәваллы чожык» («Кызганыч бала») драмасында хатын-кыз азатлыгы, көчләп кияүгә бирү, балаларның һәрдаим иске карашлы ата-ананың басымы астында яшәргә тиешлеге кебек мәсьәләләрне яктырта, «Гөлнихәл» (1875) әсәрендә исә идарәче һәм гади халык арасындагы конфликтны ачып бирә.

«Хәрәзм шаһы Җәләлетдин» (1882) тарихи драмасын Н.Кямал XIII гасыр вакыйгаларына—Чыңгыз ханның Урта Азиягә яу чабуына—бәйле фактларга нигезли. Ләкин биредә дә заман өчен әһәмиятле булган проблемалар күзлегеннән карап эш итә, бары тик белемле җитәкче генә идарә системасын тиешле дәрәҗәдә оештыра һәм туган халкын чит-ятларның һөҗүменнән саклап кала ала дигән фикер уздыра.

Бер-бер артлы иҗат ителгән әлеге драмалар театр сәхнәсендә даими уйнала башлый. 1868 елда оешкан беренче профессиональ төрек театрының тарихы шактый кызыклы. Европа әдәбияты һәм сәнгате үрнәкләренә тартылган төрек зыялыларын моңа кадәр эшләп килгән «Карагөз», «Урта уены» халык театрлары канәгатьләндерми башлый. Яңа идеяләр белән сугарылган европачыл театрның барлыкка килүе дә шуның белән аңлатыла. 1830 елларда Франция, Италиядән килгән театр труппалары һәм җирле әрмәннәр Истанбул шәһәрендә Европа драматургларының берничә әсәрен сәхнәләштерә. 1840 елда европалылар һәм заманча карашлы җирле зыялылар өчен концертлар, балет һәм спектакльләр куелуы мәгълүм.

1845 елда Истанбулда әрмән театры ачыла. Оештыручы исеме белән атап, төрек халкы аны «Наум театрысы» (Наум исеменнән алынган) дип йөртә. Бу театрда спектакльләр Европа халыклары телләрендә куела. Аны оештыруда төп вазифаны

әрмән драматурглары һәм театр әһелләре башкара. Бирегә төрек һәвәскәрләре дә тартыла. Театрда төрекләр өчен үз милли телләрендә, Европа авторларының әсәрләренә нигезләнеп, спектакльләр куела башлагач, хатын-кыз рольләрен йә иратлар, йә мөселман диненнән булмаган хатын-кыз артистлар уйный. Төрек телендә күбрәк француз һәм итальян авторларының пьесалары сәхнәләштерелә. Бу, үз чиратында, милли драматургиянең, театрның нәкъ менә француз һәм башка Европа халыклары әдәбиятлары традициясенә нигезләнеп үсеп китүенә бер сәбәп була.

«Төрекләрнең милли вә госманлы дигән театрларында әрмән, грек вә Италия артистлары уйнап, уйнаган нәрсәләре дә халык мәгыйшәтенә аз нисбәтле булган вакытта, безнең Русия татарларының саф милли сәхнәләре мәүҗүд (бар.—Р.Х.), уйналган нәрсәләр халык тормышыннан алынган, вә анларны иҗраэ итүче (уйнаучы, халыкка житкерүче.—Р.Х.) артистлар да татар мәгыйшәтене чын белү белән белгән, чын тану белән таныган гайрәтле яшь зыялыларымыздыр»[1],—дип яза язучы һәм тәржемәче Солтан Рахманколый төрек әдәбияты хакында Истанбулда Гаяз Исхакый тарафыннан бастырылган («Санин» дип аталган газетада) бер мәкаләгә бәйле рәвештә.

Дөрестән дә, төрек театр әдәбияты һәм сәнгате беренче адымнарын француз, итальян һәм башка халыкларның әдәби-мәдәни традицияләренә бәйле рәвештә ясый, Европа стилендә зур үсеш ала. Сәхнә сәнгате шул чорда ил идарәчесе булган Габделмәҗит солтанның да игътибарын җәлеп итә һәм ул 1846 елдан сараена артистларны даими чакыртып тора башлый. Ә 1858 елда исә аның фәрманы буенча Долмабахча сарае (Солтан сарае) янәшәсендә театр бинасы төзелә. Биредә төрек телендә дә спектакльләр уйнала. Төрек телендә куелган тәүге әсәр И. Шинасиның «Шагыйрьнең өйләнүе» дип аталган пьесасы була. Әлеге театр Габделмәҗит солтанның вафатына, ягъни 1861 елга кадәр эшли. Тәхеткә Габделгазиз солтан килгәч, бина хәрби хезмәт вәкилләре кулына күчә. Инде алдарак искәртелгәнчә, профессиональ төрек театры 1868 елда оеша. Ул «Шәрык театрысы» дип атала.

Тарихы ерак гасырларга барып тоташкан фольклор традицияләренә артык зур әһәмият бирмәгән Н. Кямалның пьесалары бу театрда даими уйнала башлый. Үз әсәрләрен реаль вакыйгаларга, тормыш чынбарлыгын ачып бирүгә нигезләгән хәлдә, драматург театрның халыкны аң-белемле итүдә иң файдалы һәм нәтиҗәле күңел ачу чарасы булуын аңлый. Аның идеяләре алга таба безнең татар драматурглары иҗатында да чагыла.

Шулай да төрек әдәбиятына булган игътибар нәрсә белән аңлатыла соң? Төрек сүз сәнгате төрки әдәбиятлар арасында беренчеләрдән булып Көнбатыш Европа эстетик тәҗрибәсен актив үзләштерә башлый, драматургия, проза кебек яңа әдәби төрләргә, жанрларга байый, әдәбият белеменә һәм тәнкыйтькә караган беренче хезмәтләр языла, вакытлы матбугат җанлана, әдәби телне халыкка аңлаешлы итү өчен көрәш кыза; феодаль тәртипләрне, иске культураны тәнкыйтьләү үзәккә куела; ватан, милләт, ирек, хатын-кыз азатлыгы, шагыйрьнең гражданлык бурычы кебек әһәмиятле мәсьәләләр күтәрелә. Шул юнәлештә янару кичергән төрек әдәбияты билгеле күләмдә татар язучыларының игътибарын җәлеп итә[2].

Төрек әдәбиятының үсешенә китергән сәбәпләр арасында чит илләр белән икътисади-сәяси бәйләнешләр иң мөһимнәреннән булса, төрек-татар әдәбиятларының үзара тәэсирендә тел-дин уртаклыгы, гомумтрадицияләр, төрле архетиплар шарт булып тора[3]. Язучыларыбызның төрек әдипләре иҗатына мөрәҗәгать итүе татар әдәбиятын идея-тематик яктан булсын, форма ягыннан, эстетик яктан булсын яңалыкка этәрә, баета. Әлеге өлкәдәге катлаулылык, әдәби бәйләнешнең күпкырлылыгы турында шактый сөйләп була: төрек әдипләренең Европа, бигрәк тә француз әдәбияты үрнәкләрен үзләштерүләре, аларның иҗат

[1] Рахманколый С. Төрек әдәбияты / С.Рахманколый // Гаяз Исхакый: әсәрләр: 15 томда. – Казан: Татар.кит.нәшр.,2001. – 8том.

[2] Ганиева Р. Көнчыгыш традицияләрен үстереп / Р.Ганиева // Татар әдәбияты тарихы. XX гасыр башы татар әдәбияты: 6 томда. – Казан: Татар.кит.нәшр.,1986. – 3 том. – Б.530.

[3] Харрасова Р. Әдәби бәйләнешләр яктылыгында / Р.Харрасова. – Казан: «РПФ «Гарт», 2002. – Б.6-7.

үзенчәлекләреннән файдаланулары, татар язучыларының төрек әдипләре язганнарга ияргә, шунын аша Европа әдәби үрнәкләренә якынаюы, ә бу очракта төрекләрнең арадашчы вазифаларын үтәве һәм башкалар.

Татар әдипләренең төрек әдәбиятына тартылуы мәгърифәтчелек идеологиясенең милләт өчен зур мөмкинлекләр вәгъдә итүенә дә бәйле. Гасырлар буе формалашкан эстетик нормалар инде әкренләп үзгәреш кичерә, аларны яңалары алмаштыра. Хатын-кызның ир-атлар белән тигез хокукка ия булырга тиешлеге, заманча тәрбия һәм дөньяви белем һәр кешенен камиллеккә, бәхеткә ирешүендәге беренче әһәмиятле адымы булу, мәдәниятнен, сәнгатьнен туып килә торган беренче чаткыларын үстереп җибәрү, гыйлемгә омтылу һәм фәннәрне өйрәнү халыкның наданлыктан котылуына төп чара икәнлекне алга сөрү әнә шундыйлардан. Үсешкә омтылган татар әдәбияты өчен нәкъ менә шулар кирәк була да. Татар зыялылары бу мәсьәләләрдә күп яктан төрек әдәбиятын үзләренә үрнәк итеп куялар. «Без бервакыт госманлы әдәбиятына шәкерт идек. Ул вакыт бездә госманлы тәэсире бар иде»[4],—ди Г.Ибраһимов.

XX гасыр башында Төркия зыялылары Госманлы империясен җөмһүрият буларак ныгыту, Төркия дәүләте чикләреннән тышта калган төрки кавемнәрне ят халыклар йогынтысыннан саклап калу идеяләрен алга сөрәләр, әлеге юнәлештә зур эшчәнлек алып баралар. Тугандаш халыкның фикерләренә кушылып, татар әдипләре дә төрки кавемнәрне европалаштыру, аларны империалистлар тарафыннан изелүдән коткару, мәгариф-тәрбия челтәрен яңарту программаларын һәм чараларын тикшерү юнәлешендә эш башлыйлар.

1913 елның мартында Фатыйх Кәримигә язган хатында Галимҗан Ибраһимов Төркиядә яшәүче зыялы милләттәшләребезнең татар халкына кызыклы, ә язучы-әдипләренә үрнәк булырдай әдәбияты турында күбрәк сөйләмәүләре өчен борчыла. Ф.Кәриминең элегрәк матбугатта басылган мәкаләләренә бәйле рәвештә, ул болай ди: «Татар журнализмысында бөтенләй яңа, бөтенләй башка төстә килеп чыккан ул мәктүбләренез җан ачлыгы белән укылдыгы хәлдә, күңел сездән тагын бер нәрсә көтә иде. Әйтәчәгем—төрек әдәбияты мәсьәләседер. Сез аңа бик аз урын бирдеңез. Сәбәбе ачык. Әхвәле мәмләкәт язмышы (дәүләт язмышы хәлләре) хәл ителәчәк бер ноктага житкәндә, әллә кем шагыйрьләр тугрысында тәфсыйләт сөйләп утыру ятрак булыр иде. Шулай да без һаман сездән, әдәбиятчы улмагыңыз сыйфатыннан, ул хакта бер сүз көтәбез.

Истанбулда ни чаклы шәкерт укый. Йосыф әфәнде (сүз Йосыф Акчура турында бара.—Р. Х.) ничә еллар анда яши, шунда ук М. Гаяз әфәнде барды, ләкин һичбере шул матур, шул нәфис әдәбиятны авызга алмады һәм алмый. Хәлбуки Фөзүли (Фөзүли Мөхәммәт—атаклы әзәрбайҗан шагыйре.—Р. Х.) вә Кәмальләре (Нәмык Кямал—төрек язучысы, атаклы драматург.—Р. Х.)... Габделхак Хәмид (күренекле төрек драматургы.—Р. Х.), Әкрәм (танылган төрек шагыйре, пьесалар авторы.—Р. Х.), Халид Зыя (Ушаклыгөл—танылган төрек язучысы, төрек әдәбиятында роман жанрын нигезләүчеләрнең берсе.—Р. Х.) һәм Тәүфикълары (Тәүфикъ Фикрәт—төрек поэзиясе вәкиле.—Р. Х.) булган ул әдәбиятта безем татар өчен бик күп гыйбрәтләр, бик күп нәмүнә (үрнәк.—Р. Х.) вә хәзинәләр бардыр»[5].

Шуннан соң ул күптән түгел генә Габделхак Хәмиднең трагедияләре белән танышып чыгуын әйтә. Аның 1886 елда шигырь һәм проза белән язылган «Зәйнәб» драмасын җентекләп укыганнан соң, Ф. Кәримидән шул зат хакында «тәфсыйль өмид иткәнлеген әйтеп», элегрәк тә бер хат язганлыгын белдерә. «Вакыйган, мин ул куәт алдында хәйранмын,—ди Г. Ибраһимов.—Ул трагедияләр яза. Ләкин иң зур трагедия аның үзендә, үз язмышында. Ул төрек галәмендә төрек угылы булып туган, менә шул аны Шекспир, Шиллер, Гетелар белән беррәттән алырга тиеш булган урынынннан мәхрүм итә. Мин рус әдәбиятында да моңа тиң шәхесне күрмим. «Нәмидә» («Бәхетсез»—Халид Зыяның 1891 елда басылган романы.—Р.Х.), «Фәрди вә шөрәкясе» (Халид Зыяның 1884 елда чыккан романы.—Р.Х.) кебек нәфис, «Мави вә сияһ» («Зәңгәр вә кара»—Халид Зыяның 1897 елда чыккан романы.—Р. Х.)

---

[4] Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда / Г.Ибраһимов. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1978. – 5 том. – Б.231.

[5] Ибраһимов Галимҗан: хатлар һәм документлар. – Казан: Фикер,2000. – Б.71-72.

хикәяләр кебек назик әсәрләр тудырган Гошшакый Задә (төрек суфи шагыйре.—Р. Х.) Халид Зыя бәк, Нәжад Әкрәм (төрек әдәбиятында тәнкыйди реализм методын нигезләүчеләрнең берсе, көчле сатирик.—Р. Х.) белән хатимәләнгән (тәмамланган.—Р. Х.) әшгаре сәхибе (шигырьләр иясе.—Р. Х.) безем өчен, безем әдәбияттан мужик чабатасы күренеп торуын эзләгән тупас натуралистларымыз өчен бөек тәэсир итә белерләр иде. (Шунда ук.—Б.72-73.)

Әдип, теле татар халкына аңлашылып бетмәсә дә, күренеп торган ниндидер кимчелекләре булса да, «бөтенләй читкә ташланган» шул әдәбиятның безнең милли сүз сәнгатебезнең үсеше өчен әһәмиятле булуын аңлый. «Ул косурын (кимчелекләрне.—Р. Х.) игътираф илә бәрабәр (тану белән бергә.—Р. Х.) татар андагы сәнгатькә, андагы нәфасәткә (нәфислеккә.—Р. Х.) ирешергә бик ерак төсле күренә. Төрек әдәбияты диләр дә, кул селкәләр, хәлбуки, бу—балалык. Берничә косуры (кимчелеге.—Р. Х.) өчен бөтен шәйне инкярдыр (бөтен нәрсәне юкка чыгарудыр.—Р. Х.). Шуның белән көрәш башлансын иде»,—дип яза ул әлеге хатта.—«Төрек әдәбиятына хәсрәтем әдәбиятка мотлак (ничек кенә булмасын.—Р. Х.) рус народниклары күзе илә карауны (народниклар әдәбиятны революцион идеяләрне пропагандалауда куәтле чара итеп бәялиләр. Г. Ибраһимов төрек әдәбиятында да шуңа якын караш урнаштыру ягында тора.—Р. Х.) бераз игътидальгә (урта дәрәҗәгә.—Р. Х.) китермәсме дигән өмидемнәндер». (Шунда ук.)

Әлеге хаттан күренгәнчә, Төркиядә барган сәяси реформалар, мәгърифәтчелек идеяләрен тормышка ашыра башлау һәм башка үзгәрешләр биредә яшәгән татар зыялыларын да читтә калдырмый. Ләкин Төрек әдәби процессын татарларга тәфсилләп язылган мәкаләләр сирәгәя (әле ул мона кадәр дә күп булмый, XIX гасырның икенче яртысында әдәбиятлар үзара бәйләнышка ныклап керешә генә башлый). Болар, әлбәттә, Г. Ибраһимовны борчуга сала. Ул мона берникадәр аптырый да әле. Татар зыялыларының, татар халкына төрек әдәби әсәрләрен шәрехләп утырмыйча, сәяси процессларга катышып йөрүе аны гаҗәпкә сала. Ләкин әлеге чор (XIX йөз ахыры) татарлар һәм төрекләрнең уртак максат-бурычлары билгеләнү белән әһәмиятле. Бу, иң беренче чиратта, мәгариф һәм мәдәният, рухи тормыш кебек өлкәләргә карый: «фикердә һәм гамәлдә урта гасырлар торгынлыгыннан котылу, ислам динен, яшәеш фәлсәфәсен искергән төшенчәләрдән арындыру, дөньяви белем алу һәм кәсеп итүдә Европаның алдынгы халыкларына ияру». (Әйди Т. Хәзинәләр уртак / Т.Әйди // Казан утлары.—1993.—№ 11. )

Дөрес, җәмгыятьтәге, гомумән, яшәештәге һәр үзгәреш, һәр яңалык төрле киртәләргә, каршылыкларга очрамый калмый. Шулай булмаса, аның кыйммәте, бәясе дә бик түбән булыр иде. XIX гасырның икенче яртысы—XX йөз башларында формалашкан иҗтимагый фикер үсеше дә гади халык тарафыннан шактый зур шикләнүләр аша, саклык белән үзләштерелә башлый. Бу исә, үз чиратында, җәдитчелек дип аталган мәгариф һәм мәдәни хәрәкәт барлыкка килүгә, аның кадимчелеккә каршы кискен көрәшенә китерә. Җәдитчеләр үз максатларына ирешү юлында һәм Европа, һәм Шәрык мәгърифәтчелеге ирешкәннәрне һәр өлкәдә үрнәк итеп файдалана. Укымышлы, алдынгы карашлы милләтпәрвәрләр тәрәккыятьне милли сәясәт дәрәҗәсенә күтәрә. «Идеология уздыруның бер чарасы булган матур әдәбиятка да иҗтимагый хәлләр үз эзен сала»[6]. Иҗат дөньясына килеп кергән мәгърифәтчелек реализмы методы алгарыш өчен җәмгыятьтә барган көрәш белән, һичшиксез, бәйле була.

Дөнья әдәбиятлары контекстында карасак, мәгърифәтчелек реализмы баскычына төрки әдәбиятлар бер гасыр чамасы соңрак баса. Реалистик сәнгатьне үстерү максатыннан, аларның үзләренә әзер өлге булган Көнбатыш әдәбиятларны өйрәнүе дә шуның белән бәйле.

Төрек-татар бәйләнешләре хакында сүз йөрткәндә, шуны истән чыгарырга ярамый: Төркиянең иҗтимагый үсеш-үзгәреш даирәсендә татарларның тоткан урыны зур. Билгеле булганча, иҗтимагый-сәяси шартларга бәйле рәвештә, XIX гасырның соңгы чирегендә татарлар күпләп Истанбул шәһәренә күчә. 1890 елларда Төркиягә илле меңләп татар күчеп китүе мәгълүм. Аларның бер өлеше төрле михнәт-

[6] Нуруллин И.З. Реализм турында / И.З.Нуруллин. – Казан: Татар.кит.нәшр.,1974. – Б.10.

афәтләрдән юлда вафат була, икенче өлеше кире борылып кайта, әмма күпчелеге изге дип саналган Госманлы жиренә барып житә һәм шунда тамырланып яши башлый, әлеге төбәктә яшәүче җирле халыкны үзенең гореф-гадәтләре, әдәбияты-мәдәнияте белән якыннан таныштыра. Шулай ук 1905-1907, 1917 елгы инкыйлаблардан соң да, икенче Бөтендөнья сугышыннан соң да (мәсәлән, Ерак Көнчыгыш һәм Германия татарларының Төркиягә күчеп килүе мәгълүм) татарлар Төркиягә күпләп күчә. Әнә шулай төрек-татар багланышлары тагын да киная, рухи хәзинәләр, тормыш тәҗрибәсе алмашу, үзара аңлашу һәм дуслашу яңа баскычка күтәрелә.

Күренекле татар язучысы, җәмәгать эшлеклесе Ф.Кәриминең төрек язучысы Ә.Мидхәт белән иҗади бәйләнештә торуы, бу танышлыкның Ф.Кәрими Төркиягә киткәнче үк булганлыгы мәгълүм. Алар күпмедер хат алышалар. Бер хатында Ә.Мидхәт Ф.Кәрими сораткан газеталарны җибәрүен хәбәр итә һәм татарларны белемгә-укуга, чит телләр өйрәнүгә омтылышлары булмауда гаепли. Рус ориенталистлары исламнан курыкмаган заманда, христианлыктан өркеп, татарларның рус мәктәпләренә укырга кермәвенә гаҗәпләнә. Ул татар яшьләренә башка халыкларда булган мөмкинлекләрдән файдаланырга киңәш итә.

Әлеге хатлардагы киңәш-тәкъдимнәр, ике халык (татар белән төрек) арасындагы уртак һәм аермалы якларны билгеләү Ә.Мидхәт белән Ф.Кәрими арасында барлыкка килгән туганнарча якын мөнәсәбәтләргә сәбәп була.

1892 елда Ф.Кәрими, Истанбулга күчеп килгәч, Төркиянең иң алдынгы уку йортларыннан саналган «Мөлкияи гали мәктәбе»нә укырга керә. Биредә дүрт ел гыйлем туплый, төрек һәм француз телләрен, әдәбиятларын өйрәнә. Бу исә, үз чиратында, аның иҗатында төрек, француз һәм алар аша башка Европа халыклары әдәбиятларында кулланылган алым-чараларның, мотивларның чагылуына китерә. Мәсәлән, «Салих бабайның өйләнүе» әсәрендә кулланган чегәннәрнең жыйма образын Ә.Мидхәтнең «Ченкәнә» исемле хикәясеннән алуын Ф.Кәрими сюжет барышында ук искәртә.

Шунысы кызык: Ф.Кәрими дә, исемнәре алдарак аталган башка бик күп язучы-әдипләребез кебек, Төркиядә гыйлем эстәп һәм нәрсәгәдер өйрәнеп кенә калмый, мәгариф эшләрен оештыру, программа һәм укыту планнарын яңарту, яңа кулланмалар, дәреслекләр төзү эшләре белән дә кызыксына, үзе дә катнаша. Төркиядән кайткач, ул Ә.Мидхәтнең «Белгеч кыз» һәм шулай ук төрек язучысы Ш.Саминең «Хатыннар» дигән әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итеп бастыра.

Татар милли драматургиясенә нигез салучыларның берсе булган Г. Камал да үзенең сәхнә әдәбияты өлкәсендәге тәүге адымнарын төрекчәдән тәрҗемә белән башлый. Ул Н. Кямалның «Зәваллы чоҗык» драмасын «Кызганыч бала» исеме астында тәрҗемә итә. «Рус теле нечкәлекләрен белүе чиклерәк бер вакытта, аның өчен төрек әдәбияты—зур байлык. Н. Кямалның «Зәваллы чоҗык» китабы булачак классик драматургны кузгатып җибәрә»[7]. Әлеге драма әсәрен кулына төшергәч, ни дәрәҗәдә шатлануын Г.Камал үзе болайрак тасвирлый: «Нинди зур байлык!.. Аны кат-кат укыйм, аңлыйм. Нәкъ шул вакытларда минем үземнең башымда да бер тема йөри. Н. Кямалның китабы мине кузгатып җибәрә дә мин үзем уйлап йөргән «Бәхетсез егет» дигән нәрсәмнең беренче редакциясен язып, укытучым Миргаяз Иманаевка күрсәтәм, ул бик күтәреп каршы ала да, китапның артына берничә юллык «Кыйссадан хыйсса» язып, Петербургка цензурага җибәрә»[8]. Г. Камалны бу чорда төрек һәм Европа әдәбиятларында хакимлек иткән революцион-демократик идеяләр, гуманистик юнәлеш, мәгърифәтчел рух җәлеп итә. Ул алар аша татар халкының теләк-омтылышларына җавап таба.

Г. Камал тәрҗемәләре—катлаулы әдәби-эстетик күренеш. Фәндә расланганча, татар драматургиясендә беренчеләрдән булып тәрҗемәчелекне ул башлап җибәрә. Утызынчы елларга кадәр чорны үз эченә алган бу зур әдәби эшчәнлек татар театры һәм тамашачыларының шул чорлардагы эстетик таләпләре, зәвыклары белән тыгыз бәйләнештә бара. Татар милли сәхнә әдәбиятына һәм сәнгатенә нигез салучыларның

[7] Ханзафаров Н. Г.Камал—тәрҗемәче / Н.Ханзафаров // Галиәсгар Камал. Язучының 100 еллыгына багышланган мәкаләләр җыентыгы. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1981. – Б.135.

[8] Камал Г. Әсәрләр: Шигырьләр,проза һәм публицистика: 2 томда / Г. Камал. – Казан: Таттосиздат,1951. – 2 том.

берсе буларак, Г. Камал театр алдына житди тәрбияви бурычлар куя. Ул аны вакыт уздыру, күңел ачу урыны, «кәмит» дип карауучыларга катгый җавап бирә: «Дөрес, менә ат кәмитләренә баруны бик мактап булмый, анда биргән акча җилгә (бушка) китә дисәң дә ярый, чөнки анда, көлкедән башка, вәгазьләнерлек һич гыйбрәт булмый! Театрга биргән акчаларыбыз исә җилгә китми, анда җыелган акча белән фәкыйрьләрне, мәктәп вә мәдрәсәләрне тәрбия кылалар»[9],—ди ул.

Күргәнебезчә, Г. Камалның үз иҗаты шушы карашлар нигезендә башланып китә. Ул бер-бер артлы «Бәхетсез егет», «Өч бәдбәхет» исемле пьесалар яза. Драматург иҗатының башлангыч чорын чагылдырган бу әсәрләрнең сәнгатьчә эшләнеше бик үк камил түгел. Әмма аларда XX йөз башындагы яшәеш өчен гаять актуаль мәсьәләләр—«кеше язмышы, шәхес белән патриархаль тормыш арасындагы каршылык, аталар һәм балалар проблемасы, гаилә тәрбиясе белән яңа заман таләпләре арасында туган конфликт һәм башка проблемалар»[10] күтәрелә. Шунысы игътибарга лаек: Г. Камал, әле иҗат тәҗрибәсе булмавы нык сизелүгә карамастан, күп кенә мәсьәләләрдә, алган вакыйгалар, аларны ничек күрсәтү, конфликтларны ничек хәл итү өлкәсендә яңа юлга баса. Бирелә гел бәхетле тәмамлана торган финаллар да юк, тискәре типларның көтмәгәндә уңайга үзгәреп китүләре дә күренми. Әсәрләрендә тормышның катлаулылыгы, драматизмы чагыла, уңай геройларның характеры да башка[11].

Дөрес, шактый ук житлегеп килә торган татар театры көчләренә бәйле рәвештә, Г.Камалның тәрҗемә әсәрләренә, шул исәптән, үзе иҗат иткән пьесаларга да таләбе үзгәрә, үсә төшә. Моны без, төрек авторлары әсәрләреннән аермалы буларак, диалоглардагы һәм монологлардагы озынлыкны киметүе, шуңа бәйле рәвештә, әсәрдәге вакыйгалар алмашын җанландыруга, эчке агымны, хәрәкәтне көчәйтүгә ирешүе аша да күрәбез.

Г. Камал үзенең тәрҗемәләренең сыйфатына беркайчан да битараф түгел. Аның «тәрҗемәләре, тулаем алганда, заман таләпләрен канәгатьләндерерлек дәрәҗәдә эшләнгәннәр. Әдип тәрҗемәләрдә мәгънә төгәллегенә омтылып эш итә»[12]. Татар укучысы өчен таныш булмаган тәгъбирләрне ул әсәренең теленә кертмәскә тырыша. Аларны тиешле синонимик, фразеологик формалар белән алмаштыра. Бу исә, үз чиратында, әсәрне халыкка тагын да якынайта, аны үз милләте турында әйтелгән сүз итеп кабул итәргә тулы мөмкинлек бирә. Шул ук вакытта тәрҗемә әсәрләренең персонажлары үзләренә генә хас сөйләм үзенчәлекләрен дә югалтмыйлар, алар хәтта тагын да камилләштерелә төшә. Ә бу автор өчен һәр образының үз телен булдыруда әһәмиятле бер фактор булып тора. Дөрестән дә, Г. Камалның персонажлары үткен, табигый телдә сөйләшүләре белән күп кенә язучы-әдипләрнекеннән аерыла.

Төрек-татар әдәби багланышлары турында сөйләгәндә, Н. Кямал иҗатының башка татар әдипләренә ясаган йогынтысы турында да искәртү мөһим. Мәсәлән, Г.Исхакыйның «Алдым-бирдем» драмасында Хәлил байның, «Зәваллы чожык»тагы кебек, хатыны Гарифәне үз кызларын көчләп кияүгә бирү уеннан кайтарырга теләве, Гарифә һәм Таһирә образларының булачак бай кияүләренә мөнәсәбәте һәм башка кайбер хәл-әхвалләр шул турыда сөйли.

М. Фәйзинең «Кызганыч», «Галиябану» кебек әсәрләре туура да «Зәваллы чожык» драмасының билгеле бер роль уйнавы күренә. Мәсәлән, конфликт уртаклыгы, каршылыкларның чишелү рәвеше, ягъни пьесаларның фаҗига белән тәмамлануы, Галиябануның да, «Зәваллы чожык»тагы Шафиканың Ата бәй белән хушлашуын хәтерләтеп, сөйгәне Хәлилдән аерылуы һәм башкалар менә дәлил булып тора. М. Фәйзинең «Кызганыч» драмасының исеме үк Н. Кямал әсәреннән алынуы ачык аңлашыла. Әсәрләрдә, конфликт охшашлыгыннан кала, геройларның сурәтләнешендәге сентиментальлек, романтик алымнар, саф сөю, йомгактагы

[9] Камал Г. Әсәрләр: Пьесалар: 3 томда / Г. Камал. Татар. кит. нәшр., 1978. – 1 том.

[10] Хәсәнов М. Татар драматургиясенә һәм театрына нигез салучы / М.Хәсәнов // Галиәсгар Камал. Язучының 100 еллыгына багышланган мәкаләләр җыентыгы. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1981. – Б.98-99.

[11] Мәхмүтов Һ. Октябрьгә кадәрге татар театры / Һ.Мәхмүтов, И.Илялова, Б.Гыйззәт. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1988. – Б.25.

[12] Ханзафаров Н. Г.Камал – тәрҗемәче / Н.Ханзафаров // Галиәсгар Камал. Язучының 100 еллыгына багышланган мәкаләләр җыентыгы. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1981. – Б.135.

вакыйгаларның катлауалануы, мажаралылык—һәммәсе уртаклыкларның көчле булуын күрсәтә.

Күргәнебезчә, Н.Кямал иҗаты татар әдипләренә, бигрәк тә Г.Камалга йогынты ясый. Төрек язучысының әсәрләре аның иҗат юнәлешен генә билгеләп калмый, ә тулаем татар драматургиясе үсеп китүгә, милли театрыбыз беренче адымнарын ясауга этәргеч була. Төрек әдәбияты йогынтысы әсәр атамаларында, конфликт оештыруда, образлар системасын булдыруда, төрле алым-чаралар куллануда, вакыйгаларны укучы-тамашачыларга бер эзлеклелектә, үстерелештә бирүдә һәм башкаларда күренә. Тәүге татар драма әсәрләре Н. Кямал пьесаларына идея-эчтәлек ягыннан охшатып языла.

Татар сәхнә әдәбиятының формалашуы һәм үсеп китүе драматург Г. Камал исеме белән бәйле. Нәкъ менә ул төрек пьесаларын, аеруча төрекләрнең милли карашлары белән Европа әдәбиятларына хас мәгърифәтчелек идеяләренә нигезләнгән Н.Кямал әсәрләрен татарчага тәрҗемә итә, шуна бәйле рәвештә, үз әсәрләрен яза башлый. Аларда тәнкыйди һәм мәгърифәтчелек реализмы, сентиментализм, психологик романтизм кебек иҗат методларының үзенчәлекләре күзәтелә.

Гомумән алганда, XIX гасыр ахыры—XX йөз башында төрек-татар әдәби бәйланышлары үзен шактый көчле сиздерә. Мәгърифәтчелек идеяләре белән сугарылган төрек милли әдәбияты татар зыялыларын һәрдаим үзенә тартып тора. Бу яна идеологиянең милләт өчен зур мөмкинлекләр вәгъдә итүе белән дә аңлатыла. XIX гасыр ахыры—татарларның һәм төрекләрнең уртак максатлары билгеләнгән чор. Бу, иң беренче чиратта, мәгариф һәм мәдәният, рухи тормыш кебек өлкәләргә карый. Урта гасырлардан ук килә торган торгынлыктан котылу, ислам динен, яшәеш кануннарын кадими карашлардан арындыру, дөньяви белем алу һәм кәсеп итүдә европалыларга иярү кебек төшенчәләргә бәйле рәвештә, рус һәм Көнбатыш Европа халыкларының телләрен белмәгән бер чорда әдипләребезнең дөнья әдәбиятыннан күпмедер хәбәрдар төрек язучыларының әдәби үрнәкләре белән азыклануы күзәтелә. Бу, үз чиратында, татар милләтенең мәгарифе үсешенә, әдәбияты һәм сәнгате җанлануга, вакытлы матбугаты барлыкка килүгә этәргеч ясый. Дин уртаклыгы, телләрнең якынлыгы, Төркия дәүләт эшлеклеләренең төрки кардәшләренә һәрдаим теләктәшлек күрсәтүе багланышларның тагын да көчәюенә китерә. Шул ук вакытта татар зыялыларының Төркия һәм төрек милләте, әдәбияты, мәдәнияте, сәнгате, иҗтимагый үсешенә керткән өлешен дә инкарь итәргә ярамый.

Һәрдаим үсештә булган, яңалыкка омтылган татар әдәбияты ике гасыр чигендә үзгәрешләр кичерә. Төрек әдәбиятын үрнәк иткән хәлдә, аның аша Көнбатыш Европа халыкларының традицияләрен, үзенчәлекләрен дә үзләштерә башлый, яңа жанрларга, иҗат методларына байый, яңа жанр формалары аша дөнья мәдәниятләре белән бәйләнешкә керә. Шул рәвешле, татар әдәбиятында тәнкыйди һәм мәгърифәтчелек реализмы, романтизм, сентиментализм кебек иҗат методлары барлыкка килә. Төрек драматургларының классицизм юнәлешендә язылган трагедияләрен, романтик, тарихи һәм тормыш-көнкүреш драмаларын, мелодрамаларын, комедияләрен укып азыкланган татар әдипләре әлеге жанрларга нигез салалар. Бу процесста, әлбәттә, тәрҗемә эшчәнлегенең роле зур була.

XIX гасыр ахыры—татар драматургиясе туган чор. Алдарак күрсәтелгән шартларда тәүге драма әсәрләре, нигездә, төрек әдәбиятыннан тәрҗемә ителә, әмма оригиналь сәхнә әсәрләре тудыруга омтылыш көчәйгәннән-көчәя бара. Шул рәвешле, XX гасыр башында татар драматургиясе зур үсеш ала, беренче спектакльләр куела башлый. Инде 1868 елда ук оешкан төрек театры татар сәхнә сәнгатен булдыруда әһәмиятле вазифа башкара. Төрек театрының оешкан чорларында милли телдә күбрәк француз, итальян авторларының пьесалары уйналу алга таба татар драматургиясе һәм театрында да чагылыш таба.

Төрек-татар әдәби багланышлары кысасында караганда, без татар драматургларының әдәби-эстетик карашларындагы үсеш-үзгәреш закончалыкларын, тенденцияләрен, милли сүз сәнгатенең татар чынбарлыгына якыная баруын, әдәбиятның заман мәсьәләләре белән торган саен ныграк сугарылуын күрәбез.

**Рамил ХАННАНОВ,**
*филология фәннәре кандидаты.*

## «МАТБУГАТ.РУ»ДАН БЕЗНЕ УКЫГЫЗ

**Фәнис Фәтхинең мәшһүр җырчы**
**Фәридә Кудашева белән әңгәмәсе. 2011, ноябрь**

ТНВ каналында Фәридә апаның 88 яшьтә башкарган «Илдарым» җырын тапшырдылар. Тавышы нинди көр янгырый, яшьлек елларындагы шикелле. «Нишләп сәхнәдән шулай иртә китте икән ул?» дигән сорау бер минем генә уема килмәгәндер. Хәзер бит әнә, җырчылар «тамашачыдан аерыла алмыйбыз» дип сәхнә белән унар ел «хушлашып» йөриләр...

*Мансур. Оренбург.*

Китмәде беркая да. Чакырган һәрбер җиргә килә иде. «Ваһапов» фестиваленә дә килеп җырлап китте. Җәй көне теплоходта да килде.

*Мансурга*

Кечкенәдән тыңлап үстем Фәридә апа белән Гөлсем апа Сөләйманова җырларын. Ул заманнарда батарейкалы радиоприемниклар иде. Бу—1950-51 еллар. Фәридә апаның тавышы картайгач та көр, матур—үзгәрмәде. Сагынабыз аны.

*Сагынам*

Фәридә апаның үлгәндә янында бер кашык су каптырырдай кешесе булмавы кызганыч.Үлгән вакытын төгәл белмәүләре дә мәгълүм. Адәм рәтле күршеләре дә булмады микәнни...

*Фәрхәт*

Фәридә Кудашеваның табигатьтән куелган тавыш иде ахры аның.

Кайсы җырын алма, шунысы шедевр. Ул халык җырларын да җырлый иде, композитор җырын да үлмәс сәнгать югарылыгына күтәрде. Алайса, «попса»ны, шоу-бизнес номерларын музыкаль сәнгать дип үтерә яздылар берничә көн элек. Куелмаган тавышлар картая.

*Иркә*

**Разил Вәлиев. «Бәләкәй Разил».**
**2011, ноябрь**

Хикәяләреңне сокланып укыдым. Депутатлыгың да милләткә хезмәт итә. Шулай дәвам ит. Көнчеләргә исен китмәсен.

*Братан*

Бу «бәләкәйләр» бүлеген уйлап тапкан кешегә рәхмәт! Журналның һәр санын шулардан укый башлыйм. Р.Вәлиев хикәяләре дә бик ошады. Мин аны үзем өчен яңа яктан ачтым. Ул чыннан да Алмаз Хәмзин белән бер авылданмыни? Чын булса, Рафаэль Сәхәбиев, Гамил Әсхәдулла, Зөлфәт Хәким дә шул авылдан дип ишеттем. Зөлфәт белән Разил туганнар да икән әле. Бер гади татар авылыннан күпме талант чыккан! Шаккатырлык нәрсә бит бу.

*Искәндәр*

«Манарага менеп әлеге күгәрчен тәрәзәсеннән башны тыгып карасам, мина

күрше авыллар гына түгел, Казан һәм Мәскәү калалары, бөтен дөнья, хәтта Ходай Тәгалә үзе дә күренер сыман иде... ...Ул чакта мин күккә генә ашып калмадым, тәүге кат Аллаһы Тәгаләнең үзе белән очрашкандай булдым...» Бу кадәр көфер сүзләрне ничек язарга була икән? Кечкенәдән манаралы мәчете булган авылда үсеп, яшәп тә иманга килә алмаган кешеләр булыр икән!

*Кактус*

Кактус,син үз каланчаңнан торып фикер йөртәсең. Сүз бит монда алты-жиде яшьлек малай турында бара. Үзеңнең балачагыңны искә төшер әле.Әллә син шул чакта ук бүгенге кебек философ идеңме?

*Искәндәр*

Алмаз Хәмзиннең эссе мунча ләүкәсендә баян уйнап утыруын күз алдына китерәм дә, көлә башлыйм. Рәхәт булып китә шулчак. Мунчада сөйләшүгә житми инде. Мунчада бөтен кеше дә тигезләшә.

*Авыл агае*

Икенче хикәяне укыганда үземнең балачакны искә төшереп көлемсерәп утырдым... Күрше малае белән аның кильки кадәр кипкән балыгына каклаган казүрдәк ите алышулар, күрше кызының маргарин ягылган ипиенә—хәлвә, конфет алышулар дисеңме... Даааааа, ак май ашаган кешегә маргарин житмәгән инде, алдап та торганнар инде мине кечкенә чакта.

*Зиләйлүк*

Бу «бәләкәй» хикәяләрне мәктәп дәреслекләренә кертергә иде.Ул дәреслекләрдә һаман гел бер авторлар, примитив әсәрләр. Шуңа күрә кулга аласы да килми аларны. Әдәбият һәм Туган тел дәреслекләрендә Р.Вәлиевнең һәм мона кадәр чыккан башка авторларның «бәләкәйләрен» бастырсалар, укучыларга да, хәтта укытучыларга да укуы кызык булыр иде. Бик мәгънәле, гыйбрәтле хикәяләр бит. Теле дә балаларга аңлаешлы, гади. Мәгариф министрына бу тәкъдимне житкерсеннәр иде.

*Мин*

**Рәфикъ Юныс. «Фәүзия Бәйрәмова татарга кем тия ул?» 2011, декабрь**

«Казан утлары»—молодцы! Тагын кайсы басмалар котлар, татарның бүгенге иң фидакарь кешесе турында язып чыгар икән? Бу бит матбугат чаралары өчен үзенә күрә бер «проверка на вшивость».

*Исмәгыйль*

Фәүзия ханым бүгенге көндә хакимнәр тарафыннан читкә тибәрелсә дә, татар халкы күнелендә аңа һәйкәл куелды. Аның уңай образы сатлыкжаннар фонында тагын да калкурак күренә. Ул халыкны күтәреп, Мәскәү тозагыннан йолып калучыларның берсе.

*Фәрхәт*

Камал театры кебек затлы бинада татар халкының фидакарь кызы—язучы, тарихчы, җәмәгать эшлеклесе Фәүзия Бәйрәмовага 60 яшь тулу көнен хакимият зурлап үткәрергә тиеш иде. Татарлар өчен зур әһәмияткә ия булган мондый чараны мөмкин булып та оештырмаучыларга ни дияргә инде?!

*Укучы*

Бу тормышта иң авыры—нинди генә язмышларга тарысаң да, һәрчак кеше булып калу, кешечә яшәү! Ә аның иң мактаулысы—үз халкыңа, милләтенә хезмәт кылып, аз гына булса да аны алга этәрү, югарыга, бөеклеккә күтәрү. Фәүзия апай, дәүләтсез калган халык баласы булса да, иң бәхетле кешедер. Чөнки ул—сынмаган, сыгылмаган, Аллаһы Тәгаләдән башка беркемгә дә сыгынмаган милләтче, сәясәтче—һәрдаим үз халкын яклаучыдыр.

Без яшәргә мәҗбүр ителгән кешелексез дәүләтнең юкка чыгып, аның нигезендә һәр милләткә дә үз теләгәнчә яшәү мөмкинлеге туачагына ышану һәм шуның өчен

гадел көрәш сафына басу—Фәүзия апай өчен зур бүләктер.

«Казан утлары» журналына вә «Матбугат»ка Фәүзия апайны котлау мөмкинлеге тудырулары өчен зур рәхмәт!

*Нурулла Гариф*

Бөтен татар матбугатын алып укыдым бу атнаныкын: Фәүзия апа турында ләм-мим, өстән указание кетәләрдер инде. Безнең язганнарны укып баксалар, бәлки оялырлар.

*Чын мишәр*

Фәүзия апага, аның турында ишетеп белә башлаганнан бирле олы хөрмәтем. Ямьсез уйдырмалар таратучылар белән урыс форумнарына кадәр чыгып бәхәсләшәм. Махсус таратылган гаепләр өчен җәзасын һәркем алыр.

Фәүзия апа, Сезне халык ярата. Ә бу иң олы дәрәҗә. Алга таба да хәерле, имин тормышта, гаилә бәхете белән сау-сәламәт озак яшәргә һәм милләтебезгә таяныч булырга язсын.

*Илфат Фәйзрахманов*

Фәүзия ханым, Сезнен фидакарьлегегезгә сокланып, һәм юбилеегыз белән котлап калучы Сембер шәһәреннән Айрат бабай. «Туган тел» оешмасы әгъзалары да бу теләккә кушылалар.

*Айрат бабай*

*Кадерле милләттәшләр! Сезнең котлауларны һәм шигырьләрне укып бик тетрәндем, күземә яшьләр килде... Бөтен гомерем күз алдымнан үтеп киткән кебек булды. Гомереңнең азагында булса да халкыңнан яхшы сүзләр, изге теләкләр ишетәсең икән, димәк, заяга яшәлмәгән. Минем дә тормышымда күп авырлыклар булды, ялгыш-хаталарым да булгандыр, Аллаһ кичерсен инде! Әмма мин милләтемә зарар китерерлек гамәлләр кылмадым кебек. Тормышымның авыр вакытларында үземне һәм йөземне саклап калырга Аллаһка ныклы ышаныч ярдәм итте, хезмәт коткарды. Татарстанда этеп-төртеп йөртелә башлагач, китапларымны төяп, Себер-Уралларга чыгып киттем. Анда да менә дигән татарлар белән очраштым, ул якларның тарихы турында дөнья хәтле материал тупладым, соңыннан тау-тау китаплар яздым. Татар булуым белән горурланам, мөселман булуыма бик сөенәм. Сезгә дә шул бәхетне телим!*

*Фәүзия Бәйрәмова*

---

## Арзангарак язылырга була

Хөрмәтле укучылар!

Почта бүлекләрендә 1 февральдән льготалы подписка ачылды. Ул 31 мартка кадәр дәвам итәчәк. Шушы вакыт аралыгында сез 2011 елның 1 яртыеллыгына булган бәяләр белән 2 яртыеллыкка языла аласыз.

«Казан утлары»н арзангарак алдырырга теләсәгез, ашыгыгыз!

# ҖӘЛИЛ БЕЛӘН ОЧРАШУ

*Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә*
*Һәм үләргә кыю ир булып.*
М. Җәлил

## Муса Җәлил музей-фатирының визит карточкасы:

*Музей Татарстан хөкүмәте карары белән 1983 елда ачыла. Казан шәһәр советы карары нигезендә 1991 елда аның гомуми мәйданы киңәйтелә (130,8 кв.м.). Ул Татарстан Милли музееның бер бүлекчәсе итеп санала.*

*Музей-фатир 1940 елда мәгариф, мәдәният һәм сәнгать хезмәткәрләре өчен салынган коммуналь торак йортның дүртенче катына урнашкан. Биредә, Кызыл Армия сафларына алынганчы, 1940-41 елларда Татарстан Язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре Муса Җәлил яшәгән. Минзәләдә политработниклар курсын тәмамлаганнан соң, 1941 елның 8 январендә шагыйрь шушыннан фронтка китә.*

*Узган ел (2010) музей-фатирда барлыгы 5 меңнән артык кеше булган. Адресы: 420015, Казан, Максим Горький урамы, 17 йорт, 28 фатир, тел. 238-50-48*

*Интернет сәхифәсе: М 2173*



**Назирә Газиз кызы ФӘТТАХОВА,**
**Муса Җәлил музей-фатирының мөдире:**

*- Безнең музей ишеген ачып керүчеләр нинди максат белән килә дисәк, моны аңлату бер дә кыен түгел. Республикабыз башкаласы Казанга елның төрле вакытларында күп кунаклар килә. Аларның Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты, патриот-шагыйрь Муса Җәлил яшәгән йортны күрергә теләүләре бик табигый. Мәктәп укучылары, студентлар, галимнәр, әдипләр, әдәбият белгечләре, тагын күп төрле башка һөнәр ияләре дә еш була. Шагыйрь ничек яшәгән, кайда-ничек иҗат иткән, аның биографиясендәге мөһим сәхифәләр нидән гыйбарәт—әнә шундый күп кенә сорауларга җавап табу мөмкин бездә. Биредә татар халкының горурлыгы саналган Җәлилнең рухы, хәтере саклана.*

***

Муса Җәлилнең кем булуы, аның үлмәс иҗаты турында бу язмада озын-озак итеп сөйләүгә ихтыяҗ юктыр, мөгаен. Татар шагыйренең тоткынлыкта язылган «Моабит дәфтәрләре» циклын барлык илләр, кыйтгалар белә.

Муса Җәлилнең музей-фатиры...

Музей «Шигърият. Мәхәббәт. Сугыш.» дигән экспозиция белән башланып китә. Ул әдәби-музыкаль салонның бизәлеше дә. «Качкын» һәм «Алтынчәч» операларының

беренче куелышы уңаеннан чыгарылган афишалар, фоторәсемнәр Ватан сугышына кадәрге елларның иҗади атмосферасын якыннан тоярга һәм күзалларга ярдәм итә. М. Җәлил байтак еллар опера театрының әдәби бүлек мөдире булып эшли. Яңа оешкан Татар дәүләт опера һәм балет театры 1939 елның 17 июнендә «Качкын» операсының премьерасы белән ачыла (Милли операбызның сәхнәгә күтәрелүе–ул заман өчен зур казаныш икәнен онытмыйк–Р. Н.). 1941 елда куелган «Алтынчәч» операсын исә композитор Нәҗип Җиһанов белән шагыйрь Муса Җәлил якын иҗади дуслыкта бергәләп язалар. Төп партияләр Галия Кайбицкая, Мәрьям Рахманкулова, Фәхри Насретдинов, Усман Әлмиев кебек беренче җырчыларыбыз тарафыннан башкарыла.

Салон түрендә саргылт төстәге пианино. Шагыйрьнең үзенеке түгел түгелен, ләкин Җәлилнең пианино сатып алу турында хыялланувы мәгълүм факт. Килгән кунаклар белән әдәби-музыкаль очрашулар, гадәттә, шушы бүлмәдә уза.



*Бинаның тышкы күренеше*

Менә күргәзмәләр залы. Анда «Мусада кунакта» дигән интерактив (бердәнбер) күргәзмә даими эшләп килә. «Интер...» сүзе белән башланып киткән бу төшенчә ни мәгънәне анлата соң? Кагыйдә буларак, музей залларына һәм андагы кайбер экспонатлар янына «кул белән кагылмаска» дигән кисәтү (табличка) элеп куелган була. Биредәге «тере» экспонатларны исә бер дә икеләнмичә кулларың белән тотып-капшап карарга мөмкин. Бәлки, шунлыктандыр да әле, музей хезмәткәрләренең әйтүенчә, балаларның иң яраткан, якын иткән бүлмәсе шушы икән. Ни әйтсәң дә, кече яшьтәге мәктәп укучыларының шагыйрь Муса белән, чыннан да, якыннан беренче тапкыр «очрашуы» бит бу!

Бүлмә чын мәгънәсендә шул замандагы татар өе итеп бизәлгән. Иң әүвәле почмаклары калайдан чүкеп ясалган агач сандыкка игътибар итик. Капкачы ачык сандыкта–энҗеле калфак, бәрхет түбәтәй, чигүле сөлге, өс киемнәре. Ядкарьнең тагын да кадерлерәге гарәп хәрефләрендә язылган әлифба китабы... Әйе, татар халкы гомер-гомергә укымышлы-гыйлемле, китапка, басма сүзгә аеруча игътибарлы булган. Сандыктагы хәзинәләр әнә шуны искәртә кебек...

Акшарланган авыл миче. Аның алгы ягына көнкүрештә көн дә диярлек кирәкле табагач, ухват, ипи көрәге ише кирәк-яраклар сөяп куелган. Мич авызында аш-су чүлмәге шәйләнә. Куначада керосин лампасы монаеп утыра. Экскурсовод шагыйрьнең балачагы турында сөйли. Шагыйрьне кемнәр, ни-нәрсә шагыйрь иткән? Моңа җавап бер генә: нигезе, туган һәм яшәгән йорты, әбисе яисә әнисе сөйләгән әкиятләр. Менә шуңа күрә дә экскурсия барышында әкият яисә берәр риваятьтән өзекләр дә яңгырый, бу исә әңгәмәгә җылылык һәм табигыйлек өсти. Шамаил, йон эрләгеч каба, орчык, агач сәке, аш өстәле, чәйнек-самавыр. Бүлмәдәге шушы өстәл артына утырып, чәй дә эчеп җибәргәч, балалар өчен моннан да истәлекле тагын ни булыр икән? Иң мөһиме–аларга тәрбия, әби-бабаларыбызның гореф-гадәтләре онытылмаслык булып сеңеп кала.

Ниһаять, мемориаль бүлмәләргә аяк басабыз. Шагыйрьнең эш бүлмәсендә гадәти булмаган тынлык... Әйе, биредә хәзер генә илаһи тынлык, кайчандыр Муса монда үзенең күпсанлы шигырьләрен, «Алтынчәч» либреттосын, «Хат ташучы» поэмасын, әдәби тәнкыйть мәкаләләрен язган. Әлеге өстәлне Муса әле Мәскәүдә чакта ук, 1935 елда сатып алган. Ян-яктагы тартмалары тавышсыз-нисез генә бик ансат ачыла. Өстәл өстендә пыяладан коелган кара савыты,

корыч каләм-ручка, вак-төякләр салу өчен бакыр тартма, фил сөягеннән эшләнгән пычак... Шулар янәшәсендә «Хат ташучы» поэмасының 1940 елда нәшер ителгән беренче басмасы. Аның алгы битендә шагыйрьнең үз кулы белән язган автографы: «Закиров иптәшкә. Истәлек өчен. 12.07.40 ел». Өч яшьлек кызы Чулпан белән төшкән фоторәсемнән тыныч еллар рухы, гаилә җылысы бөркелеп тора.

Муса кечкенәдән үк китап укырга яраткан, үзенең шәхси китапханәсен булдыру турында хыялланган. Мәскәүдә яшәгән елларында ук бик күп китаплар туплый. Үзенең амбар кенәгәсенә шәхси китапларының исемлеген теркәп барган. Исемлектәге 400 гә якын китап, һәммәсе дә сакланмаган. Сакланып калганнары исә барлыгы–216. Алар әдипнең китап шкафына һәм этажерканың шүрлекләренә пөхтәләп тезеп куелган. Хәсән Туфанның «Шигырьләр» дигән китабы да исән. Латин хәрефендәге әлеге китап 1932 елда, ягъни сөргенгә хәтле чыгып өлгергән була. Муса аны КГБның үткер күзләреннән ничектер саклап кала алган, күрәсең. Бу басма «Урал эскизлары» белән ачыла.


*Җәлил кызы Чулпан белән*

Агач урындык инсәсендә Мусаның күзен-кышларын муенында йөрткән шарфы эленеп тора. Иренең төсе итеп саклаган бу истәлекне музейга Әминә ханым тапшырган. Гомумән, мемориаль ике бүлмә Әминә Җәлилова һәм шагыйрьнең замандашлары истәлегенә таянып эшләнгән. Юл чемоданы, мандолина, дисбе, гаилә альбомы, кара тәлинкә-репродуктор һ б.

Бил каешының тарихы гыйбрәтле. Җәлил сугышка китәр алдыннан Җиһанов белән озаклап Казанның төнге урамнарында йөриләр. Хәтәр һәм ерак юлга китәсе булганлыктан, иҗатташ ике дус каешларын алмашалар: Муса сугыштан исән йөреп кайткач, янадан очрашырлар, янәсе. Юк шул, тәкъдирдә бөтенләй икенче язмыш язылган була... Торак бүлмәдә бер өстәл. Анарда аклы-каралы фигуралар тезелгән шахмат тактасы саклана (дусты Гази Кашшаф тапшырган). Муса буш-рак вакытларында шахмат уйнарга яраткан. Оттырса, үз-үзеннән «Грошмейстер» дип көлә белгән. Үз-үзеннән көлә алу сәләте–шәхеснең көчле рухлы, юмор хисенә ия булуы турында сөйли. Тәмамланмаган шахмат партиясе исә шагыйрьнең бу йортка әйләнеп кайтмавын искәртә.

Тумбочка өстендә Мусаның Әминәгә язган шигыре. Шагыйрьнең пөхтә һәм чиста почеркы һәркемдә соклану тудыра, ак кәгазь битендәге хәреф-җөмләләр сәйләндәй тезелгән. 1941 ел, 9 / IX датасы куелган шигырь–илдәге дәһшәтле көннәрдән бер аваз, кыйтга:

*Тәнем белән синнән аерылсам да,*
*Уем белән синнән аерылмам.*

Сугыш! Китаплардан укып, экраннардан карап Бөек Ватан сугышы турында күп нәрсәләр белсәк тә экспозициянең бу өлешен тетрәнмичә карау мөмкин түгел. Муса–кызылармеецларның «Отвага» исемле газетасында хәрби корреспондент, өлкән политрук. Волхов тирәсендә барган канлы сугышлар вакытында аларның часте чолганышта калып, М. Җәлил каты яраланган хәлендә дошман кулына эләгә...

Шагыйрьнең Гази Кашшаф дустына язган васыяте. «Иҗатымның 30 проценты гына матбугатта басылды. Редакцияләү һәм бастыру өчен барлык әдәби мирасымны сиңа тапшырам...» дигән юлларны да укыйбыз анда.

Тоткынлыктагы ике ел гомерен иҗатта һәм көрәштә үткәргән шагыйрьнең күңеле сизгән, ахры:

*Үлгәндә дә әйтә алсам иде,*
*Үлдем, диеп, туган ил өчен!*

.................................................

*Исемең калсын, үзең үлсәң дә,*
*Тарихларда укып ятларлык.*

Шагыйрьләргә югары сизгерлек, алдан күрүчәнлек сәләте бирелгән, диләр. Бу, чыннан да, шулайдыр. Мусаның әйткән сүзләре дөрескә чыкты.

Бәһасез «Моабит дәфтәрләре», шулай ук Җәлил һәм аның көрәштәшләре кулларына тотып тормыш-яшәү белән хушлашкан Коръән Татарстан Милли музее фондында махсус саклануда тора.

Минзәлә шәһәрендәге һәм Татарстанның Балтач районы Карадуган авылы музейлары да легендар шәхеснең истәлеген кадерләп саклый.

Әйтергә кирәк, соңгы вакытларда М. Җәлилгә кизәнүчеләр, аның батырлыгына «ревизия» ясарга тырышучылар да табылды. Әмма мондый вандализмга кин катлам җәмәгатьчелек һәм әдипләр тарафыннан кискен җавап бирелде.

М. Җәлил һәм җәлилчеләрнең, яшерен оешма төзеп, фашизмга каршы алып барган көрәше турында дистәләрчә китаплар язылган, кинофильмнар төшерелгән, һәйкәл-скульптуралар коелган. Җәлил безнең белән яши. Аның үлмәс иҗаты безне һәрвакыт матурлыкка һәм батырлыкка чакыра.

**Рашат НИЗАМИЕВ.**

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында сакланган кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире иясенә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкарьләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**

*Татар энциклопедия сүзлегендә* ***Адлер Камил улы Тимергалин****ның кем булуын язмаганнар. Китапларын санап чыгу белән чикләнгәннәр. Бөтен эшчәнлеген колачларлык, татар өчен әһәмиятен күрсәтерлек сүз таба алмаганнардыр инде.*

*Миңа Адлер абый белән Китап нәшриятында алты еллап бергә эшләү насыйп булды. Хәтта аңа начальник та тия идем әле: ул редактор булган фәнни-техник әдәбият редакциясенең мөдире, баш мөхәррир урынбасары. Ләкин бу мөхәрриргә мин «сез» дип, «Адлер Камилович» дип дәшә идем, ишеген шакып ук кермәсәм дә, кабинетына ихтирам бусагасы аша үтә идем. Хәер, мин генәме, түш киереп йөргән, соңрак академиклар булган зур гына галимнәребез дә аның янында ничектер кечерәеп, хата җибәрмәсәм ярар иде дигән укучы балаларга охшабрак кала иде.*

*Соңрак, мин «Идел» журналына, аннары «Казан утлары»на күчкәч тә багланыш өзелеп үк бетмәде, сирәк-мирәк кенә телефоннан сөйләшкәләдек. Йә аның иҗатына бәйле рәвештә, йә миңа киңәшфәлән кирәк булганда. Ләкин бу гаҗәеп зат белән бер иркенләп, тәмләп сөйләшеп алу теләге миндә беркайчан да сүнмәде. Форсат чыкты менә. Бәлкем, безнең гәп укучыларыбызга да кызыклы булыр дип диктофон да кыстырып бардым әле.*

# «ШОМАЛЫКНЫ, ШОМАЛАРНЫ СӨЙМИМ!»

ӘҢГӘМӘИ ХИКӘЯТ

## Язылмый калган җыр

*—Адлер абый, сез 1949 елны Сталинга атап шундый сүзләр язгансыз ки, укыса, аның чәче үрә торган булыр иде. Моны эшләр өчен кем дигәндә мөстәкыйль фикерләүгә ия булырга кирәк бит инде. Каян килде ул сезгә, ять-яшь егеткә?*

—Кечкенәдән бар иде инде ул аңлыйсы, төшенәсе килү дигән әйбер. Апам 10нчыда укыганда аның китапларын караштыра идем мин. Бик кызыксынып химия дәреслеген актарганымны хәтерлим. Ул заманда химиядә молекулаларның, атомнарның төзелеше Бор теориясенә нигезләнгән иде. Бу теорияне кире кактылар. Әмма ул минем хәтергә уелып калды.

*—Үзегез ничәнче класста укый идегез соң?*

—Знчедә чак булгандыр.

*—«Ай-яй-яй» дияргә генә кала монда!*

—Ләкин иң нык кызыксындырганы астрономия булды. Ул дәреслек татарча, латин хәрефләре белән язылган. Китапта рәсемнәр дә бар. Төрле йолдызлыклар гына түгел, Марс планетасы, аның каналлары да күрсәтелгән. Аннан, үсә төшеп, сорашкалый-эзләнә торгач, кулыма «Кызыклы астрономия» дигән китап килеп керде.

*—Перельманмы?*

—Перельман, әйе, ләкин татарчасы. Кыскартылган тәрҗемәсе. Рәимов атлы

физика укытучысы тәрҗемә иткән. Бу инде ул заман баласы өчен чын бүләк, җинел генә ачыла торган фән капкасы кебек иде. Нәшрияттә эшли башлавымның беренчеме, икенчеме елында без бу китапның тулы тәрҗемәсен бастырдык.

*—Перельман башка фәннәрне дә «кызыкландырды» инде ул.*

—Әйе, аның ике томлы «Кызыклы физика»сы һәм «Кызыклы механикасы» һ.б. китаплары да бар әле. Бу автор миңа ниндидер бер илаһи зат шикелле тоела башлаган иде. Чынлыкта бернинди гыйльми дәрәҗәсе дә юк гади бер кеше булган ул. Ләкин аны барыбер олылап «профессор» дип йөрткәннәр. *(Бу урында мин, әңгәмәдәшемнең «йөзенә бәреп» әйтмәсәм дә, тач сезнең шикелле икән дип уйлап куйдым.)* Блокада вакытында Ленинградта ачтан үлә ул. Перельман астрономиясеннән соң башка, җитдирәк китапларга да күчтем, урысчаны да сукалый башладым. Минем гыйлем һәм романтика тансыклаган үсмер җанымда астрономиядән дә биегрәк һәм мавыктыргычрак фән юктыр дигән фикер туды. Хәзер дә мин астрономиядән дә югарырак һәм кызыклырак фәнне күз алдына китерә алмыйм. Ничектер эченә кергән саен бүтән фәннәр белән бәйләнешләры ачыла бара аның. Башка дөньялардагы тереклекне эзли башлыйсың. Алланы эзлисең.

*—Алланы эзләү дигәннән, Адлер абый, Гагариннан, җирдән ничәдер йөз чакрым гына күтәрелгән кешедән, Хрущев, син анда алланы күрдеңме, дип сораган. Гагарин юк дигәч, тантаналы төстә игълан иткән: белдегезме инде, алла юк ул!*

—Көлке хәл бу, әлбәттә. Шунысы да көлке: адәм баласы Алланы үзе төсле итеп, ике аяклы, ике куллы итеп, тәхеттә утырган патша рәвешендә күз алдына китерә... Хәер, бу хакта озаклап сөйләшү кирәкмидер дә, чөнки «Казан утлары» минем «Алла» дигән фәлсәфи уйлануларымны бастырып чыгарды бит инде.[1]

Китап дигәннән, шуны да әйтим әле. Мин Казанда фатирда торган кешеләрнең ике катлы зур агач өйләрен тартып алып, үзләренә шуның ике бүлмәсен генә калдырганнар. Тыштагы утын сарайлары да калган тагын. Менә шул сарайдагы иске китаплар арасыннан ике китап табып алып кердем мин. Аларның берсе ул чакта тыелган Галимҗан Ибраһимовның "Тирән тамырлар"ы иде. Гарәп хәрефләре белән язылган. Мин ул чакта әле берничә хәрефне генә таный идем. Калганнарын хуҗа карчык өйрәтте. Тәки укып чыктым бит мин бу китапны. Шулай итеп, Галимҗан агай һәм теге әби гарәп язуыннан минем беренче хәлфәләрем булдылар.

Икенче китап «Генетика» иде. Мәктәп дәреслеге. Генетика да, соңрак кибернетика кебек, тыелган, чүплеккә ташланган фән ул чагында. Мин шунда Мендель законнарына юлыктым, бу фәннең математик төгәллегенә шаккаттым. Ләкин генетикадан лекцияләр тыңлаячагымны, галимнәрнең ул лекцияләрне төрмә психбольницасы камерасында сөйләячәген ул чакта башыма да китерми идем.

*—Адлер абый, без хәзер сүз башы булган «шүрәле»гә—Сталинга якынайдык. Димәк, һәр мәктәп ялтыратылганның алтын түгеллеген һәм, киресенчә, һәр сүгелгәннең начар түгеллеген аңлау, ягъни тормышка тәнкыйтьчел мөнәсәбәт сездә инде балачактан ук калыплаша килгән икән.*

—Аның формалашып җитүенә нәкъ менә Сталин бабай гаепле. Төгәлрәк әйткәндә, аның турындагы җыр гаепле.

*—Ничек инде? Ни рәвешле? Нинди җыр?*

—Аз-маз каләм тибрәтә башлаган идем инде мин. Бер хикәя яздым да, аны Язучылар берлегенә күтәреп килдем. Анда Әпсәләмов бик әйбәт каршы алды мине. Ул чагында әдәби консультант булгандыр инде. Тикшерербез, карарбыз, диде. Шунда килгәләп йөргәндә бер егет белән таныштым. Исем-фамилиясен хәтерләмим инде. Аны өч кенә тапкыр күрдем мин. Театр училищесыннан иде ул. Әйдә, Сталин турында җыр язабыз, диде бу. Сталинның 70 еллык юбилее якынлаша иде. Музыкасын мин, сүзләрен син язарсың, диде. Ул чакта инде рифма эзләп тә маташкалаган бар. Җыр язу авыр булмас дип уйлыйм инде. Ярар, әйдә, язабыз, дидем. Ләкин тора салып юлбашчы турында яза алмыйм икән бит әле. Мин аны

[1] 2009, № 2.

Сталин бабай дип кенә беләм, шәхес буларак белергә, тоярга кирәк бит.

Уйлый торгач, бигрәк тә эзләнә торгач, Сталин турында бик аз белгәнебезне аңладым мин. Аның чын биографиясе юк иде! Ярдәмчесе, төрле документлар өчен кирәк булса дипме, кыскача биография генә әзерләгән икән. Шәхси сыйфатларын, холык-фигылен белим дисәң, аннан берни дә ала алмыйсың.



Бүтән чыганаклар эзли башладым. Болак буендагы хәчтерүш кенә бер китапханәдә Анри Барбюсның Сталин турындагы китабын табып бирделәр. «Человек, через который виден весь мир» дигән китапны. Французчадан тәрҗемә инде бу. Ләкин монда да гомуми сүзләр өстенлек итә. Берничә кызыклы факт таптым үзе.

Сталин Кремльдә ике бүлмәле фатирда яшәп яткан икән. Ике улы (берсе—тәрбиягә алынган) һәм кызы бар юкса. Хатыны ул вакытта атылып үлгән инде. Ничек сыйганнардыр болар. Малайларының берсе сандык өстендә йоклаган... Китапта Сталинның эш хакы да әйтелгән. Төгәл хәтерләмим, ике йөз сум чамасымы шунда. Шулар белән алдый инде Сталин. Имеш, менә шундый гади һәм тыйнак инде ул! Ләкин аның чыгымнары булмаган бит. Фатирга түләми, ашарга Кремльдәге махсус ашханәдән китерәләр. Шуңа күрә Сталин акчаның бәясен белмәгән дә. Брежнев кебек. Брежнев турында шоферы болай дип сөйли бит. Дачага барышлый ул, машинаны кибет янында туктаттыра да...

*—Бер ярты алып чык, дигәндер инде.*

—Әйе, шулай ди. Һәм бер сум акча тоттыра тегенә! Кызы Светлана сөйләвенчә, Сталин да, акча турында сүз кузгатсаң, шул бер сумны чыгаргалаган икән.

Тагын берничә чит ил язучысы килә әле Мәскәүгә. Ләкин алар өметне акламый. Андре Жид, мәсәлән, килеп матур гына йөри дә, монда тиз-тиз китапларын русча чыгаралар. Ул исә Франциягә кайткач Сталинны шәп кенә тукмый.

Шулай итеп, җыр язарга рухландырырлык берни дә тапмадым мин, баш тарттым бу эштән. Теге егет үзе язды микән, юк микән, белмим. Ләкин Сталин бабай җырга мохтаҗлык кичермәгәндер ул, аның турында шигырь яки җыр язмаган шагыйрь калмады бугай. Рафак Тимергалин дигән журналист бар иде бит әле.

*—Әйе, озак вакытлар «Социалистик Татарстан»да баш мөхәррир урынбасары булып эшләде.*

—Менә шул да язган хәтта. Адаш бит, синең шигырьме бу дип тинтерәтүчеләр булды.

## Сталин дөмексен!

*—Чын, дөрес уңай мәгълүмат җитмәү бер хәл. Сталинга мөнәсәбәтнең тискәрегә үзгәрүе ничек булды инде?*

—Ниһаять, теге юбилей килеп житте. Шунда мин Сталин исеме гәзиттә бер санда ничә тапкыр кабатлануын санап чыктым. Ничә йөз тапкыр икәнен хәзер хәтерләмим инде. Ошамады бу миңа. Башка саннарда да Сталинның Ленинннан күбрәк телгә алынуын искәрдем. Аның турында фактик материал таба алмау да мәгълүмат махсус яшерелгәнлектән түгел микән дигән шик тә килде әле башка. Һәм ул көчәйгәннән-көчәя барды. Ничек болай булган соң бу? Ничек күтәрелә алган бу кеше? Уйлый торгач, башымда кинәт яшен яшьнәгәндәй булды. Бу бит алдакчы! Шуннан соң мин әлеге фикердән котыла алмадым инде. Һәрнәрсәдә аның алдавын гына күрдем. Аның турында көчләп укытыла торган нәрсәләрнең барысы да примитив бит. Ленинның әле фәнни тикшеренүләре, теориясе бар. Ә моның багажында ни?

*—Йә, шуннан соң, боларны белгәннән соң ни үзгәрде инде?*

—Мин—романтик. Бу оятсызлыкка каршы көрәшергә кирәк дигән ярсулы теләк туды күңелдә. Ләкин нәрсә эшли алам соң мин? Көрәшнең нинди ысуллары бар? Горькийның «Давыл хәбәрчесе турында жыр»ы искә төште. Аны, листовка итеп язып, театрларда да ыргытканнар. Башка шул уй килү белән йөрәк дөп-дөп тибә башлады. Көрәшнең мин булдыра алган бердәнбер ысулы шушы лабаса!

*—Сталин режимына каршы мылтык тотып чыга алмыйсың инде, әйе. Ә листовка дигәне ничегрәк булды?*

—Язып, төрле жирләргә ташлап йөрдем, шул.

*—Ә текст, текст нинди?*

—Текст анда бик кыска, өндәмә кебек кенә иде ул. Нинди сүзләр булганын төгәл генә хәтерләмим дә инде хәзер.

*—Нинди кәгазьгә язылды?*

—Дәфтәр кәгазенә. Ләкин мин аларны, күзгә ташланып торсын дип, матур кәгазьгә төрәдер идем.

*—Каян аладыр идегез соң аны?*

—Каян алганым истә түгел. Ялтыравыклы яшел кәгазьгә төргәнемне хәтерлим.

*—Мәктәп каләме белән язылдымы?*

—Ну, ул чакта шарикلы ручкалар чыккан иде инде. Ләкин пычрак язалар иде әле. Шул булырга тиеш.

*—Бер кичнеме, ничек, кая утырып язылды? Йә, Адлер абый, следователь чыгамы миннән?*

—Рәвешен китерәсең. Следователь болай ук төпченмәгән дә иде шикелле... Мин аны яшереп эшләдем инде. Мин торган фатирда хуҗалар йоклап беткәч.

*—«Тираж» күпме иде? Ун, егерме, утыз?*

—Юк, бер илле-йөз генә булгандыр инде ул. Аны бит, кыска булгач, әзерләве дә җиңел.

*—Сезне кайда тоттылар, ничек?*

—«Унион»да кино карап чыккач, хәзерге «Родина» инде бу, Болакка таба борылдым. Бер ишек алдына кереп берничә кәгазьне калдырганда каяндыр арттан ике дәдәй килеп чыгып, эләктереп алдылар.

*—Формадан түгел, әйеме?*

—Юк, формадан түгел. Мине Бауман урамына алып чыгып, такси туктатты болар. Шунда кызык хәл булды. Таксист безгә карап алды да, эшне аңлады булса кирәк. Туктатканына «Пошел ты на...» диде дә, китте дә барды. Шуннан болар «черек күл»гә мине җәяүләп алып киттеләр.

*—Кем янына алып кердpoints?*

—Ну, анда, предварилкада, эшне тиз тоталар. Мине, хәзер машинада инде, мин торган фатирга алып бардылар. Тентергә дип. Анда әллә ни юк инде, кәгазьләр, хат-мазар, язган нәрсәләр, дәфтәр-китапларны алып киттеләр. Китапханәнекеләрне дә. «Алар китапханәнеке бит» дигәч, «Үзебез тапшырырбыз»,—диделәр, юк тапшырмаганнар. Үземне дә алып киттеләр, әлбәттә. Һәм шуннан тиз генә әйләнеп кайта алмадым инде.

*—КГБдагы сезнең ул листовкаларны күргән кеше—Рафаэль Мостафин белән сөйләштем мин, Адлер абый. Алар барысы да «Смерть Сталину!» дип башланып китә икән. СССР дигән мәмләкәттә бу рәхимсез тиранга шулкадәр дә каты бәрелгән кеше булды микән ул тагын?*

## Төрмәдә

*—Шуннан сезнең төрмә тормышы башланып киттеме инде?*

—Әйе. Камерада берүзем утырам. Утырам, әйе, бик йөреп булмый чөнки. Чалбарның каешын алдылар, төймәләрен өзделәр. Соңрак әнә Берияне дә шулай иткәннәр, кулга алгач... Берме, икеме көн үтте микән, минем янга ниндидер бер кешене керттеләр. Хәзерге акылым белән нигә кертүләрен аңлыйм, аның бик

юмалап сөйләшүеннән.

*—Сораштырдымы соң?*

—Юк, шикләнмәсен, үзе сөйләсен дигәндер инде... Ләкин мина файдасы да тиде анын. Чалбарны шырпы белән эләктереп куярга өйрәтте. Аннан шырпыдан энә ясарга да өйрәтте әле.

*—Ничек була инде ул?*

—Шырпы яндырып очлана, теге башын ярып, анда жеп кыстырасын.

*—Баштан ук башлыйк әле, Адлер абый, төрмәгә килеп кергәч сезне нишләттеләр?*

—Иң әүвәл тентеделәр. Нәрсә дип аталадыр инде ул—бер шкафка шәрәтән ябып куйдылар да, бөтен нәрсәмне, киемнәремне эчәсеннән жебенә хәтле тикшереп чыктылар.

*—Шкафка нигә кертәләр?*

—Туңмасын өчендер инде. Ләкин соңыннан мине сап-салкын бүлмәгә кертеп яптылар. Батарей-фәлән юк. Форточканы төбенә хәтле ачып, су сибеп катырганнар—ажгырып суык кереп тора. Тышта минус 31 градус дип хәтердә калган. Димәк, эчтә дә шул чама инде. Шул камерада төн кундым мин. Куну дип, ниткән куну булсын инде ул. Шәрә тимер караватка ята торган түгел, юкса йокы да бик килә. Ярый әле тәмәке бар иде, шуны тартып, әрле-бирле йөреп үткәрдем төнне. Бик каты салкын тидердем.

*—Ничә яшь инде сезгә ул вакытта? Һәм кайсы ел бу? Сез кем инде: укыйсызмы, эшлисезме дигәндәй.*

—Университетның астрономия бүлегендә 2нче курста укый идем. 1950нең гыйнвары бу.

*—Димәк, яңа гына 19 тулган. Яңа ел көнне тугансыз бит инде. Күңел төшү, күңел кайту, үкенү дигән нәрсәләр булмадымы? Сорау алучылар каршына килеп утыргач, ни хис иттегез? Алар энә гайрәтле ирләрнең дә ихтыярын шартлатып сындыра торган булганнар бит.*

—Мин аларга бирешмәдем. Җиңдем мин аларны. Наивлыгым белән җиңдем. Следовательләр өчен яңа әйбер бу, наивлык. Алар бит хәйләләү, алдашу, яшерүләр белән көрәшеп өйрәнгән. Шуны бәреп чыгармакчылар. Ә мин булганны һич яшермим, әйе, шулай иттем, дим. Сталин турында ни уйлаганымны да сөйлим. Берсендә тикшерүче каядыр чыгып китте дә, аның урынында практикантлары, студентлар калды. Чуаш егетләре. Сөйлим инде боларга, сез менә чуашлар бит, йә, әйтегез әле, чуаш халкының нинди хокукы бар соң, дим. Авызларын ерып карап торалар. Ниткән дурак бу диләр инде. Тикшерүче кергәч, ана, көлеп:

—Он нас агитирует,—диделәр.

*—Туктагыз әле, Адлер абый. Наивлык белән җиңдем, дисез. Өстегезгә шулай күп алгач сезне ни көткәнен уйламадыгызмыни соң? Монда бит сезнең тәнгә, сөякләрегезгә кадәр үтеп, сап-салкын курку кереп тулырга тиеш иде.*

—Юк-юк, курку булмады.

Бер төнне мине министр кабинетына алып керделәр.

*—Ул эшләгән булып утыра инде. Сталин төнлә эшләгәч, чиновниклар да кайтып китәргә курыккан бит. Юлбашчыларының көндез йокы бүскәнен белмәгән шул алар.*

—Шулай инде, канга сеңгән бит бу ул чакта. Аң булыгыз, Сталин уяу!.. Бик зур иде моның кабинет. Авыр шторалы өч тәрәзә. Берни күренми тәрәзәләрдән, ул штораларны пуля да тишә алмас кебек. Бик зур курку һәм газап дозасы алырга тиеш булганмындыр инде мин. Көндез тагын да ныграк йокы килде, ләкин глазоктан карап кына торалар. Төнге, инде чын сорау алулар бүтән кабинетларда күп тапкырлар кабатланды. Тикшерүчеләр анда бер-берсен алыштырып та эшләделәр. Мондый төннәр рәттән килгәндә бик авыр була торган иде.

Тикшерүчеләрнең шундый алымы да бар иде: өстәлдә, ымсындырып, тәмәке төпчекләре ята. Кайберләре яртылаш кына тартылган. Күпләр шуны сорап алалар.

*—Һәм җаваплары белән тулиләрме?*

—Юкка гына сыйламыйлар инде, әйе. Шөкер, ничек кенә тартырга теләсәм дә, бу җимле кармакка капканым булмады.

Мине аннары дүрт кешелек камерага күчерделәр. Шунда ике айга якын булдым.

*—Анда кемнәр иде? Уголовниклар түгелме?*

—Юк, барысы да 58нче статья...

*—Сәясәт!*

—Әйе. Төрмәдә, танышканда, һәркем үзенең үткән тормышын сөйләп чыга. Камерадашларымның берсе авыл агае, сугышта әсир төшкән. Ул чакта пленда булганнарның бөтенесен дә җыеп алдылар бит. Берсе, Найденов дигәне, полицай булган. Әйтүенчә, мәҗбүрләп куйганнар инде. Аннары, авылларын азат иткәч, совет армиясенә язылган. Сугыш бетеп ничәдер ел үткәч, каптырганнар менә. Курск ягыннан ул, ничек Казанга килеп эләккәндер. Минем биография кыска. Вакытны үткәрергә кирәк бит—отбойга кадәр. Мин инде аларга берәр романтик әсәрне сөйләп чыга идем. Жюль Вернның «Серле утравы»н, Виктор Гюгоның «Көлә торган кеше»сен сөйләдем. Икесен дә рәхәт чигеп тыңладылар.

Камерадашларым мине төрмә тормышына өйрәттеләр. Ипи кисүдән башлап. Көнгә 400 грамм тирәсе ипи бирелә. Без сындырып, чемченеп ашарга гадәтләнмәгән бит инде. Кисәргә пычак юк. Моның өчен киемеңнән нычка җеп суырып чыгарасың. Шуның ике очына шырпы тартмасыннан таякчыклар ясап куясың. Пычак әзер... Хәер, мин дә сынатмадым, беренче атнада ук шырпы тартмаларыннан шашка ясадым. Берничә тапкыр уйнап та өлгердек әле. Җикеренеп килеп керделәр дә, шашканы алып чыгып киттеләр. Уеннар тыелган икән монда. Ясау дигәндә исә төрмәдә шахматны да бик оста ясыйлар.

*—Аны нәрсәдән ясыйлар соң?*

—Ипи йомшагыннан. Башта бик каты чәйнәп, кульяулык аша сытып чыгаралар. Сыек өлеше менә дигән җилем була.

Осталыкның чиге түгел икән әле бу. Төрмәләрнең берсендә ипидән хәтта йөри торган сәгать тә ясаганнар!

*—Сорау алулар барамы соң? Нәрсә сорыйлар?*

—Үз «җинаятьләрем»нән тыш бер нәрсәне сорадылар: кемнәр белән танышсың? Миннән Аяз Гыйләҗев турында кат-кат сорыйлар иде.

*—Ә сез аның белән ничек таныштыгыз соң?*

—Ул безнең Сарман районыннан бит. Бер ел Сарман мәктәбендә бергә дә укып алдык. Аязны белмәү читен. Үзен күрсәтергә ярата иде ул. Әйтик, инша язарга дисәләр, ул аны шигырь белән генә яза!.. Аяз университетның татар бүлегенә кергәч, аның белән күп тапкырлар очраштым мин. Сәяси темаларга да сөйләшкән булды. Бер тапкыр шулай, колхозлар турында сүз чыккач, мин, белеп җиткермәгәнгә, бер начар сүз дә әйтә алмадым. Аяз исә колхозларның череп таркала баруы, кирәксезлеге турында сөйләде. Ә икенче елны очрашканда безнең рольләр алышынды. Мин колхоз системасының ни икәнен аңлаган идем инде, колхозларны сүктем. Аяз исә көтмәгәндә аларны яклады.

Ә тегендә Аяз турында мин әйбәт итеп кенә сөйләдем. Менә сөйләшкән бар колхоз турында да, мин колхоз системасы таркала бара дигәч ул моңа каршы чыкты, шундый-шундый сүзләр әйтте, дидем.

*—Тагын кемнәр турында сорадылар?*

—Гурий Тавлин турында да сорап маташканнар иде. Гурий да безнең якташ. Ләкин мин аны аз белә идем.

*—Адлер абый, менә шушы ике язучы, аларның үзара мөнәсәбәтләре турында сөйләшеп алыйк әле. Икесе дә төрмәдән кайттылар бит. Тавлин үзенең «Афәт» дигән автобиографик романында бүтән исем белән бирелгән, ләкин Аяз абый аермачык төсмерләнгән персонажны үзенә «нахак бәла ягу»да гаепли. Хәер, Гурий абыйның миңа бу хакта Аяз Гыйләҗев дип, аермачык сөйләгәне дә булды.*

—Мин бу мәсьәләдә Гурий Тавлин белән килешә алмыйм. Алар Аяз белән болай дус иделәр үзе. Ләкин Гурий, урыны җәннәттә булсын, хатын-кызны бик ярата иде. Артыгы белән диик. Анын Аяз белән юлы кисешкән булырга мөмкин дип беләм. Гурий шактый чәүчәләк кеше иде, мәрхүм, күнеленә хуш килмәгәнрәк сүз ишетсә, янагында төерләр уйнаклый башлар иде... Кырт кисеп берни дә әйтә алмыйм, чөнки Аязның чын хатирәләрен белмим.

*—Бу хакта мин КГБ архивындагы «эш»ләр белән танышкан Рафаэль Мостафиннан сорадым, Адлер абый. «Аларның һәркайсы бер-берсе өстеннән ни дә булса язган»,—диде ул. Шундагы бер тикшерүче моның хикмәтен дә ачып биргән аңа. Баксаң, шул максатта комитетчылар тарафыннан хәйләкәр провокацион алым кулланылган икән. Рафаэль абый Аяз Гыйләҗевнең үз сүзләрен дә кәгазьгә төшереп бирде. Бу бүлекне шул сүзләр белән тәгаллисем килә: «Без өчәү (тагын Мәҗит Рафиков дигән язучы да була әле—Р. Ю.) бик үк әйбәт тотмадык үзебезне, ну Тимергалин искиткеч нык торды, беркем өстеннән берниндн сүз әйтмәде.»*

## Психушкада

Ике айлап вакыт үткәч, сорау алмый башладылар. Тынычлана төштем. Көннәрдән бер көнне мина «с вещами, на выход!» диделәр. Жинел машинада каядыр алып киттеләр. Урамда плакатлар—сайлау алды плакатлары. Март ае бит.

Психиатрия хастаханәсенә китергәннәр икән мине.

*—Каян белдегез инде моны?*

—Ишектә язылган.

*—Укыгач нинди тәэсир туды инде?*

—Эчтән болай дип тәкрарлый башладым: «Мин берни дә белмим».

*—Авызны боргычлап куяр өчен инде бу, әйеме?*

—Эчтән ныгытып куяр өчен үземне. Анда психиатрлар каршына бастырачаклар бит. Сынаячаклар. Аннан, белгәннәремне укыдым инде.

*—Нәрсә белә идегез соң?*

—Бисмилланы беләм инде. Тагын... Андый чакта белгән искә төшә ул. Сабира әбием әйткән искә төште. Мәдрәсәдә укыганда имтихан алдыннан шушы сүзне тәкрарлый идек дигәне. Имтиханга хәзрәтләр Казаннан ук килә торган булганнар. Инспекция белән. Мәржани үзе дә сугылып чыкмады микән әле безнең Минзәләбаш мәдрәсәсенә. Шуңа күрә хәзерге шәкертләр—студентлар ничек дулкынланса-каушаса, авыл талибләре дә шулай ук дулкынланган инде. Аны басарга ошбу гыйбарә ярдәм иткән: «Йа Раббым хасби, ган суали, вәхвә гыйлем бихәли» «Раббым, жавап тотканда хәл бир» була инде кыскача мәгънәсе. Төрмәдә Аллага ышанмаган кеше дә Алланы искә төшерә. Руслар күп бит инде анда, алар «Отче наш»ны укый башлыйлар иде.

*—Психиатрлар каршына килеп бастыгыз инде.*

—Профессор-фәләннәр, 5-6 кеше. 15 минутлап сораштырдылар. Мине алып килгән тикшерүче дә шунда иде, кайчагында аңа да мөрәҗәгать итәләр. Бер-берсенә карашып, ымлашып алалар. Аннан чыккач, тикшерүче минем белән саубуллашты. Шуннан соң кая килеп эләккәнемне аңладым инде.

*—Кайгымы, сөенечме, аптырауммы—нинди хис кичердегез?*

—Аптыравы булгандыр. Шулай да, төрмә үк түгел лә бу дигән уй күнелне беркадәр жылытып җибәрде. Ләкин төрмәдәгеннән дә начаррак булып чыкты монда. Төрмәдә чалбар кия аласың әле. Монда—юка кальсон гына. Ялан аякка башмак киеп йөрисең. Тәнгә жылы житми иде. Кышы да салкын килде бит анын. Ләкин мине монда озак тотмадылар. Эчке больницага—төрмәләр идарәсенең махсус психиатрия хастаханәсенә тапшырдылар. Димәк, экспертиза тәгәлләнгән, диагноз куйганнар. Психка чыгарган инде болар мине. Яшь малай дип жәлләүләре булды микән?

*—Юк, Адлер абый, органнар шулай үз өсләреннән җаваплылыкны төшергәннәрдер. Сталинның үзенә каршы листовкалар таратып йөрергә алар юл куйган бит.*

—Сак-фәлән түгел, өлкән медсестра гына алып барды мине тегендә. Саубуллашканда бик тә кызганып карады ул миңа. Чөнки белә, моннан чыгу юк инде. Гади больницадагы кеше терелгәч чыга. Хөкем ителгән кеше хөкем вакыты үткәч чыга. Монда исә, авырыймы, саумы—чыга алмый. Бу чыннан да таш капчык инде.

Мине башта ярымподвалдагы палатага керттеләр. Монда 10-15 көн карантин үтәргә тиеш икәнмен. Камерада минем белән дүртәү булдык. Берсе бик тә чәүчәләк, гасаби бер кеше иде. Украин. Берсе диңгезче штурман. Берсе эстон кешесе, биредә күптәннән утыра икән. Аңа нигәдер «Иван» дип дәшәләр иде.

*—Больницада—яталар. Төрмәдә—утыралар. Сез «утыра» дидегез. Димәк, сез анда берберегезгә авырулар дип карамагансыз?.. Чын психик авырулар бар идеме соң?*

—Сирәк-мирәк кенә. Алары да асылда биредә ята-ята чирләгән кешеләр. Профессор Фабрикант кебек.

*—Фабрикант—фамилияме?*

—Әйе. Эстон бик тә әйбәт, киң күнелле кеше икән. Гомумән, Балтыйк буеныкылар тәрбияле, культуралы дигән тәэсир калды миндә.

Менә шул эстонга әллә посылка килгән, әллә передача булган. Анда кипкән җиләк-җимеш бар иде. Ләкин минем тәмәке бик тә истә калган. Бездә махра—махорка үстерәләр бит. Аннан да агулы нәрсәнең булуы мөмкин түгел. Ә Балтыйк буенда ничектер мүк тәмәке үстерә беләләр икән. Шундый да хуш исле инде! Тәтене дә хуш исле. Җәлләми иде, бирә иде, төреп тарт, дип.

Диңгезченең исә штурман дәреслеге бар икән. Укырга әйбер булмагач, шуны актаргалый башладым. Һәм анда кояш сәгате схемасын күреп алдым. Шуны ясап та куйдым.

*—Рәсеменме?*

—Юк, үзен. Катыргыдан, башка нәрсәләрдән. Прогулкаларга да алып чыккаладым әле мин аны. Дөрес күрсәтә иде сәгатьне.

*—Сүз әйтмиләр идеме соң?*

—Юк, бу төрмә түгел инде. Әйбер ясауда бик оста кешеләр бар иде монда. Берәү миңа бернинди коралсыз-нисез пенал ясап бирде.

*—Җиләме шул ипидер инде. Материал ни?*

—Материал—кәгазь. Ләкин, ничек кенә җилемләсәң дә, кәгазьдән картон ясарга кирәк бит әле. Ул тип-тигез булып катсын. Бөтен почмаклары да килгән, төп-төгәл ябыла торган пенал иде бу!

*—Нәрсәгез бар иде соң пеналда тотарлык?*

—Карандаш бар иде.

*—Сыңар карандашка пенал!*

—Сынар дип, сынар гына булмады инде ул аннан. Кәҗәсе кыйммәт түгел, мәзәге кыйммәт бит аның.

Монда айга бер мәртәбә хат язарга рөхсәт итәләр. Мин татарча язам инде. Бер татар әфисәре укый аны. Авылдан җавап килгәч, тагын ачып укыйлар. Ручка белән яза башладым. Шул ук кеше кара савыты да ясап бирде. Аның теге кара сала торган җирен алюмин теш пастасының авыз тирәсеннән әтмәлләгән.

*—Кем иде соң ул, нинди рәк кеше?*

—Бернинди таныш лык-ни юк. Ул бит бушка эшләми. Мин йә берәр порция май бирәм. Иртән безгә менә моның чаклы май эләгә.

*—10 граммдыр инде—армиядә безгә дә бирәләр иде.*

—20 дә булырга мөмкиндер.

*—Ә тегендә, тикшерү үткәндә бирәләр идеме соң?*

—Анда юк. Тозлы балык бирәләр иде. Тәмле иде балыклары—тозланган треска.

*—Төрмәдәгеләр өчен генә махсус тәмсезне эшли алмаганнардыр шул инде.*

—Ул елларда сәяси тоткыннарның хәленә халыкара контроль кебек нәрсә дә

бар иде бит...

*—Карантин узгач ничек барды тормыш?*

—Сигез кешелек палатага күчерделәр. Мин башта ишек төбендә булдым, аннары, Шулейн дигән галим белән танышкач, тәрәзә янына күчтем.

*—Урын буш идемени?*

—Анда бер агай үлеп китте. Мин ул чакта әле мәет яткан җир дип шикләнә торган яшьтә түгел. Тәрәзә түбә язар-нитәр өчен дә җайлы. Тик тәрәзә берни күрсәтми. Махсус эшләнгән—соры тоныкпыяладан, эчендә металл чыбыклар калдырып—ватылмасын өчен.

*—Ватып чыгып булмый, димәк.*

—Ватып кая барасың ди 3нче каттан?

*—Ышан сезгә, сез бит «психлар».*

—Форточканы ачып була үзе. Кайвакытны менеп басам да, озак кына карап торам. Еракта агачлык күренә. Урыс зираты һәм парк бу—Горький паркы. Ике арадан поезд үткәли—тавышы ишетелә инде... Бер тапкыр шулай парктан музыка тавышы килеп ирешә... Джаз. Бервакытны Казанда джаз шактый көчле иде бит.

*—Лундстрем!*

—Әйе, Олег Лундстрем, аның оркестры Казанда чак иде бу. Менә шушы ерактан ишетелгән джаз авазы үзәкләрне өзде дә инде!

*—Тылсымлы дәрт тулы музыка, сез—яшь-яшь, һәр матур авазны ымсынып, дәшү, чакыру дип кабул иткән, тормышны тансыклаган чак.*

—Әйе, искиткеч нык тәэсир итте миңа бу музыка, джаз мине бу тормыштан котылырга өндәде. Киләчәккә дәште. Нindидер могҗиза да катнашты кебек монда. Бу иң әүвәл җилнең парк ягыннан исүе. Аннан калкулыкны үтеп килүе. Кайчагында тавыш дулкыннары да яктылык дулкыннары кебек сынып-кәкрәеп килергә мөмкин икән.

Шуннан соң мин бу кыргыйлык-йомыкыйлыктан арына төшәргә булдым.

*—Ягъни?*

—Ягъни бу тәртипкә буйсынгандай итеп. Эш бүлеге дип атала иде инде—шунда язылырга булдым. Берәүләр көн саен килеп, эшләп утыралар иде. Тегүчеләр—алары безнең арада да бар. Аяк киеме ремонтлаучылар—күршедәге зэклар, ләкин әшәке уголовниклар түгел. Аннан инде—рәссамнар, картиналарның копияләрен алу кебек эшләр майтаручылар. Мин дә шунда язылдым.

*—Белмәгән килеш тә алалармени анда? Өйрәтәләрмени?*

—Мазуренко дигән хәрби врач безнең белән утырадыр иде. Исеме Александр. Менә шул Мазуренко художник буларак та шактый сәләтле иде. Агач тактада бизәкләр, бер-берсе белән үрелгән чәчәкләр ясаудан башладым мин. Кайберләрен Мазуренко да ошатты. Аннан соң, майлы буяу белән эшли торган рәссамнар өчен, берәр картинаның зурайтылган күчермәсен әзерли, ягъни караламалар ясый башладым. Бер тапкыр миңа, күрәсең, монда психиатрлар да катнашкандыр, «Прием в комсомол» дигән рәсемнең күчермәсен ясауны йөкләделәр. Анда бер чибәр генә кызны комсомолга алалар. Райкомолладыр инде бу, җитди чырайлы яшьләр өстәл тирәсендә тезелешеп утырганнар. Кыз басып тора. Уртада, тумбочкада, Сталин бюсты. Менә нигә биргәннәр икән миңа бу эшне. Янәсе, ясармы бу Сталин бюстын, әллә баш тартырмы? Мин шундук уйлап куйдым: бу минем файдага була ала. Картинаны квадратларга бүлеп күчерәсең бит инде. Сталинны аеруча вак квадратларга бүлдем. Аны нәкъ шундый итеп күчердем дә куйдым. Башкаларны ничек эшләгәнемне хәтерләмим, ә менә кызны, бигрәк тә аның түшен, матур балтырларын ясаганда тирләп пештем. Хәтта кул да калтырый башлады.

*—Егет, ир-ат уянган берәүдә!*

—Әйе, шулай булды шул. Кыз да, тулаем рәсем дә шәп кенә килеп чыкты кебек. Мондый шөгыль үземә дә кызык тоелды. Нәрсәдер биргән инде ул миңа.

Аннары Яңа ел кичәсенә чакыру билетлары да ясадым әле мин. Тышына төсле

карандаш белән кар кызын да төшердем. Мазуренко карады да моны, башкаларны да үз янына дәште. «Татарка!» диделәр беравыздан. Моңа үзем дә гаҗәпләндем. Кар кызы, ягъни ниндидер абстракт кыз ясаган идем кебек юкса. Мазуренко исә, шулай була ул, аңышмастан үзеннән-үзе эчтән килеп чыга, диде. Искиткеч әйбәт кеше иде Александр Мазуренко.

*—Үткән тормышы нинди иде соң аның? Монда каян килеп эләккән?*

—Украинаны немецлар басып алгач, анда «Самостийная Украина!» дип оран салалар. Һәм ирекләләр туплый башлыйлар. Мазуренко пленга эләккән була. Язылa инде ул. Безнекеләр килеп, Украинаны азат иткәч, аны штрафбатка алалар. Иң хәтәр урыннарга, үлем күзенә шуларны куалар бит инде. Бер йорт немецлар кулында иде, дип сөйләде ул үзе. Бер канатын, ниһаять, алалар. Икенчесенә исә якын да җибәрми немецлар, пулеметтан кыралар гына. Бер-бер артлы берничә кешегә гранаталар бәйләме тоттыралар, качып-посып барып пулеметны шартлатырга дип—чүкеп кенә торалар боларны. Чират Мазуренкога җитә. Шунда ул нәзер әйтә. Әгәр дә мәгәр исән калам икән, Катюша исемле кызга өйләнәм, ди. Ничек итсә итә, гранаталарны теге пулеметка тондыра ул. Тик менә Катя-Катюшасын гына һаман очрата алмый икән. Төрмәдә бик очрамыйдыр шул инде.

*—Романтик егеткә моны ишетү күңелле булгандыр.*

—Бик якынайган идек без Мазуренко белән. Аның бер хикәясен дә укыган идем әле мин. Миңа ул чын талант булып тоелды. Бу хикәя Шукшинның «Калина красная»сын хәтерләтә иде.... Әмма киләчәк язмышы гына нинди булгандыр. Алып киттеләр аны. Әше һаман ябылмаган икән. Аның миңа, кайбер сәерлекләрне махсус та эшлим, дип әйткәне бар иде. Алдап җиткерә алмаган, күрәсең... Менә шундый кешеләр арасында булдым мин анда.

*—Ничектер үтеп киттек. Сез караваты янына күчкән галимнең исемен атаган идегез.*

—Шулейн, Соломон Шулейн. Яһүд булырга тиеш ул. Прогулкада йөргәндә таныштырдылар безне. Үзем теләдем инде. Монда шәп бер галим бар, вакытыңны әрәм итмә, аннан ни булса да алып кал—шулай диде миңа берәүләр. Шулейн Германия кешесе, русча бер авыз сүз белми икән. Шөкер, аның янында гел ахирәте, СССРда яшәгән немец кешесе була иде. Гозеремне кире какмады, ризалашты ул. Нәрсәң бар, биргәләрсең әзрәк дип кенә әйтте. Ризык-фәлән инде. Шөкер, үз ягыбыз булгач, миңа ярдәм дә килгәли. Аның исә бернинди багланышы да юк.

Чыннан да, күп нәрсә бирде миңа Шулейн. Бер-ике, күп булса өч көннән бер язу тулы мәктәп дәфтәре тоттыра иде ул миңа. Карандаш белән бик пөхтә итеп язылган текст. Немец телендә. Беренче дәфтәрдә Германия тарихы бәян ителгән иде. Икенчесендә—Эйнштейнның чагыштырмалылык теориясе. Өченчесендә—логика, безнеңчә әйтсәк, мантыйк нигезләре... Шулай итеп миңа төрледән-төрле гыйлем керә торды. Аның чыннан да киң колачлы, тирән акыллы зур галим булганлыгын аңладым мин.

*—Немецча текстны ничек шулай сеңдерә алдыгыз соң?*

—Башта ярдәм иттеләр—немецча белүчеләр бар иде анда. 1-2 айдан миңа тылмач кирәк булмый да башлады инде.

Шулейннан да алда Гойхбарг белән танышкан идем мин. Вышинскийны беләсездер инде?

*—Беләм, генераль прокурор. Берләшкән милләтләр оешмасында СССРдан тәүге вәкил булган кеше.*

—Менә алар Гойхбарг белән үсү, карьера дигәндә гел көндәш булганнар. Бик тә акыллы кеше.

*—Гойхбарг белән ничек таныштыгыз инде?*

—Үз бәясен белә торган зат бу. 3-4 кеше белән генә аралаша иде. Домино уйнап таныштым мин аның белән. Йөрергә чыккач. Ә мин кешеләр белән аралашуга, уен-көлкегә бик тә сусаган идем. Моның шаянлыгы исә йөзенә чыккан. Домино уйнарга маһир иде. Бер тапкыр, прогулка вакытында, почмактагы такта өстәл каршына

килеп утырды бу. Янчыктан доминолар чыгарып өстәлгә салды. Фил сөягенә тартым пластмасстан ясалган ап-ак доминолар. Матур да инде! Килеп утырдым мин моның каршына. Тагын икәү килде, уйный башладык. Оста бу, чукынган! Домино рәтен бик белмәсәм дә, ана кирәклене чыгып, аның жаеннан торып уйный алдым бит. Ошатты бу минем уенны. Шуннан якынаеп та киттек. Әйбәт кеше иде Гойхбарг. Карун түгел. Ана Мәскәүдән посылка килгәли. Посылкадан татлы сохари исе чыгып тора. Мина да бер сохари эләкми калмый инде.

Шулейн белән без остаз белән шәкерт булсак, Гойхбарг белән бабай һәм онык кебек идек.

*—Әңгәмә башында сезнең авыздан төрмәдәге генетиклар дигән сүз чыккан иде.*

—Үзем дә шуларга кучмәкче идем, әйе. Биолог галимнәр бик күп иде бу «психханә»дә. Аларның да ниндиләре әле—сүгелгән, каргалган генетиклар. Бөтенсоюз Авыл хужалыгы академиясенең 1948 елгы сессиясе генетиканың ялган концепциясен бар иткән, Сталин рухландырып торган Лысенко һәм аның тарафдарларының жинүе белән төгәлләнде. 13 яшендә генә укый-язарга өйрәнгән. Лысенконың үзен шул Академиянең президенты итеп сайладылар. Жинелүчеләрнең язмышы мина мәгълүм түгел иде. Аларның бер өлеше белән менә монда очрашырга язган икән. Теге профессор Фабрикант дигәнем дә, ботаник ул, шушы статья белән эләккән.

Менә шул генетикларга, 6-7 кеше булганбыздыр инде, әйдә, безне агартыгыз әле, дип мөрәжәгать иттек. Статья астында булгач, куркучылары, тел яшерүчеләре дә бар иде. Бу эшкә дәртләнеп алынучы да табылды. Күрше палатадан Ростислав Степанов безгә лекция арты лекция укып торды. Моннан аның үзенең дә ләззәт алганы сизелә иде. Рус фамилияле булса да румын-бессараб чырайлы иде. Шулкадәр дә оста һәм мавыктыргыч итеп сөйли иде ул, минем башка «Их, биолог булып китәсе калган ла!» дигән үкенүле уй килде. Абзыкай астрономияне дә кысрыклап чыгара язды бит хәтта ки!

Лысенкочыларның бер чәчкәч, чүп үләне кебек мәңге үсә торган күп башаклы бодай кебек, Сталинны гына түгел, Хрущевны да сихерләгән әкиятләре күптән онытылды инде. Әмма фән һәм авыл хужалыгы күпме зыян күрде ул елларда! Мин үзем исә бирелдәге палата һәм камераларда әйтерсең лә тулы бер академия үттем.

Моны укыган кешеләргә анда академия генә түгел, ял йорты да булгандыр кук тоела башлагандыр, бәлки. Ләкин юк, арыта, алжыта иде бу тормыш. Жанда да, тәндә дә ниндидер киеренкелек туплана бара иде. Бер тапкыр шулай, хәтерләмим инде, ярамаган сүз әйттеме шунда, палатадагы миннән өлкәнрәк берәүне бәрдем дә ектым. Хәер, кирәкмәгәндә юл куярга, үзенне бастырырга да ярамый монда... Чыңгыз хан турындагы киноны карагач, мине, ярымшаяртып, «Потомок Чингизхана» дип йөртә башладылар хәтта.

*—Нинди төшләр күрә идегез?*

—Иркенлекне, басу-кырларны күрә идем. Өйдә йөргәнне. Төш юрау бар иде монда. Әйбәткә чыгарырга тырышып. Бер төшемдә коега егылып төшеп киттем мин. Бурасы тимер. Суга төшеп житә яздым. Аның салкынлыгын да тойдым инде. Палатадагылар шуны да минем файдага юрый алдылар.

*—Бөтенебез дә белә торган затлар да утырмадымы анда сезнең белән?*

—Порфирий Ивановны беләсездер, шәт. Су белән дәвалау «профессоры»н. Мин үзем күрмәсәм дә, аның турында легендалар йөри иде. Монда ике тапкыр булып чыккан ул. Тән температурасын теләсә кайчан 40 градуска житкерә алуы белән врачларның нервысын күп ашаган. Бу осталыкны аннан бер актер отып калган, анысын күреп белдем. Мин ясаган кар кызын «татарочка» диючеләрнең берсе инде ул. Аның температурасын үлчәп тә маташмаганнар.

Прогулкада йөргәндә Балтыйк буе кешеләренең «Пятс!» «Пятс!» дигәнен ишеткәли идем, ни әйткәннәрен анламый идем. Баксаң, Эстониянең беренче президентының исеме икән бу. Ул да бирелдә икән, ләкин нык кына авырый икән. Эстоннар алган посылкаларын да иң әүвәл аңа китергәннәр. Рентгена барганда

безгә, унлап кешегә, ятып авыручылар бүлеге аша үтәргә туры килде. Шунда берәү пышылдап кына «Пятс» диде һәм бер палатаның ачык ишегенә таба башын изәде. Караватта ак күлмәк-ыштаннан бик тә йончыган кыяфәтле бер карт утыра иде. Аны күргәч, мин бик дулкынландым. Хәтта пионерлар күк кулны өскә күтәреп, «салют!» дип сәлам бирәсем дә килгән иде. Ләкин тыелып калдым. Ярамаганга түгел, авыру кешене борчудан куркып. Эстониягә совет гаскәре кергәч, 1940 елны кулга алалар Константин Пятсны. Мин күргәндә аңа 76 яшь булган. Шушында, Казанда дөнья куйгандыр дип уйлап йөргән идем мин аны. Баксаң, 1956 елда бугай, Эстониягә кайта алган икән. Ләкин шунда бөтен Эстониядән аның янына халык агыла башлаган. Моны күреп, бу 82 яшьлек картны тагын кулга алганнар һәм СССРның төньягына, Вологда өлкәсенә дип хәтердә калган, алып киткәннәр. Шул елны ук шунда үлгән дә ул. Ләкин эстоннар аны онытмаганнар. 90нчы елларда авылларның берсендә каберен эзләп табып, җәсәден илләренә алып кайтканнар... Моны белгәч, сөякләре Архангел зиратында һәм башка җирләрдә сыкрап яткан асыл затларыбыз искә төште. Татарның чиксез битарафлыгы, ваемсызлыгы искә төште...

*—Чыгу вакыйгасы ничек булды ул?*

—Алдан белмәдем мин моны. Врачлар, минә өегездән килделәр, алып китәргә, дигәч, каушап та калдым әле. Әйберләремне дә җыя алмадым. Кайсын бүләк иттем, кайсы болай калды дигәндәй.

*—Пенал да калдымы?*

—Калды. Пенал, кара савыты, төрмәдә кадерле тоелган башка нәрсәләр өйдә авыр ядкарь булачак иде.

*—Иреккә чыккач, нәрсәгә исегез китте?*

—Өзлексез бара алуга. Барасың, тагын барасың. Ничәдер атлау белән кырт борыласы юк. Чиксезлек! Бер атна-ун көннәрдән генә узды бу. Иркенлек, пространствоны тою рәхәт иде.

*—Моннан чыгу юк дигән идегез бит. Ничек чыга алдыгыз соң?*

—Шул наивлык, сабыйлык алып чыгышкандыр инде. Психиатрлар ялганны бик оста тоя. Сталин да коткарышкандыр, бәлки. Бюстын ясауны әйтүем. Бераз могҗиза кебек тә инде бу хәл. Көтелмәгән хәл.

*—Сезгә кадәр һәм сездән соң чыгучылар булдымы?*

—Мин анда чакта чыккан кешене белмим. Миннән соң Степанов чыккан. Теге безгә лекцияләр укыган галим. Аның бөтен гаебе фәнгә турылыклы булу гына бит инде. Бу генетик... Бөгелмәдә кирпеч заводына эшкә урнашкан. Мине эзләп тапты ул, авылга өч тапкыр килде...

*—1950нең гыйнварында утырттылар сезне.*

—1951нең сентябрендә чыктым.

*—Шул вакыт аралыгын үткәргән җиргә читтән карап торырга туры килмәдеме берәр?*

—Булды андый хәл. Ничектер көтмәгәндәрәк килеп чыктым мин ул якка. Таш диварны, таныш шомлы биналарны күрүем булды, аяк шып туктап калды. Берничек кузгатып булмый. Борылдым да, тиз-тиз кире китеп бардым.

Казандагы бу сәяси тоткыннары белән данлыклы психиатрия хастаханәсе бер уйлаганда газап урыны инде. Икенче уйлаганда, Гойхбарг кебек күпме күренекле кешене монда махсус салганнардыр, зуррак газаптан яки хәтта үлемнән саклап калыр өчен. Без исә аларга фон гына булганбыз.

*—Әмма сезне дә саклап калган ул.*

—Шулай, әйе.

*Әңгәмәдәш—*
**Рәфикъ ЮНЫС.**

*Дәвамы бар.*

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Югары Аккуҗа

Югары Аккуҗа авылы Апас районында, район үзәге Апас авылыннан 34 чакрымда, Колангы тимер юл станциясеннән—7, Борындык пристаненнан 15 чакрым ераклыкта урнашкан. Югары Аккуҗа авылы—җирле үзидарә советы үзәге.

Аккуҗа атамасы тарихи чыганакларда искә алына.

Д. А. Корсаков бастырып чыгарган белешмәдә (XVIII йөз) Югары Аккуҗада 17 керәшен татары яшәве билгеләнә. Азбаба авылы Кече Аккуҗа дип бирелә һәм анда 27 керәшен татары яшәгәнлеге күрсәтелә. Бу авыл Имәлле суы янына утырган.

1898 елгы белешмәдә Югары Аккуҗа авылында татарлар яшәгәнлеге әйтелә. К. П. Берстель белешмәсендә күрсәтелгәнчә, Югары Аккуҗа (Мошкево) авылында 624 татар, Азбабада (Аккуҗа) 601 татар һәм чуаш кешеләре яшәгән.

Авыл атамасының килеп чыгуы турында халык телендә мондый риваять йөри. Имеш, моннан күп еллар элек бу авыл урынында куе урман булган. Бер агай үзенә йорт салу өчен урман чистарткан һәм шунда төпләнгән. Тора-бара бирегә башка гаиләләр дә килеп утыра башлаганнар. Авылга нигез салучы кешене Хуҗа дип йөрткәннәр һәм авыл исеме Аккуҗа дип кулланыла башлаган.

Аккуҗа авылы янында гына Имәлле суы ага. 1,5 чакрымда гына Зөя елгасы үтә. Авыл тирә-юнендә Ай күле, Төнзирек, Урта күл дигән күлләр бар.

Аккуҗада татарлар һәм чуашлар дус булып яши. Авылның урамнары да шуңа бәйле рәвештә Татар башы һәм Чуаш башы дип йөртелә. Элек Татар башы урамында мәчет, Чуаш башы урамында чиркәү эшләгән. Чуашлар татарларның дини бәйрәмнәрен белеп торганнар, хөрмәт иткәннәр, мәчеткә җимешләр һ.б. бүләкләр китергәннәр. Татарлар исә чуаш балаларына буялган йомырка бүләк иткәннәр, үз балаларына да шундый йомыркалар пешергәннәр. Татарлар һәм чуашлар әле дә бер-берсен хөрмәт итеп, бер-берсенең бәйрәмнәрен белеп, искәреп торалар.

Авыл зират өстендә утырган (халык шулай сөйли). Авыл халкы идән аслары, нигезләр казыганда кеше сөякләре һәм скелетлар чыккан. Авыл халкы бу мәет сөякләрен элекке заманнарда булган сугышлардан калган каберлекләр дип исәпли.

Татар башы урамын чыгып бераз баргач, яңа зират дип аталган зират, ә Чуаш башы урамы тирәсендә чуаш зираты урнашкан.

Аккуҗа урамында хәзер дә ялгыз каберлекләр очратырга мөмкин. Яңа урам башында яши торган Зинтимерова Люзияләр йорты каршында тимер рәшәткә белән уратып алынган ялгыз кабер тора. Моннан берничә дистә еллар элек Мәрдәнова Әлфияләр каршында чокыр булган, караңгы төшкәч анда һәрвакыт яктылык күргәннәр. Авыл халкы фикеренә караганда, бу—кеше сөякләрендәге фосфорның яктыруы нәтиҗәсе булырга тиеш.

Зиратлар агач рәшәткә белән уратып алынган. Аларның махсус караучылары бар.

Авыл урманнарга бай. Нарат урманы Имәлле елгасының аръягында, Төнзирек

*Дәвамы. Башы 2006 елның бнчы санында.*

күле янында җәелгән. Бу урманның бер өлеше инде шактый борынгы, икенчесе әле күптән түгел утыртылган. Шул урмандагы яшьрәк агачлар арасыннан кереп киткәч бер матур алан җәелеп ята. Әлеге аланда бик күнелле итеп сабантуйлары үткәрелә. Урманда гөмбә бик әйбәт уңа, моннан халык күп итеп гөмбә җыя.

Зөя аръягында Ивановск таулары бар. Анда Явыз Иван Казан ханлыгын җимергәннән соң килеп урнашкан урыс авыллары да утырган. Тау башында электән калган зур чиркәү, алма бакчасы да шунда булган. Бу бакчадан көз көне халык капчык-капчык алма ташый.

Элек авылда мәдрәсә булган. Малайларны мулла үзе, ә кыз балаларны абыстай укыткан.

## Әзәк авыллары

Югары Әзәк Арча районында, район үзәге Арча эшчеләр бистәсеннән 15 чакрымда, җирле үзидарә советы үзәге Иске Кырлай авылыннан—6, Казан шәһәреннән 81 чакрым ераклыкта урнашкан. Ә Түбән Әзәк авылы хәзер таралып беткән.

Югары Әзәк һәм Түбән Әзәк—күпне күргән авыллар. Арча юлы өстендәге Әзәк авылы Казан ханлыгы чорыннан ук мәгълүм. Казан өязенең теркәү кенәгәләрендә (1602—03) Әзәк искә алына, анда йомышлы татарлар һәм керәшен татарлары яшәгәнлеге күрсәтелә.

Н.Н.Вечеслав җыентыгында (1878) Түбән Әзәк авылы Икенче Әзәк дип аталган һәм андагы 46 йортта 144 ир-ат һәм 146 хатын-кыз теркәлгән. Авылда бер су тегермәне һәм мәйханә (кабак) булган. Югары Әзәктәге 95 йортта 218 ир-ат һәм 260 хатын-кыз көн иткән. Авылда бер җил тегермәне эшләгән.

Түбән Әзәк авылы Югары Әзәк кебек үк Ия суы буена, Себер элемтә юлының сул ягына утырган. Югарыда искә алынган бу авыл халкы яңа чукындырылган ясаклы кешеләр итеп күрсәтелә. Авылда барлыгы 44 хуҗалык булып, аларда керәшенлеген ташлап яңадан исламга кайткан 97 ир-ат һәм 101 хатын-кыз яшәгән. Тормышлары уртача булган, он тарту, киндер сугу һәм тегүчелек белән шөгыльләнгәннәр.

Югары Әзәк һәм Түбән Әзәк авыллары халкы элек июль ае башында Өчиле, Бирәзәбаш, Урта Бирәзә, Зур Бирәзә, Мөндеш, Югары Мәтәскә, Түбән Мәтәскә, Кәче һәм Күкчә Бирәзә авыллары белән Күкчә җыены бәйрәм иткән. Икенче төрле аны Кыр җыены дип йөрткәннәр.

Көчләп чукындыру сәясәте башлангач, ике Әзәк халкын да Ия суына коя торган елгага куып кертәләр һәм шунда берьюлы чукындыралар. Чукынырга теләмәгән кешеләрне төрлечә җәберлиләр һәм канга батырганчы кыйныйлар. Шул көннән бу су Кан елгасы дип атала башлый.

## Юртыш

Юртыш авылы Биектау районында, район үзәге Биектау тимер юл станциясеннән 110 чакрымда, җирле үзидарә советы үзәге Мәмдәл авылыннан 1 генә чакрым ераклыкта урнашкан.

Тамак суы буенда утырган Юртыш авылы тарихи чыганакларда еш искә алына. Казан ханлыгы чорында булган авыллар исемлегендә Алат юлы өстендәге Юртыш авылы күрсәтелгән. Казан өязенең теркәү кенәгәсендә (1602—03 еллар) Юртыш авылы шактый күп урында телгә алына, анда ясаклы һәм йомышлы татарлар яшәве күрсәтелә.

Юртыш авылы турында А. Артемьев түбәндәгеләрне яза. Авылдагы 132 хуҗалыкта 549 ир-ат һәм 543 хатын-кыз көн иткән. Анда бер мәчет эшләгән. Авылда бер агач мәчет, мәдрәсә, тимерче алачыгы, кибет, су тегермәне, өч җил тегермәне эшләгән. 1898 елгы китапта Юртыш авылында барлыгы 1157 татар кешесе яшәгәнлеге әйтелә.

И.А.Износков Юртыш авылы турында түбәндәге мәгълүматларны бирә. Апса суы ярындагы Юртыш авылы Гәреч сәүдә юлы өстенә урнашкан. Халыкның тормышы уртача. Алар балта эше, итек-читек тегү, он тарту, мич чыгару белән шөгыльләнгәннәр.

В.П.Семенов житәкчелегендә нәшер ителгән тарихи чыганакта Апса суы буена

утырган Юртыш авылында 1400 кеше яшәгәнлеге, 58 кеше эшли торган ике шырпы фабрикасы булганлыгы хәбәр ителә, Юртыш авылы халкы күрше авыллар белән берләшеп Кабак җыены бәйрәм иткән.

Аксакаллар сөйләвенә караганда, элек бирεдә тоташ урман булган. Әле хәзер дә халык телендә һәрдаим кулланыла торган Ат, Корманай, Ваһаб, Шакир ышналары урман төпләп ясалган. Юртыш авылының элекке урыны хәзер халык тарафыннан Йортлар өсте дип аталган җирдә булган. Элек Юртыш ике мәхәлләгә бүленгән.

Юртышта байлар да булган. Хәмитовлар дигән байлар Юртыш авылында шырпы фабрикасы тотканнар.

Юртыш авылы кешеләре үзләренең күренекле затларыннан Хәмит хәзрәтне атыйлар. Зиратта аның кирпеч белән әйләндереп алынган кабере бар икән. Хәсрәте яисә авыруы булган кеше Хәмит хәзрәткә адарына, сәдака бирә.

Хәзрәт турында авыл халкы хәтерендә шушындый риваять сакланып калган. Авылның ярлы бер кешесе Хәмит хәзрәткә тормыш авырлыгы турында зарланып сөйләгән. Хәмит хәзрәт аңа Кала тавындагы бер агач янына менәргә киңәш иткән. Әлеге кеше агач янына менеп караса, исе китә: агачның тирә-юне алтын-көмеш белән тулы икән. Бу кеше тиз генә өенә кайтып алтын тутырырга зур капчык алып менә. Менсә, аптырап кала: алтын-көмештән җилләр искән. Ул кире хәзрәт янына килә. Аны игътибар белән тыңлаганнан соң, хәзрәт: «Син кесәңне генә дә алтын белән тутырган булсаң, гомерең буе рәхәт яшәр идең, үзең ялгышкансың»,—ди. Хәзрәт бу кешегә нәфес дигән котырткычны тезгенли алмавына төртеп күрсәтә.

Зиратта калкытып язган тагын өч кабер ташы сакланган. Алар арасында Якуб ибн Җәгъфәргә куелган таш та исән әле. Ул инде 200 еллар чамасы тора икән.

## Ябалак

Ябалак авылы Апас районында, район үзәге Апас авылыннан 12 чакрымда, җирле үзидарә советы үзәге Шәм Балыкчы авылыннан—5, Каратун тимер юл станциясеннән—4, Тәтеш пристаненнан 40 чакрым ераклыкта урнашкан.

Ябалак авылы янында археологлар болгар чорларына мөнәсәбәтле әйберләр табалар.

Д. А. Корсаков җыентыгында Ябалак авылында 118 йомышлы һәм 8 керәшен татары яшәгәнлеге әйтелә.

Ябалак авылы зиратында шагыйрь Габдулла Харисның (1893—1931) кабере бар. Ул бу авылда мулла гаиләсендә дөньяга килгән. Башта авылда, аннары Казанда мәдрәсә тәмамлаганнан соң Габдулла 1910-11 елларда иҗат белән шөгыльләнә башлый. Аның шигырьләре «Йолдыз» газетасында, «Ак юл» һәм «Сөембикә» журналларында басылган. Беренче бөтендөнья сугышыннан кайтканнан соң шагыйрь укытучы һәм журналист булып эшли. 1931елда ул туган авылында үпкә авыруыннан үлә.

Аксакаллар авыл оешканга 350 еллар бар, дип сөйлиләр. Имештер, халык агачка беренче килеп кунган кошны көткән. Берзаман агачка ябалак килеп кунган һәм авылга Ябалак исеме кушканнар.

Элек авыл урнашкан урын шау урман булган. Хәзер ул авылдан бер-ике чакрым ераклыкта. Аны Кайбыч урманнары дип атыйлар. Урман җиләк-җимешкә, гөмбәгә һәм чикләвеккә бай. Урман кырыеннан Бия елгасы ага. Хәзер ул кечкенә генә булып калган, элек исә анда берничә су тегермәне булган, дип сөйлиләр. Авыл читендә кечерәк күл ялтырап ята. Халык телендә ул Вәли күле дип йөртелә. Ташлы чокырдан халык мунча ташы ала икән. Аннан ерак та түгел Коры күл дигән җир бар. Кайчандыр аның суы да булган, әлбәттә, ләкин хәтерләүче юк инде.

Урманда бик матур түгәрәк аланда халык сабан туе үткәрә. Аланны Айсалан дип атыйлар. Урман кырыендагы бер урын Лашман чокыры дигән исем йөртә. Бу урыннарда, күрәсең, лашманчылар эшләгән.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

## *«Татар энциклопедиясе» битләреннән*

# М

**МАДЬЯРОВ** Нәҗип Гәрәй улы (3.3.1928, хәзерге Әтнә районы Кызыл Утар ав.—15.4.2002, Яр Чаллы шәһ., туган авылында җирләнгән), шагыйрь, ТССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1991). Казан ун-тын тәмамлый (1962). 1960 елдан журналистлык эшендә: «Коммунизмга» исемле Арча район газетасы редакциясендә бүлек мөдире (1960-63), Лениногорск телевидениесендә редактор (1964-65), «Хезмәт» исемле Балтач район газетасында редактор урынбасары (1966-78). 1979 дан Яр Чаллы шәһ. яши.1979-88 дә №67 СПТУның директор урынбасары. Авыл хезмәтчәннәре, туган як табигате, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләргә багышланган «Син генә уйларымда» (1962), «Җәйге янгыр» (1970), «Мең төрле уй» (1976), «Рәшәле офыкларым» (1979) дигән шигырь җыентыклары авторы. Юмор һәм сатира әсәрләре «Кызыклы шигырьләр» (1990), «Хикмәтле хәлләр» (1995), «Көлке көлтәсе» (2000) җыентыкларына тупланган. Балаларга атап язылган «Ялкын яллы кара айгыр» (1966), «Ямьле кыш» (1971), «Утлы кыя» (1978), «Салават күпере» (1988) кебек китаплары нигездә мажаралы сюжетка корылган, шигырьләре фантазиягә, юморга, нечкә лирикага, табигать күренешләрен сурәтләгәндә шигъри төсмерләргә бай булулары белән аерылып торалар. Бөек Ватан сугышында катнашкан, медальләр белән бүләкләнгән.

Әд.: Галиев Ш. Нәҗип Мадьяров // Казан утлары. 1979. №10; Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т.2.

*Г.М.Габделхакова.*

**МАҖАРАЛЫ ӘДӘБИЯТ**, мавыктыргыч сюжетка, кискен конфликтка, төрле табышмак һәм серләргә корылган әсәр; эчтәлеге б-н «авантюр» әдәбиятка, детективка, фәнни фантастикага, юлъязмага (сәяхәтнамәгә) якын. Татар әдәбиятында М.ә. урта гасырларда формалаша башлый. Котбның «Хөсрәү вә Ширин», Сәиф Сараиның «Сөхәйл вә Гөлдерсен», Сәйядинең «Дастаны Бабахан» дастан-поэмалары мәхәббәт маҗараларын поэмалар рәтенә кертәләр. Урта гасыр әдәби традицияләр 19 йөздә дә дәвам иттерелә: К.Насыйринең «Кырык вәзир кыйссасы», «Әфсанәи Гөлрөх вә Камәрҗан», Ф.Халидинең «Әсфе сәхәр вә сәхәр, ягъни мең дә бер сәхәр», «Әлфе ләйлә вә ләйлә», Г.Фәезхановның «Тутыйнамә», Ш.Рәхмәтуллинның «Кылаф белән Турандык», «Малик», «Сәйфелмөлек» һ. б. күп кенә әсәрләр укучыга шәрекъ илләре, мәхәббәт маҗаралары, каһарманлыклар, тәхет өчен көрәш турында сөйлиләр. Вакыт барышында М.ә. формасы үзгәрә төшә. 18 йөздә сәяхәтнамә жанры, һәм аның бер төре—хаҗнамә формалаша башлый. Аноним авторның «Исмәгыйл агай сәяхәтнамәсе», Гали Чокрыйның «Хаҗнамә»се, Мәрҗанинең «Рихләт әл-Мәрҗани»е, Ф.Кәриминең «Европага сәяхәтнамә»се, С.Максудиның «Англиягә сәяхәт»е һ.б. ерак җирләр, башка халыкларның тормышы һәм көнкүреше турында сөйли. М.ә.нең бу төре татар әдәбиятының дидактик традицияләрен дәвам итте. 20 йөз ахыры юлъязмаларында прозаиклар М.Юныс («Юлда уйланулар», «Җиде могҗиза»), М.Мәһдиев («Җир йөзендә алты кыйтга»), Т.Әйди («Оҗмах утравы», «Кардәшләр кочагында») һ.б. әсәрләрендә сәнгати һәм документаль, лирик һәм аналитик башлангычлар берләшә.

19 йөзнең 2нче яртысында М.ә.нең яңа—детектив төре барлыкка килә. З.Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» татар әдәбиятында беренче детектив әсәр булып санала. 1920-30 нчы елларда яхшы б-н яман арасындагы конфликт антагонист сыйныфлар каршылыклары (Г.Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романы) кысаларында карала башлый торган совет детективының аерым бер төре оеша; тора-бара ул өстенлек иткән идеологик юнәлеш басымында социаль һәм антисоциаль конфликтка әверелә (А.Расихның «Бәхет орлыклары», «Урланган хәзинә»). Сугыштан соңгы еллар татар әдәбиятында Р.Ишморатова («Милиция лейтенанты», «Тормыш дәвам итә»), Т.Әйди («Бoҗра» детектив повесте, «Елан угы», «Иблискә ришвәт» маҗаралы романнар) һ.б. әсәрләре таныла. Советтан соңгы елларда М.Насыйбуллинның («Телсез шаһитләр», «Яшерен касса»,

*Дәвамы. 2005 елның 4нче саныннан басылып килә.*

«Капкан»), Ф.Галиевнең («Урман йорты серләре», «Өрәк эзеннән», «Следователь Сомов хикәяләре»), Р.Сәгъдинең («Каргыш») психологик детективлары калкып чыга. Аларда «милиция» детективы традицияләре социаль-әхлакый проблемалар б-н үрелеп бара. З.Фәтхетдинов әсәрләренә («Гөмергә тиң сер»—«Тайна стоит жизни», «Унынчы мәет»—«Десятый мертвец», «Кыйммәтле шартнамә»—«Ценный договор») тарихи ретроспекция хас. Социаль, психологик, әхлакый мәсьәләләр күтәргән детектив әсәрләр сериясен М.Маликова иҗат итә («Хөкем», «Августның беренче кичендә», «Утлар моны», «Югалган якутлар», «Чәчкә балы» повестьләре, «Өермә» романы).

М.ә.нең тагы бер тармагы—фәнни фантастиканың барлыкка килүе 20 йөз башына карый (Ф.Әмирханның «Сәмигулла хәзрәт»е). Бөек Ватан сугышы елларында ул Г.Кутуй әсәрләрендә чагылыш таба («Рөстәм мажаралары»). 1960-70 нче елларда А.Тимергалинның уйлап чыгарылган киләчәк галәмнәре турындагы хикәя һәм повестьләр җыентыклары («Пәһлеван кабере», «Космостан кунаклар»), 1990 нчы елларда реалистик әсәргә мистик элементлары килеп кергән хыялый фантастика әсәрләре (Ф.Латыйфиның Р.Якушев б-н берлектә язылган «Тамга», «Игезәкләр», «Соңгы кисәтү» повестьләре) басылып чыга.

Хәзерге көндә М.ә. детектив, «фэнтези» (Г.Гыйльмановның «Албастылар», «Оча торган кешеләр»), авантюра-мажаралы повесть (Н.Гыйматдинованың «Елан»), «хатын-кыз» романнары (М.Маликованың «Шәфкать», «Фидая») әдәби әкиятләр (Р.Батулланың «Елантау»ы), «киң халык (масса) өчен язылган әдәбият» б-н якынлаша. 20-21 йөзләр киселешендә мажара жирлеге бүгенге кешегә (Н.Гыйматдинованың «Таң ата да, кич була», «Аргы якта, бирге якта» повестьләре), вазгыятькә (Ф.Латыйфиның «Бәйсез этләрне атарга» повесте) тәнкыйди карашны көчәйтү йөзеннән һәм уен башлангычын (игровое начало?) (З.Хәкимнең «Агымсуда ни булмас...» романы)көчәйтү өчен, «автор үлеме» концепциясен куллану өчен (Т.Миннуллинның «Минһаж мажаралары» романы; А.Фәләхнең «Татлы газап») файдаланыла.

Әд.; Бәширов Ф.К. XX йөз башы татар прозасы. К., 2002; История татарской литературы Нового времени (XIX—начало XX века). К., 2003.

*Д.Ф.Заһидуллина.*

**МАЗУНОВ** Мөнир Хәсән улы (1.4.1978, хәзерге Пенза өлкәсе Лопатино р-ны Иске Карлыган ав.—31.3.1987, Казан), шагыйрь. Казан педагогия ин-тын тәмамлый (1949). Бөек Ватан сугышында катнаша, Ерак Көнчыгыш фронтның «Тревога» газетасында хәрби корреспондент. 1946-59 (бүленеп) елларда Татарстан радиокомитетында мөхәррир, соңрак начальник урынбасары. 1949-53 тә совет гаскәрләренең Төньяк группасы составындагы «Вольность» газетасында өлкән әдәби хезмәткәр. 1960-63 тә Татарстан кит. нәшриятында өлкән мөхәррир, 1967-71 дә «Кооператор Татарстана» газетасында җаваплы мөхәррир. «Йөрәк җырлый» (1959), «Күнелем аккошы» (1966), «Ул кайтмады» (1968), «Ак күгәрченнәр» (1972), «Туган як» (1975), «Офыклар» (1988) исемле шигырь җыентыклары авторы. М.ның шигырьләренә нечкә лиризм хас, аларда туган як табигате ачык картиналарда чагыла. Композиторлар Б.Мөлеков, М.Мозаффаров, Р.Яхин, Ә.Бакиров, З.Хәбибуллин, А.Ключарёв тарафыннан көйгә салынган «Туган як», «Язгы хисләр», «Яшьләр җыры», «Әниемнең җылы кочагы» кебек җырлары халык арасында киң популярлык казанды. Балалар өчен дә «Энесенә ул апа» (1960), «Урал улы» (1962), «Нәни төзүчеләр» (1967),»Уйнагыз, балалар» (1985) дигән китаплары да бар. А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, С.Я.Маршак, Н.Хикмәт, П.Хузангай шигырьләрен татарчага тәрҗемә иткән. Медальләр белән бүләкләнгән.

Әсәр.: Ихлас күнелдән. К., 1980.

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т.2.

*Дәвамы киләсе саннарда.*



*Фронтовик каләмдәшләр. Сулдан уңга: язучы Әнәс Галиев (1920-196) һәм шагыйрь Нури Арсланов (1912-191), 1989 елда төшерелгән фото.*



*Шагыйрь Харрас Әюпов (1946-2008).*



*Балык Бистәсе төбәгеннән чыккан ир-егетләр, әдәбият-сәнгатебезнең күренекле вәкилләре. Сулдан уңга: шагыйрьләр Равил Фәйзуллин, Роберт Әхмәтҗанов һәм артист Равил Шәрәфиев. 2007 ел.*



*Замандашлары һәм якташлары белән соңгы чәркә. Уртада шагыйрь Зөлфәт (1946-2007). Вафатына 1 ай калгач төшерелгән фоторәсем.*



*Шагыйрә Флера Гыйззәтуллина (1931).*



*Сынчы, монументаль сәнгать рәссамы Фәһим Фәсхетдинов (1944). 80нче елларда төшерелгән рәсем.*

# МОХТАР ӘҮЭЗОВ ҺӘМ МУСА ҖӘЛИЛ: ӘДӘБИ БАГЛАНЫШЛАР ТАРИХЫ

## 1

XX гасырның 50нче еллары уртасында татар шагыйре Муса Җәлилнең 1942-1944 елларда фашист төрмәләрендә язган шигырьләре җәмгыять һәм киң катлау укучыларның байлыгына әверелде.

1953 елдан алар гәҗит-журналларда басылып чыкты, күпчелек очракта «Моабит дәфтәрләре» исемендәге җыентыкларда тупланып дөнья күрделәр. Шигырьләр иң элек татар һәм урыс телләрендә, соңрак Советлар Союзының башка телләрендә һәм чит илләрдә басылды. Шагыйрьнең соңгы җырлары кешеләр күңелендә яңгыраш тапты, кыю ватанпәрвәрләрнең холкы һәм немец илбасарларына каршы көрәшүчеләрнең тиңдәшсез батырлыгы белән горурлану уятты.

1957 елның иң яхшы әдәби әсәрләре өчен премияләр бирү мәсьәләсе килеп тугач, СССР Министрлар Советы каршындагы Әдәбият һәм сәнгать комитеты илнең иҗат берләшмәләре, учреждениеләре һәм коллективлары тарафыннан тәкъдим ителгән күпсанлы кандидатуралары арасыннан иң лаеклыларын ачыклау максатыннан фикер алышулар уздырды.

Комитетның әдәбият секциясе утырышларының берсендә казакъ язучысы һәм җәмәгать эшлеклесе Мохтар Омархан улы Әүэзов Муса Җәлилне бүләкләүне таләп итеп чыгыш ясый.

Кыска гына кереш сүздән соң ул, уй-фикерләрен һәм тәэсирләрен хис белән белдереп, шагыйрь иҗатын тәфсилләп бәяли.

«Моабит дәфтәрләре»н укыганда сез нindидер өстәмә тойгыларның озата барганын—шигырьләрнең төрмәдә, шагыйрьнең «муенында элмәк» булган килеш язылганлыгын сизәчәксез»,—диде Мохтар Омархан улы. Комитет әгъзаларының кайберләре Муса Җәлил шигырьләренең урыс теленә тәрҗемәләренә шикләнеп һәм түбәнсетеп карамасын өчен, М.Әүэзов чыгышын башлап җибәргәндә шигъри әсәрләрне тәрҗемә итүдәге кыенлыкларны һәм еш кына төп нөсханең шомартылуын искәртә. Чынлап та ул чакларда да, элгәрерәк, 30-40нчы елларда да, тәрҗемәчеләр тугандаш милләтләр шигырьләренең кимәлен билгеле бер дәрәҗәгә кадәр «житкерергә» омтылганнар. Ихтимал, шуңа да Муса Җәлилнең урыс теленә тәрҗемә ителгән шигырьләрендә төп нөсхә белән чагыштырганда тышкы пафос күбрәктер. Чыгыш ясаучы Җәлилнең һәм аның шигырьләре дөньясына тирәнтен үтеп кереп, төрмә юллары авторының нечкә һәм шигъри хисләрен тоемлаган. Ул Муса Җәлил шигырьләрендәге туган җиреннән һәм якын кешеләреннән аерылган тоткынга хас булган сагышны, аның теләсә кайсы минутта тормышының һәм иҗатының фаҗигале рәвештә тәмамланачагын аңлап моңсулануын сизми калмаган.

Яшь чагында Семипалатинск шәһәрендә Татар бистәсендә яшәүчеләр һәм татар интеллигенциясе белән тыгыз элемтәдә булган һәм шул вакытта ук татар телен яхшы белгән казакъ язучысы, ихтимал, шигырьләрне анализлаганда төп нөсхәгә мөрәҗәгать иткәндер. Бу урыс теленә тәрҗемә ителгән «Буря» балладасына бәя

биргәндә үк күренә. М.Әуэзов аны төп нөсхәдәгечә «Буран» дип атый. Ул болай ди: «Безнең тәржемәче Арсений Тарковскийга башка дәгъвабыз юк, әмма баллада исемен автор куйганча «Буран» дип калдырырга кирәк иде».

М.Әуэзов утырышта язучының «төрмәдә бергә утырган бельгияле А.Тимерманска» багышланган шигырьләрен дә игътибардан читтә калдырмый. «Дуслык темасы аның бар иҗатын колачлый»,—дип басым ясап әйтә ул. Күрәбез ки, фашистларга каршы көрәштә нәкъ менә тоткыннарның дуслык хисләре һәм бердәмлеге шагыйрь-ватанпәрвәрнең соңгы шигырьләрен саклап калды һәм халыкка илтеп җиткерде.

Мохтар Омархан улы шагыйрьнең батырлыгы, чын җырчыда гына табигый рәвештә туа һәм нәфис-эстетик формада укучыларга тапшырыла торган ватанпәрвәрлек көче турында әле тагын да сөйләде: «Кызы турында әйтеп, ул Ватан турында сөйли, сөйгән кешесе турында әйтеп, ул Ватан турында сөйли. Әле тагын палач балтасы астына башын куйганда да Ватан турында уйлаячагын әйтә».

Чын поэзиянең көченә, матурлыгына һәм батырлыгына ышанган зирәк рәссам Мохтар Омархан улы йөрәге түреннән чыккан иң мөһим сүзләрен чыгышының ахырында әйтә: «Әгәр дә премиягә бер генә исем лаек дип табылса да, ул Муса Җәлил исеме булырга тиеш. Аның исән булмавы мөһим түгел. Ул яшь һәм сугышның һәр каһарманы кебек үк, безнең белән киләчәктә дә яшәячәк. Шагыйрь күп сүзле, күпшы сүзле түгел, ә ихлас һәм ялкынлы. Ул кылыч йөзенә басып иҗат итә һәм анда хакыйкать ак карга тамган кан кебек ачык күренеп тора».

Күрәбез ки, сүз остасы Комитет әгъзаларына Муса Җәлил поэзиясенең көче гражданлык пафосында гына түгел, ә бәлки аның бөтен соңгы шигырьләрен дә сугарган тәэсирле лирикада да икәнлегенә ышандырырга омтылган.

Әдәби тәнкыйтьче Е.Книпович билгеләп үткәнчә, М.Әуэзов чыгышлары арасыннан аны иң дулкынландырганы Комитетның әдәби секциясе утырышында Муса Җәлил турындагы сүзләре булган: «Сөйләүчедә көнчыгышка хас серле гыйлемлелек, үзенә һәм башкаларга карата олы таләпчәнлек һәм берүк вакытта чит иҗатка сакчыл игътибар берләште». Мохтар Омархан улы Әуэзовка хас нәрсәләр—холкының әхлакый тулылыгы, гражданлык аңының югарылыгы, художник һәм фикер иясе зирәклеге турында Н.С. Тихонов, А.А.Фадеев, Мирза Ибраһимов, Камил Яшен һәм XX гасырның башка сүз осталары да билгеләп үттеләр.

Нәтиҗәдә югары премиягә чын, югары поэзия—кеше рухының көче—киләчәк буыннарның бәхете һәм иреге турындагы китабы лаек булды.

## 2

«Моабит дәфтәре» цикллары өчен Ленин премиясен тапшырганга ярты гасырдан артык вакыт үтте, ә күңелдә кабат-кабат бер сорау туа: әлеге ике бөек язучы шәхсән очраштымы икән?

Бүгенге көндә бу хакта уңай яки тискәре җавап бирү бик кыен. Сугышка кадәр Муса Җәлилне һәм аның иҗатын белмәве яисә аның белән таныш булуы турында Мохтар Омархан улы китап турындагы фикер алышуларда әйтә алмый, чөнки ул вакытта төп игътибарны «Моабит дәфтәре»нә бәя бирүгә юнәлтергә, гадел булырга кирәк иде. Бу чыгышның төп идеясе, поэзияне бәяләүдә төп таләп була, ә өстәмә мәгълүматлар, ярдәм итәсе урында, киресенчә, тоткын җырларына дөрес, тирәнтен анализ бирергә комачаулар, төп максаттан читләштерер генә иде. М.Әуэзов билгеле вакыйга—Алма-Атада Муса Җәлил либреттосы буенча «Алтынчәч» (Н.Җиһанов музыкасы) операсы куелуны да искә алмый бит. Операның премьерасы 1943 елның апрелендә була һәм ул хакта үз вакытында «Известия» хәбәр итә. Мохтар Әуэзовның спектакльне каравы яки кем дигәндә ул хакта ишетүе бик мөмкин хәл.

Әгәр читтән карасак, ике күренекле шәхеснең тормыш юллары, бүгенгечә әйткәндә, төрле орбиталар буйлап үтә.

М.О.Әуэзов—казакъ язучысы, әдәбиятчы галим, Ленин һәм Дәүләт премияләре лауреаты,—1897 елда Семипалатинск өязендәге үзәктән ерак казакъ авылында туа.

Муса Җәлил—татар шагыйре, шулай ук Ленин һәм Дәүләт премияләре лауреаты, Советлар Союзы Герое—1906 елда Оренбург өлкәсендәге үзәктән ерак татар авылында туа.

Муса Җәлил озак кына вакыт «мәскәүле» булды. 5 ел (1926-1931) Мәскәү университетының филология факультетында белем ала, башкаланың гәҗит һәм журналларында эшли, төрле өлкәләрдә—шагыйрь, тәрҗемәче, журналист, либретточы буларак тынгысыз иҗат эше алып бара. 1939 елның февраленә кадәр, Казанга күчкәнче, хатыны Әминә һәм кызы Чулпан белән Столешников тыкрыгындагы үз бүлмәсендә яши.

Мохтар Әүэзов исә—«ленинградчы», 5 ел (1923-1928) Ленинград университетының филология факультетында укый, әдәби иҗат һәм фәнни эзләнүләр белән актив шөгыльләнә. 1926 елда Такта яру заводы хезмәткәре кызына, курсташы Валентина Николаевнага өйләнә.1928-1930 елларда Ташкентта, калган елларда Алма-Атада яши, укый һәм эшли.

Әмма болардан чыгып кына язучылар күрешә алмаган, иҗат һәм тормыш юллары кисешмәгән дип әйтә алмыйбыз.

30нчы еллар—М.Әүэзов иҗатында уңышлы чор. Ул киләчәктә танылачак, укучылар һәм тәнкыйтьчеләр тарафыннан югары бәяләнәчәк повесть һәм хикәяләр иҗат итә («Һәлакәтле ел», «Үткелдәге атыш», «Ятимнәр язмышы», «Соры Явыз»). Шул еллардагы драма әсәрләре («Аҗаган», Л.Соболев белән бергә язылган «Абай» трагедиясе), чит һәм урыс телләреннән казакъчага тәрҗемә ителгән әсәрләр (Н.В.Гогольнең «Ревизор»ы, У.Шекспирның «Отелло» һәм «Кирелекне тыю»ы) сәхнәләштерелә. Республиканың «Казакъ әдебиети» исемле гәҗите, гомумсоюз һәм Казакъстан журналлары белән тыгыз элемтәдә торып, ул хәзерге заман әдәби барышын игътибар белән күзәтә, мәдәни тормышның үзәгендә кайный. Ул сугыш алды елларында Мәскәүгә еш килә. Шуңа да аның Муса Җәлилнең вакытлы матбугат битләрендә урын алган кайбер шигырь һәм поэмалары, шулай ук 1941 елга кадәр урыс һәм татар телләрендә дөнья күргән 6 шигъри җыентыгы, аерым китап булып басылып чыккан «Хат ташучы» поэмасы һәм «Алтынчәч» драмасы белән таныш булуы ихтимал. Тәнкыйтьче Р.Мостафин «сугышка кадәр үк Җәлил Татарстанның киң танылган шагыйре булып, шигырьләре мәктәп хрестоматияләрендә урын алды» дип язды.

Язучыларның тормышы һәм иҗаты турындагы яңа мәгълүматларның басылып чыгуы милләтара әдәби бәйләнешләрнең аз билгеле яки бөтенләй билгеле булмаган өлкәләренә яктылык өсти.

Мисал өчен, 2000-2001 елларда Казакъстанның «Таң-Шолпан» журналында урыс һәм казакъ телләрендә М.Әүэзовның күптән түгел табылган хатлары басылгач, каләм иясенең озак кына Мәскәүдә яшәгәнлеге һәм анда иҗат белән шөгыльләнгәнлеге расланды. Төгәлрәге, ул башкалада 1940 нчы елның җәй-көзендә җәмгысе дүрт ай була һәм тугандаш республикаларның мәдәният эшлеклеләре, язучылары туктала торган «Милли» һәм «Мәскәү» кунакханәләрендә яшәп, Абай турында пьеса һәм роман иҗат итә.

Алдарак әйтелгәнчә, Муса Җәлил 1939 ел башында Казанга күчә, әмма «мәскәүчә» тормышын дәвам итә, чөнки еш кына бирегә иҗади һәм иҗтимагый эшләре белән килә: ул Татарстанның Язучылар Берлеге рәисе итеп сайлана. Ул Мәскәү язучылары, СССР язучылар берлеге җитәкчеләре, бигрәк тә Мохтар Әүэзовның якын кешесе, икесен күпьеллык ихлас дуслык берләштергән А.А. Фадеев белән тыгыз мөнәсәбәттә була.

Бүгенге көндә Казакъстанда М.О.Әүэзов әсәрләренең 50 томлык Тулы җыентыгын бастыруга керештеләр (алдагылары 12 һәм 20 томда чыкты). Зур фәнни-тикшеренү, текстологик һәм библиографик эш алып барыла, басма язучының моңа кадәр дөнья күрмәгән әсәрләре белән тулылана. Шуңа да киләчәктә казакъ һәм татар әдәбиятының үзара бәйләнешенә кагылган мәгълүматлар табылыр һәм алар басылып чыгар дип фикер йөртә алабыз. Аерым алганда, ике күренекле сүз остасының сугыш алды елларындагы әдәби бәйләнешләре турындагы мәгълүматлар да билгеле булырга мөмкин.

Тагын да бәһалерәк мәгълүматлар, мөгаен, мемуар әдәбиятта, шул елларның вакытлы матбугатында сакланадыр. Әминә Җәлилова үзенең истәлекләрендә татарның беренче операсы «Алтынчәч»не иҗат иткәндә Муса Җәлилнең сугыш алды

елларында Мәскәүдә уздырыла торган СССР милләтләренең Әдәбият һәм сәнгать декадасыннан файда күрүе турында яза. «Төрле милли операларны тыңлаганнан соң (казакъ, кыргыз, башка халыкларныкын), Муса операның гомуми планы һәм төп теманың ачыклануын таныды»,—ди ул.

Казакъ Әдәбият һәм сәнгать декадасы 1936 елның 17-27 маенда Мәскәүдә үтә. Анда катнашучылар арасында язучы-драматург М.Әүэзов та була. Башкала сәхнәсендә күрсәтелгән «Кыз Жибек» операсы зур уңышка ирешә, башкаручылар бүләкләнә, җырчы Күләш Байсәетовага исә СССРның халык артисткасы исеме бирелә. 1937 елда Алма-Атада Казакъ музыкаль-драматик театры нигезендә Абай исемендәге опера һәм балет театры ачыла. Аның җитәкчелеге иҗади эшкә драматург М.Әүэзовны да тарта: 1940 елда ул «Бекет» операсы өчен либретто, бераз соңрак—«Абай» операсы өчен Әхмәт Жубанов белән татар шагыйренең үсмерчак һәм яшьлек дусты Латыйф Хәмиди иҗат иткән музыкага либретто яза.

30нчы елар ахырында Муса Җәлил Татарстанның башка мәдәният эшлеклеләре белән бергә Казанда опера һәм балет театры ачу эшенә әзерлек белән мәшгуль була: Мәскәү консерваториясе каршындагы татар опера студиясенең әдәби бүлеге мөдире була, куелачак спектакльләр өчен либреттолар яза. Бүгенге көндә Муса Җәлил исемен йөрткән Татар дәүләт опера һәм балет театры Казакъстанның Абай исемендәге Дәүләт опера һәм балет театрыннан бер ел соңрак, 1938 елда ачыла. Шулай итеп милли мәдәниятнең күренекле эшлеклеләре саналган ике язучының охшаш иҗат язмышлары булган. Шуңа да алар очрашкан булырга да мөмкин. Әмма Казакъ сәнгате һәм әдәбияты декадаларының ул чактагы вакытлы матбугатта аз яктыртылуы, башка мәгълүматларның азлыгы яки бөтенләй булмавы уңай җавап бирүне кыенлаштыра. Әдәбият белгечләренә, бигрәк тә яшь тикшеренүчеләргә бүгенге көндә дә раслаучы документаль белешмәләр табылмау сәбәпле, Мәскәү, Алма-Ата, Казан, Оренбург, Ташкент, Омск архивларындагы беренчел чыганакларга, шулай ук архивлары бүгенге көндә дә ачылмаган дәүләт органнарына кабат-кабат мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Әлбәттә, тикшерер-раслар яисә алдарак күтәрелгән гипотетик фаразларны кире кагар өчен Казакъстанда да, Татарстанда да яңа тикшеренүләр уздырасы бар.

Ике тугандаш халыкның әдәбият тарихы нәфис-эстетик һәм социаль-иҗтимагый мөнәсәбәтләрдә шактый кыйммәтләргә ия һәм ул XXI гасыр кешеләренең рухи хәзинәсенә әверелергә тиеш.

### 3

XX гасырның 40нчы-50нче еллары борылышында Казакъстанда күренекле мәдәният һәм фән кешеләре өстендә «болытлар куера»: кабаттан тәнкыйтьләүләр, гаепләүләр, эзәрлекләүләр башлана. Төп мәрәйләрнең (мишеньнәрнең) берсе итеп күренекле сүз остасы М.Әүэзов сайлана. Күп кенә көнчеләр һәм «яхшылык теләүчеләр» өчен язучының лаеклы рәвештә югары бүләкләргә лаек булуы тынгы бирми: 1949 елда ул Абай романы өчен (I том) СССР Дәүләт премиясе белән бүләкләнә, 1951 елда «Мактау Билгесе» ордены ала. Абай турындагы роман 100 меңләгән тираж белән басылып чыга, Советлар Союзындагы дистәләгән телләргә һәм чит телләргә тәрҗемә ителә.

«1951 елда—гәҗит һөҗүмнәренең яңалары башлана,—дип яза атаклы әдип гомеренең шул чоры турында талантлы шагыйрь һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе Олжас Сөләйманов.—Гаепләүләр һаман да шул ук—«феодализм җырчысы», «буржуа милләтче», «Алаш-урда» идеологы. Вакыт үтә, дөньяда бөек үзгәрешләр бара, ә бездә бернәрсә дә үзгәрми. Хәтта фикерләр һәм алымнар да.

Академиклар Сатпаев һәм Әүэзовны кулга алу өчен ордерлар әзерләнгән. Икесе дә яшерен рәвештә Мәскәүгә китә».

Тырышлыгы нәтиҗәсендә (партиянең ҮК политбюросына мөрәҗәгать итәләр) Мохтар Әүэзов «Мәскәү» кунакханәсенең тыныч бүлмәсендә иҗади эшчәнлек белән шөгыльләнү мөмкинлеге ала.

Әлбәттә, М.Әүэзов «шәрәфле кунак» булып гамьсез генә утыра алмый: әдәбият аксакалының килүе турында ишетеп, күпсанлы дуслары һәм танышлары,

каләмдәшләре аңа үзләренең ихтирамын белдерергә ашыга. Әдәбиятчы галим С.Даронян мәгълүматларына караганда, 1953 елның язында ук, Мәскәү университетында СССР халыклары әдәбияты тарихы кафедрасы төзелү белән, профессор М.О.Әуэзов могтәбәр галим, көнчыгыш белгече буларак, лекцияләр укырга чакырылган. Ләкин ул чакта әдип иҗади эшен бүлә алмый. Һәм менә аның Мәскәүгә килүеннән СССР халыклары әдәбияты тарихы кафедрасы файдаланырга ниятли: профессордан, филология докторыннан казакъ әдәбияты буенча лекция курсы алып баруны үтенәләр.

Академик М.Әуэзов укытучы эшен иҗат, әдәби тәнкыйть эше белән бергә алып бара. Нәкъ менә шушы чорда ул Муса Җәлилнең гражданлык дәрте, ватанпәрвәрлек идеяләре белән сугарылган шигырьләренең тәрҗемәләре белән беренче тапкыр таныша.

СССР язучыларының Икенче Бөтенсоюз съездына әзерлек чорында М.Әуэзов башка сүз осталары, тәнкыйтьчеләр, әдәбиятчы галимнәр белән берлектә съезд барышында да һәм аннан соң да күпмилләтле бүгенге заман әдәбиятының үзара бәйләнеше һәм баюының үсеш тәҗрибәсе хакындагы һәм югары уку йортларында «СССР халыклары әдәбияты тарихы» исемле яңа курсны укыту проблемалары турындагы фикер алышуларга кушыла. Бу аның укучылар алдындагы, республика һәм үзәк басмалардагы чыгышларыннан күренә. Муса Җәлилгә Ленин премиясе тапшырылганнан соң да М.Әуэзов шагыйрь иҗатын күз уңында тота, аның әдәби мирасын яңа заман әдәби барышы белән бергә өйрәнүне дәвам итә һәм мөмкинлек туган саен аның таланты турында басым ясап әйтә, аны сүз осталарының беренче рәтенә куя.

«СССР халыклары әдәбиятының чәчәк атуы» (1958) исемле тирән эчтәлекле, зур күләмле хезмәтендә М.О.Әуэзов төрле республика язучыларының уңышларын күзәтеп, Татарстан бүлегендә Муса Җәлил иҗатына бәя бирә, төп игътибарны шагыйрь язмышының фаҗигалелегенә, немец-фашист әсирлеге шартларында иҗат итүенә юнәлтә. «Ул совет әдәбиятының иң күренекле язучы-ватанпәрвәрләреннән берсе,—ди автор.—Иҗатчы буларак та, героик шәхес, батыр гражданин буларак та шагыйрьләр арасында аерым урын тота». М.Әуэзов билгеләвенчә, фашистларның тәмуг әсирлегендә булып та, корыч ихтыярлы һәм буйсынмас җырчы йөрәгеннән суырып чыгарылган кайнар җырларын чын күңелдән яраткан Ватанына васыять итте. М.Әуэзов тагын бер кат Муса Җәлилне исеме Икенче Бөтендөнья сугышы тәмамлануга тынычлык өчен көрәшкән кешеләрнең һәммәсенең дә телендә булган, яшәү белән үлем арасында иҗат иткән Юлиус Фучик белән бергә атый.

Е.В.Лизунова белән бергәләп язылган «Урта Азия халыклары һәм Казакъстан әдәбиятлары үсеше турында» исемле мәкаләдә совет әдәбиятының күпмилләтле булуы билгеләп үтелә һәм иң яхшы сүз осталарының гомуми мәдәни традицияләргә һәм уңышларга керткән өлеше күрсәтелә. Иҗатларында «якты лирика һәм дәртле гражданлык кайнарлыгы» чагылган хәзерге заман шагыйрьләре Якуб Колас, Сәмәд Вургун, Гафур Гүләм, Мирзо Турсун-Задәләр белән беррәттән Муса Җәлил исеме дә атала. Авторлар бүгенге заман сүз сәнгатенең яңалыгы турында әйтеп, Муса Җәлилне Сәмәд Вургун һәм Гафур Гүләм белән янәшә куялар.

Әлеге хезмәттә авторлар күренекле казакъ шагыйре-фронтовигы Жубан Мулдагалиевнең «Җыр турында җыр» исемле яңа поэмасында «ялкынлы совет ватанпәрвәре, татар шагыйре Муса Җәлил образын тудыруын» да игътибардан читтә калдырмыйлар.

Күреп торабыз, авторлар шагыйрь-ватанпәрвәр иҗатына хезмәтнең исеменнән күренгән әдәби төбәк чикләреннән читкә чыгып мөрәҗәгать итәләр. Муса Җәлил Бөек Ватан сугышы чоры әдәби барышына табигый рәвештә кушыла һәм иҗатының үзенчәлекләре белән, олы талант, яңалык кертүче шагыйрь буларак аны тагын да баета.

**Ф. ФӘТКУЛЛИН,**
*Казакъстан Республикасы, Шымкент шәһәре*

*Бәләкәйләр*

# БӘЛӘКӘЙ БАТТАЛ

## Олугъ табигатьнең бәләкәй җан иясе

Үземне белә башлаган көннәрнең берендә пыр туздырып җан-фарманга үлән йолкыйм. Без үскәндә, уртадан үткән ике тәгәрмәч эзен исәпкә алмаганда, урамнар ине-буе белән яшел келәм кебек иде бит. (Әле хәзер уйлап куям: ишек төбеннән үк җир җиләге җыю бәхетен күргән буыннарның без иң соңгысыдыр...) Чебиләр адаша иде урамдагы үләндә, каз бәбкәләренең аяклары чәбәләнә иде.

Үземне йә чалгылы, йә уракльı итеп күз алдыма китергәнмендер, мөгаен, ашкынып-ашкынып үлән йолкыйм. Ул чак ыштан шәрифләренең безгә түгел, бездән зурракларга да тәтемәвен истә тотсак, нindирәк сурәттә булуым да һәм ярап бетмәгән гамәл өчен ата-ананың кай төшкәрәк чәпелдәтергә тиешлеге дә аңлашыладыр, шәт...

Чәпелдәүдән һәм авыртудан туктап калдым. Шулчак әнкәмнең кырыс тавышы ишетелде:

—Нишләвең бу, ә? Үлән йолку фәрештә канатын каеру белән бер бит ул!

Еларга, кызгандырырга дип авызымны күтәрүем булды, каршымда, дөресрәге, өстә калын иренле, усал карашлы баш күреп, шым булдым. Шулчак бу караш әнкәйгә текәлде һәм аның зур авызыннан, гөлдер-гөлдер килеп, сүзләр агыла башлады:

—Син нәрсә, Бәдәрттәй, булачак коммунистны, коммунизм төзиячәк совет гражданинын дин белән агулыйсың?!

Әнкәй каушап калды:

—Соң... үлән йолкый бит, Шәех... гөнаһлы булмасын дию ем инде...

—Әпәйт гөнаһ турында. Нинди гөнаһ ул, нинди фәрештә? Йолкысын рәхәтләнеп.—Ул күнитекле аягы белән мин өеп куйган үләнгә басты.—Шушы гауна өчен дин белән куркыталармыни баланы?

Әнкәй агарынып сүзсез калды. Куркыну ингән күзләренә, калтыранган иягенә карап алдым да, мин—«булачак коммунист, коммунизм төзиячәк совет гражданины" әнкәйгә үч итеп, давайланып, янадан йолкый башладым.

Тиеп кара син миңа, әзмәвердәй гәүдәле яклаучым булганда!

Шулчак Шәех абзый (үскәчрәк аңлавымча, колхоз рәисе), үлән өемен тырый-бырый китереп, аягы белән типкәли-типкәли, як-якка чәчте дә, әнкәйгә бармак янады:

—Ничава, дин йоктыручыларга управа бар хәзер. Кәнсәләрдә җавап бирерсең!

—И-и, Шәех, бөтен балалар үлән йолкый башласалар, илдә дә калмас бит ул

үлән,—дип тилмерде коты алынган әнкәй.—Бөтен жир шәрә калыр бит...

—Калмас! СССР киң ул. Балалар кыю булып, көрәшче булып үссеннәр,—диде Шәех абзый, китеп барышлый.

...Әйе, кыюлар, көрәшчеләр күп үрчеде илдә. Минем яшьтәшләр үк мондый урамнарны тракторлар, машиналар белән актарып бетерергә өлгерделәр. Яшел үлән өстенә кереп, бөтерчектәй боралар чылбырлы тракторны үзләре теләгән тарафка!..

Туктале, ник сүз озайтып торам. Ниһаять, урамнары гына түгел, бөтен жире шәрәләнеп, таланып бетте СССРның, үзе дә өзгәләнеп, таркалып бетте. Артык киң булганга, жир кадере беткәнгә шәрәләнгәндер ул, бәлкем, ә?

...Авылга ел саен бер булса да кайтырга тырышам. Аунап-тәгәрәп үсүче балалар белән тулып яшәгән элекке яшел урам хәзер кап-кара. Балалар да күренми... Әз генә жил чыктымы, тузан күтәрелә, өермә йөри. Без кармак салган, күлмәк белән балык сөзгән, колач салып йөзгән инеш бака да яшәмәслек, маймыч та йөзә алмаслык хәлгә килгән.



—Агач сындырганчы минем кулымны каер!

—Үлән йолкысаң, кулың корыр!

—Һәр үсемлек Аллага мәдхия әйтү өчен үсә! Гөнаһлы булма!

Әнә шундый үгетләр, бераз шомландырып та ала торган кәлимәләр белән үстергән әнкәм авылның нәкъ менә шушы хәлгә каласын алдан күрмәде микән? Юктыр, бу кадәр үк куркынычны күз алдына китерә алган булса, шучакта ук йөрәге ярылган булыр иде аның...

Шушы юлларны язып утырганда радиодан жыр яңгырый:

Дошман явы ауган кебек
Ава печән пакусы...

Үзен үстергән табигатьне дошман белән тиңләүче жәмгыять кай тарафка бара? Акылына килерме ул бервакыт?

Авылыбыздагы умартачы бабай әйткәндәй, бал кортларыннан үрнәк алырга кирәк. Бал корты чәчәк таҗына иплән кенә кунар, үзенә кирәген саклык белән генә жыяр һәм дә чәчәккә бернинди дә зыян китермичә очып китәр... Жирдә без шулай яшәргә тиеш. Чәчәкнең хуш исе жил уңаена таралыр, ә игелекле кешенең үрнәге, матур исеме жилгә биреши—төрле якка таралыр...

## Теориясез сабаклар

Без хәзер милли рух, милли горурлык хакында иркен сөйләшәбез. Туган телен белмәүчеләрне йә кызганабыз, йә сүгәбез. Мәктәптә—укытучылары, югары уку йортында профессорлары юньләп өйрәтмәгән, аңлата-төшендерә белмәгән, дибез. Кайберсенә ташлама да ясыйбыз, имеш, ни хәл итмәк кирәк, ул шәһәрдә, урыс арасында үскән. Малай-шалайларга яки егет һәм кызларга гына түгел, өлкәннәргә дә урыс исеме белән эндәшәләр. Фәйзулла—Федор, Сабиржан—Саша, Гөлнур—Гуля, Сания—Соня... Хәер, санап та утырасым килми. Ник дисән, меңнәрчә мәртәбә кабатланган, колакларны туйдырып бетергән тема бу. Ләкин, иманым камил, милли рух тәрбияләү тулаем диярлек ата-ананың эше дип саналырга тиеш. Кешенең үз милләтенә мөнәсәбәтен белүгә үк, гөнаһын-савабын да, зурлавын-хурлавын да бары тик үзен бар иткән, үстергән затлардан эзли башларга кирәк, һәрдаим туган тел кадере, милли гореф-гадәтләрнең изгелеге хакында сөйләнелгән өйдә башка милләткә авышкан, үз исемен кушаматка алыштырган (яки алыштырткан) кеше үсә алмый.

...Дөнья үзем туган авылга, аның кыр-болыннарына сыеп беткән сыман тоелган заманда, ягъни бала чагымда иң зур абыем сугыштан кайтты (Хәзер исәпләп карыйм,

23 яшьтә булган ул.) Гомер буе җинел хәрәкәтле, күргәнен-белгәнен түкми-чәчми сөйли торган булды мәрхүм. Ул чакта, яшьлеге кайнап торган елларда, бу сыйфатлары аеруча көчле булгандыр: пилоткасын әле өстәлгә чәпи-чәпи, әле күкрәк суга-суга фронтта йөрүләрен сөйләпме-сөйли бу!

—... Шуннан алга киттек без. Карасак, берничә немес автоматларын яр читендәге агачка сөягән. Үзләре инештән флягаларына су тутырып маташалар. Шунда Пенза егете Саша пышылдап кына: «Миша, туктап тор әле»,—ди...

Шулчак әткәй абыйның сүзен бүлдерә:

—Сине урыс дип беләдериемени ул Сәшке дигәннәре?

—Юк инде, белә, бик белә татар икәнне!..

—Сон, шулай булгач, үз исеменне әйтмәденмени ана «Мулланур мин», дип. Исеменне әйтергә теле әйләнмимени?

—Ну, бигрәк инде син, әткәй...—дип туктата аны башыннан үткәннәрне канатланып-канатланып дәвам итәсе килгән абый.—Анда бит исемгә игътибар итеп тормыйлар. «М»нан башлана бит инде минем исем. Шулай булгач, Миша диләр инде.



—Ә ул Сәшкенеке «С»дән башлана. Сафа дип әйтә иденме сон үзенә?

—Йә инде, әткәй, юк-бар сөйләмә инде. Алай дисәм, көләрләр иде...

—Ә син ник үзеннән көлдерден?!

Тәки сөйләп кинәнә алмады ул көнне Мулланур абый сугышта күргәннәрен. Улының исән-имин кайтуын зар-интизар булып көткән, ниһаять, шул көнне дә күрү бәхетенә ирешкән әткәй кырт кисте:

—Сугыш бит ул югалтканны табу, башкалар талап алганны кире кайтару өчен. Ә син исеменне дә югалтып кайткансын!

Икенче көнне абыйның кыйссасы болайрак дәвам итте:

—Саша әйтә: «Син, Мулланур, туктап тор әле»,—ди. Аннан сон болай ди бу миңа: «Тише, Мулланур, мин хәзер аларга якынрак барам...»

Әткәй, әледән-әле башын иеп, мыегын, битен сыпырып куя—елмаюын күрсәтмәскә тырыша. Ә тегесе җилләнә-җилләнә сөйләп утыра...

...Берничә елдан үземә дә Федя булып китү ихтималы туды.

Мине ике-өч атнага авылда калдырып, Минзәләгә барып урнашкан әнкәм, алырга кайтты да:

—Синен килүенне күрше-тирәдәге малайлар да зарыгып көтә инде,—диде. Аннары ачыклап куйды.—«Минем дә сезнен яшьтәге малаем бар» дигәнием үзләренә, «кайчан алып киләсен инде, апа, малаенны?», дип, көн саен сорап кына торалар... Дүртесе дә урыс малайлары түлке, дүртесе дә Вәнке исемле.

Минзәләгә килеп, чәй эчеп алгач, урамга чыктым. Чыннан да көтеп торганнар икән Ванькалар. Уратып алдылар. Бер-бер артлы сорау бирәләр.—«Когда приехал»?—«Сегүдне». «Рыбачить любишь?»—«Лүблү кәнишне...» Шул чорга хас сафлык белән һәр җавабымнан рәхәтләнеп көләләр. Шуннан берсе сорап куя.

—Как тебя зовут?

«Нинди завод турында сорый икән болар?» дип уйланган арада берсе:

—Имя-то как?—дип куя.

Менә монысын беләм! Бер хәрефне русчалатыбрак:

—Фанзаман,—дим.

Әле кайбер татарларга да сәеррәк булып тоелган һәм татар дөньясында бер генә булган исемем боларны бөтенләй мәзәксендерде.

—Как-как?

—Фәнзаман...

—А!.. На «Ф» начинается,—диештеләр, кат-кат сораудан үзләре дә туйгач.—

Значит, Федькой будешь.

—Зачим?—дигәнемне үзем дә сизми калдым.

—Ну ведь на «Ф» начинается...

—У тибә, у тибә, и у тибә на «В» начинается. Вас я тужы Вазыйх буду говорить.

Тагын көлделәр, тагын аңлаштылар, истә калдыру өчен исемемне дә кат-кат сорадылар. Шул көннән соң да алар—Ванька, мин—Фәнзаман булып калдым. Күнектеләр. Минем исем бозылмады, аны әйткәннән генә аларның теле сынмады.

## Шайтанны ничек чакыралар?

Их, әнкәй!..

Тормышның һәр очрагына, һәрбер вакыйгасына карата нинди дә булса кәлимәсе әзер иде аның. Тәртибең, кылган гамәлең, бирәр хәрәкәтең адәмчә түгел икән, сине йә бәләкәй генә бер кыйсса, һич югы гыйбрәтле сүз көтә. Сагаеп та куясың, вакыты-вакыты белән күңелгә шом да йөгерә.

Аяклары урындыктан идәнгә житми торган балаларның ашаганда аяк селкеп утыруларын кемнең генә күргәне юк икән? Билгеле, әнкәсен имгәндә кәҗә бәрәне дә койрыгын пропеллердай тизлек белән дырылдатып тора: күрәмсең, ризык ләззәтенең хикмәте бу. Шуңа күрә гаеп итәргә дә сәбәп юк сыман. Ләкин адәм баласы хайван түгел...

Әле узган ел гына, йомышым төшеп, бер фотографларга бардым. Табын янына утырттылар—анысына рәхмәт. «Монысыннан авыз ит, тегесеннән житеш»,—диди, кыстап та тордылар—анысына да рәхмәт. Мәгәр ике-өч минуттан ук авызыма капкан ризыгым аркылы тора язды. Кинәт хуҗабикә:

—Чо ногами дрыгаешь?! Ну-ка өстәл артыннан катись!—дип кычкырып җибәрмәсенме!..

Баксаң, безнен белән бер өстәл янында утыручы дүрт-биш яшьлек Искәндәрләре аякларын селкеп утыра икән.

—Матри-ка син аны, нинди тәртипсез!—дип ялгап куйды сабыйның әтисе.—Тикай моннан! Әнә, кунак абыең да яратмый синең кебек некультурный малайларны...

Маңгаена төрттеләр дә малайның, өстәл яныннан суырып алдылар. Чәч төпләренә кадәр тирләп чыкты сабыйның!.. Аннан соң шыпан-шыпан гына читтән мине күзәтеп йөрде. «Син килмәгән булсаң, тимиләр иде миңа, син яратмаганга кудылар мине өстәл буеннан», ди кебек иде аның мөлдерәп торган карашы.

...Шунда мин әткәм белән әнкәмне күз алдыма китердем. Искәндәрдәй бәләкәй чагым. Ашап утырабыз. Әнкәй, ниндидер вакыйганы искә төшергәндәй, әткәйдән:

—Карале, атасы, син Тулбайдагы Нуриларны беләсең бит, әйеме?—дип сорап куйды.

—Ник белмәскә инде, беләм. Ни булган?—диде әткәй.

—Менә шуларның бәләкәй малайлары ашаганда аяк селкеп, шайтан чакырып утыра торган булган. Хәзер инде аягы бик авырта икән. Врачлар да төзәтә алмый дип әйтеп торды төнәген Гайфулла. Кәнки шуарга да чыга алмый икән, мескенкәем.

Сагаеп калдым: аякларымны селкеп утырам икән ләбаса!..

Әле хәзер дә сокланам мин аларның бер-берсен ярты сулыштан ук аңлап яшәүләренә. Берсенең әйтүе, икенчесенең кайгырган сыман:

—Чакырып китергән шайтан бигрәк тә яман кылана инде ул. Төзәлә күрсен инде аягы, төзәлә күрсен,—дип җөпли белүе бүген дә яшь аралаш елмайта.

Ә мине бу сөйләшүдә искә алучы да юк. «Аягыңны тик тотмасаң, син дә шул хәлгә төшәрсен» дию дә, хәтта мин утырган тарафка күз төшереп алу да юк. Алар белән бергә ниндидер Нури малаен кызганам, ә эчемнән нәтиҗә ясаган булам: ашаганда аяк селкеп утыру ярамый икән, ярамый икән!..

Билгеле, әгәр кемдер: «Ярамаган гадәтне бик тиз ташлаган бу»,—дисә, ялгышыр. Кайсы балага бер генә әйтеп кергәне бар?

## Җил сөйләп тора...

Бихисап буш сүзгә караганда бер хикмәтле сүзнең үтемлерәк икәнен һәркайсыбыз белә. Ә гыйбрәтле мисал акыллы сүздән, яхшы үгеттән дә файдалырак.

Һаман да шул балачакның бер гыйбрәтле вакыйгасы инде...

Минзәләдә Мәхмүт абзый бар иде. Гомер буе музыка мәктәбендә укытты мәрхүм. Бу дөньяда инде ул үлгәч тә гомер сөрдем, әмма скрипкада аның кебек үк оста уйнаган кешене күргәнем юк сыман. Хәер, сүз ул хакта түгел. Төп эшеннән соң ике-өч сәгать кенә буш вакыты булса да кармаклары белән су буена төшә иде ул. Ә мин, унике яшьлек малай, аның аерылмас юлдашы.

Ял көннәрендә без еракларга, еш кына монарчы мин күрмәгән-белмәгән якларга китәбез. Чабатасы белән туп-туп басып, җиде-сигез кармак таягы күтәреп, пөф-пөф төтен чыгарып, алдан ул бара. (Заманча аяк киемнәренә һәркем тиенеп беткәч тә табигатькә чыкканда чабатасын кия иде ул. Шикләнмим, Минзәлә ягында иң соңгы чабатаны ул туздыргандыр.) Ә мин арттан тәпилим...

Нинди генә чытырманлыкларны, куаклыкларны ярмый идек балык тотар өчен яңа урын эзләгәндә...

Бервакыт без куаклык аланына килеп чыктык. Күрәм, аланның урта бер җиренә киртә тотканнар. Чардуган дияр идең, зуррак бу. Бакча да түгел. Чөнки ярты сутый да юк. Мин аптырап калдым. Иң гаҗәпләндергәне—киртәләрнең үзләре: аларның кайберләре сөяктәй ялтырап тора, кайсылары кайчандыр корт ашаудан тишкәләнеп-челтәрләнеп беткән, шактые коелган һәм билдән үлән арасында ята торгач, череп таркала башлаган... Ә җил шушы киртәләрне курай итеп уйный сыман. Нинди генә тавышлар, сызгырулар чыгармый бу киртәләр. Елыйлар да, көләләр дә, хәтта чиныйлар да кебек... Хәтердә: бик тә шомлы булып китте. Әйтерсең лә җил сине төрле гасырлар буйлап йөртә.

Ниһаять, Мәхмүт абзый телгә килде:

—Мин малай чакта ук бар иде инде бу киртәләр. Ул вакытта да шушылай ук искеләр, корыганнар иде.

Исәпләп карыйм: димәк, бу хикмәтне Мәхмүт абзый күргәнгә дә кырык-илле ел үткән!.. Шулай да ышандым.

—Ә нәрсәгә кирәк соң бу монда?—дип сорадым.

—Һе-ей!.. Хикмәте дә, мәгънәсе дә бик зур аның,—диде абзыем.—Аны һәркемгә аңлатырга кирәк тә бит, тик аның янына килеп чыгучы бик сирәк. Күрәсең бит, аяк эзе дә юк монда.

Аннан соң сөйләп бирде:

—Борын заманда шушында бер татар печән чапкан. Арыгач, ачыккач, ашарга утырган. Туйгач, аш-суын җыештыра башлаган. Бәй, күргән бу—ипинең бер валчыгы үлән арасына төшеп киткән. И эзләгән, и эзләгән—таба алмаган. Табудан өметен өзгәч, валчык төшкән урынны әйләндереп, шушы киртәне тотарга мәҗбүр булган.

—Ни өчен?

Мәхмүт абзый, әкәмәт нәрсә күргәндәй өздереп-яндырып карады да, капыл гына урыныннан кузгалып, китеп барды. Ул сүгенә-зарлана алдан бара, ә мин, унбер яшьлек малай, бик үк рәхәт булмаса да, һәр сүзен колакка сеңдереп, арттан теркелдим.

—Һы! Ни өчен дип сорап тора бит әле тагын! Шуны да аңламагач, баш ни өчен? Ушлы булып үсәргә кирәк әзрәк, ушлы булып...

Бушаган чабата киндерәсен сүтеп, яңадан бәйләргә утыргач, әйтеп куйды:

—Өстенә мал-туар баса күрмәсен, кешеләр ялгыш таптамасын өчен тоткан ул абзаң киртәне. Ипи бит ул!

...Шушы кыйссага өстәп: «Хәзер ипи кадерен белүче юк. Ипи теләсә кайда аунап ята» диебрәк сүземне дәвам итсәм, икмәк кадере турында фәлсәфә сата башласам, укучы нәрсә дияр иде икән минем хакта? Алла сакласын! Ул инде мораль укудан туйган.

**Фәнзаман БАТТАЛ**



*Фәнил Гыйләҗев*

Фәнил Гыйләҗев—КФУның журналистика бүлеге студенты. «Иделем акчарлагы—2010» яшь язучылар конкурсының шигърият буенча Гран-при лауреаты яулаган егет!

# МИН ЫШАНАМ, ХАЛКЫМ, КАЙТЫР ЯЗЛАР...

***

**Тулпарларны йөгәнлисе бар бит,**
**Өйрәтәсе бар бит ияргә.**
**Тышауларны өзгән чыгымчыга**
**Иртә әле...**
**Иртә әле камыт кияргә.**

**Ашыктырма вакыт чаптарларын!**
**Мин аларны үзем иярлим.**
**Тезгеннәрне кулга ныклап тоткач:**
**«Далаларны**
**Бергә иңлик, әйдә!»—диярмен.**

## *Караңгы төн*

**Караңгы төн.**
**Урам йоклый әле.**
**Этләр генә өрә кайвакыт.**
**Яфрак шаулый,**
**җил абынган чакта...**

**Исерек килеш урам буйлатып**
**Бары тик җил,**
**Бары тик җил йөри...**
**«Бераз гына салып алуга:**
**Әле анда барып сызгыра ул,**
**Әле монда...**
**Бәрелә, абына...**
**Ботакларга тотылмакчы була,**
**Ләкин,**
**Шуа аның «хәлсез» куллары.**

Караңгы төн.
Бары тик җил дулый.
Туарылган...
Һәм юк богавы.

Караңгы төн.
Тышта Җәйнең соңы.
Һаваларда йолдыз атыла.
Тик тулган ай йоклый алмый һаман,
Моңсу карап,
Җиргә тартыла.

Караңгы төн.
Урам күптән йоклый.
Әмма мин
Һич йомалмыйм әле күзләрне:
Айга карап бүре улаган мәл—
Шагыйрь җаны әллә
Түзәрме?!

***

Ничә гасыр ярларына тулып
Сабыр гына аккан Казансу
Кечерәеп калган, суы кимеп.
Чикләре тар! Бик тар!! Ямансу!!!


Чуерланган кирмән ташын юып,
Төпкеленә серен сеңдергән
Тарихыбыз ачылсынга дипме,
Казансуның суы кимегән?!

Яманнарын гына язма, Хода!
Иркенлек соң кемнәр кулында?!
...Хәтта елга яры кысанайган
Кимсетелгән кирмән буенда.

Яр буенда уйга батып йөрим:
Казансуның төбе күренә...
Тар үзәнле халык түгел лә без,
Болай булу тиеш түгел лә!

Мин ышанам—кайтыр әле язлар!
Үзәннәр бит әле кипмәгән:
Ярлары бер тулыр, ташкын булыр,
Җимерелер дамба-киртәләр...

# РӘСЕМЛЕ КРОССВОРД



**Зөфәр ХИСАМОВ** *төзеде.*
*Буа.*

***Журналыбызның узган санында, «Ак җилкән» сәхифәсендә басылган кроссвордның җаваплары.***

1. Ахиярова; 2. «Алмачуар»; 3. Рөстәм; 4. «Мокамай»; 5. Йолдыз; 6. Зарипов; 7. Вахит; 8. Тинчурин; 9. Нәшрият; 10. Тенор; 11. «Раушан»; 12. Натюрморт; 13. Вәлиев; 14. Тажетдинов; 15. Валторна; 16. Ария; 17. Якупов; 18. Вальс; 19. «Спартак»; 20. Корректор; 21. Равил; 22. Либретто; 23. Орган; 24. «Наемщик»; 25. Каралама; 26. Аббревиртура.

---

*«Ак җилкән»гә хат язу өчен адрес:*
*420066, Казан, Декабристлар ур., 2, «Казан утлары», «Ак җилкән».*
*E-mail: kazanutlari@telebit.ru.*

## Басыйр Рәфыйковка 90 яшь

Басыйр Шаһинур улы Рәфыйков 1921 елның 10 февралендә Татарстанның Мамадыш шәһәрендә хезмәткәр гаиләсендә туган. 1931 елда анын әтисе, гаиләсен ияртеп, Магнитогорск шәһәренә күчеп китә. Шунда Басыйр 35нче татар мәктәбен (ТБУМ), аннары 1936—1939 елларда Троицк шәһәрендәге (Чиләбе өлкәсе) татар-башкорт педагогия техникумын тәмамлый. 1939—1941 елларда Чиләбе өлкәсенен Ялан-Катай районындагы Әлмән авылы (хәзер Курган өлкәсенә керә) җидееллык татар мәктәбендә рус теле укыта.



Бөек Ватан сугышы башлангач, Б. Рәфыйков хезмәт армиясенә алына һәм 1945 елның көзенәчә Магнитогорск металлургия комбинатында эшли. Шул чорда, хезмәтеннән аерылмыйча, Магнитогорск педагогия институтының тарих факультетында укый һәм аны 1947 елда тәмамлап чыга. Бер ел һөнәр училищесында укытучылык иткәннән соң, 1948 елдан 1960 елга кадәр Троицк татар-башкорт педагогия училищесында тарих фәне укыта, бер үк вакытта училищенын читтән торып уку бүлеге директоры урынбасары булып эшли. 1960—1976 елларда ул Троицкидагы урта белем бирү мәктәпләрендә башта уку-укыту бүлеге мөдире, соңыннан директор вазифаларын башкара.

Басыйр Рәфыйковның исеме матбугатта беренче тапкыр 1964 елда күренә: шул елны «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналының сигезенче санында, Гомәр Бәшировның сүз башы белән, авторның бер төркем лирик шигырьләре басыла. Шуннан соң анын шигъри әсәрләре Татарстан газета-журналларында, күмәк җыентыкларда, русча тәрҗемәдә Чиләбе газеталарында һәм Көньяк Урал нәшриятында чыккан альманахларда дөнья күрә.

Басыйр Рәфыйков тарихи ватаныннан еракта яшәсә дә, анын иҗатын якташлары гына түгел, Татарстанда да һәм шулай ук Россиянең милләттәшләребез күпләп яшәгән төбәкләрендә дә яхшы беләләр. Анын табигать күренешләре, мәхәббәт лирикасы һәм фольклор мотивлары өстенлек иткән «Җырым сиңа минем», «Кадерле минутлар», «Туган тупсалар», «Кара каен», «Вакыт җиле» исемле җыентыкларын шигырь сөючеләр кулдан-кулга йөртеп укый. Якты дөньяга беренче кат күзләре ачылган Мамадыш ягының сабый күнелендә сенеп калган җирсү хисләре, туган җирнең инеш-елгаларга, урман-кырларга бай гүзәл табигатен сагыну мотивлары, яшьлек мәхәббәте, кайчандыр татар сәүдәгәрләре, эшмәкәрләре, мәктәп-мәдрәсәләре белән дан тоткан, шагыйрь өчен икенче Ватан булып әверелгән Троицк дигән татар мәдәни учагының шанлы үткәне һәм бүгенге көндәге аянычлы хәле, сугыш чорының авыр хатирәләре, татар теле язмышы турындагы хәвефле уйланулар—болар шагыйрь иҗатының төп тематик эчтәлеген тәшкил итәләр.

Б. Рәфыйков халык иҗаты әсәрләрен җыю, үзе яшәгән төбәктә татар мәдәниятенә бәйле тарихи документларны һәм аерым шәхесләрнен тормыш-эшчәнлеген өйрәнүдә дә нәтиҗәле эш алып бара һәм урындагы көндәлек матбугатта шул мәсьәләләргә багышланган мәкалә-очерклары белән катнаша.

Басыйр Рәфыйков—1974 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

# ҖЫРЧЫ ШАГЫЙРӘ

Кайчандыр шигърият сөючеләргә:

*Сезнең белән бүген җыр теленда,*
*Төсле моң телендә сөйләшәм,—*

дип эндәшкән Шәмсия Җиһангирова, чынлап та, нечкә лирика белән сугарылган шигырьләре, җырлары белән танылу алды.

Мөслим ягы—талантлы каләм ияләрен әдәбиятка мулдан биргән. Зөлфәт, Х. Әюпов, Н. Гамбәр, Ф. Латыйфи, Ф. Садриев кебек гаярь ир-егетләр арасында 1951 елның 28 февралендә Баек авылында туып, кече яшьтән үк җырга-моңга, шигърияткә тартылган нечкә хисле Шәмсия Җиһангированың булуы да гаҗәп түгел. Моң-сагышка уралган шигырьләре, композиторлар тарафыннан көйгә салынып җыр сәнгатендә дә үз урынын алды. «Тик син диеп» (Ф. Әхмәтов көе), «Ак күлмәгем», «Пар канатлар» (И. Дәүләтшин көе), «Минем кадерлеләрем» (М. Гыйләҗев көе), «Күрәсем килгән иде» (Г. Сафиуллин көе) һ.б. җырлары җырчыларыбыз тарафыннан яратып башкарылдылар.



Ш. Җиһангирова үзенең тормыш юлын татар әдәбиятына хезмәт итүдән башлый. Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын 1974 елны тәмамлаганнан соң, Татарстан китап нәшриятында эшли. Бераз вакыт гаиләсе белән Әлмәт шәһәрендә яшәп алганнан соң, кабат Казанга кайта. Әлеге нәшриятта редакциянең өлкән мөхәррире буларак эшен дәвам итә. 1992 елда Татарстан радиосына эшкә килгән шагыйрә, бүген «Яңа гасыр» радиосында өлкән мөхәррир вазыйфасын башкара. 2002 елдан «Татарстан—Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясендә радионың баш мөхәррире.

Беренче шигырьләр җыентыгы «Төсле моң» (1985) басылып чыкканнан соң, Ш. Җиһангированың яшьлек романтикасы белән сугарылган «Яшел гармун» повесте (1987), балалар өчен шигырьләре тупланган «Балачак кая китә?» (1989), лирик шигырьләрен җыйнаган «Ни өчендер безнең язмыш шундый» (1996)», «Жирсү» (2001), «Якты сагыш» (2006) исемле китаплары дөнья күрә.

Ш. Җиһангирова—1991 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы. 1996 елда исә «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» исеменә лаек була.

***Каләмдәшебезне юбилее белән ихлас котлыйбыз, аңа иҗат уңышлары, исәнлек-саулык телибез.***

# УЛ ЯЛТАДА, ЛӘКИН ЯЛ ИТМИ

Вакыт җинел канатлы кош булып оча гына. Еллар, нәкъ ракеталар шикелле, очалар һәм кире әйләнеп кайтмыйлар.

Әле кайчан гына Хәдичә ханым һәм Фоат аганың алтын туйлары бөтен Ялтаны гөр китергән иде. Аккан су кебек сиздермичә генә айлар, еллар үттеләр, ун ел гомер үтте дә китте.

Ниһаять, 2008 елның 5 октябре житте. Бу көн аларның бергә—никахта һәм рәсми ЗАГСта яшәүләренә нәкъ 60 ел тулды. Аларның «Гомергә—бергә!», «Мәнге бергә!» дигән тормыш девизларының чынга әверелүе турында сөйләүче дәлил бу.

Ирле-хатынлы Мортазиннар Ялтага даими яшәү өчен пенсиягә чыкканнан соң, 1984 елда Татарстан Республикасының Буа районыннан күчеп килделәр. Килүләренең беренче көненнән үк үз алларына шундый олы бурыч куйдылар алар: Якташларын—Идел буе, Урал һәм Себер татарларын эзләп табарга! Хәтта алай гына да түгел: аларны бердәм, тату һәм яхшы оешкан җәмгыятькә берләштерергә, дуслаштырырга һәм туганлаштырырга. Безнең бабаларыбыз:



*Заманалар авыр, еллар ябык,*
*Дус-иш кирәк гомер итәргә»,*

—дип тикмәгә генә җырламаганнардыр ласа!

Алар Ялта шәһәренең телефоннар кенәгәсеннән татар фамилияле кешеләргә шалтыраталар, эчке шәһәр транспортында, урамнарда, мәйданнарда, кинотеатрларда, Чехов театрында, җәмәгать урыннарында, шәһәр буйлап йөргәндә—һәркайда һәм һәрвакыт милләттәшләрен һәм якташларын эзлиләр. Эзли торгач, Ялтада дүрт районлаш табылды. Симферопольдә эшләүче Кишер Аксуы (күрше авыл) егете Хәйбуллин Рифкать белән дуслык җепләрен ялгап җибәрәләр.

СССР Мәгарифе отличниклары Мортазиннар яна танышларын үзләренен өйләренә чәй эчәргә, татар музыкасы тынларга, гәпләшеп утырырга чакырдылар. Элекке традициягә тугры булып, әледән-әле кунак җыйдылар.

Ике ел да үтмәгәндер, якташларны теркәү кенәгәсендә ике йөзләп кеше тупланды.

Фоат ага каләм тибрәтә торган шәхес буларак Кырымда чыга торган газеталарга мәкаләләр, тасвирламалар, Ялтада һәм Кырымда яшәүче күренекле милләттәшләребез турында очерклар язарга кереште.

Газета материаллары эзеннән Мортазиннар белән танышу өчен хәтта күрше Алуштадан да килә башладылар. Шулай бер көнне аларга баһадир гәүдәле скульптор Данис Сөләйманов рәхим итте. Бер кулында—үзе ясаган Сталин барельефы, икенче кулында—гипска язылган Әлхәм догасы. Бу дуслык менә егерме ел инде дәвам итә.

Аларның бусагасын 25 ел эчендә кем генә үтеп кермәде дә, кем генә дуслык тәкъдим итмәде!

Әкренләп, ләкин тайпылышсыз Мортазиннарның тыйнак кына өе Ялта татар диаспорасы Милли-мәдәни үзәгенә әверелде.

«Акчура» исемен алган җәмәгать оешмабыз тиздән Ялта шәһәр Советында да теркәлде.

Мәкальләрдә халыкларның тормыш тәҗрибәсе тупланган. Мондый үзбәк мәкале бар: карт агачны күчереп утыртмыйлар. Фоат ага белән Хәдичә ханым исә яна

туфракта яңа тамырлар җибәрә һәм бик яхшы җимешләр бирә алдылар. Аларның океан шикелле киң күңелләренә еракта калган туган як та, бүген яши торган шәһәрләре дә сыя.

Бүген дә хәтеремдә, Мортазиннарның алтын туенда (1998 ел) Алушта татар җәмгате рәисе Марс ага Шафиков әйткән сүзләр, үз вакытында авыздан-авызга күчеп, газетадан-газетага күчеп, көчле кайтаваз булып яңгырадылар. «Әгәр Фоат ага һәм Хәдичә ханым 1984 елда Ялтага күчеп килмәгән булсалар, бирелә, Кырымда безнең тормышыбыз күңелсез һәм бертөрле генә агар иде. Алар безне бер-беребез белән таныштырдылар, дуслаштырдылар һәм берләштерделәр. Безнең ул чакта үз эчебезгә бикләнгән тормышыбызга саф кислород агымы керттеләр, йоклаган җаннарыбызны уяттылар. Безнең инде шактый онытылган милли рухыбызны, традицияләр—гореф-гадәтләребезне, милли бәйрәмнәребезне, милли телебезне һәм, ниһаять, хак динебезне көндәлек тормышыбызга керттеләр. Алар безгә Тукай һәм Җәлилебезне, Галимҗан ага Ибраһимовны, Гаяз Исхакыйны, кәләпүшләр һәм изге китабыбыз Коръән Кәримне алып килделәр.»

Марс аганың бу фикеренә Севастополь татар җәмгыяте рәисе Җәмил Хисаметдинов та, Ялта татар җәмгыяте рәисе Рәисә Алексеева да бик теләп кул куя алалар.

Аларны бүген Ялтада татар җәмәгатенә нигез салучылар, читтә яшәүче якташларыбызны берләштерүчеләр дип саныйлар. Хәдичә ханымны—общинабызның әнисе, Фоат аганы общинабызның әтисе дип таныйлар. Хәдичә ханым «Коръән укучы карчык» буларак та дан казанды, ә Фоат ага—безнең коеп куйган журналистыбыз һәм шагыйребез.

Гадәттә безнең барлык шатлыкларыбыз кешеләрдән килә. Мөгаен, шуны истә тотыптыр, Фоат ага үзенең бер китабына «Мин сезне яратам, кешеләр!» дип исем биргән.

Кырымга күчеп килгәч тә, бу ике сәйях күп көтелмәгән шатлыклар кочтылар.

...2001 елның марты. Без Урман поселогында яшәүче инженерларда—Нәҗия һәм Мәгъмүр Кәримовларда кунакта. Мәҗлесне алып баручы мәрхүм-галим Рәүф Акчурин болай ди:

—Безнең арада шигырьләр язып, аны Казан, Уфа газеталарында бастырып, шигърият белән рухланып яшәүче шәхес бар. Ул—Фоат ага Мортазин. Сез беләсез, газета бер генә көн яши. Әйдәгез, иптәш Мортазинга беренче шигырь китабын чыгарырга булышыйк. Менә мин аның китабын бастырып чыгаруга 300 гривна (Россия акчасы белән 1500 сум) акча кертәм. Сезне минем үрнәгемә ияреpгә чакырам.

Башка иптәшләр дә читтә калмады. Бер мәҗлестә үк 10.000 сум Россия акчасы җыйналды.

2001 елның июнь аенда Фоат ага үзенең беренче шигырь китабы—«Ялта бүләге»н алып кайтты (тиражы 350 данә).

Әлбәттә, беренче чиратта бу китаплар автографлар белән Ялта җәмәгате әгъзаларына бүләк итеп бирелделәр.

Икенче шигырь китабы—«Дингез сәламе» дә күп санлы химаячеләр ярдәмендә дөнья күрде.

Безгә Киевта «Туган тел» Бөтенукраина Татар культура үзәге чыгара торган «Дуслык» журналының 2008 елгы октябрь саны да килеп иреште. Тышлыкның 1нче битендә—шул елның 5 октябрендә үзләренең бриллиант туйларын үткәргән Фоат ага һәм Хәдичә ханым.

Кырымда Фоат аганың фамилиясе һәм мәгърифәтчелек эшләре «История в лицах» (Симферополь. «АНООНК, 1997) һәм «Кто есть кто в Крыму» (Симферополь. Реноме, 2001) исемле китапларда тасвирланган.

Хәдичә ханым да, 85 яшьтә булуына карамастан, кул кушырып утырмый: мөселман кардәшләрне Коръән укырга, дин-исламча яшәргә өйрәтә. Вафат булган милләттәшләрен шәригать кушканча соңгы юлга озатырга булыша. Кеше булмаганда, хәтта мәет юудан да баш тартмый.

Шулай итеп, Мортазиннар яңа җирдә яңа тамырлар җибәрделәр һәм гөрләтеп яшәп яталар. Милләттәшләрен сөендереп.

**Хәсән ТИМЕРБУЛАТОВ.**

Исәнмесез, хөрмәтле «Казан утлары» хезмәткәрләре һәм баш мөхәррир Равил абый! Сезгә күптән язам дип йөри идем, менә, ниһаять, утырдым әле.

Безнең Красногвардеец районында ике генә татар авылы бар. Берсе, Үтәй-Урасан, туган авылым, Ибрай—торган авылым. Әнием ягыннан бабам хәзерге Татарстандагы Чистай районының Исләй авылында туган. XIX гасырдагы ачлык вакытында бәләкәй арба тартып Оренбург ягына юлга чыккач, үлеп калган ул.

Бабам кечкенәдән тулы ятим булып, авыр тормыш кичергән. Минем күптән инде Чистайга барып, аның туган җирен күреп кайтасым килә. Булыр әле, Алла боерса.

Равил абый, рәхмәт сезгә, рәхәтләнеп укырлык шәп журнал чыгарганыгыз, татарны яклап кыю әйберләр бастырганыгыз өчен. Үзегезнең дә кыю-кыю мәкаләләрегезне укыган бар. Кайбер нәрсәләр мине дә борчый менә.

Казанга баргалаган бар. Ләкин ул һич тә татар мәркәзенә ошамаган. Ульянов өлкәсе ягыннан кердем. Юл буенда бер татарча сәламләү юк. Казанның татар башкаласы икәнен эчкә кергәч тә сизмисең. Ә менә Түбән Камага баргач, шул хәтле матур лозунглар күрдем татарча, күңелгә рәхәт булып китте. Чаллыда да әнә русча сорасаң татарча җавап бирәләр.

Без Казанга татар мәркәзенә дип, татар булып яшәү дәртен тоясы килеп тә киләбез бит. Казанны дөрес юлда дип ышанмыйм мин. Казанны элек яулап алсалар, хәзер ул үз ирке белән сатылган, аны коткарып булмаячак.

Хәсән Туфан, Фатих Кәрим, Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Туфан Миңнуллин, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов, Лена Шагыйрьҗан, Клара Булатова, Зиннур Мансуров, Рәдиф Гаташ...—исән һәм мәрхүм бу һәм тагын күп язучылар, шагыйрьләрне чын ярату белән яратам. Татарның акыл ияләре булган шундый затлар хәзер тиеннәр санап утырырга калгач, ниткән эш була инде ул?

Безнең монда сигез баш эре мал, ике сыер савам, җәй буена 50-60 чеби, 30-40 үрдәк, бәрәңге, кабак, иренмәсәң, бар да өелеп ята, акчага да тилмергән юк болай. Казанда гомер буе интегеп эшләп, җимерек йортларда кайнар су, ванна-бәдрәф күрмичә тилмереп яшәгән кеше нихәтле. Казанга баргач, минем 4-5 көннән качасым килә. Безнең авылдан киткән Мәрхәбә апам әнә гомер буена сасы мех фабрикасында эшләгән, аның суы да юк иде, эчкә су кертергә 60 мең кирәк икән. 3-4 мең пенсиягә яшәгән апа ул акчаны каян алсын ди? Безне яклап сугышкан Хатыйп җизнәй 1997 елны вафат. Бичара апамның суыткычында берниндәи запас юк, шикәр, он, дөгене учлап кына диярлек ала.

2005 елның 30 августында Казанда булдым. Шунда күрдем, татарлар күп, әйдәүче юк, көтүчесез калган көтү кебек йөриләр.

Хәзер, «капитализмга» күчкәч, инде күңелләр дә бозылып беткәндер. Һәркем үз кесәсен кайгырта. Кешенең бәһасе юк. Сәхнәдә бот-түш күрсәткән җырчыбикәләребез, яшьлеген саткан кызларыбыз, хәрәм мал өчен адәм суярга әзер ир-атларыбыз бар чакта татар бөек дип әйтеп булмый ул...

Күңелдә җыелган әйбер күп инде, ярый, сау булыгыз.

**Наилә ХӘЙРУЛЛИНА-МӨСӘГЫЙТОВА.**
*Оренбург өлкәсе.*

# МАМАДЫШ МӘЗӘКЛӘРЕ

### Һаман яшәргә уйлыйсыңмыни?

35 яшьлек Хуҗа абый үзеннән 22 яшькә олырак Хәят исемле хатынга йортка керә. Шуңа күрәдер инде, хатынына ул күбрәк «әби» дип эндәшә. Шактый озак һәм тыныч яшәделәр алар бергә.

Бервакыт алар өй тәрәзәләрен, ишек яңакларын ак буяуга буяп куялар. 65 яшьлек Хуҗа абый «әбисенә» буяу банкасын чүплеккә ташларга куша. Хәят әби иренә:

—Ташламыйк, банкада шактый буяу калды әле,—ди.—Ике-өч елдан тагын буярбыз, гел-гел буяу алып торырбызмыни, акча әрәм итеп.

Хуҗа абый хатынына: «Син әле шул вакытка кадәр яшәргә җыенасыңмыни?» дигәнен сизми дә калган.

### Әүлия булган икән

Үткән гасырның илленче еллар ахыры. Җәйге чиллә вакыты. Мамадыш авторотасы шоферлары шәһәр үзәгендәге паркта, салкын сыра эчә-эчә, үзләре белән булган кызыклы хәлләр турында сөйләшеп утыралар. Алар арасында бөтен районга бердәнбер дәүләт автоинспекторы Искәндәр абый Галимов та бар. Таралыр алдыннан ГАИ капитаны сүзен болай дип тәмамлый:

—Эзләп табып сыйлаганыгыз өчен рәхмәт сезгә, егетләр! Ә бит минем кем икәнне дә белмәүче шоферлар бар. Югыйсә мотоцикл белән бөтен районны әйләнеп чыгам. Авызга грамм капмыйча кайтып кергән көннәр була. Килер заман, юлда машиналар мыжлап торган кырмыска оясын хәтерләтер. ГАИ инспекторлары шоферларның һәр хәрәкәтен тикшереп торырлар. Гаепләре өчен сыра эчертеп кенә котыла алмаслар...

Әүлия булган икән капитан абзабыз.

### Үзеңә хуже будет

Нигъмәтулла абый, шактый озак салып йөргәннән соң, өенә кайта. Ләкин аны бикле капка каршы ала. Капканы ачучы булмагач, ул йодрыкларын эшкә җигә:

—Сәлимә дим, Сәлимә!? Ачасыңмы капканы, юкмы? Ну, керсәм...

Җир астыннан чыккан диярсең, аның янында участковый Хөрмәтуллин пәйда була.

—Нишләвең бу синең, Нигъмәтулла абый? Ник төясең ул капканы? Сәгать дүрт тә юк бит әле. Җәмәгать тәртибен бозып йөргән өчен штраф түлисең киләмәллә?

—Хатын өйгә кертми. Капканы эчтән бикләгән, заразы. Баш авырта. Ә өйдә яшереп куйган урында аракы бар. Чәкидән артык.

Үзенең дә башы авырткан Хөрмәтуллин капканы ике куллап төя башлый:

—Ану, Сәлимә апа, капканы ач әле! Живо! Ачмасаң, үзенә хуже будет. Протокол төзергә дә күп сорамам...

Бераздан капка ачыла һәм Сәлимә апаның куркудан агарган йөзе күренә.

## Күңелне бик ачтың

Безнең Яна Комазан авылында Мөхәммәт Абдулычны еш телгә алып сөйлиләр. Төрле мәзәк хәлләргә юлыгып торгангадыр инде. Озак еллар сельпода каравылчы булып эшләде ул. Аннан бервакытта да зарлану сүзе ишетмәссең. Ул һәрвакыт шат күңелле, ачык йөзле. Уен-көлкене дә бик ярата. Бөтен сөйләшүе күңелгә дәрт-шатлык өсти.

Менә беркөнне ул урам буйлап килә. Гадәтенчә, бераз салып алган. Кулында гармун. Үзе белән үзе сөйләшә-сөйләшә атлый:

—Мөхәммәт Абдулыч! Сез бераз гармунга кушылып җырлый алмассыз микән? Бу арада бер дә җырлаганыгыз ишетелми. Әйе-әйе, нинди җыр да ярый.

Бераз тынып торганнан соң, сүзен болай дип дәвам итә:

—Ник җырламаска ди! Җырлыйбыз аны. Менә бу җырны тыңлап кара әле, ничегрәк яңгырый икән:

Ана үрдәк балаларын
Чумарга өйрәтәме?
Күңелләрем шат чагында
Хәлләрем әйбәт әле...

Мөхәммәт абый бераз туктап тора, аннан, канәгать булганлыгын белдереп, болай дип әйтеп куя:

—Рәхмәт, рәхмәт, Мөхәммәт Абдулыч, күңелне бик ачтың. Болай тавышың ничава гына икән әле. Әйдә, тагын бер әйттереп җибәр әле!

**Рәим ГОБӘЙ**

# УЛ БАШЛАП ЙӨРҮЧЕ ИДЕ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ Р. Н. МИҢНЕХАНОВНЫҢ КОМПОЗИТОР НӘҖИП ҖИҺАНОВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ ТУЛУ УҢАЕННАН МӨРӘҖӘГАТЕ

Хөрмәтле ватандашлар!

Быел без күренекле татар композиторы, музыка һәм җәмәгать эшлеклесе Нәҗип Гаяз улы Җиһановның тууына 100 ел тулуны билгеләп үтәбез.

Ул лаеклы рәвештә халкыбызның бөек уллары исәбенә керә. Аның иҗаты татар милли музыкаль мәдәнияте үсешендә яңа чор башлаган. Әкренләп хәзерге заман татар музыка сәнгатенең нигезен тудырган Нәҗип Җиһанов югары профессиональ мәдәниятне һәм халык иҗаты казанышларын яңа мәгънәви дәрәҗәдә берләштерүгә ирешкән. Нәҗип Җиһановның күпкырлы эшчәнлеге аны Татарстанда гына түгел, Россия күләмендә дә XX гасыр музыка мәдәниятенең иң талантлы вәкилләренең берсе дип атарга мөмкинлек бирә.

Нәҗип Җиһанов классик музыканың күп жанрларында беренче булып иҗат иткән. Ул безгә бай мирас калдырды—сигез опера, шул исәптән, милли классикага әверелгән "Җәлил" һәм "Алтынчәч", өч балет, унҗиде симфония, симфония һәм камера жанрындагы күпсанлы әсәрләр. Искиткеч осталыгы, көйләренең кабатланмас аһәңе, музыкаль образларының матурлыгы аркасында аның иҗаты Татарстаннан читтә дә киң таралды. Ә инде "Кырлай" симфоник поэмасы, татар темасына сюита, "Сабан туе" симфониясе һәм башка әсәрләре аша татар симфония музыкасы Россия мәдәниятендә үзенчәлекле күренеш буларак танылды.

Ул һәрвакыт яңалыкка, рухи камиллеккә таба хәрәкәт итүче рәссам иде. Нәҗип Җиһанов шәхесенә хас иҗади ялкын аның күпкырлы дәүләт, җәмәгать һәм педагогия эшчәнлегенә дә күчкән.

Ул Казан дәүләт консерваториясе оештыруны башлап йөрүче һәм кырык елдан артык, гомеренең соңгы көннәренә кадәр, аның ректоры булды. Татар дәүләт филармониясе—аның беренче симфониясе белән, ә Татар опера һәм балет театры аның "Качкын" операсы белән ачылган. Сәләтле балалар өчен консерватория каршында махсус музыка мәктәбе оештырылу, Казанда симфония оркестры барлыкка килү һәм Татарстан музыка мәдәнияте тарихындагы башка мөһим гамәлләр дә Нәҗип Җиһанов исеменә аерылгысыз бәйләнгән.

Дүрт дистә ел диярлек Нәҗип Гаязович республиканың Композиторлар берлеген җитәкләгән, чирек гасырдан артык СССР Композиторлар берлеге секретаре, Россия Композиторлар берлеге идарәсе әгъзасы булган.

Нәҗип Җиһанов—үз халкына фидакарь хезмәт итүнең иң ачык үрнәкләреннән берсе. Ватаныбыз аның хезмәтен югары бәяләгән: ул Социалистик Хезмәт Герое, СССРның халык артисты исеменә, Габдулла Тукай исемендәге премиягә, өч тапкыр СССРның Дәүләт премиясенә һәм күп кенә башка бүләкләргә лаек булган.

Бүген Татарстанның башкаласы—мең яшьлек Казан—опера һәм филармония шәһәре, бездә тулы музыкаль белем алу өчен кирәкле барлык уку йортлары бар. Моңа, һичшиксез, Нәҗип Җиһановның һәм аның фикердәшләренең олы хезмәте кергән. Композиторның бөек казанышларын хөрмәт итү—шушы күркәм традицияләрне саклау һәм үстерү ул.

Нәҗип Җиһановның туган көнендә һәрбер татарстанлының йөрәгендә һәм бөтен республикада аның безгә яшәргә һәм эшләргә рухи көч бирүче мәңгелек музыкасы яңгырасын иде!

***

**ПОЛЬША РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ БРОНИСЛАВ КОМОРОВСКИЙГА, ПОЛЬША РЕСПУБЛИКАСЫ СЕНАТЫ МАРШАЛЫ БОГДАН БОРУСЕВИЧКА, ПОЛЬША РЕСПУБЛИКАСЫ СЕЙМЫ МАРШАЛЫ ГЖЕГОЖ ЮЛИУШ СХЕТЫНАГА ҺӘМ ПОЛЯК ХАЛКЫНА ПОЛЬША РЕСПУБЛИКАСЫНДА РЕЧЬ ПОСПОЛИТА ТАТАРЫНА ҺӘЙКӘЛ АЧЫЛУ УҢАЕНАН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ МӨРӘҖӘГАТЕ**

2010 елның 25 ноябрендә Польша Республикасының Гданьски шәһәрендә Речь Посполита татарына һәйкәл ачылу тантанасы булды. Бу истәлекле вакыйга поляк һәм татар халыклары арасында гасырлар буе үзара аңлашып, дус-тату яшәү традицияләренең дәвам итүен чагылдыра. Польша Президенты Бронислав Коморовский тарафыннан һәйкәл ачу тантанасында татарларның Польша дәүләте алдында тарихи казанышларына бирелгән югары бәяне Татарстан Республикасы һәм бөтен татар халкы поляк халкына олы рәхмәт хисләре белән кабул итте.

XIV гасыр ахырында Алтын Урда тәхете өчен дәвам иткән көрәш хакимнәрне үзләренә тугры суышчылар белән бергә Польша һәм Литва кенәзләре янында сыену урыны эзләргә мәҗбүр иткән. Татарлар һәрвакыт дәүләтчелек тарафдарлары булды һәм, төрле сәбәпләр аркасында чит-ят җирләргә килеп урнашып, шул илгә ышанычлы һәм тугры хезмәт итә. Элек-электән алар Польша дәүләтенең бәйсезлеге өчен көрәштә хәрби батырлыклары белән дан казана. Аларның варислары бүген дә тырыш хезмәтләре белән хәзерге Польшаның алгарышына лаеклы өлеш кертә, һәм без моның белән горурланабыз.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Татарстан Республикасының күпмилләтле халкы һәм бөтен татар халкы исеменнән Польша Республикасы Президенты Бронислав Коморовскийга, Польша Республикасы Сенатына, Сеймына һәм бөтен поляк халкына шунда яшәүче татарлар өчен икенче Ватанга әверелгән Польшаның бердәмлеген һәм бөтенлеген саклауда татарларның казанышларын югары бәяләгән өчен рәхмәт хисләрен белдерә.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Польша Республикасының һәм Россия Федерациясенең эшлекле багланышларын һәм мәдәни хезмәттәшлеген ныгыту адымнарын хуплый. Татарстан Республикасы Польша Республикасы халкы белән Россия Федерациясенең күпмилләтле халкы арасындагы дуслык мөнәсәбәтләрен ныгытуга һәрьяклап ярдәм итәчәк.

---

**МЕТРОНЫҢ ЯҢА СТАНЦИЯСЕ**

Казан метрополитенының икенче чиратындагы «Кәҗә бистәсе» станциясе 30 декабрьдә ачылды.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та яңа станцияне карап чыкты. Илбашы метрода 2 кмдан артык юл үтте. Яңа станция сафка басу белән башкала метросының гомуми озынлыгы исә 11 мең метрдан да артып китте. Әлегә пассажирларга 4 кенә поезд хезмәт күрсәтә. Шуңа да аларны 15әр минут көтәргә туры килә. Ел башында, яңа поездлар йөри башлагач, җир асты юлыннан файдаланучылар тукталышларда 8 минуттан да озаграк басып тормаска тиеш. Тукталышларның саны да артачак. Бүген метро төзүчеләр «Завод», «Мәскәү» һәм «Декабристлар» станцияләрендә эшне башлаган инде.

Казансу елгасының бер ягында яшәп, икенчесенә эшкә йөрүчеләр метроның бу тукталышын көткән иде инде. «Кәҗә бистәсе» станциясе эшли башлау метроның керемен бермә-бер арттырыр, дип фаразлана.

Бүген Казан метросыннан көн саен якынча 40-50 мең кеше файдалана. Бу көннәрдә исә җир асты юлына төшүчеләр 100 меңгә кадәр житәр дип көтелә.

**КАБИНЕТТАН—АППАРАТКА**

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, республика территориясендә дәүләти-конфессиональ мөнәсәбәтләрне камилләштерү, конфессияара татулыкны ныгыту һәм дини экстремизмның таралуын киметү максатыннан чыгып, Президент Аппараты структурасында ТР Президентының Дини берләшмәләр белән берлектә эшләү идарәсен оештыру турында Указга кул куйды. Шул сәбәпле, ТР Министрлар Кабинеты каршындагы Дин эшләре идарәсе бетерелә.

ТР Президентының Дини берләшмәләр белән берлектә эшләү идарәсе начальнигы итеп Марат Илшат улы Гатин билгелән-

де. Монарчы ул ТР Президенты Тышкы элемтәләр департаментының Азия һәм Африка илләре секторы мөдире булып эшләгән.

### БӨЕК ИХТЫЯҖЧЫНЫ ЯД ИТҮ

Казанда бөек композитор Нәҗип Җиһановның 100 еллыгы уңаеннан төрле чаралар булып узды. Композиторның музей-фатирында ачык ишекләр көне үткәрелде. Аннары бер төркем иҗат әһелләре Арча кырындагы зиратка барып, аһәнсазның каберенә чәчәкләр салды. Чәчәкләр салуда һәм С. Сәйдәшев исемендәге дәүләт Зур концерт залында булып узган гыйльми советның киңәйтелгән утырышында Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева да катнашты. Анда Татарстан Республикасы симфоник оркестры тамашачыларга композиторның «Сабантуй» исемле 2 нче симфониясен башкарды.

Аннары композитор Н. Җиһановның хатларына, үзенең һәм туган-тумачалары, дуслары, иҗатташларының истәлекләренә нигезләнеп эшләнгән «Дөньялар якты булсын өчен җырлыйм...» дип исемләнгән әдәби-музыкаль спектакль күрсәтелде. Анда Казан дәүләт консерваториясе мөгаллимнәре һәм студентлары, башкалабызның балалар музыка мәктәпләре укучылары, Югары Ослан районының В. Ульянов җитәкчелегендәге ир балалар капелласы катнашты. Спектакльдә Н. Җиһановның фортепиано өчен язылган әсәрләре, инструменталь-камера музыкасы, җырлары, «Алтынчәч», «Җәлил» операларыннан өзекләр башкарылды. Сәхнәдә беркетелгән экранда композиторның тормышы вә иҗаты турында искиткеч бай мәгълүмат биргән, һәркайсы зур тарихи кыйммәткә ия фотоларны күрергә мөмкин иде. Бу чараларны композиторның туган ягы Уральскидан килгән вәкилләр дә тамаша кылды.

### ЭШЛЕКЛЕ СӨЙЛӘШҮ

«Казан утлары» журналының күптән түгел булып үткән редколлегия утырышында 2010 елдагы әдәби эшчәнлеккә йомгак ясалып, яңа—2011 елга максатлар билгеләнде.

Уртага салып сөйләшәсе һәм бергәләшеп хәл итәсе мәсьәләләрнең күплеге белән аерылып торган редколлегия утырышында «Казан утлары» журналының иҗат коллективы, ТР Премьер-министры урынбасары—ТР мәдәният министры Зилә Вәлиева, «Татмедиа» ААҖ генераль директоры Айдар Сәлимгәрәев, өлкән әдибебез Туфан Миңнуллин, Гәрәй Рәхим, Мөдәррис Вәлиев, ТР Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, тарих фәннәре докторы, этносәясәтче Дамир Исхаков, әдәбиятчы галимнәр Тәлгат Галиуллин белән Хатыйп Миңнегулов һәм башка язучылар, каләм әһелләре катнашты.

—Казанышлар белән беррәттән, соңгы елларда татар мәдәниятендә, бигрәк тә көндәлек матбугат һәм китап дөньясында әллә никадәр сәер үзгәреш-метаморфозалар, кемнәрдер әйткәнчә, реформалар булды,—дип журналның баш мөхәррире Равил Фәйзуллин утырышны ачып җибәрде.—Нәшрият һәм газета-журналлар даирәсендә бигрәк тә ачык чагылды бу хәл. Оптимизация шаукымында кушылулар, күченүләр, кыскартулар дисеңме... Без шушы шартларда эшлибез. Шуңа да карамастан, «Казан утлары» һәрьяктан—эчтәлеге, тышкы кыяфәте, таралышы ягыннан әдәби журналлар арасында ил күләмендә беренчеләрдән санала. Болар безне, әлбәттә, сөендерә, иҗади дәрт бирә, горурлык уята.

Редколлегия әгъзалары «Казан утлары» журналының 2010 елда чыккан саннарына күзәтү ясады. «Казан утлары»ның поэзия һәм проза бүлеге мөхәррирләре Рәдиф Гаташ белән Камил Кәримов кулъязмаларның күп булуын һәм шуның нәтиҗәсендә иң яхшыларын сайлап бастыру мөмкинлеге барлыгына куануларын әйтеп уздылар.

—Татар шигърияте, шөкер, аз гына да үз дәрәҗәсеннән төшми. Яшьләргә зур игътибар бирелә. Аларның барысы да уйлый, фикерле белә торган егетләр һәм кызлар. Проза да үз юлыннан тайпылмыйча бара. Журналдагы рубрикалар, бигрәк тә «Бәләкәйләр» укылышлы. Киләчәктә журналда элеккеге, борынгы, үрнәк әсәрләрне кабаттан бастырасы иде, юкса китапханәләрдән матур әдәбиятны алып укучылар саны кимегәннән-кими,—дип Туфан Миңнуллин уй-теләкләре белән уртаклашты.

«Казан утлары»ның тәүге саннарыннан ук әдәби үзәкләрнең берсе булуы тарихтан билгеле. Бүген дә ул язучыларны, галимнәрне, тәнкыйтьчеләрне һәм китап сөючеләрне бергә туплап, аралаштырып тора. Шуңа да редколлегия утырышында сүзнең, гомумән, әдәбиятыбызның торышына, андагы проблемаларга, язучыларда ризасызлык уяткан гонорар мәсьәләләренә күчүе гаҗәп түгел. Күптән түгел генә Илфак Ибраһимовны Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов кабул итеп, шул темага сөйләшүләр булган иде инде. Язучылар берлеге рәисе утырышта катнашкан җитәкчеләргә Башкортстанда каләм хакы өчен Татарстан белән чагыштырганда 2-3 тапкырга артыграк түләнүен хәбәр итеп, гонорар буенча хөкүмәтнең махсус карары булдырылсын иде, дигән үтенечен җиткерде.

—Мин Башкортстандагы хәлне өйрәндем. Аларның матбугаты, чыннан да,

зуррак күләмдәге акча белән тәэмин ителә. Билгеле булганча, гонорарга кагылышлы маддә үзгәрде. Шунлыктан, каләм хакы өчен түләүләрнең башка юлларын эзләргә кирәк. Ә алар бар. Әлеге мәсьәләдән Татарстан Президенты да, «Татмедиа» житәкчеләре дә хәбәрдар,—диде Зилә Вәлиева.—Әлбәттә, рухи азык хакын шулай мескен хәлдә калдыру дөрес булмас иде. 2011 ел—Тукай елы. Аны иң беренче чиратта әдәбият өчен файдалы итеп уздырырга кирәк. Шуңа да киләчәккә өмет белән карыйк. Мондый очрашулар алдагы елда күбрәк булсын иде.

Айдар Сәлимгәрәев тә мәдәният министрының сүзләренә кушылды:

—Каләм хакы өчен түләү мәсьәләсе юктан гына килеп тумады. Алга таба аны күтәрүнең юлларын бергәләп табарбыз һәм хәл итәрбез,—дип ышандырды ул.

Шушы көннәрдә «Казан утлары» журналының 1059 нчы саны дөнья күрде.

### СӘНГАТЬКЯРЛӘРГӘ ИЛБАШ БҮЛӘГЕ

ТР Мәдәният министрлыгында Татарстан Президенты грантына ия булган мәдәният һәм сәнгать әһелләрен бүләкләү тантанасы узды. Аларны Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева тапшырды. Ул әлеге грантка 200 кеше тәкъдим ителгәнен дә әйтеп узды. «Профессионаллар» төрендә әлеге бүләккә лаек булучылар арасында «Казан нуры» халык уен кораллары оркестры житәкчесе Рәсим Ильясов, Дәүләт фольклор ансамбленең сәнгать житәкчесе Айдар Фәйзрахманов, Казан театр училищесы укытучысы Рәүф Нуриев, «Таяныч һәм дәрәҗә» төрендә республика халык иҗаты фәнни-методик үзәгенең әйдәп баручы белгече Камил Саттаров, «Перспектива» төрендә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт театры артистлары Нәфисә Хәйруллина һәм Гүзәл Минакова бар. Грантка җәмгысе 54 кеше ия булды.

### СЕЗ—БЕЗНЕҢ ГОРУРЛЫГЫБЫЗ

Казан Кремлендә «Созвездие-Йолдызлык» ачык республика эстрада сәнгате телевизион фестивале җиңүчеләренә һәм лауреатларына ТР дәүләт стипендияләрен бирү тантанасы узды. Сәләтле балаларга стипендия дипломнарын ТР Президенты Рөстәм Миннеханов тапшырды. «Россиядә «Созвездие-Йолдызлык» кебек фестиваль юк. Мәскәүдә 1 ноябрьдә сез күрсәткән концерт зур уңыш белән үтте. РФнең мәдәният министры Александр Авдеев та аңа югары бәя бирде,—дип билгеләп үтте Президент.—Сез—безнең горурлыгыбыз, киләчәгебез. Бүген татар халкының мәдәниятен, телен, традицияләрен саклау мөһим мәсьәлә булып тора. «Йолдызлык» фестивале моңа зур игътибар бирә». Президент сүзләренчә, балалар—безнең киләчәгебез, аларның һәрберсе үзенчә сәләтле. «Бу сәләтләрне ачарга ярдәм итүче укытучыларга рәхмәт. Проект житәкчесенә аерым рәхмәт»,—диде ул.

### ХӘЕРЛЕ СӘГАТЬТӘ!

Татарстан Республикасының РФдәге Тулы вәкаләтле вәкиллегендә Медиаклубның беренче очрашуы узды. Анда Матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр буенча республика агентлыгы житәкчелеге, федераль һәм Мәскәү мәгълүмат чаралары, «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе вәкилләре катнашты. Матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр буенча республика агентлыгы житәкчесенең беренче урынбасары Фәрит Шаһиәхмәтов республика агентлыгы, «Татмедиа» ачык акционерлык җәмгыяте, гомумән алганда, Татарстанның медиа киңлеге турында сөйләде. Аерым алганда, ул Татарстанда федераль мәгълүмат чаралары белән элемтә җайга салынган, дип билгеләп үтте.

Медиаклубның беренче утырышында ТР Президенты Рөстәм Миннеханов та катнашты. Ул республика потенциалын федераль дәрәҗәдә тәкъдим итү әһәмияткә ия, дип саный. Республика житәкчесе яңа IT-технологияләр кулланылуын билгеләп үтте. Ул моның белән бәйле рәвештә «Электрон Татарстан» һәм «Электрон документ әйләнеше» проектлары хакында искәртеп узды. Президент журналистларны актив хезмәттәшлеккә чакырды, Медиаклубның журналистлар эшчәнлеген һәм республика тормышын федераль дәрәҗәдә яктырту өчен нәтиҗәле мәйданчык булачагына ышаныч белдерде.

### ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булды. Анда ике идарә утырышы арасында башкарылган эшкә хисап ясалды. Шагыйрь Мөхәммәт Мирза (Илфак Ибраһимов) «Киек каз юлында» (Татарстан китап нәшрияте, 2003 ел) дигән шигырьләр, газәлләр, поэмалар, «Тере су» (Татарстан китап нәшрияте, 2007 ел) дигән газәлләр, робагыйлар, гыйбарәләр китаплары, «Адәм баласы» («Мәгариф» нәшрияте, 2009 ел) дигән китапка тупланган һәм 2006-2010 елларда «Казан утлары» журналында басылган «Адәм баласы» циклы өчен, прозаик Камил Кәримов «Ком сәгате» (Татарстан китап нәшрияте, 2000 ел) һәм «Сакау күке» (Татарстан китап нәшрияте, 2005 ел) романнары өчен 2011 елда Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә тәкъдим ителде.

Утырышта шагыйрьләр Таһир Шәмсуаров, Рүзәл Мөхәммәтшин, шагыйрә-тәржемәче Вера Хәмидуллина Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителде.

### АТЛАСИНЫ ЗУРЛАДЫЛАР

Шушы көннәрдә Чүпрәле районының Түбән Чәке авылында күренекле җәмәгать һәм дин эшлеклесе, тарихчы, галим Һади Атласига багышланган чаралар үтте.

Әлеге тантанада Татарстан Дәүләт Советы депутатлары, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры актерлары, Язучылар берлеге вәкилләре катнашты. Чара Һади Атласи туып-үскән һәм яшәгән йорт белән танышудан башланды. Мемориаль такта исә авыл урта мәктәбендә ачылды.

Чүпрәледәге бу чараларның төп үзәге—Һади Атласи әсәрләре тупланган 2 томлык, «Шәхесләребез» сериясендә Атласига багышлап чыгарылган китапларны халыкка тәкъдим итүгә багышланган иде. Китапларны татар телен һәм мәдәниятен саклау һәм үстерүче «Җыен» фонды һәм ТАИФ ачык акционерлык җәмгыяте бастырып чыгарды. Бәйрәм район мәдәният йортында әдәбимузыкаль кичә белән тәгәлләнде. Бу кичәдә Чүпрәле муниципаль районы башлыгы Тимур Нагуманов, язучылардан Туфан Миннуллин, Разил Вәлиев, Гәрәй Рәхим, Газинур Морат, күренекле галимнәр, артистлар, Чүпрәледә туып-үскән атаклы шәхесләр чыгыш ясады.

### АК КЫШЛАРДА—АК НИЯТЛӘР

Инде өченче ел рәттән Буа районында «Ният» фестивале үткәрелә. Ел буена дәвам иткән әлеге чараны Буа Татар дәүләт драма театры оештыра. Анда елның беренче яртысында—укучылар, икенче яртысында укытучылар катнаша, ә декабрь азагында исә «Ният»кә йомгак ясала, җиңүчеләр тәгаенләнә.

Чираттагы театр сәнгате бәйгесендә Буа районының 28 мәктәбе катнашты һәм алар җәмгысе 29 спектакль сәхнәләштерде. 200дән артык мәктәп укучысы спектакльләрдә уйнаган!

Фестивальдә җиңүчеләрне бүләкләү тантанасын Буа театрының директоры һәм сәнгать җитәкчесе Раил Садриев алып барды.

### АРТИСТКА ХӨРМӘТ

Камал театры Наилә Гәрәевага 70 яшь тулуны өр-яңа премьера белән билгеләп узды. Яшь драматург Илгиз Зәйниевнең «Бабайлар чуагы» дип аталган лирик комедиясендә Наилә Гәрәева төп рольләрнең берсен башкарды. Спектакль тәмамлангач котлау кичәсе башланды.

Наилә Гәрәеваны хезмәттәшләре, бүтән театр артистлары, чит өлкәләрдән килгән кунаклар котлады. Ә ТР халык депутаты Разил Вәлиев актрисага «Россиянең халык артисты» дигән мактаулы исем бирелүе турында хәбәр итте һәм әлеге мәртәбәле исемнең түштамгасын тапшырды. Мәдәният министрлыгы исеменнән Кадрия Идрисова котлап, Россия мәдәният министры Александр Авдеевның һәм Татарстан мәдәният министры Зилә Вәлиеваның котлау хатларын укыды. Ул арада сәхнәгә Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев исеменнән искиткеч зур, матур чәчәк бәйләме менгерделәр.

### МӨСЛИМ ЯЗУЧЫЛАРЫН ЗУРЛЫЙ

Яңа ел алдыннан гына Мөслим тарафыннан куанычлы хәбәр килеп иреште: район Советы карары нигезендә, әлеге төбәктә туып-үскән каләмдәшләребез **Фоат Садриев, Шәмсия Җиһангирова** һәм **Мөҗәһит Әхмәтҗанов**ка «Мөслим районының шәрәфле гражданы» дигән мактаулы исем бирелде.

Мөслимлеләрнең әлеге гамәле башка төбәкләр өчен дә күркәм үрнәк булып тора.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Беренче биттә:* Кышкы манзара.

*Дүртенче биттә:* шагыйрь **Ленар Шәех**.

# Яңа китаплар




**Мәрҗани:** Фәнни-популяр җыентык.—Казан: «Җыен» нәшр., 2010.—704 б.—(«Шәхесләребез» сериясе). Тиражы—1500 данә.

Китап күренекле татар галиме, тарихчы, дин һәм җәмәгать эшлеклесе Шиһабеддин Мәрҗанинең тормыш юлына, иҗатына багышлана. Ул—бөек галимнең тууына һиҗри ел исәбе белән йөз ел тулуга багышланып, 1915 елда дөнья күргән «Мәрҗани» исемле мәҗмуганың хәзерге татар әдәби теленә күчерелгән яңа басмасы.

Китап милли мәдәниятебез һәм әдәбиятыбыз тарихы белән кызыксынучы киң катлау укучыларга тәкъдим ителә.




**Равил Фәйзуллин.** Илбагар уйлар: фәлсәфи язмалар, әдәби портретлар, хатирә-уйланулар, юлъязмалар.—Казан: Татар. кит. нәшр., 2011.—414 б. Тиражы 1500 данә.

Бу китапта Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллинның соңгы елларда иҗат ителгән публицистик язмалары тупланган. Алар чор-заман, милләт язмышы, халкыбызның күренекле шәхесләре турында эссе-уйланулардан гыйбарәт.

Китапта шулай ук Татарстан Язучылар оешмасы турында күләмле документаль хезмәт һәм гыйбрәтле сәяхәтнамәләр дә урын алган.



Ленар Шәех

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)